# Казан утлары

4

АПРЕЛЬ-1972

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

4

АПРЕЛЬ
1972


## Бу санда


КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНДА

Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында . . . . . 3

М. ШАБАЕВ. Бар да таныш... Шигырьләр . . . 5
М. ЮНЫС. Энҗе эзләүчеләр. Хикәя . . . . . 9
ЗӨЛФӘТ. Ерактагы гудок. Шигырьләр . . . . . 18
Ә. РӘШИТОВ. Күңел бөреләре. Шигырьләр . . 21
Ф. САФИН. Замандаш сүзләре. Шигырьләр . . . 23
М. МӘҺДИЕВ. Фронтовиклар. Роман . . . . . 26
К. МОСТАФИН. Тачанкалар. Шигырьләр . . . . 96
С. ГӘРӘЕВА. Урал. Шигырьләр . . . . . . . 101
Н. ИЗМАЙЛОВА. Язлар килгәч. Шигырь . . . . 103

ӘДӘБИ МИРАС

Ә. МАЛИКОВ. «Узсын гомер сагынып сөйләрлек...» Истәлек . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Г. ХУҖИ. Съезд ачылганда. Шигырь. Йөрәк каны белән, йөрәк уты белән. Мәкалә. Хатлардан . 108

КамАЗдан ОЧЕРКЛАР

Р. ВӘЛИЕВ. Каурыйлар чыныкканда . . . . . . 114

М. ЗАРИПОВ. Диссертация . . . . . . . . . 125

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ

ХАТИП ГОСМАН. Эмоциональ төенләнешле шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . 133

ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Г. БӘШИРОВ. Уйланулар . . . . . . . . . 140

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ә. ШӘРИПОВ. «Мөһиммат әз-заман» кем әсәре? . 148



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. МОСТАФИН.** Тәнкыйтькә — тәнкыйть уты . . . 154

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ш. ХАММАТОВ.** Большевистик татар матбугатына нигез салучы . . . . . . . . . . . . . . . 166
**М. ВӘЛИЕВ.** Инешләр Иделгә кушыла . . . . . 173
**Р. ХАРИС.** Мескенлектән килгән аваз . . . . . 176

Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . . . . . 180

ЮМОР-САТИРА

**В. НУРУЛЛИН.** Люзия. Хикәя . . . . . . . . . 181

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгать Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 7/I-1972 ел. Басарга кул куелды 23/II-1972 ел. ПФ 04018. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87046 экз. Заказ Г-14. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1972 ел.

# ӘДӘБИЯТ - СӘНГАТЬ ТӘНКЫЙТЕ ТУРЫНДА

*КПСС Үзәк Комитеты «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» карар кабул итте. Анда партия комитетлары, культура учреждениеләре, иҗат союзлары, матбугат органнары әдәби тәнкыйтьнең дәрәҗәсен күтәрү турында КПССның XXIV съезды күрсәтмәләрен тормышка ашыруда актив тырышлык куялар, дип билгеләп үтелә. Тәнкыйть алдында торган бурычлар съездларда, пленумнарда, художество интеллигенциясе җыелышларында тикшерелде. Социалистик реализм сәнгатен тагын да үстерү турында кайгыртучанлык белән сугарылган тирән эчтәлекле мәкаләләр күбрәк басыла башлады.*

**Шуның белән бергә, КПСС Үзәк Комитеты карарында тәнкыйтьнең торышы әдәбият-сәнгатьнең коммунистик төзелештә үсә барган роле белән билгеләнә торган таләпләргә тулы җавап бирми, дип күрсәтелә. Совет әдәбияты һәм сәнгатенең үсеш процесслары, социалистик милләт культураларының берберсен баетулары һәм үзара якыная барулары тирән анализланмый. Күп кенә мәкаләләр, күзәтүләр, рецензияләр өстән-өстән генә языла, аларның фәлсәфи һәм эстетик дәрәҗәсе югары булмый, тәнкыйть сәнгать күренешләрен тормыш белән чагыштырып карый белми. Шушы көнгә кадәр тәнкыйтьтә идея һәм художество ягына карата килешүчән мөнәсәбәт, субъективизм, эшнәлек һәм группачылык кебек берьяклылык сизелә. Кайчагында совет сәнгате һәм революциягә кадәрге сәнгать тарихын дөрес яктыртмаган материаллар басыла, аерым художникларга һәм әсәрләргә күрәләтә дөрес булмаган бәя бирелә. Социалистик реализм сәнгатенең революцион гуманистик идеалларын раслауда, буржуаз «массовый культура»ның һәм декадентлык агымнарының реакцион асылын фаш итүдә, әдәбият һәм сәнгать турындагы ялгыш карашларга эстетик концепцияләргә каршы көрәштә тәнкыйть һаман да җитәрлек дәрәҗәдә актив һәм эзлекле түгел.**

**Партия комитетлары, министрлыклар һәм ведомстволар, иҗат союзлары үз карамакларындагы матбугат органнарының, нәшриятларның, телевидение һәм радионың тәнкыйть-библиографик эшчәнлегенә тиешле контрольне тәэмин итмиләр, хезмәт ияләрен идея-эстетик яктан тәрбияләү өчен, күп милләтле совет сәнгатенең иң яхшы казанышларын пропагандалау өчен информация чараларыннан йомшак файдаланалар.**

**Күп кенә газета һәм журнал редакцияләре тәнкыйть мәкаләләренең идея-теоретик дәрәҗәсенә һәрвакытта да таләпчән түгел. Рецензияләү практикасында җитди кимчелекләр яшәп килә. Басыла торган рецензияләр еш кына берьяклы характерда була, нигезсез мактауга, әсәрнең эчтәлеген өстән-өстән генә сөйләп чыгуга кайтып кала, әсәрнең реаль әһәмияте һәм кыйммәте турында дөрес фикер бирми. Күп кенә китаплар, спектакльләр, фильмнар, сынлы сәнгать күргәзмәләре, музыкаль әсәрләр, концерт программалары гомумән тәнкыйтьтән читтә кала. Марксистик-ленинчыл эстетика, сәнгать теориясе һәм тарихы өлкәсендәге белгечләр, совет культурасы осталары матбугат эшенә тиешенчә тартылмый; редакцияләр тәнкыйть материалларының жанр төрлелегенә һәм аңлаешлылыгына җитәрлек игътибар бирмиләр.**

**КПСС Үзәк Комитеты карарында күрсәтелгәнчә, иҗат союзларының җитәкче органнары әдәби иҗатның өлгереп җиткән проблемаларын бергәләп тикшерүләрне сирәк оештыралар, тәнкыйть комиссияләре һәм советларының эшен акрын үзгәртеп коралар. Тәнкыйтьчеләрне идея ягыннан тәрбияләү һәм профессиональ хәзерләү турында, әдәбият һәм сәнгать работниклары арасында югары таләпчәнлек, тәнкыйть чыгышларына дөрес караш тудыру турында көндәлек кайгыртучанлык күрсәтелми.**

**Карарда: әдәби тәнкыйтьтәге җитешсезлекләр шактый дәрәҗәдә квалификацияле**

кадрларның җитешмәве белән аңлатыла, диелә. Шул ук вакытта университетларда һәм гуманитар вузларда студентларны һәм аспирантларны тәнкыйть өлкәсендә специальләштерү өчен кирәкле шартлар тудырылмаган, бу эш әдәбият һәм сәнгать уку йортларында да канәгатьләнерлек куелмаган. Фәнни-тикшеренү эшендәге җитди кимчелекләр, фәнни һәм иҗат кадрларының ведомство ягыннан таркаулыгы, фәнни учреждениеләр эшчәнлегендә тиешле координациянең булмавы тәнкыйтьне үстерүгә кире йогынты ясый.

КПСС Үзәк Комитеты союздаш республикалар Компартияләре Үзәк Комитетлары, КПССның край һәм өлкә комитетлары, министрлык һәм ведомстволар, иҗат союзлары, матбугат органнары, нәшриятлар, телевидение һәм радио җитәкчеләренең игътибарын әдәби тәнкыйтьнең идея-теоретик дәрәҗәсен күтәрү, художество иҗаты өлкәсендә партия линиясен үткәрүдә аның активлыгын һәм принципиальлеген күтәрү кирәклегенә юнәлдерде.

Тәнкыйтьнең бурычы, диелә карарда, бүгенге әдәби күренешләрне, тенденцияләрне һәм закончалыкларны тирән анализлаудан, ленинчыл партиялелек һәм халыкчанлык принципларын ныгытуга һәрьяклап булышлык итүдән, совет сәнгатенең югары идея-эстетик дәрәҗәсе өчен көрәшүдән, буржуаз идеологиягә каршы эзлекле чыгыш ясаудан гыйбарәт. Әдәби тәнкыйть художникның идея кругозорын киңәйтүгә һәм аның осталыгын камилләштерүгә ярдәм итәргә тиеш. Марксистик-ленинчыл традицияләрне үстерә барып, совет әдәби тәнкыйте идея ягыннан бәяләүләрнең төгәллеген, социаль анализның тирәнлеген эстетик таләпчәнлек белән, талантка, нәтиҗәле иҗади эзләнүләргә сак караш белән бергә кушарга тиеш.

Тиешле министрлыкларга һәм ведомстволарга, иҗат союзларына буйсынган журналлар, газеталар, нәшриятлар, телевидение һәм радио редакцияләренең тәнкыйтьбиблиографик эшчәнлеген яхшырту чаралары эшләргә һәм тормышка ашырырга; редколлегияләрне, нәшрият советларын, редакцияләрне квалификацияле, политик яктан өлгергән кадрлар белән ныгытырга, авторитетлы тәнкыйтьчеләр арасыннан штаттан тыш актив булдыруны тәэмин итәргә; әдәби тәнкыйть, әдәбият һәм сәнгать белеме өлкәсендә иң яхшы эшләрне бүләкләү формаларын күздә тотарга кушылды.

КПСС Үзәк Комитеты иҗат союзларына әдәби тәнкыйтьнең идея-теоретик һәм профессиональ дәрәҗәсе турында көндәлек кайгыртучанлык күрсәтергә, коммунистик төзелеш бурычларын хәл итүдә, җәмәгать фикерен формалаштыруда, чит карашлар һәм концепцияләр белән көрәштә аның ролен күтәрергә тәкъдим итте. Иҗат союзлары, диелә карарда, әдәби иҗатның актуаль мәсьәләләрен, әдәбият һәм сәнгатьнең аерым әсәрләрен тикшерү инициаторлары һәм оештыручылары булырга, социалистик реализмның теоретик проблемаларын эшләүгә үз өлешләрен кертергә тиешләр. Тәнкыйть комиссияләре һәм советларының эшчәнлеген яхшыртырга кирәк.

СССР Фәннәр академиясенә, министрлыкларга, ведомстволарга алар буйсынуындагы институтларның игътибарын әдәби тәнкыйтьнең теория һәм методология проблемаларын тирәнтен өйрәнүгә юнәлдерергә, хәзерге заман художество процессын, социалистик лагерь илләре культураларының бер-берсенә йогынтысын тикшеренүдә галимнәрнең тырышлыкларын активлаштырырга тәкъдим ителде. КПСС Үзәк Комитеты карарында әдәбият, кино, театр, музыка, сынлы сәнгать тарихы һәм теориясе өлкәсендә белгечләр хәзерләүне яхшырту турында да тәкъдимнәр бар. Университетлар, педагогия институтлары һәм махсус югары уку йортларының укыту планнарында студентларны һәм аспирантларны әдәби тәнкыйть проблемалары буенча факультатив специальләштерү өчен кирәкле мөмкинлекләр тудыру күздә тотыла. КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясенә академия базасында әдәбият һәм сәнгать теориясе, әдәби тәнкыйть өлкәсендә квалификацияле белгечләр хәзерләүне яхшыртырга һәм киңәйтергә кушылды.

Тәнкыйть-библиография эшен һәм матур әдәбиятны пропагандалауны тагын да яхшырту максатларында массовый әдәби тәнкыйть һәм библиографик журнал булдыру максатка яраклы дип табылды.

Партия комитетларының мөһим бурычы, диелә КПСС Үзәк Комитеты карарында, тәнкыйтьче кадрлар тәрбияләү, сайлап алу һәм урнаштыру эшендә министрлыкларга һәм ведомстволарга, иҗат союзларына, матбугат, телевидение һәм радио органнарына ярдәмне көчәйтүдән, тәнкыйтьчеләрнең коммунистик төзелеш практикасы белән элемтәләрен ныгытудан, аларның марксистик-ленинчыл хәзерлеген камилләштерүдән гыйбарәт.

## Марс Шабаев

# Бар да таныш...

Бар да таныш.
Инде әйтеләсе
Беткән, дисең, күптән әйтелеп.
Шулзй!
Расладандай моны, күктән карый
Мәңге җансыз, гамьсез ай көлеп.

Бар да таныш.
Инде суынылган.
Хисләр ярым-йорты, томанлы.
Кеше, ахры, тормыш таный-таный
Суыныр, сүнәр өчен тугандыр.

Бар да таныш.
Фәлсәфәләр инде
Бакыр акча кебек шомарган.
Тормыш сәхнәсендә син — үзешчән,
Юаныргa кала шуңардан.

Бар да таныш.
Ләкин кинәт менә
Гел юк кына таныш нәрсәгә,
Яңа күргән кебек, исең китеп
Карыйсың да...
Челпәрәмә килә фәлсәфәң!

Бөтерелә башлый уй давылы,
Күкрәгеңә сыймый хисләрең.
Син яшәрдең, син гел яңа кеше,
Син янасың, әллә нишләдең.

Бар да таныш?
Булмый торсын әле!
Мин кычкырам бөтен дөньяга:
— Җиргә күпме кеше килә-китә,
Тормыш барыбер кала әр-яңа!

Мин яңадан янам, куанам...

## Чорлар хакында

Булган Җирнең, булган Таш гасыры,
Бронза чоры булган, Тимере.
Һәрбер чорның сугышлары булган,
Кем әйтмешли,
Муены асларына килгере!

Безгә туры килде Атом чоры,
Күрдек Хиросима шәүләсен.
Җир, бу синең соңгы җырың әллә,
Ахырзаманмы бу әллә соң?

Юк, ышанмыйм!

Әкиятләрдә шешәсеннән чыккан
Гыйфритләрне җиңә алучы,
Ә тормышта Атом атлы җенгә,
Авызлыклап, йөгән салучы
Гали зат — ул гади Кешедер.

Атом чорын Җирдә Алтын чорга
Әйләндерү — аның эшедер.
Таш гасырда кулына таш алуы
Бары шуның, шуның өчендер.

Мин ышанам!

## Тургайлар

Кайда барма, җыр да җыр монда.
Мин уяндым тургай җырына.

Тургай җыры...
Кайдан инде бу?
Төзелеш шавы, чыңы...
Әллә соңгы,
Әллә соңгы тургай инде бу?

Төн уртасы иде.
Арып-талып,
Мин йокларга яттым бик соңлап.
Ә күршедә кирпеч бушаттылар,
Дөнья торды чыңлап чың-чыңлап.

Төзелеш шавы, төзелеш чыңы белән
Изрәгәнмен икән мин — бәндә!
Йоклаганмын,

Тургай кебек кызлар
Төн буена эшләп йөргәндә.

Тургай жыры уяттымы диеп,
Кояш белән торсам, ашкынып —
Тургай жырларыннан аһәңлерәк
Кызлар жырын тыңлый ак болыт!

Тургай ялгыз, тургай биек була,
Кайда икән, дисәм, ул тургай? —
Ак болытка ашкан зур кранда
Таң жырларын жырлап утыра, эй!

Кайда барма, жыр да жыр монда,
Мин уяндым тургай жырына.

●

Меңнәр арасыннан табышырга
Юкса инде кем кушкан безгә?
Юл читендә зәгыйфь учак күреп,
Тик очраклы очрашканбыз да —
Күзләр ял сораган.
Туктаганбыз
Һәм әйткәнбез:
Дөнья, бар, йөгер.
Без калабыз әле.
Икәү булгач,
Бер мизгелең безгә бер гомер.

Дөнья агышында кинәт шулай
Туры килгән безнең тукталыш,
Кирәк булган безгә
Күздән-күзгә
Сүнмәс-сүрелмәслек ут салыш.
Сүнмәс-сүрелмәслек уртак учак.
Уртак табын...
Ләкин мин беләм:
Дөнья өчен мизгел бер гомердә
Күзләреңнән туеп өлгермәм.

Бер-беребезгә салган ике уттан
Өченче ут инде кабынган.
Өченче ут...
Ул яңаны көтә...
Кузгалырбыз, ахры, табыннан.
Башка мизгел.
Башка күзләр өчен.
Ә без дөнья әйләнешендә
Яңа юлга инде җыенабыз...
Ут калдырып алар өчен дә.

Кабырчыклар жыям, кабырчыклар —
Диңгезләрдән түгел, инештән.
Бала чаклар — энҗе табар чаклар...
Ни кылансаң, бар да килешкән.

— Агымсуда энҗе буламыни?
Ул диңгездә үсә, тирәндә.
Дулкын шавы, дулкын бәллүендә...—
Зурлар миңа шулай дигәннәр.

Күпне таптым, күпне югалттым мин
Агымсудай еллар эчендә.
Хыялдагы җем-җем энҗе хәзер
Чагыла инде, чагыла чәчемдә.

Тик барыбер кабырчыклар җыям,
Диңгезләрдән түгел, инештән.
Хыялдагы бөртек энҗе өчен
Баш тартам мең алтын-көмештән.

Минем энҗем — урман күлләрендә,
Үзебезнең агымсуларда.
Дөнья бәяләре җитми аңа,
Эзлим һаман, эзлим шуңарга.

Миргазиян Юныс

# ЭНҖЕ ЭЗЛӘҮЧЕЛӘР

хикәя

Айсыз төннәрдә Фарасан[1] ярлары тирәсендә диңгез өстенә тонык бер яктылык иңә. Таң алдыннан мондый яктылык югала, диңгез әкрен генә шәмәхә төскә керә башлый. Зөннүн йокыдан уянганда, шәмәхә төс сыекланып, күксел фирәзә төсенә әйләнә башлаган иде инде.

Урыныннан торгач, Зөннүн таң кызара башлаган төшне эзләп тапты да көннең ничек булачагын чамалады. Таңның алсулануында җил кузгалыр алдыннан була торган тоныклык сизелә иде.

Зөннүн озак итеп киерелде. Авызын кулы белән каплап, иснәнеп алды: «Лә хәүлә вәла кувватә...»

Төнге дымнан сакланыр өчен башына урап яткан чүпрәкне таш астына яшереп куйгач, ялан аяк салкынча комга басып, су читенә таба китте.

Дулкын ялап шомарткан җирдә ике диңгез кысласы ком өстендә йөгерешеп йөри иде. Аяк тавышы ишеткәч, алар тизрәк ояларына кереп постылар. Зөннүн кыслалар яшеренгән җирне урабрак үтте. Яр кырыена җиткәч, туктап, бер тын диңгезгә карап торды да сакланып кына суга керде.

Су комга караганда җылырак иде. Зөннүн учы белән диңгездән су алып авызын чайкады. Учында калган суны сибеп битен чылатты. Тозлы су тигәч, бармагының җәрәхәтләнгән җире әрни башлады.

Зөннүн аяк-кулларын әйбәтләп юды. Ашыкмый гына тәһарәт алды.

Судан чыкканда Зөннүннең тәне җиңеләеп, әгъзаларына көч кереп киткән иде. Диңгез суы тәнгә сеңеп калган йокыны юып төшерде.

Зөннүннең кулдашы — егерме ике яшьлек Гыймран — кыя уентыгына төшәгән суүсемнәре өстендә йоклап ята иде. Ул аяк-кулларын як-якка җәеп җибәргән. Йөзе сабый балаларныкы шикелле җитди һәм тыныч.

[1] Фарасан атаулары төркеме Кызыл диңгезнең көньяк-көнчыгыш өлешендә.

Кояш чыкканчы иртәнге ашны әзерләп өлгертергә кирәк иде. Зөннүн ком өстенә өеп куйган такта кисәкләренә ут төртеп җибәрде. Төн чыкканчы утыннар дым тарткан иде. Учак пыскый башлагач, төтен әскә күтәрелмичә ком өстенә таралды. Төтеннең җир өстенә җәелүе дә көннең бозыласын белдереп тора иде.

Төтен, тарала-тарала, Гыймран яткан тәшкә барып җитте. Гыймран төчкереп куйды. Күзен ачмыйча гына иснәнде. Төтен диңгез ягына китеп таралганда, узган көннәрдә җыйган кабырчыкларның бозылуыннан чыккан авыр ис аңкып китә иде. Гыймран баш астына түшәгән суүсемнәренә капланып ятты. Суүсемнәреннән чыккан йод исенә кушылып, астан нииндидер әчкелтем ис күтәрелә иде.

Әлегә аллага шөкер, Гыймранның бары тик колак пәрдәләре генә ертылган иде. Су басымы колак пәрдәсен генә ертып калмый, буыннарны катыра, бәвел куыгын эштән чыгара. Энҗе эзләүче йоклаган җирдән шушы әчкелтем ис килә башлагач, кабер якасына якынлашырга да күп калмый инде. Гыймран дустының шушы чиккә килеп җиткәнлеген белми иде әле.

Энҗе эзләүчеләр арасында картайганчы яшәгән кеше сирәк очрыйдыр. Тәкъдир акуладан саклап йөрткәндә дә аларның күбесе утызлар тирәсендә үк дөнья белән бәхилләшә. Ләкин энҗе эзләүчеләрнең берсе дә үзе теләп һөнәрен алыштырмый. Уйлап карасаң, алар тапкан кыйммәтле энҗене тагып, гомер буе рәхәттә генә яшәгән кешеләр дә мәңге тормыйлар бит.

Гыймран урыныннан торгач, салкынча кыя ташына аркасын терәп, бераз офыкка карап утырды. Көн туганда офыкның яңаданяңа төсләргә кереп, үзгәреп торуы Гыймранны һәрвакыт хәйран калдыра иде.

Кояш атауның кызгылт кыялары артыннан калкып чыга башлагач, Зөннүн йөзен кыйблага юнәлдереп намаз укырга кереште. Намазга һәвәслеге булмаса да, дустының күңелен күрер өчен, Гыймран да иптәшенә кушылды. Фатиханы бергәләп укып бетереп, дога кылдылар.

Намаздан торганда, учактагы көлчәләрдән атауга тәмле көйгән ис тарала башлаган иде. Энҗе эзләүчеләр учак янына утырып тамак ялгадылар. Амин тоткач, Зөннүн дулкын кагып чыгарган тактаны алып көлгә күмеп куйды. Гыймран кыя уентыгына яшергән чуму коралларын барлап алды. Ишкәкләрне көймәгә илтеп салды.

Агачтан чокып ясалган сай көймәне икәүләп суга төшерделәр. Ишкәкне комга терәп этеп җибәргәч, көймә, артыннан аксыл эз калдырып, ачык диңгезгә таба шуышты.

Гыймран, аякларын көймә төбендәге тактага терәп, каерып-каерып ишә иде. Зөннүн чуму коралларын тикшерергә керешге. Агач саплы авыр гарпунны алырга уңайлырак итеп көймә читенә урнаштырды. Чуму ташына таккан озын бауны әйбәтләп төреп, көймә борынына салды. Утыргыч астындагы су чүлмәгенә юеш чүпрәк каплады. Чүлмәк янында пыяла төпле агач тартма ята иде. Зөннүн тартманың төбен чайкап чистартты. Пыяла өстендәге кипкән тоз юылып беткәч, тартманы су төбенә утыртты.

Гади агач тартма кинәт могҗизалы тәрәзәгә әйләнеп китте.

Диңгез төбендә аклы-кызыллы мәрҗән урманы үсеп утыра иде. Ак куаклар эчендә тутый кошларга охшашлы матур-матур балыклар очып йөри. Сәхрәдә үскән чәчәкләргә охшашлы алсу-зәңгәр актинияләр селкенеп утыра. Актиния чәчәкләре эчендә гөлдән-гөлгә кунып йөргән күбәләкләрне хәтерләтеп, вак балыклар уйный. Канатларын кыймылдатып, су төбеннән диңгез йолдызы күтәрелә башлады. Мәрҗән ботаклары арасыннан диңгез шайтаны карап тора иде.

Бу тартма шәрык әкиятләрендәге тылсымлы балдак шикелле җир йөзендә булмаган могҗизаларны күрсәтми иде. Агач кыса кояш нурларын куләгәләп, пыяла төп су өстен тигезләгәнгә күрә, диңгез эче шулай аермачык күренә иде.

Диңгез төбен дулкынланып торган карасу-яшькелт пәрдә каплады. Җимгә бай урын эзләп йөргән балык көтүе көймә астыннан узып китте.

Ниһаять, көймә кабырчыклар чәчелгән алан җиргә килеп чыкты. Диңгез төбендә уч төбе зурлыгы яшькелт-көрән энҗе кабырчыклары күренә. Ара-тирә капкачлары арасыннан лайлалы телләрен чыгарып, су агымы алып килгән планктонны суыручы гигант кабырчыклар — тридакналар[1] очраштыргалый.

Энҗе кабырчыкларның куерак җиренә җиткәч, Зөннүн кулындагы тартманы утыргыч астына яшерде. Гыймран ишүдән туктады, ишкәкләрен көймә эченә салды. Энҗе эзләүчеләр чумарга хәзерләнә башладылар. Аларның кыяфәтләре җитдиләнде, хәрәкәтләре әкренәеп калды.

Зөннүн белән Гыймран йокыдан уянгапнан бирле бер-берсенә авыз ачып сүз әйтеп карамадылар. Алар көчләренең бер мыскалын да бушка исраф итмәскә тырыштылар. Эсселек һәм мәкерле су басымы белән көрәшү өчен көчнең һәр тамчысын саклап тотарга кирәк иде.

Иптәшенең күзәтү тартмасын утыргыч астына яшергәнен күргәч, Гыймран чумарга хәзерләнә башлады. Уң аягының баш бармагына пальма җепселеннән бәйләгән җәтмә беркетте. Уң кулына чуму ташын алды. Сул кулы белән билендәге пычакның сабын кысып тоткач, соңгы мәртәбә тирән итеп сулады да, иелә төшеп, диңгезгә ташланды.

Бисмиллаһи...

Көймә тирәсендә уралып йөргән вак балыклар куркышып якъякка атылдылар. Гыймранның гәүдәсе бер тамчы су чәчрәтмичә диярлек диңгез өстен ертып керде дә, тукталып тормыйча, сузылып аска төшеп китте.

Зөннүн иптәшенең чумганын күзәтеп, аның һәр хәрәкәтенә бәя биреп тора иде. Кулдашының тыныч, ышанычлы эшләве аның күңелендә горурлык уятты.

Моннан өч ел элек бергә эшләүче хәбәшне акула ботарлап ташлаганнан соң, Зөннүн, яраклы кеше таба алмыйча, айдан артык берүзе эшләде. Су астында ялгыз эшләү бик хәтәр иде. Хорафатка ышанучан фарасанлылар, фаҗигале вакыйгадан соң, Зөннүннең көймәсенә утырырга куркалар иде. Хиҗаз энҗечеләренең борынгы йоласы чит кабиләдән килгән кеше белән аралашмаска куша. Шуңа күрә Зөннүн башта Гыймранны кулдашлыкка алмыйча, борып җибәрде. Күңеленә ошарлык башка кеше табылмагач, соңгы чиктә генә егетне диңгезгә алып чыгарга мәҗбүр булды.

Гыймран гадел һәм зирәк егет булып чыкты. Кулдашы аны бик тиз яратты. Егет бик сәләтле иде шул. Бер айдан ул иптәшеннән калышмый эшли башлады. Хәзер инде Гыймран шикелле оста чумучылар Фарасанда гына түгел, Даһлак[2] атаулары тирәсендәге атаклы энҗечеләр арасында да күп очрамый. Шуңа карамастан, фанатиклар өчен бу егет бары тик пәйгамбәрләр җиренә килеп эләккән килмешәк кенә иде әле.

Гыймранның этисе сугыш вакытында немецләргә әсир төшкән Идел буе татары иде. Ул ватанына кайткан әсирләрне гомерлеккә

---

[1] Т р и д а к н а — зурлыгы 1,5 метрга җитә.

[2] Даһлак атаулары Кызыл диңгезнең көньяк-көнбатыш өлешендә.

сөргенгә җибәрәләр икән дигән коткыга ышанып, сугыш беткәч, Бельгиядә калды.

Кулыннан эш килгән тырыш кеше кайда да ачка үлми. Гыймранның әтисе ач-ялангач йөрмәде. Ләкин Европаның фани тормышы көчеңнең соңгы тамчысына кадәр сыгып биреп торуыңны сорый иде. Никадәр тырышып та мондый тормышка яраша алмагач, шәрык ягы туган илгә охшаш булмасмы дип, ул Хиҗаз җиренә күчеп килде.

Бәхетсезлеккә каршы, монда да тел — башка, җир — ят, гадәтләр ят иде. Монда да туган илне сагыну, җирсенүе басылмады. Гыймранның әтисе көннән-көн сызды, көннән-көн катырак сагына башлады.

Үләр алдыннан әтисе малаена әйтте: «Әсир төшүдә минем бер бөртек гаебем юк. Безне Власов атлы генерал армиябез белән немецләргә сатты. Сагынуыма чыдый алмыйча үләм. Туган җир туфрагы җиде буынга кадәр тарта диләр. Чит ил сине дә җирсетер. Син дә минем шикелле үк мантый алмассың дип куркам. Җай чыкса, минем туган авылыма кайтырга тырыш. Ул авыл Идел исемле данлыклы елга буенда. Анда минем туганнарым калды. Безнең ата-бабаларыбызның сөякләре шул җирдә ята. Анда кайткач, минем ничек әсир төшкәнлегемне сөйләп аңлатырсың...»

Бу турыда Гыймран беркемгә дә сөйләмәде.

Пәйгамбәрләр илендә яшәү Гыймранга бернинди куаныч китермәде. Ул фашист концлагеренда туып, Бельгия җирендә үсте. Биш яшендә әнисез калды. Гыймран яшәгән җирләрнең берсе дә аңа ватан түгел иде. Ватан дигән изге җир әлегә егетнең хыялында гына яши иде.

Әтисе үлгәннән соң ялгызлык тойгысы бер генә минутка да Гыймранның күңеленнән чыкмады. Шат күңелле булырга тырышса да, ул бик боега, ямансылый иде. Соңгы вакытта шушы тойгыга әчке бер киеренкелек килеп кушылды. Диңгез төбенә төшкән чакларда су өстенә күтәрелеп өлгерә алмам дип курку егетнең күңеленә шом салып тора иде.

Гыймран, ташны кысып кочаклаган килеш, аска таба очуын дәвам итте. Таш аны туктаусыз аска сөйрәде. Энҗе эзләүчедән курыккан балыклар, артларыннан ялтыравыклы эз калдырып, зәңгәрсу киңлеккә атылалар. Чуар бизәкле попугай балыклар әрсезләнеп Гыймран тирәсендә әйләнә башладылар. Кыя тишегенә поскан куркак лангуст, антеннага охшашлы мыекларын тырпайтып, энҗе эзләүчегә карап калды.

Терсәге ләмгә тию белән Гыймран кулындагы ташны ычкындырып җибәрде. Җәтмәне аягыннан алып муенына асты. Кыя ташка ябышкан кабырчыкларны куптарып җәтмәсенә тутырырга кереште. Кыя тишегеннән агулы елан-балык — мурена карап тора иде. Ерткыч балыкка әһәмият биреп торырга энҗе җыючының вакыты булмады. Муренаның исә бу ят җан иясенә ташланырга кыюлыгы җитеп бетмәде.

Унбиш-уналты секунд эчендә Гыймран якын-тирәдәге кабырчыкларны җыеп бетерде. Хәзер бер генә секундка да соңга калырга ярамый иде. Соңгы кабырчык җәтмәгә эләгү белән ул очып өскә менеп китте.

Гыймран вакытны чамалый алмады. Нииндидер әчке сизгерлек кенә секундларны санап, һәр мизгелдә аңа нәрсә эшләргә кирәклекне төгәл әйтеп тора иде. Тырышлык һәм тәҗрибә нәтиҗәсендә туган бу халәт һәр мизгелдә ярдәмгә килә иде. Ул кулдашының гаделлегенә, кирәк чакта һич икеләнмичә ярдәмгә ташлануына да ышана иде.

Башы су өстенә калкып чыгу белән Гыйймран комсызланып сулыш алып җибәрде. Тирә-якка ыңгырашуга охшашлы көчле тавыш яңгырады.

Зөннүн иптәшен көймә эченә сөйрәп менгерде. Гыйймран җыйган кабырчыкларын көймәгә бушатып, буш җәтмәне кулдашына сузды. Зөннүн җәтмәне аяк бармагына эләктерде, кулына таш алды. Борын тишеген уң кулының ике бармагы белән кысып тотты да, бисмилласын әйтеп, диңгезгә чумды.

Хәзер Гыйймран иптәшенең аска төшкәнен күзәтеп, һәр минутта аңа ярдәмгә ташланырга хәзерләнеп торырга тиеш иде. Кулдашы төпкә төшеп җиткәч, ул чуму ташын бавыннан сөйрәп көймәгә күтәрде.

Диңгез төбенә төшеп җитәр өчен егерме секунд чамасы вакыт кирәк иде. Әгәр ерткыч балык Зөннүнгә ташланса, Гыйймран барыбер аны коткара алмаячак. Шуңа карамастан энҗе эзләүчеләрнең буыннан-буынга күчеп килгән гадәтләре буенча су астындагы кешене зур гаделлек белән саклап торырга кирәк иде. Көймәдә калган кешенең ярдәменә ышану су астында эшләүчегә көч кертә, фаҗигале минутларда кыюлык бирә.

Кулдашының өскә күтәрелә башлаганын күргәч, Гыйймран ашыга-ашыга сулыш алырга тотынды. Су астында озаграк тору өчен канны алдан ук кислородка баету кирәк иде.

Зөннүн иптәшенең кулына ябышып көймәгә күтәрелде. Гыйймран тагын су астына төшеп китте.

Шулай итеп, алар төш җиткәнче эшләделәр.

Кояш югары күтәрелгәч, диңгез өсте эрегән кургаш төсле булып ялтырый башлады. Дымлы кайнар һава сулыш алганда тынга каплана. Тәндә калган соңгы көчне тир агызып алып чыга иде.

Һава кызып, бөркүлек соңгы чиккә җиткәч, энҗе эзләүчеләрнең хәрәкәтләре сүлпәнләнде.

Өстә йөргән балыклар да кояшның зәһәр нурларыннан качып тирәнгә төшеп киттеләр. Ялкау медузаларга кадәр каядыр китеп югалдылар. Эсселектән качып, күләгә җир эзләүче ялгыз акчарлак, ярдәм сорагандай, кычкыра-кычкыра, энҗе эзләүчеләрнең баш өстеннән очкалап узды. Эрегән металлга охшашлы ялтыравыклы соргылт су өстендә чумып бәхет эзләүче ике адәм баласы гына калды.

Эсселектән тәмам әлсерәгән чакларда Гыйймранның күңеленә хыял иткән күренешләр матур мираж кебек булып килә башлый иде:

...Яшел үлән үскән ярлар арасыннан, әнә, мул сулы киң елга ага. Салкынча җил су кырыендагы бөдрә талларның яфракларын селкетә. Һава рәхәт, җиләс. Ташлар арасыннан чаптырып чыккан салкын чишмәдән ятып су эчсәң, сусавың шундук басылачак...

Кайвакыт шушы мираж сыман күренешләр чынбарлыкка әйләнеп киткән кебек тоела башлый. Әйтерсең кайчандыр елга яры буенда яшәгән кешенең кичерешләре күңел түреннән калкып чыгалар.

Мул сулы киң елга, аның ярларындагы яшел болыннарны Гыйймран әтисеннән ишетеп белә иде. Әллә туган якның табигате безгә кан аша ата-бабадан тапшырыламы? Бер дә күрмәгән-белмәгән җирне ничек шулай ачык итеп күз алдына китерер идең?

Көймә төбендәге кабырчыклар әкренләп ачыла башладылар. Соңгы мәртәбә судан чыккач, Зөннүн:

— Аллага шөкер, Гыйймран, күп җыелды,— диде.— Аллаһ тәгалә насыйп иткән булса, эзләгәнебез шушы кабырчыклар эчендәдер, бәлки. Нәфеснең чиге юк аның. Биргәненә шөкер итик тә туктыйк инде.

— Соңгы төшүемдә бик ышанычлы кабырчыклар күргән идем. Шуларны алып чыгыйм инде,— диде Гыймран.

Зөннүн сукранып куйды:

— Аллаһ тәгаләнең кабырчыклары күп. Аларның барысын да алып бетерә алмассың.

Чыннан да соңгы вакытта Гыймранның нәфескә бирелә башлавы сизелгәли иде. Әллә аны иблис котырта, әллә берәр төрле яшерен мохтаҗлыгы бар. Җиддәгә барып кайтканнан бирле Гыймран үзен әллә ничек тота башлады.

Узган җомгада алар Җиддә базарына энҗе сатарга бардылар. Кергән акчага азык-төлек алып, хаҗ кылучыларны йөртә торган иске пароходка утырып, кайту юлына чыктылар. Җиддә лоцманы, пароходны хәтәр урыннан үткәреп җибәргәч, чират көтеп торучы океан корабына күчте.

Зур кораб белән чагыштырганда иске пароход бигрәк тә кечкенә, бигрәк тә зәгыйфь күренә иде. Пароход палубасында, эсселектән әлсерәп, хаҗ кылып кайтучылар аунап яталар. Ә океан лайнерының өске палубасында ике яшь егет теннис уйныйлар. Өлкән генә яшьтәге бер диңгезче койрыкта кармак салып утыра. Лайнерның корылмасыннан музыка тавышы агыла.

Корабның исеме ниндидер ят хәрефләр белән язылган иде. Ераклаша төшкәч, Гыймран күперчек өстендәге латин хәрефләре белән язылган исемне күреп алды. Дулкынланудан ул Зөннүннең җилкәсенә ябышты:

— Зөннүн, кайсы ил корабы бу?!

Зөннүн хаҗдан кайтучы ямәнледән Кәгъбә хәлләре турында сораштырып тора иде:

— Әләме төрекләрнеке төсле кызыл,— диде ул гамьсез генә.— Юк, бу төрекләрнеке түгел.

Корабның исеме Гыймранга бала чактан ук таныш иде.

Идел елгасы, туган авылы, күршеләре турында сөйләп бетергәч, Гыймранның әтисе туган иленең мәшһүр кешеләре турында сөйли торган иде. Шулар арасында Муса Җәлил дигән кешенең исеме һәрвакыт беренче урында була. Шушы исемне әйткәндә әтисенең күзендә күптән сүнгән өмет чаткылары кабынып киткән кебек була иде.

Гыймран кораб исемен кат-кат укып чыкты. Юк, ул ялгышмый иде. Корабка әтисе чиксез ихтирам иткән ил батырының исемен кушканнар. Бәлки, ул кеше ватанына кайта алгандыр? Бәлки, анда кайткан кешеләрне, әтисе уйлаганча, сөргенгә җибәрмәгәннәрдер? Сөрген киткән кешенең исемен океан лайнерына бирмәсләр иде...

Иске пароход калтырана-калтырана алга таба сөйрәлә. Ара һаман ерагая бара. Хәзер инде сикереп суга төшеп, йөзеп китсәң дә корабка барып җитә алмассың. Барып җитсәң дә корабның эченә кертмәячәкләр. Төрле илләрдә яшәүче кешеләрне бер-береннән аерып торучы шәфкатьсез законнар турында Гыймран яхшы белә иде.

Гыймран чыгыр артындагы аулак урынга барып утырды да уйга чумды.

Икенче көнне энҗе эзләүчеләрне Фарасан атавына илтергә ялланган көймәдә оча торган балыкларны күзәтеп утырганда Гыймранның планы тәмам ачыкланып беткән иде инде. Ул башта ничек кенә булса да кыйммәтле энҗе табарга тиеш. Шул энҗене сатып, юлга акча әзерләргә кирәк. Юлга җитәрлек акча юнәтү белән, бер минут тормыйча, Идел буендагы авылга китәргә тиеш. Билгеле, Зөннүн белән аерылышу авыр булыр. Ләкин әтисенең васыятен үтәми торып ул гомергә бәхетле була алмаячак.

Гыймрандагы үзгәрешне Зөннүн ачык күрсә дә, аның сәбәбен

белми иде. Шуңа күрә ул дустын нәсихәт белән сабырлыкка, канәгатьлеккә өндәп, бу гадәттән арындыруына ышанды.

Авыр ташны кысып кочаклап, Гыймран суга чумды. Аның диңгезгә төшеп киткән җирендә көлтәләнеп су чәчрәп калды. Хәрәкәтләренең төгәллеге инде югалган иде, күрәсең. Көймә дә агымга иярәп урыныннан күчкән иде. Гыймран соңгы чумуында күреп чыккан кабырчыкларны таба алмады. Аның төшәсе җирен мәрҗән куаклары каплаган иде. Куаклык эчендәге энҗеләрне җыюы бик уңайсыз. Тәҗрибәле эзләүчеләр куаклык эченә кермәскә тырышалар.

Гыймран бер төшкәч кабырчыксыз менәргә теләмәде.

Беренче мизгелдә егет нәрсә булганлыгын аңлап өлгермәде. Башта ниндидер шомлы көч Гыймранны диңгез төбенә беркетеп куйгандай булды. Икенче мизгелдә сул аягының тубык сөяге шартлап сытыла башлады...

Гигант кабырчыкның капкачлары чатырдап ябылды. Коточкыч авырту Гыймранның сөякләренә кадәр үтеп керде.

Ул әле һаман һәлакәтнең якынлашканлыгын белми иде. Егетнең йөрәге тоныкк тавыш белән калган секундларны саный. Үпкәдәге һаваның соңгы тамчылары канга таралып килә. Аяк авыртуы ми эченә саркып кереп һушны ала башлады...

Кулдашының бер урында катып калганын күрү белән, Зөннүн фаҗига барлыгын сизеп алды. Гыймранның аяк астында су кызара башлаганын күргәч, ул диңгезгә сикерде.

Иптәше төшеп җиткәндә, Гыймран, тозакка эләккән җәнлек шикелле, акылдан шашып йолкына иде. Зөннүн дустының аяк астындагы гигант кабырчык — тридакнага ташланды. Билендәге пычакны тартып алды. Капкачлар арасына кысылган аяк сеңерләрен кисте дә, Гыймранны кочаклап, өскә менеп китте.

Ашыгырга кирәк иде. Зөннүн ашыкты. Ләкин соң иде инде. Күтәрелеп җитәргә берничә аршын калганда, Гыймран сулыш алып җибәрде. Аның үпкәсенә ургылып тозлы су керде.

Зөннүн кулдашын көймә төбендәге кабырчыклар өстенә сузып салды. Аяк өзелгән җирдән туктаусыз кан ага иде. Зөннүн дустының балтырын бау белән кысып бәйләде. Аяк күгәреп юаная башлады. Кан туктамады. Билендәге чүпрәкне чишеп алып җәрәхәткә урады. Кан чүпрәк аша саркырга тотынды.

— И раббым, мәрхәмәтеңнән ташлама!

Диңгез өстендәге эссе пар аша атау яньчек булып күренә иде. Атауны уңдарак калдырып, Зөннүн материк ягына таба ишәргә тотынды. Туктамыйча, тәмам хәлдән тайганчы ишсәң дә, ярга чыгу өчен тәүлек ярым вакыт кирәк булачак.

Кан исен сизеп, көймә тирәсенә акулалар җыела башлады. Аларның берсе, арка йөзгече белән су өстен ертып, көймәне урап узды.

Суэш каналы ачык вакыт булса ла! Канал эшләгән чакта меңнән минут саен кораблар узып тора иде. Яһүд гаскәрләре каналны җимергәч, пароход юлы бөтенләй бушап калды. Шуңа күрә бу тирәдән үтәчәк корабны туктатып, аның табибына Гыймранны күрсәтү турында өметләнеп бушка вакыт уздырасы да юк иде.

Тукта! Кояш баеганда атау янынннан Сабиягә кайтучы балыкчыларның моторлы көймәләре уза. Кичкә кадәр көтсәң, Гыймранны балыкчыларга салып ярга алып чыгып булачак. Зөннүн көймәсен атау ягына борды.

— Су-у! Су эчәсем килә! — Гыймран чатный башлаган иреннәрен ялап алды. Зөннүн утыргыч астындагы чүлмәкне алып, дустының авызына су коярга тотынды.

Су эчкәндә Гыймран күзен ачып иптәшенә карады. Аның бу карашында коточкыч тетрәнү, өмет, курку тойгысы җуелмаслык булып сурәтләнеп калган иде.

— Түз, Гыймран. Түз, яме! Кич белән безнең яннан Сабия балыкчылары үтәчәк. Мин сине шуларның көймәләренә салып, ярга алып чыгармын. Түзәргә тырыш, күп калмады.

Гыймран җавап бирмәде. Күзен йомып бер тын ятты да елмаеп куйды.

«Иншалла, су эчкәч, хәл керде. Хәле арулана башлаганга сөенеп елмая торгандыр инде. Раббым, аңа түземлек бир». Дустының хәле арулануга Зөннүн чын күңелдән сөенә иде.

Күзен йому белән Гыймран бушлыкка очып төшә башлады. Кызгылт караңгылык эченнән бик озак баргач, тирә-ягында яшел сәхрә җәелеп ятканын күрде. Бу күренеш аңа гаҗәп таныш иде... Менә ул йомшак үләнгә басып мул сулы киң елгага таба бара. Яр буен куе яфраклы бөдрә таллар каплаган. Ерак та елга буена тезелеп утырган зәңгәр тәрәзәле йортлар күренә... Бу, билгеле, Гыймран әтисенең авылы. Тирә-якта моңлы итеп кошлар сайрый. Елга ягыннан әкрен генә салкынча җил исә. Әнә ташлар арасыннан чаптырып чыккан таныш чишмә... «Күрергә насыйп булган икән,— диде Гыймран сөенеп.— Мәрхүмкәй үзе генә күрә алмады...».

Гыймран саташып кем беләндер сөйләшә, ара-тирә елмаеп ала иде. Зөннүн аны атауга алып чыкты. Кыя уентыгына түшәлгән сүсемнәрен йомшартып кабартты. Хәзер бу урынга күләгә төшә башлаган иде. Иптәшен йомшак урынга китереп яткыргач, кипкән актиния ботагы белән Гыймранның аягына кунган чебеннәрне куып тора башлады.

«Йоклады мескен. Балыкчылар соңга калмасалар гына ярар иде. Төн урталарында Сабиягә барып җитеп булса, табиб аны коткарачак. Кешеләрне терелтә торган хикмәтне белсәң иде аны.— Ул хикмәтне түгел, Зөннүн бу очракта укыла торган доганы да белми иде. Аның гомере суга чумып энҗе эзләп үтте. Башкалар шикелле мәдрәсәгә йөреп дога ятларга вакыты булмады.— Ясинның файдасы тимәсме икән соң? Бәлки тияр? — Зөннүн ясинның яттан белгән өлешен пышылдап укырга кереште: ...Вә әйтерләр: «Сүзегез хак улса, вәгъдәгез кайчан үтәлер? Бәхәсләшкәндә пәйда булган ялгыз авазнан тыш алар бернинди тавыш ишетә алмаслар. Вә васыять калдыра алмаслар, вә кайтып гаиләләрен күрә алмаслар...»

Җир астында яткан барлык мөселманнарны соңгы юлга озаткан борынгы серле сүзләрнең тантаналы яңгыравын тыңлап утыра торгач, ул йокымсырап китте...

Күзен ачып җибәргәндә, Гыймранның битенә чебен җыелган иде. Зөннүн шул чебеннәрне куарга үрелгән килеш тукталып калды. Егетнең йөзе балавыз төсле булып катып калган. Әрсез чебеннәр аның борын эченә кереп йөриләр.

Дустының күкрәгенә ятып Зөннүн йөрәк тибүен тыңлап карады. Гыймранның йөрәге тибүдән туктаган иде. Зөннүн сикереп урыннан торды. Йөгереп барып көймәдәге чүлмәкне алып килде. Чүлмәктәге суны дустының битенә, күкрәгенә сибеп карады. Гыймран уянмады.

Дустының җилкәсенә ябышып, Зөннүн җансыз гәүдәне җирдән күтәрде. Гыймранның башы артка таба каерылып төште. Куллары асылынып калды.

— Гыймран, син мине ташлап китәсеңмени?!

Шушы егет белән бергә иң кадерле нәрсә — кыйммәтле энҗе табу өмете, хыялда йөргән бәхет китәчәк бит. Зөннүн башын комга бәрә-бәрә ялварырга тотынды:

— И раббым, нигә Гыймранның күзен ачтырмыйсың? Нигә аны алып китәсең? Алма, раббым, калдыр! Гомерем буена бер гөнаһ эшләмәдем, гомерем буе сиңа гамәл кылдым — калдыр Гыймранны!

Кояш диңгезгә төшеп килә иде. Диңгез өсте кан сипкән төсле булып кызарган. Биеклектә ике козгын очып йөри иде.

Зөннүн як-ягына карап алды. Руб-әл-Хали чүле ягыннан исә башлаган кайнар җил, диңгез өстен җыерчыкландырып, дулкын куарга тотынган иде. Зөннүн яр буена барып көймәсен өскәрәк сөйрәп менгерде.

Моннан өч ел элек акулага юлыгып һәлак булган кулдашын ул кыя артындагы калкулыкка күмгән иде. Гыймранны да шунда җирләргә кирәк. Җиргә күмелгәч, аның соңгы карашы, бәлки, күз алдыннан югалыр.

Кыя артыннан чыгып, Зөннүн калку җирне эзләп тапты. Пычагын алып, кабырчык ватыклары һәм мәрҗән валчыклары белән аралашкан кайнар комны казырга кереште. Бер аршин чамасы казыгач, пычак каты җиргә төртелде. Ком астына бер аршин казып төшкәннән соң тоташ мәрҗән катламы башлана иде. Туктап бераз ял иткәч, Зөннүн чокыр төбен тазартырга кереште.

Кояш инде диңгезгә күмелә башлаган иде. Зөннүн чокырдан чыгып, мәет янына килде. Кулын аның күкрәгенә куеп, тагын бер мәртәбә йөрәк тибүен тыңлап карады. Егетнең йөрәге мәңгегә тынып калган иде инде.

Гыймранның авыр гәүдәсен көчкә сөйрәп, казыган кабер янына алып килде. Мәрхүмне кабергә төшереп яткыргач, күмәр алдыннан аның йөзенә күз салды. Хәтере чуалганлыктан, Зөннүн дустының муенындагы җәтмәне чишеп алырга оныткан иде. Җәтмәне чишеп алгач, челтәр эчендәге кара нәрсәне кулы белән капшап карады. Җәтмә төбендә бердәнбер энҗе кабырчыгы онытылып калган иде. «Соңгы төшүендә тапкан кабырчыктыр инде бу. Мәрхүмкәй, аягы кысылуга карамастан, тапкан кабырчыгын җәтмәгә салып куйган»,— дип уйлады Зөннүн. Инстинктка буйсынып, кабырчык эчендәге лайлалы итне бармагы белән каерып чыгарды. Аннан күгәрчен йомыркасы зурлыгы түгәрәк нәрсә тәгәрәп чыгып кабер эченә төште.

Сүнеп килгән шәфәкъ яктысында энҗе тирәли яшькелт нур бөҗрасы балкып тора иде. Зөннүн үз күзенә ышанмады, энҗене учына салып, кабат-кабат тәгәрәтеп карады. Сирәк табыла торган зур, кыйммәтле энҗе иде бу.

Мондый энҗене диңгез гасырга бер мәртәбә генә бирә торгандыр. Кулына шушындый энҗе кергән ярлы кеше байый, хыялы тормышка аша. Ләкин моңа кадәр кыйммәтле энҗе тапкан кешеләрнең берсе дә бәхетле була алмаган иде әле.

Энҗе белән бергә Зөннүннең күңеленә шомлы тынгысызлык кереп урнашты. Курку тойгысы аның йөрәген тырнарга тотынды. Тирә-якта ниндидер тонык шәүләләр кыймылдап йөриләр кебек. Аларның килеп ябышуларын сизми калырсың шикелле иде...

Зөннүн энҗене учына кысты. Шәүләләргә әһәмият итмәскә тырышып, каберне күмәргә тотынды.

Кинәт диңгез ягыннан бала елаган тавыш ишетелгәндәй булды. Комга басып килгән аяк тавышы һаман якынлаша сыман иде...

Зөннүн түзмәде, учын ачып энҗегә карады. Аның учында Гыймранның күзе акаеп Зөннүнгә карап тора кебек иде...

Зөннүн кычкырып җибәрде. Энҗе кабер эченә тәгәрәп төште. Энҗе эзләүче абына-сөртенә йөгереп барды да көймәсенә капланды.

Җил тәмам көчәеп җиткән, диңгез үкереп елый башлаган иде инде...

1971 ел

## Зөлфәт

### Ерактагы гудок

Тын көймәдә төнем янды минем,
Бертукталмый акты агымсу,
Бертуктамый
төнге ярга түгел —
Йөрәгемә какты агымсу.

Поезд гудоклары офыкларның
Аръягыннан һаман ишетелде:
Поезд түгел, ә чор, гудок биреп,
Мине читләп узды шикелле.

Узды поезд, бер вагонда исә
Минем урын китте —
буш инде,
Алда торган җәйләр — минсез җәйләр,
Ап-ак кышлар —
минсез кыш инде.

Буш урыным... Шуңа янәшәдә
Сөйгән ярым китте ялгызы.
...Тын көймәдә — монда мин берүзем
Шырпы сызып чилем кабыздым.

Китте поезд,
мин эшлисе эшләр,
Мин йөрисе юллар киттеләр,
Мин карыйсы күзләр,
күрешкәндә
Мин кысасы куллар киттеләр.

Соң күперне чыкты поезд.
Кире
Кайтмас өчен күпер сүтелде:
Минем гомер
шаулы поезд булып
Мине ташлап китте шикелле.

Көне җиткәч китәр...
Вагондагы
Минем урын чыннан буш булыр.
Тик мин сөйгән җәйләр кабатланыр!
Мин сөйгәнчә ап-ак кыш булыр!

Китсәм җирдән,
жаным сөйгән җирдән
Яшәгәннән соң да мең гомер,
Тормыш үзен шулай сөйгән өчен
Гудок бирер, моңсу гудок бирер
Югалтканын әйтеп кемнедер...

## Очабыз

Әрнү үтте,
инде мин тыныч,
Тик бу тынлык шундый куркыныч!

Япа-ялгыз калган төннәрдә
Мөмкин түгел аны җиңәргә!

Өзгәләнә тынлык, сызлана:
Соңгы сүзең җанда кузгала.

Хәлең ничек?
Бәлки, синең дә
Япа-ялгыз калган төнеңдә

Кубарылып хәтер төбеннән,
Әзер килеш хәтта үлемгә,

Ишетелер минем соңгы сүз?..
Әрнү үтте... Хәтер тынгысыз.

Син әрнүдән качма,
ялварам,
Тыныч төннән, тыныч таңнардан

Саклана күр,
юкса, мин — тыныч,
Тынлык
әрнүдән дә куркыныч!

Без очабыз шундый биектә,
Һич әрнүсез, тыныч киңлектә!

Без очабыз гүя парлашып...
Ачылмаган
ләкин
Парашют.

## Нигә?

...Ә сәхнәдә
аккош һәлак булды.
Караңгыда синең күзләрең
Бер сорауга һаман, бер сорауга,
Бер сорауга җавап эзләде.

— Нигә? — диден,
мин дәшмәдем сиңа...
Ничә еллар инде мин һаман
Шул сорауга һаман, шул сорауга
Җавап эзлим шушы дөньядан.

Хәлдән таеп, кайнар таш өстендә
Юл капчыгын салып иңемнән,
Зур тауларга сорау биргәнем бар,
Ә тауларның холкын мин беләм:

Соравымны нәкъ шул килеш алар
Кайтардылар кире үземә:
— Нигә-ә-ә? —
диде кыя,
— Нигә? — диеп,
Зәңгәр күлләр бакты күземә.

Тузган палас сыман иске юллар,
Тузаннарын җилләр кактылар.
— Нигә? — диде юллар,
— Нигә? — диеп,
Җилләр исте, сулар актылар.

Нигә синең гади күзләреңдә
Ал болытлар йөзеп узалар?
Нигә минем күкрәгемдә —
эчтә
Үткер кылыч гүя кузгала?

Вакыт нигә яман төшләр күрә
Һәм сискәнеп һаман уяна?
Ник үткәннәр һәр чак аңлаешлы,
Ә киләчәк һаман томанда?

— Нигә? — диеп, бөркет очты күктә,
— Нигә? — диеп, былбыл сайрады.
...Без үзебез, бәлки, табигатьнең
Үз-үзенә биргән соравы?

Ә сәхнәдә аккош һәлак булды,
Карашында шундый таныш моң! —
Юк, син түгел, синең күзләр белән
Карый гүя миңа язмышым...

## Әхмәт Рәшитов

### Күңел бөреләре

Каңгылдаша казлар, каңгылдаша,
Каңгылдашыр чагы казларның;
Иркә бәбкә булып сабый казлар
Тәпи басты тагын язларын.

Яшәү әле, димәк, дәвам итә,
Урап килеп әллә кайдан да;
Кышкы сагышларны ташлап иңнән,
Атылам мин кабат мәйданга.

Күкрәгемдә — ташкын.
Бәйгеләрне
Сагынып көткән чагы йөрәкнең;
Аңа давыл, зилзиләләр кирәк,
Яну кирәк.
Тынлык кирәкми.
Һун атлары сыман җилеп кенә
Эһ дигәнче узып китә бит! —
Яз яз инде —
Эшне кызу тота;
Егет булсаң — өлгер,
Куып җит.

Язны мактап казлар каңгылдаша —
Яшәү, димәк, яңа ярларда;
Уяналар күңел бөреләре,
Ил ирләрен чакырып яуларга.

Шыта хисләр, яңа бәхет яулап,
Шыта орлык, кояш, дым даулап;
Вәгъдә итә бәрәкәтле туфрак,
Көшелләрен аның тау-таулап.

Яшәү мәңге дәвам итсен өчен
Көйли дөнья, көйли моң-сазын;
Язлар килә җиргә.
Ә һәрбер яз
Якынайта илнең зур язын.

# Эрнесто Че Гевара истәлегенә

КПССның XXIV съезды делегатлары соңгы биш ел эчендә вафат булган революцион эшлеклеләрне бер минут тын торып искә алдылар.

*(Газеталардан.)*

Тирән хәсрәт белән искә алыйк үлгәннәрне —
Югалтулар ачысын татысын һәр йөрәк;
Тирән хөрмәт белән искә алыйк үлгәннәрне —
Бу — үлгәннәргә түгел,
тереләргә кирәк.

Бер минут тынлык эчендә Съездлар сарае —
Күпме батыр киткән көрәшчеләр сафыннан;
Сьерра-Маэстрода җыңгән барбудослардан
Гевараның да ялкынлы авазы тынган.

Эрнесто, Эрнесто, океаннар кичеп еракташ
Килгән идең син Казанга,
тәләктәшләр янына;
Очраштык синең белән бөтенләй башка залда —
Җәлил өендә...
«Шүрәле»не тыңлаганда.

Сокланган идең син күгебез аязлыгына,
Каһарман кешеләрнең
Эшенә...
Ялына...
...һәм менә исемең синең Азатлык мәркәзендә
Бүген кайгы-сагыш белән телгә алына.

Туктагыз каннар коюдан, юлбасар янкилар,
Социализмның дөньяга әйтер сүзе бар;
Кызыл байрак тотып ул яңа офыклар яулый,
Богауларын ыргыта Көнбатыш ярымшар.

Корриданы хәтерләтә көрәш мәйданнары,
Безнең канга манчылган алсу әләмнәргә
Капитал үгезе ничек кенә ташланмасын —
Җиңү барыбер җирне гөл итәр адәмнәргә.

Күтәрелә, әнә, Чили...
Перу — трибунада...
Һәм кичәге колларны алкышлыйлар бар да.
Ә Данко йөрәген тотып,
туар таңнарга таба
Үлемсез үлгәннәр атлый тыгыз сафларда.

## Фәннур Сафин

### Замандаш сүзләре

Иңнәренә авыр нужа салып,
яуга каршы китте әтиләр.
Салкын җилләр бәреп күкрәкләргә:
— Алар кайтмас...— диеп әйттеләр.

Кайтуларын, бәлки, күрербез, дип,
каеннарга мендек сарылып...
...Яшь хыяллар ташка бәрелгәндә
кулыбыздан тотты сабырлык...

Тәндә Канкай[1] каны уйнаганга
ярсып чыктык озын юлларга.
Юл күмелгән,
көмеш җәя төсле,
яңа айдан яуган нурларга.

Без, мәгаен, айлы юллар буйлап
ал таңнарга кадәр барырбыз...
Кала төзергәме?
Илме?
Җирме? —
Кайнап торган ярсу чагыбыз!

### Әнкәй!..

*Бер көндәлектән*

Үз илем бар, рәхмәт, әнкәй!
Үз телем бар, рәхмәт, әнкәй!

Дөньяларда ямьнәр табып,
дулкынланып, ярсып-янып,
яшәү шундый рәхәт, әнкәй,—
барысы өчен рәхмәт, әнкәй!

---

[1] Канкаев — Е. Пугачев белән баш күтәргән татарларның башлыгы.

Ризык биргән,
гомереннән
өзеп биргән шул ук әнкәй...
Ләкин бөтен рәхмәтләрне
ничек әйтик?..
Син юк, әнкәй...

## Кеше

Кем өчендер, бәлки, бәхет,
ә кемгәдер кайгымын.
Кем беләндер кавышырмын,
кемнәрдәндер калырмын.

Җир шарында басып торам
кеше булып, зур булып.
Шул ук җиргә ята алам
кем өчендер юл булып.

Мин кемнеңдер ышанычы
һәм кемнеңдер дәвамы.
Утлы таулар тотып киләм
Уятырга даланы.

## Сагынам

Таҗ-тәхетсез падишадай булам
читтә ялгыз калгач чагымда.
Кояшларга карап елмаям мин,
сары айга карап сагынам...

Тентүләрдә туздырылган йорттай
тәртипсез уй түгел башымда,—
ераклардан җәһәт кенә килеп,
син торасың кебек каршымда!

Мин каладан авылыма таба
сузылып киткән юлга күз атам.
Тәрәзәмне ачып, уйларымны
Туган якларыма озатам...

Ак күгәрчен булып оча хыял
Иң бәхетле узган чагыма...
Кояшларга карап елмаям мин,
сары айга карап сагынам...

●

Өметне тиз өзә торган түгел без.
Егет ялгыз калса ләкин — күңелсез.

Ак күлмәкле кызлар керә төшләргә.
Ничек төштән өнгә сикереп төшәргә?!

Гел кояшлы язлар гына күңелдә.
Ничек көздән язга сикереп керергә?!

## Авырганда

Яңгыр, яңгыр ява, яңгыр!
Туган як яңгырлары!
Агып китәр урамымның
чүп-чары, кайгылары!..

Бер чынаяк яңгыр җыеп
алып кердең, бер генәм!
Тулды яңгыр исе белән
бәләкәй генә бүлмәм...

Күрәсеңме, «кая карыйм?»
дигән кебек җилләрдә
сары калфаклы көнбагыш
кояш эзләп тирбәлә...

Шул көнбагыш шикелле мин,
өметем югалтканда,
бер чынаяк шатлык бирдең,
кояш бирдең, кыз бала!

Күрәсеңме, мин елмаям,
күрәсеңме, мин көләм!
Телисеңме, урамнардан
яңгыр булып йөгерәм!

## Нишләттең

Туган якның арыш басулары,
киң болыннар шундый кадерле!..
Иделемә карыйм, күзләремне
алалмыйча таңга кадәрле...

Йөрәгемне нидер чәнчеп ала,
алтын көннәремне сагынам...
Керфекгәге утлар аша багам
алсуланган офык ягына...

...Тыныч кына гомер кичкән чакта
шатлык-кайгыларны ишәйттең;
күкрәгемдә йөрәк барын тоям!..—
Мәхәббәт, син мине нишләттең?!.

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ФРОНТОВИКЛАР

РОМАН

### XVI



Әле ун көн элек кенә ул бала иде...

Юк, кичә концертка чыкканчы гына әле ул бала иде. Кичәге төсле зур дәрт белән аның беркайчан да сәхнәдә чыгыш ясаганы юк иде. Әтисе район алыштырган саен аңа мәктәп алыштырырга туры килде. Район үзәкләренең берсендә — сигезенче класста вакытта ул сәнгатьчә гимнастика белән шөгыльләнә башлаган иде. Шуннан бирле ул күп тапкыр сәхнәгә чыкты. Ләкин бервакытта да бу авыр күнегүләрне кичәге төсле рәхәтләнеп эшли алганы юк иде.

Кичә сәхнәгә чыкканчы ук аның күңеле нәрсәдер сизенде, нәрсәгәдер җилкенде. Кызның күңелендә мондый җилкенү, ниндидер билгесез хәлгә әзерләнү башланганга инде бер ел чамасы бар иде. Тик кенә торганда, әйтик, тригонометриядән синуслар, косинусларны үлчәп утырганда кинәт кенә йөрәк сызлап куя, ниндидер сихри көч иясе күңелне күбәләк канатын җилпегәндәй итеп кенә кытыклый — рәхәт тә, газаплы да була. Кыз мондый вакытларда шиккә төшә, үзенең эчендә нинди дә булса авыру юкмы икән дип хәсрәтләнә иде. Математикадан бик тырышкангамы әллә? Соңгы вакытта күченеп йөрү, әйбер җыю, әйбер төйнәү, чишү мәшәкатьләре белән мавыгып бу сәер нәрсә онытылып торган иде әле. Тик бу озакка бармады: Акбалык мәктәбендә беренче көнне беренче дәрестә бу билгесез, сәер хис яңадан үзен сиздерде. Моңа сәбәп нәрсә булды? Кыз моңа җавап таба алмады. Кичә сәхнә артында әзерләнгәндә тагын шул хәл башланды: йөрәге кызу-кызу типте, тын алуы авырлашты, ләкин бөтен тәнен ниндидер моңарчы әле бер дә татымаган ләззәтле ашкыну биләп алды... Шуңа күрә сәхнәдә «тәгәрмәч» ясаган вакытта гадәттән тыш кызу әйләнде, иң авыр күне-

Ахыры. Башы журналның 1, 2, 3 саннарында. Роман журнал вариантында басылды.

гуләрне ясаганда да гадәттән тыш җиңел булды. Ниндидер бер секундта ул үзен-үзе бөтенләй югалтты, сәхнә, түбәндәге халык, сәхнә артындагы укытучылар, иптәшләре, ниһаять, түбәндә беренче рәттә утырган әнисе, мәктәп директоры — барысы да болындагы чәчәкләр булып тоелдылар, менә кояшлы, нур тулган бер болын икән, менә ул шунда чәчәктән чәчәккә кунып йөри торган табигатьнең бер иркәсе икән. Шул вакыт теге ләззәтле ашкыну аның тәненнән тагын бер мәртәбә узды һәм нәкъ шул секундта ул билгесезлеккә сикерде...

Төн буе ул керфек какмады. Таң атты. Кичә ул балалыгы белән саубуллашты. Бүген — кызлык дәверенең беренче иртәсе. Монда килүгә ул зур йортның чоланындагы аерым бүлмәгә урнашкан иде — житкән кызлар җәен авылда шундый бүлмәгә караватк куялар, күбрәк шунда яшиләр. Ләйләгөлнең бүгенге иң изге, кадерле хисләренә шушы бүлмә генә шаһит. Ул урыныннан торды, кечкенә бүлмәнең челтәрле пәрдәсен тартты, бакчадагы агачлар арасыннан әле чыгып килгән кояш карый иде. Вакытны белде дә тагын ятты — зур өйдә әнисе савыт-саба шалтырата иде, димәк, бер сәгатьтән капка төбенә райком газигы килеп туктаячак. Әтисенең әле көндез бу авылны күргәне юк диярлек — иртүк китә, төнлә генә кайтып куялар.

Нәрсәгәдер елыйсы килә. Рәхәт, рәхәт итеп елыйсы, күз яшьләре белән мендәр тышларын юешлисе килә.

Ләйләгөл кызлык дәверенең беренче иртәсен шулай каршы алды: агач ботаклары аркылы үтеп кечкенә тәрәзәдән төшкән кызгылт нурлар, татлы күз яшьләре, бөтен тәнгә таралган наз, рәхәт бер калгу...

— Әнием! Ул — шулкадәр яхшы кеше, син аны белсәң иде, белсәң иде... Мин аны көн саен күреп кенә торыр идем, көне буе шуның дәресләре генә булсын иде. Әнием! Татьяна да шул хисләрне кичердеме икән Евгенийны күргәч? Наташа Ростова да шундый ук хисләр кичергән түгелме соң? Нигә алар үзләренең хисләрен белдерә алганнар? Нигә миңа ярамый?

— Ярамый, кызым. Ул — укытучы, син — укучы.

— Миңа бит унҗиде яшь, әни. Нигә ярамый? Минем берәүдән дә курыкмыйча аның янында сөйләшеп торасым килә. Аның белән култыклашып шушы урамның уртасыннан узасым килә. Татьяна белән Наташа кадәр дә ирегем юкмыни минем?

— Ярамый, кызым. Син — комсомолка. Наташа да, Татьяна да — дворян кызлары алар.

— Соң комсомолкага яратырга ярамыймыни? Зоя яратмаганмы? Чайкина яратмаганмы? Яратудан мине кем тыя ала? Ул — кешенең иң бөек, иң изге хисе дип языла бит безнең китапларда.

— Ярамый, кызым. Әтиеңнән оят...

— Әти сине яратмадымыни?

— Без икебез дә студентлар идек. Безгә ярый иде.

— Аның шулай таблицасы бармыни? Кемгә ярый, кемгә ярамый?

Әнисе биреште. Ләйләгөл хыялга чумды.

— Әнием, әйтче миңа: нәрсә ул ярату? Нигә мин Гата абыйны түгел, ә нәкъ менә шул кешене яратам? Гата абый ни төсле иде бит кичә. Төймәләре, погоннары ялт та йолт килә, итекләре көзге кебек. Үзе — менә дигән укытучы. Нигә аны түгел, ә менә тегене яраттым? Ә? Нигә, әнием?

Әнисе җавап бирми. Чөнки ул бу сүзләргә бөтенләй катнашмый. Моны Ләйләгөл сөйләшә, күңеленнән әнисе белән серләшә. Әнисеннән үзенең мәхәббәтенә рөхсәт сорый. Әнисе башта тыя, каты тора, чигенә башлагач исә — юкка чыга...

Капка төбендә газик тавышы ишетелә, өйдә хәрәкәт кызулана. Ә Ләйләгөл тын гына, рәхәт кенә елый...

Еласын ул, борчымагыз аны...

...Тугызынчы май — ял көне иде, шулай булса да унынчы класс укучылары мәктәпкә җыелдылар. Соңгы атнада көн саен диярлек инша яздылар, Нәркис көннәр буе мәктәптә дәфтәр тикшереп утырды. Ярый әле иптәшкә Заһир була иде. Заһир — олы яшьтәге егет, сугыш башланганчы ул Тын океан флотына алынган да, Япония белән сугыш тәмамлангач, кырык бишенче елның ахырында гына авылга кайткан. Ул Кытайны гизгән, Порт-Артурдагы зур китапханәләрдә бик күп китаплар укыган. Хәзер дә укытучылар бүлмәсендә газета подшивкаларын актарып, журналлар укып гомерен уздыра. Әйтүенә караганда, җәйгә авыл хуҗалыгы институтының читтән торып уку бүлегенә керергә хәзерләнә икән. Аның чәчләре агара башлаган, җиде ел буе су асты көймәсендә йөрү эзсез калмаган. Ул аз сүзле, йомык кеше. Ләкин азмаз сөйләшеп алганда да аның бөтен дөньядагы халыкара хәлләрне, географияне, тарихны, классик әдәбиятны искиткеч яхшы белгәнлеге сизелеп-сизелеп ала. Берничә көн шулай бергә мәктәптә кич уздыргач, Нәркис аннан шигәя башлады: дипломсыз авыл егете, мәктәпнең хуҗалык мөдире — ат җигеп йөрүче Заһир «Декамерон»ны да, Гай Светоний әсәрләрен дә, Бомаршены да белә икән... Алай гынамы! «Дипломатия тарихы»н да, Тарле әсәрләрен дә укыган, Порт-Артурның матрослар клубында Леонид Утесовны тыңлаган, Шанхай урамнарында рикшага утырып йөргән сигаралы әфәнделәрне дә күргән. Заһир белән өзеклөтек сөйләшүләрдән соң Нәркис йомылды да калды: аның каршында кара туфракта туып үскән, авыл мәктәбендә ун класс белем алган, дөнья күргән, искиткеч тирән белемле, дөньядагы барлык хәлләргә реалистларча аек карашлы бер крестьян егете иде. Үзенең белмәгән эше юк икән: трактор ремонтлый ала, дизельләрне белә, бөтен төрле буяуларның сыйфаты турында энциклопедик мәгълүматы бар һәм... балта остасы да икән.

Нәркис соңгыларына гаҗәпләнде.

— Флот — зур мәктәп,— диде Заһир,— ләкин укырга кирәк. Укырга, квалификацияле кадр булырга кирәк. Сугыш моның кирәклеген тагын бер мәртәбә күрсәтте.

— Ә ни өчен, шулай да, авыл хуҗалыгын сайларга булдың?

— Ничек әйтергә... Үзем дә белмим. Япония капитуляциягә кул куйгач, без Порт-Артурда тордык. Шунда безгә Кытай илендә йөрергә туры килде — мин анда кытай крестьяннарының җирне ничек эшкәртүен күрдем. Көянтә белән ике кәрзин балчык күтәрәләр, аркаларына бала асалар — үзләренең ташлы, уч төбе кадәр җир кисәкләренә әнә шулай туфрак ташыйлар. Шунда үзебезнең иркен басулар, буразналар, уйсулыклар минем күз алдыма килә иде. Аннан соң җиде елга якын гел суда яшәдем. Җирне сагындым. Укырга керә алсам, әлбәттә, шунда ук тракторга утырам. Ләкин керергә кирәк, керергә. Мин әлегә түл җыям.

Заһир шулай итеп Нәркиснең ялгызлыгына иптәш булды, калган дәфтәрләрен күтәрешеп, кесә фонаре белән юлын яктыртып, кайбер төннәрне Нәркисне озаткалап та куйды.

Бүген Заһир — өр-яңа мичманкадан, энәдән-җептән чыккан суконкадан, киң матрос чалбарының үтүк эзләренә кулың киселерлек. Местком кушуы буенча ул бүген мәктәптә Җиңү бәйрәме көненә багышланган сый мәҗлесен оештыручы. Укытучылардан җыелган акчага кичә үк инде берәүдән сарык түшкәсе сатып алынган, Минҗамалларның кар базына төшерелгән. Мәсрүрә, Минҗамал, Нәсимә һәм тагын бер-ике хатын ыгы-зыгы килеп мәктәп кухнясында кайнашалар. Бу эштән бары тик өлкән класс укытучылары гына азат: Нәркис сочинениеләргә класс белән анализ ясый, Гата кабинетында электр чыбыклары белән җенләнә, консультация бара, Рушад өч-дүрт укучы белән бер класста картаны идәнгә җәйгән дә, барысы да шуна иелгәннәр, гөрләшәләр. Ял көне булганлыктан звонок бирүче юк, Бәлкыйс инде ике-өч укучы

белән мәсьәлә чишә-чишә ап-ак булып буялып беткән. Бүген агачлар яфрак ярырга җыенганнар, көн кояшлы. Һавага чыгып йөрисе иде, атнасына бер ял көне бит! Ләкин күптән түгел генә РОНОдан кәгазь килде: унынчы класс укучылары сочинениене чит мәктәпкә барып язасылар икән. Янәсе, яклашу булмасын. Бу хәбәр укучылардан бигрәк укытучыларны тетрәтте. Нәрсә бу? Ышанмаумы? Ничек инде яклашу булсын? Унынчы класс имтихан тапшырганда һәрвакытта да РОНО вәкиле була, еш кына партия райкомының бирәр инструкторы, бүлек мөдире килеп чыга. Балаларны нигә каһәрләргә? Чит авыл, чит мәктәп, ят укытучылар. Менә, мәсәлән, Ренат нишләр? Ренат юньле, юаш малай, рус әдәбиятын бик тырышып өйрәнә, шахмат ярата, кроссвордлар төзи. Соңгы вакытта, әгәр Гөлчирә арттырып сөйләмәсә, аның борыныннан кан китә икән. Әтисе Ренатка шикәр ашата да шикәр ашата... Ә бит Ренат сынауга кергәч тә ут янып кызара да бөгелә дә төшә. Мышык-мышык бер елап ала. Әнә шул вакытта куып чыгарып кара син аны, яза алмый дип. Аңа тынычланырга гына кирәк, аннан ул, шешенгән күзләрен киң итеп ачып, эшкә тотына. Чит мәктәптә моны кем аңласын! Ренат тарих фәнен дә бик ярата, Рушад белән алар тиз дуслаштылар. Рушадның киңәше белән ул инде флот турында күпме китап укыды. Һәрберсе — тарих! Степановның «Порт-Артуры» — тарих, Сергеев-Ценский, Новиков-Прибой, Леонид Соболев әсәрләре — тарих, Станюкович — үзе бер дөнья. Боларны аңа Рушад абыйсы укытты... Шундый малай сочинение яза алмыйча бөгелеп төшсә, аны кем коткарыр? Хәер, Ренат кынамы? Һәр баланың үз характеры... Кем уйлап чыгарган бу яңа законны?

Төш вакытында укучылар таралдылар. Хәкимҗан кухняга кереп инде сөяк кимереп чыкты. Мәктәп кичке бишкә кадәр тынып калды.

Кичен берәм-берәм дә, парлап та әдәп саклап кына җыелыша башладылар. Чыркылдаштылар, көлештеләр, әйтерсең болар гомер буе шулай үтә дус, бер-берсен үтә яратышып яшиләр. Әйтерсең мәктәптә мәңгелек киеренкелек, мәңге талапчән завуч, йөрәк бозгыч икеләләр, баш авыртырлык борчулы дәресләр булмаган...

Хушният карт: «Мин барыбер эчмим»,— дип акча кертмәде, мәҗлестән баш тартты — моңа берәү дә каршы килмәде. Разия Вәлиевна: «Ирем кайтып житсә, бергәләп киләбез, кайтып житмәсә — гаеп итмәгез»,— дип калды.

Өр-яңа кителенә өр-яңа погоннар тагып, күкрәгенә орден-медаль тезгән Гата килеп керде. Теле телгә йокмый, шат. Нәркис Акбалыкта моңарчы беркайчан да булмаган затлы бер хушбуй исен алып керде. Аның юка ефәк плащы ул сулаган саен калку күкрәге турысында аллы-гөлле булып төсен үзгәртеп тора иде. Керде, көзге янына басты, чәчләрен рәтләде, почмакка барып аяк киемнәрен алыштырды, аннары кулларын юды, елмаеп нур чәчте...

Рушад белән Заһир юри бергә керделәр. Икесе дә өр-яңа тельняшкадан, икесе дә өр-яңа мичманкадан, икесендә дә өчәр медаль. Алар кергәч, шау итеп бер көлделәр.

— Полундра, полундра! — дип кычкырдылар.

Футлярга салган скрипкасын тотып, кыйммәтле йон гимнастеркасы өстеннән яссы каеш буган Мостафа килде. Аның хром итекләренә карап кырынырлык, алар чыгыр-чыгыр җырлап торалар. Ике Дан ордены бар.

Хатынын кадерләп кенә, биленнән тоткан сыман сак хәрәкәт ясап, ишектә Хәкимҗан күренде. Кара син аны, мыштым! Бер ордены, өч-дүрт медале бар икән...

Аннан башкалар җыелды.

Бәлкыйс тә акбурдан чистарткач матур була икән. Әллә ниткән затлы, челтәрле якалары, хикмәтле йон кофталары бар икән. Тәки әрәм

булып калган бит вакытында кияүгә чыкмыйча. Бала итәкле яңа күлмәк кигән тол хатын Миңҗамал да бүген ярыйсы гына күренә. Башлангыч мәктәп укытучысы дип әйтеп булмыймыни?

Мәсрүрә белән Нәсимә ризык ташый башладылар. Иң соңгылар булып, дәрәҗә саклап кына Гөлчирә белән Сабир килде.

Аннан мәҗлес башланды.

Болай утырыштылар: түргә, әлбәттә, директор белән аның хатыны. Директорлар белән янәшә — парлы кешеләр — Хәкимҗан белән Былбылниса. Гата, Рушад, Мостафа бер аулакка — тәмәке тартырга шулай әйбәт була. Ирсез хатыннар, ялгызак кызлар өстәлнең бер почмагына — бергәрәк. Заһир әллә план буенча, әллә очраклы рәвештә — Нәркис янына туры килде. Нәркис башта моңа уңайсызланган сыман булды. Әллә ниткән мәгънәле караш белән Рушадка сөзеп бер керфекләрен сирпеп алды. Ләкин бераздан тынычланды — бит урталарына кинәт чыккан кызыллык аксыл таплар белән аралашты — Заһир белән алар салмак кына сөйләшә башладылар.

— Димәк, болай, иптәшләр,— дип торып басты Сабир Ишмуратович.— Рөхсәт итегез мәктәп коллективының бөек Җиңү бәйрәменә багышланган мәҗлесен башлап җибәрергә.— Барысы да кул чаптылар. Сабир Ишмуратович өр-яңа зәңгәр пиджагына таккан сыңар медале өстеннән кулын шудырып алды.— Күргәнегезчә, иптәшләр, безнең арада булган ирләрнең күбесе, күбесе сугышның башыннан ахырына кадәр илебезнең честен, намусын саклап көрәшкәннәр. И мин уйлыйм ки, бу иптәшләр бүген күңелле итеп бәйрәм итәргә бик лаеклылар дип, бик лаеклылар дип. Иптәшләр, минем бер генә тәкъдимем булыр: тәккәк мин үзем сугышта ике ай гына булып калган кеше, и шуна күрә дә мин әйтер идем, штубы бу мәҗлесне безнең арада званиесе буенча иң югары булган һәм Берлингача барып җиткән өлкән лейтенант иптәш Сәләхиев алып барсын дип. И тагын бер сүзем бар: беренче тостны мин тәкъдим итәр идем безнең Ватан сугышында җиңүләребезнең төп оештыручысы саулыгына...

Беренче тостны аягүрә торып хәл иттеләр. Аннан Гата инициативаны үз кулына алды.

— Рота! Слушай мою команду! — дип сүз башлады.— Мәҗлесне алып бару миңа тапшырылды. Безнең бурыч болай: уен-көлке, ашау-эчү, җырлау-бию. Авыр булмасмы? Үтәп булырлыкмы? Алай булса ярый. Армиядә командирның сүзе һичнинди тайпылусыз үтәлә. Минем сүз — мәҗбүри. Һәр кушканымны үтисез.

Кемдер бүлдерде:

— Әллә син кеше эшли алмаслыкны кушарсың?

— Барыбер үтәргә!

— Бөтенләй мөмкин булмаганны дамы?

— Бөтенләй мөмкин булмаган эшне кушардай кешегә командалык итү тапшырылмый. А что сез? — Гата кызды.— А как же? Менә мин шушыннан команда бирәм икән, мәсәлән, «Мостафа Асан оглы, хәзер үк пионервожатый Нәсимәне бөтен кеше карап торганда үбеп ал», дип — ул үтәргә тиеш.

Мәҗлес гөр килде. Гата аның саен кызды. Күзләрен Нәркискә юнәлтте. Нәркис нинди хәтәр сүз чыгачагын сизенеп читкә карады.

— Ә менә, мисал өчен, әйтәм икән: рус әдәбияты укытучысы фройлейн Нәркис, хәзер үк, бүген кич үк берәр егетебезгә кияүгә чыгарга ризалык бир дип — ул үтәлергә тиеш. А как же? Күпме йөрергә мөмкин егетләрнең күзен яндырып?

Гатаның телгә мондый осталыгы барын әле моңарчы берәү дә белми иде. Бу тон мәҗлескә хуш килде. Гата үзен хуҗаларча тотты.

— Ә хәзер,— диде ул,— сюрприз: барыгызга да авыз итү мәҗбүри. Фирменное блюдо — «а ля фронтовик»!

Ул Нәсимәгә күз кысты.

Нәсимә өстенә кызыл шакмаклы ашъяулык япкан бер табак китерде. Барысы да әсәрештеләр. Гата китель итәген күтәреп, чалбар каешына беркеткән солдат флягасын чишеп алды. Табакта — мичкә тәгәрәтеп пешергән бәрәнге икән.

— Менә болай, дуслар: һәркем фронт паегын авыз итә. Бу — мәҗбүри. Закускага бары тик мичтә пешкән бәрәнге. Тозга манарга рөхсәт ителә. Шуны капкач, хөрмәтле тарих укытучыбыз гитарасын ала. Нәрсә чиртәсен ул үзе белә. Җырлау — мәҗбүри...

Фляганың калай бөкесенә салып, ул спирт өләште. Су кушарга рөхсәт итмәде. Ирләр җиңелдән генә эчтеләр. Әлбәттә, бәрәнгегә кадәр өстәлдәге әллә нәрсәләрне кармалап, әллә нәрсәләр кабып бетерделәр. Хатын-кызларның күбесе эчә алмады. Әмма иң гаҗәбе — Нәркис берни дә уйламыйча йотып җибәрде — тынсыз калды, аны Заһир гына коткарды. Ул стакан белән су тотып утырган икән. Нәркис исән-сау калганны күреп, шыпырт кына Мәрүрә дә йотып җибәрде. Кырых-кырых тамак кырдылар, сүзсез генә бәрәнге ашадылар. Гата канәгать иде.

Рушадның гитара тотмаганына байтак бар иде — читенсенеп кенә кулына алды, боргалады. Башын читкә борды да чиртеп җибәрде. Алдан сөйләшеп куйган көйнең аккордын бирде. Гата баскан килеш җыр башлады. Кулында калай флягасы иде.

Бьется в тесной печурке огонь.
На поленьях смола, как слеза.
И поет мне в землянке гармонь
Про улыбку твою и глаза.

Мәҗлес бик тә җырлы булырга вәгъдә итә иде. Җыр күңелләрне әллә кая алып китте.

«А ля фронтовик» сюрпризы бик күпләргә тиз тәэсир итте. Җырның икенче куплетын Нәркис башлады. Миңҗамал, Гөлчирә, Былбылниса, Нәсимә кебекләрнең бу җырны беренче ишетүләре иде, игътибар белән тыңладылар, ара-тирә тозлы кәбестәгә, ипигә үрелделәр.

...Җыр сугышның авыр, дәһшәтле көннәрен искә төшерде. Кырык беренче елның көзе. Мәскәү янындагы хәлиткеч киеренке көннәр. Кар, салкын, землянкалар, Панфиловчылар, Зоя (ул чакта әле Таня), генерал Доватор... Ил — куркыныч астында, ил — киеренке хәлдә, халык ачуы актык чигенә җитеп тулган — менә-менә ташырга тиеш. Туган авыл, туган шәһәр, сөйгән ярлар, ата-аналар, балалар сагынылган — йөрәкне сагыш өзгәли. Моны белдерерлек сүз табып булмый, гадәттән тыш кырыс көннәрдә сагышны белдерү өчен яраклы сүз юк. Ә күңелләр илне сагыну белән, дошманга нәфрәт, сөйгәнгә мәхәббәт белән тулы. Хисләр менә-менә мөлдерәп тамарга тора. Шул вакытта бу хисләрне әйтеп бирүче, бөтен солдатлар исеменнән әйтеп бирүче бер кеше табыла. Ул — Алексей Сурков. Үзәк газетада шул көннәрдә басылып чыккан бу җыр окоп садасына әйләнде, ул җыр хисләрне ташытты, хисләр шуның белән юл алдылар, җыр фашистларны изге туфрактан кузгатып куа китте. Алексей Сурковның бу җыры Ватан сугышының иң бөек Солдатына әйләнде...

Гитара елады. Гатаның күзләре дымланды. Нечкә күңелле Мостафа урыныннан торып бер йөреп килде...

Пой, гармоника, вьюге назло,
Заплутавшее счастье зови.
Мне в холодной землянке тепло
От моей негасимой любви.

Сурковка шушы җыр өчен генә «Ватан сугышының почетлы Солдаты» дигән исем бирергә иде!

...Мәҗлесләрдә утырганда игътибар итегез: мәҗлесне иң авыр кичергән кеше — ялгыз хатын. Я ул баштан ахырга кадәр караңгы чырай белән утыра, күңел ачучылар — җырчылар, мәзәк сүз сөйләүчеләр, биючеләр — ана карап алалар да сүнеп китәләр. Мәҗлестәге ялгыз, күңелсез хатынның карашы аларны күктән җиргә тартып төшерә, әйтерсең ул үзенең шул салкын, рухсыз йөзе белән күңел ачучыларны кисәтә: әй, сез, адәм балалары, ди, нәрсәгә шатланасыз? Сезнең бит моннан таралышкач та шуны, шуны эшләсегез бар, сезнең бит иртәгә иртүк торып фәләнне, фәләнне эшләсегез бар. Нәрсәгә очынасыз!

Я ул күңел күтәрелеп киткәнлектән кинәт кенә кычкырып көлә башлый, бөтен кешедән дә уздырып җырлый, бии, көлке сүз сөйли, әйтерсең ул парлап килеп ире янында горур кыяфәт белән утырганнарга әйтергә тели: менә, ди, карагыз, ди, мин берәүдән дә ким түгел, әле сездән уздырып та җибәрәм. Ирләрегез бар дип бик әллә кем булып утырмагыз, ирегез янында сез әнә шулай басылып, боегып утырасыз, төкерәм мин сезнең тигезлегегезгә! Ха-ха-ха! Ләкин бу хәл — алдавыч. Мәҗлестә чамадан тыш күңеле күтәрелгән тол хатын мәҗлеснең ахырында, я булмаса, мәҗлеснең урта бер җирендә кинәт кенә үкереп елый башлый, бөтен дөньясын каргый, гасабилана... Ничек кенә булмасын, ялгыз хатын-кызга мәҗлестә авыр. Мәҗлестән соң ана бигрәк тә авыр. Ул үзенең уйлары белән ялгыз кала. Ә тол хатынга уйлары белән ялгыз калу — газап.

Менә мәҗлестә коточкыч контроль астында Сабир утыра. Гөлчирә карчыгадай аны саклый. Теге башка китмәсен, коридорга чыгып тегеләй-болай йөрмәсен, ди. Гөлчирәнең утыруы утыру түгел, чөнки бер төшереп алса, Сабир мәҗлестә хатын-кызлар белән бии башлый, каршысына чакырып алҗыта, өстерәп-суырып ала, чүгә-чүгә биегән вакытта кызып китеп, хатын-кызның теге төшенә дә, бу төшенә дә кул сала. Бию бит ул, кем гаеп итсен — ә менә Гөлчирә утлы күмер өстендә утыра. Гөлчирә газапта утыра. Ләкин өйләренә алар бергә култыклашып кайтып китәләр, ә тол хатын үзенең уйлары, кичерешләре белән ялгыз кала.

Тол хатынга мәҗлестән соңгы иртә бигрәк тә авыр була, аның башы чатный, кичәге мәҗлес турындагы уйлар ни өчендер анда авыр хис уята, йокыдан ул йончыгып тора. Ирле хатынның нәрсә! Йокыдан торганда аның һәрвакыт гәүдәсенең бөтен күзәнәкләренә наз, тамырларына шифалы кан тулган була, кичәге ачы-төченең авыздагы авыр тәме ире белән кара-каршы утырып бер чынаяк чәй эчүгә бетә дә китә...

Менә гадәттән тыш зур энергия сарыф итеп Былбылниса үзенең Хәкимҗанын саклый, гармунын кулына да алдырмый, чөнки бераз — бераз төшереп алса, Хәкимҗанның авызы ыргакларыннан ычкынып китә, күзләре майлана, һәм ул, гармунын күтәреп хатын-кызның авызы янына килеп, аерым-аерым җырлатып йөрергә ярата. Былбылнисаның алган белеме нибары адрес язарлык, ә монда әнә нинди белемле кызлар утыра, хәзер ирләр кадерле, ике дә уйлап тормаслар — авызыңны күтәреп калырсың. Менә шулай Былбылнисаның мәҗлестә утыруы — берәүнең җәйге эссе көндә бер смена плугарь булып йөрүенә бәрабәр. Ләкин алар да мәҗлестән бергә кайтып китәләр һәм, әлбәттә, кырып ясалган шарлы агач караватларында бер ястыкта яталар, кеше арасында нинди генә гүзәл, сылу, нечкә билле зифа кызларны, өлгергән кура җиләгедәй, тулган, дәрте ташкан яшь тол хатыннарны күрмәсен — чәчәкле ясгыкка менеп яткач, һичшиксез, Хәкимҗан үзенең өч бармакка калган көчле кулын Былбылнисаның юантык биленә салачак һәм, дың-дың китереп аркасына бәреп, бер назлап алачак. Хикмәт менә кайда!

Карт кызлар да шуңа күрә мәҗлестә кеше төсле тыныч утыра алмыйлар. Әнә Бәлкыйс — акыл иясе, белемле, әдәпле. Ләкин ни хәл итмәк кирәк? Күзләрен өметсезлеккә, бушлыкка терәгән дә ул берәзлексез нәрсәдер ашый. Ул аны белеп ашыймы? Ул үзенең нәрсә ашаганын белми — аңа нәрсәдән дә булса ачу алырга кирәк, әнә ул гомердә булмаганны шытырдатып тозлы кәбестә ашый, гомердә булмаганны сөяк кимерә! Бичара! Син менә кайсыдыр бер мәҗлестә хата ясагансың! Син, мөгаен, анда да шулай күңел ачудан читтә утыргансыңдыр, ә иптәш кызларың икы-чикы килеп утырганнардыр, егетләр белән танышканнардыр һәм, әлбәттә, бераздан кияүгә дә чыкканнардыр. Егетнең бит беренчесе белән генә танышу читен. Аннан үзеңә яраклысын тапканчы алар белән шаярырга, чут төймәсен салып барган кебек, аларны шудырып йөртергә була. Ә син беренче мәҗлестә шулай утырып карап булгансың! Синең йөзеңә инде җыерчыклар чыга башлаган, муен тирәләреңдә инде картаю билгесе күренә, сөякләр төртеп тора; мәсәлән, Нәркиснең алсу яңаклары белән чагыштырганда никадәр таушалган!

Миңҗамалның болай да әллә ни куәт иясе булмаган ми аппаратына Гата дуңгызның теге «а ля»сы шулкадәр суккан ки, Миңҗамал мәҗлеснең башында ук йөзенә бер төрле ярым мөлаем, ярым ахмак елмаю чыгарып уң яңагына таянып алган иде — шул көенчә уйнап-көлүчеләргә карап тик утыра... Аңа әллә күңелле бу мәҗлес, әллә күңелсез — ул аны әле рәтләп белми, белерлек куәте дә юк. Аның просто әле мие ял итә. Ул уянгач, Миңҗамалны нишләтер, елатырмы, көлдерерме — моны әле берәү дә белми...

Ә менә Мәсрүрәнең нишләсен белеп була. Ул Гата аккордеонында тиешле көйнең килеп чыкканын гына көтә. «Зәңгәр яулык» булды, «Катюша» булды — сугышта булган бөтенесе дә, ни хикмәттер, боларның барысын да беләләр. Ә Мәсрүрә белгән көй юк та юк. Мәсрүрәнең битләре ут булып яна, күзләрендә ачлык, аның бөтен тәненнән, чамадан тыш калку, ләкин килешле күкрәгеннән, ялангач магур беләкләреннән, хәтта юан ике толымыннан дәрт бөркеп тора, ул — әчендә ниндидер динамик көч тупланган куәтле бер җан ияседәй кысылып утыра — менә-менә ташланыр да Сабирыны да, Хәкимҗаныңны да, Рушад белән Гатаны да һәм өстәмә рәвештә Мостафа Асән оглы белән киң маңгайлы Заһирыңны да йотар кебек. Йотар да җибәрер! Калырсың шаккатып!

Ниһаять, Гата тыл көйләренә күчте.

Клавишалар арасыннан Мәсрүрә көткән көй дә ишетелде. Мәсрүрә кискен хәрәкәт ясап толымнарын артка ыргытты, инде караңгылык төшкән ишек алдына күз салды да тигез, көчле тавыш белән җыр башлады.

Сандугачым, мескенкәем,
Гөлгә салган күкәен.
Мәдинә — гөлкәем,
Гөлгә салган күкәен, бәгырькәем.

Бу җырга бары тик Гөлчирә генә кушылды, ничә әйтсәң дә, бу көй сугыш вакытында авылда иң мәшһүр көйләрдән берсе иде һәм аш мәҗлесләрендә моны бары тик Гөлчирә генә башлый иде. Дөньядагы бернинди гармунга да туры килми торган һәм бары тик шуның аркасында гына, тәҗрибәсез кешеләр тарафыннан җырчы исеме тагылган Гөлчирә бу җырга катнашып аның моңын үтерде, симез тавык итенең тәмен үг сыекчасы ничек харап итсә — монда да шулай булды. Һәм Мәсрүрә беркөнге хәлләрдән соң беренче тапкыр аңа туры итеп, текә итеп карап җырлады. «Их, син,— диде ул карашы белән,— ирең булу гына җитми сиңа, тагын җырчы даны да кирәк. Минем кай җирем ким соң синнән, нишләп сиңа тигезлек биргән бу алла, ә?» Өстәлнең ике башыннан торып алар шулай ике тавышка җырладылар.

Ул да минем күк ялгызы
Үткәрә гомеркәен.
Мәдинә — гөлкәем,
Үткәрә гомеркәен, бәгырькәем.

Мәсрүрәнең бөтен тавышы, бөтен карашы — дөньяга коточкыч үпкәләүдән гыйбарәт иде.

Тол хатыннар мәҗлестә биергә чыксалар — дөнья күчерәләр. Әнә матур итеп бөтерелеп Нәсимә бии — кыз бала, аның бөтенесе алда. Әнә әдәп, дәрәҗә саклап кына, горур кыяфәттә Гөлчирә бии — бер сүз дә әйтә алмыйсың. Ә менә Миңҗамалны торагаш хәленнән кузгатып биергә чыгарганнар иде — дөньялар купты. Директор берәзлексез моржага карап утырды, ауса нишләрсең? Миңҗамал идәннән бөтен үчен алды: үзен мәңгегә ирсез калдырган фашистларны таптады, берәзлексез «мал курмысы» хакында сөйләп, вакланып үзәгенә үтә торган каенатасы белән каенанасын да салып изде, берәзлексез үзгәреп тора торган укыту программаларын да таптап йөрде — Шәмсетдинов белән инспектор Хәкимовның да эчләренә типте, барысы да булды...

Тол хатыннар биергә чыкса — сак булыгыз, якын-тирәдә ава, ватыла торган әйбер калдырмагыз...

«А ля» Нәркисне дә харап итте бугай, башта ул мәһабәт кенә биеде — озын матур бармаклар, тән төсле юка оек киеп куйган килешле аяклар, ап-ак ачык муены — барысы да Нәркиснең гүзәллеген төрле яктан тутыра иде. Әйтерсең бу — кеше түгел, ә җәйге матур иртәдә урман аланындагы коедан су эчәргә чыккан болан — иртәнге кояшка, чыклы үләнгә, кошлар тавышына, ниһаять, үзенең сылу гәүдәсенә үзе сокланып юыртып йөри иде... Биеде-биеде дә Нәркис урынына утырып кинәт кенә көлә башлады, урыныннан сикереп торды, кулына рюмка алды.

— Иптәшләр! Егетләр... Фронтовиклар! Әйдәгез, сезнең исәнлеккә эчик! Мин сезнең исәнлек өчен барысын да эшләргә риза! Беләсезме — нәрсә? Мин авылга килгәндә бер генә елга дип килгән идем. Һәм әгәр авылда сезнең кебек гүзәл егетләр бар дип бер ел элек кем дә булса сөйләсә, мин ул кешене ахмакка санаган булыр идем. Мин никадәр ялгышканмын! — Нәркис башын артка ташлап көлә башлады.— Җаннарым! Мин сезнең барыгызны да 'яратам! Ватан сугышында җиңеп чыгуыбызның сәбәбен мин менә сезнең белән аралаша башлагач кына аңладым. Сезне җиңә алмый фашист, җиңә алмый! Сезнең йөрәгегез якты, күңелегез пакь! Әй, син, разведчик! — Нәркис тагын көлә башлады.— Мин синең мәҗлес башында әйткән сүзеңне үтәргә әзер! Мин барысына да әзер бүген!

Тосттан соң Гата җай белән генә вальс уйнап җибәрде — бер кат җилләнеп, тәмәке тартып керделәр.

...Ата улны, ана кызны белмәс дәрәҗәдә шаулашып-көлешеп утыра башлагач кына Мостафа скрипкасын кулына алды. Өздереп-өздереп кенә «Зөлхиҗҗә»не уйнады. Көйнең нечкә моңы кешеләрне моңландырды, уен-көлке басылды.

— Мостафа абый, җырла!

— Үзегезчә җырла! — дип, Мостафаның скрипкасын алып куйдылар. Мостафа башта ялындырды. Дөресрәге, үзеннән курыкты. Җырлый башласа, ул бары тик үз кайгысын сөйли торган җырларны гына җырлый — ә аның кайгысы — иксез-чиксез... Бу авылда Мостафаныкы кадәр кайгы бирәүдә дә юк. Бу авылда сөекле хатынын, алмадай ике кызын югалткан башка берәү дә юк. Яшәсен иде алар, алар гомерен саклау өчен Мостафа мең тапкыр үләр иде. Иң авыры — билгесезлек. Газеталарда язылган хәбәрләргә караганда чит дәүләтләрдә фашистлар алып киткән гражданнар әле дә булса яши. Кайларда сез, күз нурларым? Сез мине ишетәсезме?

Кайдадыр еракта томанлы пәрдә артыннан аның хатыны — куе кара кашлы, кара тутлы, тулы беләкле Эльмас карап тора, ул саран гына елмая: «Син безне онытмадыңмы?» дип сорый. Менә сугыш беткәннән бирле инде Мостафа һәр төнне аның белән сөйләшә, тегесе һаман бер төрле итеп саран гына елмая. Кайбер төнне Эльмас шәфкатьсез була.

— Син безнең кайларга барып чыкканны беләсеңме? Теплушкада барганда кече кызыбыз салкын тиеп авырып үлде,— ди.— Аны бер станциядә вагоннан ташлап калдырдылар...

Мостафа бу вакытта саташа, үкереп елап уяна, торып утыра һәм тәмәкесен кабызып чоланга чыга. Иртәгесен шешмәкләнгән күзләрен кешедән яшереп, ул мәктәпкә китә, дәрескә керә һәм дөньяда иң бәхетле кеше сыман дәртләнеп сөйли башлый.

— Көн саен бер алма ашаган кешегә докторның кирәге юк,— ди.— Килер бер көн,— ди,— дәүләтләр арасында ярышып ашкынып кораллану урынына алма үстерү, алманың яңа сортларын чыгару буенча ярыш башланыр. Җир йөзендә хәрби самолетлар түгел, алма чәчәге очар...

...Мостафа онытылып киткән икән. Гитараның муеныннан тоткан көе, ул бераз дәшмичә торды. Күз алдына еракта-еракта калган бала чагы килде. Аларның авылында бала чактан сукырайган Хәлил карт бар иде. Хәлил карт туйдан туйга, йорттан йортка йөри һәм җырлап тамак туйдыра иде. Картның эчкә баткан, кипкән күзләре, ак сакалы, эре тешләре, кояшта янган эре яңак сөякләре — барысы да аңа куркыныч төс бирәләр иде. Сакля кырындагы учак янында кечкенә Мостафа бу картның гыйшык җырларын берничә тапкыр тыңлаган һәм йөрәгенә сеңдергән иде. Ул үзен шул карт ролендә итеп күрде. Кешеләр аннан җыр көтә...

Ул, гитараны алай-болай чиртكәләп, төрле көйләрдән берәр, икешәр куплет җырлады.

Әллә көй елады, әллә Мостафа...

Җаным сәйранга чыккан — сыгыла таллар кеби.
Суырып үпсәм иреннәре шикәр һәм баллар кеби.
Кочагына кереп чумсаң — кош йоны шәлләр кеби.
«Кит, бу гүзәлдән аерыл» димә, дус!
«Җан сөйгән гүзәлдән аерыл» димә, дус!

Муеныма ташлар тактырып дәрьяларга агаем!
Ярым исемә төшкән саен акылымнан язаем!
Кәбаб булып гыйшык утында янаем, дус, янаем!
«Кит, бу гүзәлне ташла» димә, дус!
«Җан сөйгән гүзәлдән аерыл» димә, дус!

Бераздан Мостафа әйләнә-тирәсендәге кешеләрне онытты. Кара елтыр күзләрен бушлыкка текәде дә, мәһабәт гәүдәсен көйгә генә чайкалдырып, йөрәк белән җырлады:

Ахшам олса мән өемдә ятарым.
Түрлү-түрлү фикерләргә даларым.
Көннән-көнгә дәрдемә дәрт катарым.
    Бер оңалмас дәртка төштем, агъларым!

Бармагыма көмеш йөзек тагарым.
Кичен көндез яр юлына багарым.
Бәгыремне гыйшык утында ягарым,
    Бер оңалмас дәртка төштем, агъларым!

Җыр вакытында Нәркис һәм Заһир берөзлексез нәрсәдер кызыпкызып бәхәсләштеләр. Сабир берничә мәртәбә дәү сәгатенә карап алды — күрәсең, мәҗлесне тәмамларга вакыт җитәдер. Гата белән Рушад форточка янында тәмәке тарттылар. Мостафа дымлы күзләрен

уйнатып барысына да бер караш ташлады да гитараны бер почмакка илтеп куйды. Аннары чэй килде.

Мәҗлестә Гата философ булырга ярата.

Ул соңгы тостны әйтте. Теле телгә йокмый, кайнарланып сөйли.

— Иптәшләр, мин шушы Җиңүне тәэмин иткән бөек халкыбыз исәнлегенә тост тәкъдим итәм. Яшәсен Тугызынчы май! Кырык бишенче елның Тугызынчы маенда мин рейхстаг стенасына фамилиямне язып куйдым. Штык очы белән тырнап яздым. «Разведчик Гата Сәләхиев» дип имзамны куйдым. Тарихта минем эзем калды. Европа үзәгендәге бу язу озак торыр, безнең балаларыбыз аны экскурсия белән Германиягә баргач укырлар. Европа илләренә бер вакыт без кунак булып барырбыз, безнең бу җиңүнең әһәмияте тарих картайган саен арта барыр. Мин үземнең туган көнемне кырык бишенче елның тугызынчы мае дип исәплим. Без — кырык бишенче ел егетләре! Яшәсен кырык бишенче ел егетләре!

Шулай да иң соңгы тост Рушадныкы булды. Хисләрдән шактый дулкынланып, мәҗлестәгеләргә ул Юлиус Фучик сүзләрен әйтте.

— Ватан азатлыгы өчен һәлак булган иптәшләрнең якты истәлегенә тост тәкъдим итәм,— диде ул, мәҗлестәгеләргә күтәрелеп карамыйча гына.— Беләсезме, Чехословакиянең милли герое Фучик ничек дигән? «Бу заманны үткәреп, дөньяда исән калган кешеләрдән мин бер генә нәрсә сорыйм: онытмагыз! Яхшыларны да, явызларны да онытмагыз!

...Шундый бер көн килер, ул чакта бүгенге көн үткән көн булып саналыр. Шунда бөек заман һәм тарихны тудыручы исемсез геройлар турында сөйләрләр... Бу көрәштә һәлак булган кешеләр сезгә дусларыгыз, туганнарыгыз шикелле якын булсын... Киләчәккә турылыклы булып шул киләчәкнең чиксез матурлыгы өчен үлгән кешеләрнең һәрберсе һәйкәлгә лаек».

Бу сүзләрне Миңҗамал аягүрә торып тыңлады. Аның бите буйлап берөзлексез яшь агып торды.

...Искиткеч җылы төн, урамга шомырт агачы исе тулган иде... Саф һавага чыккач, иркен сулап куйдылар. Һәркем үз ягына таралды. Тик ирләр генә мәктәп капка төбендә сөйләшеп калдылар. Таралысы килми иде, җилкәне җилкәгә терәп, фронттагыча дөнья ваклыкларыннан азат булып, үзеңне ир итеп, егет итеп сизәсе, шуны тоясы килә иде. Шуны аңлапмы, Гөлчирәгә хәтле Сабирны калдырып кайтып китте. Хәер, Мәсрүрәне кунарга дип үзенә Миңҗамал алып киткәнне күргәч кенә андый юмарт карарга килә алды Гөлчирә. Хәкимҗанның бик тәмләп сөйләшеп торасы килгән иде — урамның теге ягына чыгып баскан Былбылниса: «Әйдә, әйдә, озак йөрелде» дип тукып торгач, чыдый алмады — бирелде. Ничә әйтсәң дә, фронтта дошман белән сугышу — бер нәрсә, ә үз хатының белән бәхәскә керү — бөтенләй икенче. Заһир урамга чыгуга шактый кыю рәвештә Нәркисне култыклап алды. Рушадның моңа бераз гына эче пошып китте. Үзе дә сизмәстән, Заһир белән Нәркискә кесә фонарен юнәлтте. Нәркиснең зур күзләре тагы да зураеп киткән сыман күренде. Фонарьдан төшкән нурга аның алсу яңагында кунып калган яшь бөртекләре ялтырап алды. Нәрсә булган бу кызыйга? Нигә каушаган ул? Нигә бу Заһир гадәттән тыш кыю тота үзен? Нәрсә турында сөйләшкәннәр болар? Ләкин Рушад шунда ук үзен-үзе «печән өстендәге эт» дип эчтән генә тиргәп салды. Заһир исә Нәркисне бөтенләй кире якка — тегермән буасы ягына алып китте.

Бераздан директор белән Мостафа аерылып киттеләр. Мостафа борыннарын киңәйтеп иркен итеп бер сулыш алды да:

— Бүген үк караватымны шомырт бакчасына чыгарам,— диде.— Мондый төндә өйдә йоклау — җинаять. Кеше агач яфрагы, чәчәк, үлән исен иснәп елына утыз гына көн йокласа — аңа докторның бөтенләй кирәге юк.

## XVII

Авыл тын иде, утлар күренмәде. Тик бу төн тынгысыз булды. Мәҗлестә катнашкан кешеләрнең күбесе йоклый алмады.

Төн җиле иң башта Сабирга кагылды. Матур хатын-кызлар белән мәҗлестә утырганнан соң кайсы гына ирнең күңеле иләс-миләс килми? Алай түгел дисәләр, ышанмагыз, рыяланып кына әйткән сүз ул. Нигә бу дөньяда шундый кырыс канун нар бар соң? Әйтик, нигә менә Миңҗамал бөтен кеше алдында Мәсрүрәне үзенә кунарга алып кайтып китте, нигә менә Заһир бөтен кеше күз алдында Нәркисне култыклап тегермән буасына китә алды? Нигә Сабирның мондый хокукы юк? Нигә?

Бу сорауга җавапны урам үзе бирде.

Чирәмле тыкрыктан яшь бер егет белән кыз килеп чыкты. Алгебрадан булачак язма эш турында кызып-кызып бәхәсләшәләр иде. Соңгы вакытта унынчы класс укучылары кичләрен әле берсенә, әле икенчесенә җыелып шулай хәзерләнәләр. Ләкин бу егет алгебрадан хәзерләнүдән тыш башка исәпләр белән дә йөридер, ахрысы, чөнки кызны култыклап ук алган. Директор моны белергә тиеш — монысы бераз гына рамкадан тышрак иде, ул тукталды. Тукталды... Һәм тынсыз калды. Җиңен сызганып ак күлмәк кигән буйчан егет — директорның улы Ренат иде. Ничек? Ни арада? Ренат кыз култыклаганмы? Райком секретаренең кызынмы? Туктале, ничә яшь соң боларга? Унҗидеме? Унсигезенчеме? Кем гаеп итә ала...

Сабир шул минутта гына үзенең инде олы кеше, карт кеше икәнлеген аңлады. Сүзсез генә Мостафа белән бергә кайтты, башын иеп өенә керде, чишенеп ятты. Караватта Сабирның бердәнбере — иң ышанычлысы, картайса да, чирләсә дә, авыр хәлгә төшсә дә аның белән бергә барысын да уртаклашырга әзер торган бердәнбере — Гөлчирә ята иде. Сабир аның ябык кулын үзенең учына алды, йомшак кына кысты. Гөлчирә исә моннан шуны аңлады:

— Мин соңгы бер-ике елда бераз гына тегенди-мондый юлда йөрдем. Инде мин үземнең ялгышлыгымны һәм сиңа күпме хәсрәт чиктергәнемне аңладым. Моннан соң мин синең турылыклы юлдашың булырмын. Безнең балаларыбыз үсеп бара икән. Булдыра алсаң, син мине гафу ит...

Урамда Гата белән Рушад кына калдылар.

Гата бүген йокламаска карар итте, чөнки мәҗлескә килер алдыннан гына аңа почтадан заказ хат бирделәр. Эльзадан икән. Май ахырына командование аны җибәрергә булган, һәм Эльза көннәрне санап торырга кушкан иде.

Рушад үз хисләрендә үзе буталды. Кичәге концерттан соң ул үзенең уйларына контрольне югалткан иде. Моңарчы ямьсез булып күренгән Акбалык аңа дөньяның иң гүзәл бер почмагына әйләнде. Рушадка дөньяның башка бер почмагы да кирәкми хәзер — бары тик Акбалык булсын да әнә шул йорттагы Ләйләгөл булсын! Башка берни дә кирәкми! Менә нәрсә өчен дөньяга туарга кирәк булган, менә нәрсә өчен яшьли үлем белән очрашырга, сугыш газапларын кичәргә кирәк булган икән! Яшәүнең мәгънәсе менә хәзер генә ачыла башлады. Кызык! Дөньяның бөтен матурлыгы, бөтен мәгънәсе унҗиде яшьлек бер кызда булсын, имеш! Нигә алай ул? Рушад Кенигсберг өлкәсендә диңгез буендагы курортларны күрде. Сугыш вакытында монда фашистлар ял иткәннәр, безнең кырларда алган яраларыннан дәваланганнар, өшегән аяк-кулларын савыктырганнар. Ләкин фашист ял иткәндә дә фашист булып кала. Рушадлар дивизионы бәреп кергән курортта әле тормыш бара иде — каштан агачлары астында чумып утырган корпуста берничә дистә яшь, сылу кыз дер калтырап аларны каршы алдылар. Барысы

да яшь, барысы да зифа буйлы, зәңгәр күзле, аксыл-сары чәчле, аксыл битле сылулар — фашист офицерларының яраткан арий нәселе. «Кара болыт» — матрослар, флот офицерлары чорнап алгач, бу кызлар үлемнән котылуның бердәнбер «чарасына» керештеләр, десантчыларның муенына асылынып, аларны кочаклый, үбә башладылар, бүлмәләренә чакырдылар. Аларның күбесе шортиктан иде. Ялангач матур аякларын ялтыратып мәрмәр баскычлардан йөгерештеләр, ялварулы елмайдылар. Сугыш башланганнан бирле хатын-кыз заты белән аралашмаган матрослар өчен бу — шактый хикмәтле күренеш иде, үлем белән күрәшеп йөргәндә мондый спектакльгә эләгермен дип кем уйлаган! Ләкин шунда бөтен кеше бер нәрсәгә берьюлы игътибар итте: чибәр кызларның ботларына — тездән югарырак эчке ягына, аксыл-алсу яшь тирегә зәңгәр татуировка төшерелгән иде.

— Яле, галим кеше! — дип чакырды шул вакытта карт мичман Рушадны.— Укып бир безгә, нәрсә дип язылган бу сөйрәлчекләрнең сыйракларына?

Моны уку артык авыр түгел иде.

Иң чибәрләренә — «f.of.», уртачаларына — «f. s.» дип язылган.

— Болары,— диде Рушад, елмаеп торган гүзәлләрне күрсәтеп.— «Фюр официерен» — офицер сөяркәләре, ә тегеләре — «Фюр зольдатен» — солдатлар өчен.

Карт мичман әшәке сүз әйтеп читкә төкерде.

Рушадка шул вакытта бик авыр булды. Яшь, чибәр кызларны кызгану тойгысы уянды. Боларның ата-аналары бардыр... Болар да балаларын моның өчен дип үстермәгәннәрдер. Әллә фашистлар морале өчен гадәти хәлме бу? Кайда монда мәхәббәт, кайда монда изге хисләр? Болар бит «арий каны»! Димәк, «югары раса»ның үз эчендә үк инде фахишлек, үз нигезендә үк инде салкын исәп, хатын-кыз матурлыгын фашистларча оятсызлык белән эшкә файдалану бар... Әйе, фашизм — яралылар төягән корабльне диңгез төбенә җибәрү генә түгел, музейларны, китапханәләрне яндыру гына түгел, чит халыкларны методик рәвештә яндырып, «Бөек Германия» туфрагына ашлама хәзерләү генә түгел, бәлки хатын-кыз гүзәллеген дә изү, таптау, Гётеләр, Шиллерләр, Гейнеләр ода җырлаган гүзәл немкаларны да пычрак фашист итеге астына салып таптау икән. Кенигсбергның һәр почмагындагы фашист эзе тарих факультеты студенты Рушадка бөтен бер курс биргәндәй белем бирде. Фашистлар курортының мәрмәр ташларына басып йөргәндә, санаторийның ап-ак чиста врач кабинетларында, процедура бүлмәләрендә йөргәндә бөтен нәрсә «монда фашистлар яшәде» дип кычкырып тора иде. Менә холлдагы фотовитрина. Дөньядагы иң гүзәл хатыннар. Фәлән хатын фәлән елда фәлән шәһәрдә матурлык конкурсында беренче урынны алган. Яше фәлән, авырлыгы — шулкадәр, биленең нечкәлеге фәлән сантиметр... Менә ул хатын профильдә болай. Менә ул аягына оек кия. Менә ул йокыга ятар алдыннан чишенә. Үзе елмая, мутланып карый... Боларның барысыннан да фашизм исе килә иде...

Рушад белән Гата урамда озак йөрделәр. Рушад Гатаны сиздермәстән генә Разия Вәлиевналар яши торган урамга алып керде. Өйләре турысыннан гына булса да бер узасы иде! Рушад алда торган перспективаны күз алдына китерде: тагын ун көннән Ләйләгөл имтихан бирергә күрше районга китәчәк. Ул кайтканчы Рушад җәйге сессиягә киткән булачак. Димәк, җәй буе бер тапкыр да күрешеп булмаячак. Егетнең җаны өшеп китте. Ә алдагы ук көндә? Берничек тә булмый. Киртәләр — егет атлап чыга торган түгел. Педагоглыкның кырыс, формаль, кәҗүнни кагыйдәләре бар. Син аңа буйсынырга мәҗбүрсең. Бусы бер. Икенчедән, син инде яшькә олы. Аерма бар. Өченчедән, син — коммунист кеше. Ләйләгөл әле ничә әйтсәң дә бала. Әтисе белсә? Әнисе белсә? Ерып чыга алмаслык кыенлыклар! Гатага киңәш итеп карарга

иде. Ана да йөрәк житми. Менә кайчаннан бирле инде алар урам буйлап киләп сарып йөриләр, ә Рушад үзенең иң яшерен хисен ачарга курка.

Шомырт чәчәк ата башлаган, ахры, Разия Вәлиевналар урамында шомырт исе шактый сизелерлек...

Тыкрыктан болар каршына мыдыр-мыдыр сөйләшеп бер пар килеп чыкты.

— Әһә, Тихоокеанец бу тирәдә йөзә икән,— дип сүз салды Рушад. Ул аларны Нәркис белән Заһир дип белгән иде. Карасалар — ире белән Разия Вәлиевна икән. Гимнастеркасын яссы каеш белән буган, шыгырдавыклы хром итекләр кигән Даутов егетләргә кул бирде.

— Ишеттем, ишеттем мәктәптә нәрсәләр оештырып йөргәнегезне,— диде ул, папиросын чыгарып.— Разия апагыз бик мактый үзегезне. Фронтовиклар да фронтовиклар дип теленнән төшерми. Әле мин көнләшмәскәме икән дип уйлап йөрим: тик торганда хатының егетләрне мактый башласын әле. Житмәсә, сезнең кебекләрне. Мин бит фронттан кырык өчтә үк кайткан кеше...

Даутов көләч елмаеп инициативаны шундук үз кулына алды.

— Кайсы участоктан?

Гата тураеп куйды. Хәрбиләр гадәте!

— Беренче Украинскийдан! Берлинда тәмамладык.

— Ә син инде теге «Кара болыт» буласыңмы? Шундый бер егет бар дигәннәр иде мәктәптә.

Рушадның сабый баладай кызарганын төн генә яшерде. Нинди мөлаем, нинди властьлы кеше бу Даутов! (Ә син аның бердәнбер кызын кочакладың түгелме соң кичә? Ничек оят түгел!)

— Так точно! Кенигсбергта Җиңү көнен бәйрәм иттек. Ленинград — Таллин — Клайпеда — Кенигсберг.

— Ә мин Дугадан,— диде Даутов, авыр сулап.— Дугадан. Җиңү көнен Берлинда күрү бәхетенә ирешә алмадым. Сугыш — зур бәхетсезлек, ләкин мин шунда катнашканыма һич тә үкенмим. Дөресен әйтим, безнең халыкның бөтен психологиясен, рухи байлыгын, кешенең эчке дөньясын мин әнә шул Курск янында аңладым. Шул мәктәпне узмаган булсам, мин, әлбәттә, партия работнигы булып китмидер идем. Сугышка кадәр мин дә укытучы идем, сезнең кебек...

Разия Вәлиевна башына ак йон шарф сыман нәрсә салган, ай яктысында ул шарф аңа әллә ниткән затлы төс бирә иде. Ул ире сөйләгәндә аны култыклап тотып торә, вакыт-вакыт аңа сокланыпмы, шатланыпмы карап ала.

— Әтисе,— дип, сүзгә катышты ул.— Әллә мин кереп самовар куйыйммы?

Даутов җанланып китте.

— Менә! Менә! Авызымнан алып әйттең! Беләсезме, тормышта ничек була? Бергә яши торгач шул кадәр бер-береңә иләшәсең, бер үк ситуацияләрдә икенә дә бер үк төрле фикерләр килә һәм шуны бер үк вакытта, бер үк төрле сүзләр белән әйтә башлыйсың. Туктагыз, сез әле банкеттандыр? Мин соң кайттым, Разия апагыз миңа әйткән иде. Аннан соң, минем дәрәҗәм бик зур бит. Я, әйт инде, авыл укытучысы райком секретаре янында җырлап-биеп күңел ача аламы?

Разия Вәлиевна инде өйләренә кереп киткән иде.

Даутовлар кара-каршы салынган ике йортның урам ягында торалар икән. Өй алдыннан төшкән яктылыкта сап-сары итеп юылган баскычлар күренде. Инде алдына алъяпкыч ябып кухарка булырга өлгергән Разия Вәлиевна кунакларны гөрләп каршы алды, аякларыннан салмаска бик кыстаса да, егетләр оекбаштан гына калдылар. Өй алдында, урындык өстендәге керогазда нәрсәдер чыжылдап утыра иде. Ике йорт уртасындагы кечкенә бүлмәнең ишеге ачык, аңа марля элен-

гән. Даутовлар ягына узганчы Рушад башта шунда күз ташлады. Булмә эчендәге яктылыкта ян белән баскан, кулларын баш түбәсенә күтәрә-күтәрә чәчләрен сүтеп торган кыз баланың шәүләсе күренде. Балет декорациясе артындагы томаннан күренгән сыман бу сылу гәүдә — Ләйләгөл иде. Рушадның йөрәге тибүдән тамагы кипте. Тик моны берәү дә сизмәде...

Даутов өйгә килеп кергәч каешын салды, якаларын ычкындырды. Разия Вәлиевна керогаз белән ике арада йөгергәләгән арада ирләрчә сүз куерды.

— Син дөрес әйтәсең, егет,— диде Даутов, Гатаның сүзенә кушылып.— Бу җиңүнең зурлыгын, әһәмиятен киләчәк буын тагы да ныграк, тирәнрәк аңлар. Әйе. Яхшы полотно ерактанрак карасаң ачык күренә, диләр бит. Сез менә икегез дә бу бөек вакыйганың җанлы шаһитлары. Шуның бөеклеген яшь буынга җиткерегез, яшьләрне шушы бөек җиңү, изге көрәш традицияләрендә тәрбияләгез. Сезнең төп бурыч — шул.

— Ә йөз процент өлгереш бирү төп бурыч түгелмени? — Рушад бу йортта иркенләп сөйләшә алмаячагын сизде — тавышы өзгәләнә иде. Даутов аңа сынаулы караш ташлады.

— Йөз процентмы? Йөз процент диген, ә? Кызык бит. Миңа сөйләделәр аны. Өченче чиректә күп мәктәпләр йөз процент өлгереш биргәннәр икән. Ләкин ни файда? Мин Шәмсетдинов белән сөйләштем. Өлгереш ничек? дим. Йөз процентлылар күпчелек, ди. Ә узган уку елында ничек иде? Туксан ике ярым, ди. Соң балаларның белемнәре конкрет алганда күтәрелдеме? Әллә узган елдагычамы? Анысын әйтә алмыйм, ди...

— Алайса, менә тагын нәрсәне ачыкласагыз икән. Класс җитәкчеләре арасында ярыш оештырылган. Предметниклар арасында ярыш. Кем күбрәк процент бирә... Минемчә, анысы да гадел түгел.

Даутов тагын бер сынаулы итеп Рушадка карады.

— Я, син, туганкай, нигә дип бәйләндең әле? Мине әллә Педагогия Фәннәре Академиясенең член-корреспонденты дип белдеңме? Миңа калса — дөрес тә, дөрес тә түгел. Әлбәттә, югары өлгереш бирү өчен көрәш — төп бурыч. Ләкин ярыш гадел түгел бит. Әйтик, синең менә бу физикны узасың килә икән — тотасың да барысына да унай билге куясың. Ә классыңда элеккечә Изге Рим империясен Тын океаннан эзләүче бер-ике ташбаш утыра...

— Укыту программалары тормыш таләпләреннән шактый артта калган,— диде Гата.

— Укыту программалары гынамы? Һай, егетләр, үзегездәге беркатлылыкка сокланып туймассың! Авыл хуҗалыгы — менә кайда хәзер төп фронт. Ярый, сезнең бу авыл сугыш вакытында да арыш оныннан өзелмәгән. Ә башка колхозлар? Ә колхозчыга түләү мәсьәләсе? Ә колхозларның ссудалары? Колхозларны ныгыту өчен кимендә ун-унбиш ел кирәк булачак, белдегезме?

Даутов шкафтан бер шешә алып килде.

— Мин бүген ике җыелышта шушы турыда сөйләгән кеше — аз гына ял итик.

Ул иплән кенә дүрт рюмкага салды.

— Әнисе! Кил утыр тизрәк! Җиңү бәйрәме белән! Разияның сездәй фронтовиклар арасында эшләвенә мин бик шат. Бәйрәм белән!

Егетләр, без кунакта булдык дигән сылтау белән, авыз итеп кенә куйдылар.

Даутов ял итә алмады. Ул янадан зур темага кереп китте.

— Район аппаратларында кадрлар искергән. Сугыш вакыты методы белән эш итәргә яраталар. Миңа монда терәк кирәк, сездәй яшь коммунистлардан ярдәм кирәк. Менә карап карыйк — көзгә, бәлки, кайберегезгә мәктәп белән саубуллашырга туры килмәгәе.

— Мәктәп хатын-кызларга гына калсынмы? — диде Гата.

— Юк, алай дип әйтмим. Шулай да мәктәптә хәзергә күбрәк хатын-кызлар эшли ала.

— Мин сезнең белән бәхәсләшә алам,— диде Рушад. Даутов әсәрде:

— Тыңлап карыйк.

— Укытучылык эше күбрәк хатын-кыз эше дип карау нигездә хата. Ни өчен дисезме?

— Әйе, дим.

— Мин күреп торам — ир балаларда егетлек, ирлек сыйфатлары тәрбияләр өчен укытучыларның күпчелеге ирләр булуы кирәк. Менә сез безнең военрукны алып карагыз. Белеме дә килде-китте генә, ә никадәр эш алып бара. Бөтен малай хәрби эшкә гашыйк.

— Я инде военрукка тимик, анысы ир була бирсен.

— Ярый, менә физикны алыйк. Кыз бала — никадәр генә яхшы укытучы булмасын, менә Гата эшләгәнне эшли аламы? Ә бит, беләсезме, хәзер ничек женләнделәр? МТСтан әллә ниткән иске моторлар, движоклар ташып, бөтен мәктәпне механика цехына әйләндерделәр бит инде. Ә электр белән женләнү? Аннан соң әле укытучының дөнья күргән булуы, разведчик булуы — үзе генә дә ни тора!

— Соң, бөтен физикларны да разведчиклардан куйыйкмыни инде? Аңа разведчик каян житкерәсең?

— Юк, мин алай дип әйтмим. Миңа калса, хатын-кыз әдәбият укытырга тиеш. Анда, «Бедная Лиза»лар, Татьяналар, Галиябанулар — романтизм, сентиментализм, күз яшьләре...

— Ай-һай, кызык караш. Әдәбият — күз яшьләре... Ә «Ана» романы? Ә «Тимер ташкын»? Алардан да шулай конфет тәме генә киләме?

— Алай димим мин. Юк, әдәбият — шулай да, хис дигән сүз. Хисне хатын-кызларга бирик.

— Ярый, килештек, ди. Хатын-кызга тагын ниләр бирәбез? — Даутов хатынына карап хәйләкәр елмайды. Рушад Разия Вәлиевнаның үзенә дусларча карап торганын сизде. Кыюланып китте.

— Ну инде, биологияне бирергә мөмкин анда. Дафнияләр, актинияләр, попугайлар турында сөйләсен. Аннан, әлбәттә, башлангыч классларда хатын-кыз булсын. Тагын. Тагын, әлбәттә, телләр өйрәнү...

— Ә бит монда дөреслек бар, егетләр,— диде Даутов, бәхәсне йомгаклагандай.— Балаларда ирлек, егетлек сыйфатларын тәрбияләү — белем бирү белән бер дәрәҗәдәге бурыч. Хәер, безгә инде моңа мисал эзләп торасы юк. Сугышта барысы да күренде. Командир үзе егет булса, солдатны батырлыкка өндәүнең кирәге юк...

Бераздан өй алдына тәмәке тартырга чыктылар. Ләйләгөл әле ятмаган иде. Аның ут яктысында укып утырганы марля пәрдә аркылы күренә иде.

Ирләр мыдыр-мыдыр сөйләштеләр. Рушад сүзгә әллә катнашты, әллә катнашмады. Ул бары тик йөрәге дөпелдәгәнне генә сизде. Әлбәттә, Ләйләгөл дә укымый иде. Хәрефләр күз алдыннан йөгерәләр, юллар йөгерәләр, күз берни дә аермый... Ике арада нибары метр ярым... Ике арада нибары бер кат марля.

Саубуллашкан чакта Разия Вәлиевна искиткеч самимилек белән егетләргә кул бирде.

— Менә, әтисе, минем коллегаларның кем икәнен күрдең инде. Аларның сиңа ошавына мин бик шат,— дип горурланып иренә карады.

Болар — пар килгәннәр. Кайвакытта ир белән хатынга карыйсың да табигатьнең рәхимсез шаяруын күреп гаҗәпкә каласың. Шәп кенә бер хатын була — буе, килеш-килбәте дисеңме, сөйләшүе дисеңме — бар ягы килгән. Карыйсың — шуның янында өч тиенгә тормастай бер әү — алама, сүзенең рәте юк, әдәпсез — моның ире. Киресе дә була: шәп егет — тот та министр ит, тот та сәхнәгә чыгар, эшкә булган, үткен,

чибәр, мөлаем. Батыр. Йөрәкле. Бөтен учреждениене кулында тота, авторитеты зур. Карыйсың — хатыны бер тиенгә дә торгысыз кеше.

Даутовлар пар килгәннәр...

Урамда инде таң яктысы беленә башлаган иде. Дөньяданиндидер бер кош бар — сандугачка охшатып сайрарга тырыша. Бакчада шул сайрый иде. Сандугач сайрый башларга да инде күп калмады. Төннәр жылынганны көтә ул. Ә хәзергә әле ниндидер бер «халтурщик» тырыша. Талант иясе читтә торганда сәхнә бервакытта да буш булмый...

Урамнар тын, елга өстеннән аксыл томан күтәрелеп бакча киртәләренә сырышкан; күктән, бик ерактан, әллә нигә мен чакрым биеклектән килгәндәй торналар тавышы ишетелә иде. Шушы дымлы җирне кочакла да сузыл да ят! Рәхәт, сулышка иркен, кан уйный, сикерәсе, шул торналар янына күк гөмбәзенә менәсе килә.

Дөньяда тугызынчы мәй төне кадәр гүзәл төн булмас!

Дөньяда шушы аксыл томанлы су буйлары, юеш коймалы урамнары, әле генә аерылышкан мөлаем Даутовлары, китабына иелгән таң кызы Ләйләгөлләре булган авыл кебек бүтән бер генә авыл да булмас!

Бер генә патшалыкта да унынчы майның әкияттәгедәй аксыл тын таңында галәм киңлегеннән торналарның сихри тавышы ишетелмәс!

Бу төн — мәңгегә истә калыр!

Бу төн — фронтовиклар төне!

Бу төн... бу төндә фронтовик Заһир өенә кыз төшерде. Биленнән сак кына тотып, ул Нәркисне үзләренең бусагасыннан атлатты. Шуннан соң ничектер җинел сулап мичманкасын салды. Мангаендагы тирен сөртте. Хан кызыдай киленне Заһирның кулыннан карт-карчык икәүләп кабул иттеләр. Әйтерсең бу — затлы көмеш подноска куелган бер өстәллек фарфор чынаяклар өеме иде...

## XIX

Көтелмәгән никах иртәгесен укытучылар булмәсен гадәттән тыш хәлгә куйган иде. Никахны һәркем үзенчә кабул итте. Директор югары белемле рус теле укытучысының мәктәптә төпләнүенә шатланды. Принцессаның урнаша торуына Гөлчирә дә сөенде. Әйдә, гел аңа гына чибәрләнеп йөрисе түгел, менә безнең кебек хуҗалык алып барсын, бала үстерсен, диде. Нәсимә үзенең идеалы булган Нәркиснең гап-гади бүрәнәле йортка килен булып төшүенә күңеленнән бик рәнжеде. Нәркисне ул киләчәктә бары тик шәһәрнең зур, якты сарайларында, көяз өрәңгеләр тезелгән паркларда, дөньяңны оныттыра торган театр залларында гына итеп күз алдына китерә ала иде. Тапкан калыр урын! Юк, Нәсимә булып Нәсимә бу авылда кияүгә чыгып калмаячак! Аның ире чибәр, кара куе кашлы, йомшак карашлы, таза беләкле укыган бер яшь егет булыр! Бәлки, саргылт чәчле, зәңгәр күзле булыр? Алай да ярый. Тик Заһир кебек басынкы гына булмасын. Үзеннән яшьлек дәрте ташып торсын!

Төн йокламаган Нәркисне берәм-берәм бары да тәбрикләделәр. Һәрберсе елмайды. Үзәк өзгеч эчкәртен сагыш белән аны Бәлкыйс тә тәбрикләде. Менә бит! Бәлкыйс монда аннан алдарак килгән иде... Ә Нәркиснең килгәненә нибары алты-җиде ай. Карточкаң бер аста күмелеп калса, аны беркем эзләп алмый инде. Әнә Хәкимҗан авызын ерып сөйли бит.

— Кызларның,— ди,— үз гомерендә өч чоры була. Унҗидедән егермегә кадәр — сайлау чоры. Егермедән егерме дүрткә кадәр — өмет итү чоры. Егерме дүртнең теге ягы — «аллага тапшырдым» чоры.

Бәлкыйс — соңгысында...

Минҗамал тиз елый, ансат елый. Бичара... Нәркисне котлады да, мич артына барып, тиз-тиз генә яшь коеп килде. Һай, ул кияүгә чыккан

көннәрнең шатлыгы! Тормышның бер генә атнасы да кияүгә чыккан кызның шул беренче көннәре кадәр күңелле, ләззәтле була алмый! Миңжамал нибары әнә шул бер атнаны күреп калды. Аның ире — юаш кына, тонык кына Хәйбрие — утыз сигезенче елда хәрби хезмәткә алынды. Акыллы, әдәпле егет иде. Туйдан соң нәкъ бер атнадан. Аннан Фин кампаниясе башланды. Хәйбри башта Ерак Көнчыгышка киткән иде. Шуннан фин сугышына килеп һәлак булды. Хәйбридән калган нибары өч истәлек бар бу дөньяда. Берсе — нәкъ Хәйбринең үзе төсле аксыл чәчле, йомшак борынлы малае. Миңжамал хәзер шуның өчен генә яши. Икенчесе — ишек алдында Хәйбри утыртып калдырган каен. Яшь әле, бик назлы чагы. Акрын искән җилдән дә чайкала, сыгыла. Вак кына якты-яшел яфракларын кыштырдатып шаулаган була, әйтерсең Хәйбридән соңгы сәлам сөйли. Миңжамал ул каенны кичләрен кочаклап тора, аңа аркасын терәп тора, каен кәүсәсе җилгә тирбәлеп Миңжамалның таза, бәхетсез тәнен иркәли...

Өченчесе — Хәйбринең хаты. Өчпочмаклап конвертланган, шәмәхә кара белән язган. Нәкъ Хәйбринең үзе төсле, юаш, акыллы адрес. «Палучит: Шаймуллиной Минзамалу» дип язган. Ул хатны Миңжамал ВКП(б) тарихының «Кыскача курсы» эчендә саклый. Кышкы озын кичләрдә шул китапны конспектлап утырганда һәрвакыт хатны бер кат укып чыга. Бигрәк тә тарих китабының дүртенче бүлеген өйрәнгәндә. Анда диалектик һәм тарихи материализм турында сүз бара. Ул бүлек авыр... Ләкин Миңжамал андагы кайбер фикерләр белән килешми. Мәсәлән, анда «һәр әйбер агышта, үзгәрештә» диелгән. Ә менә Миңжамалның фронтта һәлак булган иренә карата хисләре агышта да түгел, үзгәрештә дә түгел. Нәкъ элеккечә.

«Ашау якларына килсәк — ярый. Зәнәтиеләр авыр. Ну мин инде шунысына сөенәм, сугышка монда бераз ачысын-төчесен күреп баруы лутчы. Анда инде Гарифлар, Гаптулар туп-туры фин сугышына киткәннәрдер. Аларга авыр булыр сугышка барып керүе. Без киткәч авылда нилэр сөйләделәр соң, халык гаеп итмәдеме? Яшьләр арасында ниләр бар, кылуплар ачыламы, аулагөйләр буламы? Аннан соң мин пихотта түгел, танковыйда. Суыклар илле биш градуска җитә, җылы тун, яхшы итек бирделәр. Әти-әни белән дус яшәргә кара...»

Миңжамал бу хатны күңелдән белә.

Заһир белән Хәйбри яшьтәшләр иде...

«Заһирдан хат алам, ул япун границасында икән, аларда да тыныч түгел инде, бакчага кәҗәләр кергәләп тора бит...»

Миңжамал авыр көнгә калды. Кайнана бик усал булып чыкты — киленнең канын эчте. Киленнең һич кенә дә укытучы икәнлегенә ташлама ясамады, мәктәптә озак торасың дип каһәрләде, кичләрен план төзергә утыргач, крәчин маен күп тотасың дип йөрәген бозды, утынны аз керттеләр дип бәйләнде. Ләкин егерменче число көнне Миңжамалның акчасын тиенгә-тиен санап үз кулына алып баруны гадәт итте — башкасына бөгелгәч, килен монысына да каршы килмәде. Карчыкка акча гына булсын! Хет мәктәпкә бер дә барма, план төзмә, читтән торып укыма, белемеңне күтәрмә. Карчыкның аларында эше юк. Киленне ул кичләрен үзе белән бергә колхоз басуына чөгендер, бәрәңге урларга алып йөрде. Бервакыт тотылдылар. Укытучы, бригада агитаторы Миңжамал, капчык төбенә салган чөгендерләрен күтәреп колхоз председателе Гыйлаҗ абзый каршында басып торды. Председательгә дә читен булды. Әмма Миңжамалның шул вакытта йөрәгенә кан сауды, карчыкка карата йөрәгендә бер генә дә җылы хис калмады. «Әти-әни белән дус яшәргә кара...» Их син, мәңгегә югалган Хәйбрием! Син белсәң иде минем никадәр яраргa тырышканымны! Булмаса булмый икән...

Миңжамал шулай югары белемгә җитә алмады, читтән торып чакчак кына Казан педучилищесын тәмамлады. Дүртенче класста геогра-

фия дәресендә ул Ерак Көнчыгыш һәм Ленинград тирәсе турында сөйләргә ярата, бу урыннарны төртеп күрсәткәндә күрсәткеч таягының икенче башыннан Хәйбри тоткан сыман була. Ул һәрвакыт «Финляндия» дип сөйли, аны әйткәндә «Хәйбри» дигәндәге күк йөрәктән әйтә. Дөньяда аның өчен иң кирәк, иң кадерле кеше үлгәч, калган барлык сүзләр, барлык күренешләр бик кечкенә, бик әһәмиятсез булып күренсәләр гаҗәпмени?

Ишек яңагына элгән сөлгегә күзләрен сөртеп, ул дәрескә кереп китте. Кавышкан кешеләр бәхетле булсыннар, һәркемгә тигез яшәргә насыйп итсен! Дөньяның бөтен яме, тәме — тигезлектә.

Мәктәп уку елын йомгакларга әзерләнде...

Яз иртә килде, инде урам чатларындагы каеннар суларына бүртеп авырайдылар, узган елгы яраларын яңадан кызгылт сироп каплап, кояшта әчеп утыралар. Инде беләкләренә чиләк элгән ике егет өйдән өйгә кереп мал исәбен алып йөрделәр. Гатаның боларны күреп йөрәге сулкылдап куйды. Яшьлек! Йөрисең, йөрисең, ә чиләккә гадәт буенча йомырка салалар, янәсе, малларым бөтен йөрсен дип көтүчегә ишарә ясыйлар. Гражданский киемгә күчкәч болай да үзен картайган сыман сизеп йөргән Гата тиктомалга авыр балалык елларын сагына башлады.

Язгы кыр эшләре уңае белән авылга кино килгәли башлады. Ватан сугышы турындагы фильмнарны Рушад берничә мәртәбә укучылар белән аерым карады. Унынчы классларда инде тоташтан консультацияләр китте. Буй җиткән кызлар тартылып, ябыгып калдылар, егетләрнең дә муеннарын йон басты, күлмәк якалары бушады. Алар арасындагы элеккеге ыбыр-чыбыр шаярулар бетте, барысы да җитдиләнделәр. Инде мәктәп бакчасындагы чирәмлектә унынчы классның бер кызы белән бер егете бәхәсләшеп берәр теорема исбат итеп утыралар икән — бу гадәти хәлгә әйләнде, моңа берәү дә гаҗәпләнмәс булды. Унынчылар төркем-төркем булып тегермән буасы янындагы тугайга да бардылар, бакча башына җыелышып та хәзерләнделәр, аларның зур сынау алдында торганнарын бөтен авыл белә иде. Яшьлекнең чәчәк аткан чагы — унынчы классны тәмамлаган көннәр! Әгәр җаваплы имтиханнар булмаса, бу көннәрдә егетләр, кызлар яшьлек хыяллары белән шашып күкләргә ашарлар иде! Егетлекнең иң югары, иң саф хисләре нәкъ шул язда уяна. Беләктә куәт — көрәшәсе, күтәрәсе, йөгерәсе, аударасы, очасы килә. Күңел әллә кайларга өстери, Тын океанда дулкыннар ярып кораблар йөртерсең, алтын погонлы, төз гәүдәле офицер булып берничә елдан шушы авылга кунакка кайтырсың күк тоела, күкнең нәкъ шушы турысыннан коточкыч бомбардировщикны үкертеп, көмеш канатын селкеп авылга, сабакташ кызларга сәлам биреп узарсың күк тоела. Егетләрдәге мондый хисләр ташкынын бу көннәрдә сабакташ кызлар да сизенә, аның саен аларда бу чандыр егетләргә карата өр-яңа хисләр — егетлекне ихтирам итү, егетлекнең кырыс язмышына соклану хисләре туа бара. Инде бу көннәрдә егетләрнең кесәләрендә папирос күренгәли, инде кесә төпләрендә үзләренең биш-ун тәңкә акчалары була, инде алар кызларның чәченнән тартып, кулларын борып азапламыйлар, әллә ничек кенә, җайсызланып кына кызларның беләгеннән тотып сөйләшеп баралар, кызлар исә беләкләрен тартып алмыйлар, киресенчә, шушы ун ел буе аның белән сугышып, аның дәфтәреннән мәсьәләләр күчереп, аның карасына каләм манып эгоистларча гомер кичергән, кул аркасын сөял баскан шушы егетнең яшелле-күкле тавышын тыңлап баруы кыз балага күңелле була башлый, егетнең соңгы атналарда гына сабын күрә башлаган кулы беләгенә кагылгач, кыз бала калтыранып ала — шулай да рәхәт, әйтеп булмый торган рәхәт...

Кырыс чырайлы укытучылар, тимәгез аларга бу вакытта, аларның шәхесләрен рәнжетмәгез! Алар күңеленең бик тә сизгер, бик тә нечкә чагы. Аларны олы кеше дип белегез. Тәмәке тарткан өчен дә ачуланмагыз, ул аны болай гына, егетлеккә күчеш чорында гына эшләп карый. Бераздан, тыючы булмаса, ул аны үзе ташлый... Аларны ихтирам итегез, бу — егетләрнең иң романтикалы, иң бәхетле көннәре. Әлбәттә, аларның барысы да хәрби училищега керә алмас, барысы да океаннарда йөзмәс. Шулай да кагылмагыз сез аларның рухларына, тимәгез!

Майның икенче яртысында кичен бик соң гына караңгы төшә, кино башланганда әле клубның тәрәзәләрендә пәрдә тарталар. Рушад клубка сеанс башланыр алдыннан гына керде. Урта рәтләрне тутырып унынчы класс укучылары утыра иде. Рушадның күзләре Ләйләгөлнең тирән, сагышлы карашы белән очрашып алды. Тагын ике көн, өч көн калды! Аннан Ләйләгөл имтиханга китә, ул кайтканчы Рушад сессиягә чыгып китәчәк! Аннан җәй буе очраша алмассың. Кая ул җәй буе гына. Гомергә... Тик бер генә сүз әйтергә иде. Бер генә... «Син мине онытмассыңмы? Кай якларга таралышсак та, син мине онытмассыңмы?..»

Шуны гына белергә иде.

Кино лентасы чырылдый-чырылдый әйләнә, залдагы яктылык көлтәсендә тузан болыты көмеш тузаны сыман кайный иде. Фильмның эчтәлеген Рушад аңламады. Ул күзләрен йомды. Менә аннан өч эскәмия алда Ләйләгөл утыра. Бар да эндәш! Әйдә, киттек, урамга чыгыйк диген. Юк, булмый. Алгы рәттә күзлеген борын очына элэктергән Хушият утыра. Ул карт әллә нигә генә Рушадка дәшмичә йөри. Әнә клубның бер читендә малайлар утыра. Әскәревнең егетләрчә мырылдап сөйләшкәне ишетелә. Чүкеч-көрәк тамгалы значок таккан фуражкасын башыннан салмыйча горурланып утырган берсе — Закиров. Шимбә саен кайтып йөри башлады. Берәүгә дә үпкәсе юк кебек. Әллә каян кычкырып исәнләшә.

— Рушад абый, исәнмесе-е-е-з!

Ләйләгөл алар почмагыннан да прицелга алынган булса кирәк. Шулай газапланып утыра торгач, сеансның яртысы бетте. Механик тегене-моны алмаштырып көйләгәнче, гадәттә, ирләр ишек янагына сөялеп, аякның берсен клуб эченнән алмыйча гына көйрәтеп торалар. Кыз-кыркын да бер кузгалышып ала. Шул ыгы-зыгы арасында Рушад урта рәттән бер ак кофтаның кузгалганын күрде. Ак кофта ян ишеккә юнәлде. Рушадның тамак төбе чатнады. Ак кофта — Ләйләгөл булырга тиеш. Әгәр ул кыз да Рушад кебек газапланса, һичшиксез, бу шул — булырга тиеш. Башкача мөмкин түгел. Рәхмәт төшсен, яңгынга каршы көрәш кагыйдәләрен төзүчеләргә! Клубның арткы ишеге дә ачык икән. Рушад арткы ишектән генә урамга чыкты. Тып-тын. Дөньяны алма чәчәге исе баскан. Өйләрдә ут сүнгән. Сукмаклар ярылгалап кипкәннәр, шулай да әле язгы дым сеңдереп калган җир баскан саен сыгыла. Аяк тавышы ишетелми. Кем булды соң ул ак кофта?

Клуб коймасы буйлап олы урамга таба барган ак кофта, әлбәттә, Ләйләгөл иде. Димәк, киноны ташлап кайтырга чыккан. Рушад кызу-кызу аның артыннан китте. Тик бер генә җөмлә әйтергә иде. Тик бер генә... Ул, сүзсез генә, Ләйләгөлнең кайнар бармакларын учына алды. Тегесе берни дә әйтмичә Рушадның кулын кысты. Бу — яратып исәнләшү иде. Аннан Ләйләгөл кинәт кенә тыкрыкка борылды да җиңел-җиңел генә атлап йөгерде. Рушад та аның кулын кысып торткан көе йөгерде. Менә тилеләр, клубта кино бара, ә син урамда йөгереп йөр!

Алар авыл башына барып чыктылар. Мондагы чирәмлектә кайчандыр йортлар булган, кешеләрнең баз урыннары, өй асты чокырлары бар. Киртәсез бәрәңге бакчасының башында хуҗасыз калган шомырт шау чәчәккә күмелгән. Аның тирәсендә чирәмлек. Рушад кызны шунда

алып китте. Чыклы чирәмгә пиджагын салып җәйде, кызны янына утыртты да биленнән кочты. Әле им өчен бер сүз әйтелмәгән иде. Кинәт килгән бу бәхетле минуттан икесе дә телсез калдылар. Бары тик бер-берсенең йөрәкләре типкәнне генә ишетәләр, тигезсез сулаганнарын сизәләр иде. Кыз кайнар яңагын Рушадның иягенә терәде. Сүзне ул башлады. Ярым пышылдаган тавыштан Рушад барысын да ишетеп тә, аңлап та бетерә алмады.

— Рушад абый... Рушад абый! Мин исән-сау имтиханнарымны биреп чыксам, институтка китәм. Кораблестроительныйга. Быел керә алмасам — киләсе елга. Мин моны сезне беренче тапкыр күргәч тә уйлап куйдым. Мин хәрби кораблар төзүче конструктор булам. Мин үзем төзегән беренче корабка әчемнән генә сезнең исемне бирәм...

Ләйләгөл бу юлы да елый иде.

Рушад аны юатырга дөньядагы иң матур, иң затлы сүзне эзләде. Кызганычка каршы, таба алмады һәм... әйтергә өлгермәде. Урам башында лапор-лопыр йөгерешкән тавышлар ишетелде. Ләйләгөл кинәт кенә чирәмгә егылды. Рушад алдына моңарчы бервакытта да башына килмәгән бер мәсьәлә килеп басты. Нишләргә? Кыз курка дип егет тә чирәмгә сузылып ятарга тиешме? Ул кыз синең курыкканыңны белсә нәрсә уйлар? Син хәзер күкрәгеңне киереп басып торырга тиеш түгелме соң? Юк, акыллы булсаң, сузыл да ят. Моның белән син Ләйләгөлне яман сүздән коткарырсың. Аның хакына җиргә сең. Аның өчен кирәк икән — үрмәлә, шуыш... Ул капланып ятты. Борынга җир исе, язгы үлән исе бөркелде. Җир шарының йөрәге тибә. Әллә ул планетаның теге ягындагы берәр гигант завод эшләгәнне тапшырамы? Юк, ул Ләйләгөлнең гәүдәсе дерелдәве икән. Урам башында аяк тавышлары тынды. Кесә фонареның нәзек ут көлтәсе җимерек караltыларны ялады, шомырт чәчәкләренә кереп чыкты.

— Бу якка китмәсләр алар...

— Юк инде, китсәләр шушында гына.

Тавышның берсе Әскәревнеке.

Кинәт кенә ызан буйлап кемнеңдер монда таба чапканы ишетелде. Аның нәрсәседер чылтыр-чылтыр килә иде. Ләйләгөл җан ачысы белән Рушадның беләген чеметеп тотты. Рушад күзләрен чытырдатып йомды. Бары да бетте! Язмыш аннан шушы ике минутлык бәхетне күпсенде. Кил, юньсез, кил, хәзер син каршында тарих укытучысын түгел, ә фронтовикны күрерсең. Теге нәрсә болар янына килде. Рушад күзен ачмады. Килгән кешенең авыр-авыр сулаганын ишетте. Ләйләгөл тынсыз калды.

— Ыр-р-р-р...

Тфү, мәлгунь! Эт икән...

— Вау!

Рушадның аркасына тир бәрде. Шул секундта урам башыннан тавыш ишетелде:

— Дамка! Дамка! Сюда!

Муенындагы богжрасын чылтыратып, эт, эре-эре сикергәләп, урамга таба чапты. Рушад торып утырды. Малайлар фонарь белән күкне яктырта-яктырта кайтып киттеләр. Тавышлар ерагайды, ул арада клуб янында гармун кычкырттылар, сеанс беткән булырга тиеш иде.

Ләйләгөл сикереп торды, җитез генә кагынды да кофтасын рәтләде.

— Рушад абый, миңа бер минутка да калырга ярамый, мин йөгердем...

Ул бакча башыннан гына авылга элдертте. Рушад торды, тәмәкесен чыгарды. Хәзер ник шунда аңа каршы ун эт белән чыкмыйлар! Барыбер хәзер. Ләйләгөл инде күздән югалды. Бер очрашу, никадәр газап — һәм авызны ачып бер генә сүз дә әйтелмәгән.

Гаделсез дөнья! Шәфкатьсез язмыш...

Авыл урамына кергәч, ул тәмәке кабызды. Кинодан чыккан кешеләр төркеме белән очрашканчы, ул Мостафалар капкасы янына килеп туктады. Шомырт бакчасында — скрипка тавышы. Димәк, картлач моңлана. Капка төбендә яшел чирәм, бу урам тыныч. Рушад чирәмгә капланып ятты да җирне кочаклады.

Күптән күрелмәгән күз яшьләре бугазга — ни өчендер күзгә түгел — тамак төбенә бөялделәр...

Ул таң беленгәндә генә уянып китте, бөтен гәүдәсе дерелди иде. Аны әкияттәгедәй сихри дөнья көтә иде.

Мостафалар бакчасы белән Даутовлар йорты уртак койма бүлеп тора. Мостафаның скрипкасы инде тынган, үләннәргә куе чык төшкән. Бөтен дөньяны дымлы, салмак шомырт чәчәге исе баскан. Бакчада — йөз инструментлы оркестрдай сандугач тавышы. Бу тавышны үз гомерендә бер ишетергә кирәк. Ул синең бөтен тормышыңны сөйләп бирер, бөтен хисләреңне кузгатыр. Бакчада нибары бер кошчык сайрый. Аның кеп-кечкенә тамак төбеннән бөтен авыл өстен дерелдәтеп моң тарала. Бу — кош сайравы гына түгел, бу — гашыйкларның үзләре әйтеп бирә алмаган хисләреннән авазга әйләнгән куәте, аһәңе. Сандугач үзенең шул нәни тамагыннан чыккан куәтле музыканы ярып-ярып, катлау-катлау итеп авыл өстенә тарата, әйтерсең лә монда бармак башы кадәрле бер соры кошчык сайрамый, ә оста дирижер җитәкчелегендәге куәтле оркестр җиз трубалардан бөтен планета халыклары өчен уртак булган сагыш көен уйный: бер тыңласаң — бу көйнең гаммасына, бер генә сулыш сонга калып, тагын дистәләгән трубаларның көмеш чыңы өстәлә, икенче тыңласаң — бу көй йөз орга́нлы собор тавышына әйләнә...

Бу дөньяның мондый таңнары да була икән! Рушад музыкага әсәрләнеп, койма буена үрелде — музыка тынды. Чын сәнгать тупас рәвештә тыкшынуны бервакытта да гафу итми. Шулай, киндер биләй белән тоткач, күбәләк үлә. Төлке бүген генә дөньяга килгән җелтер күзле, мамык туп кебек балаларын, аның оясына кулын тыгып кеше тотып караса — имезми. Сәнгатьнең мондый камил әсәренә кешенең кагылуы ук гафу ителми. Яшь кыз, беренче тапкыр егет белән ялгыз калгач, ул егеттән бары тик назлы сүз, нәзакәтле хәрәкәт кенә өмет итә. Шул беренче очрашуда ук тупас, алама хәрәкәт белән аның дәрт тулган күкрәгенә үрелүне ул кичерә алмый — чын күңелдән рәнҗи...

Сихри оркестр тынып калды.

Рушад койма буеннан китте. Әнә бакча эчендә нәрсәдер шыгырдады. Пөткергән тавыш ишетелде. Димәк, Мостафа да бу моңны тыңлаган. Ул да йокламый. Ни булды соң әле бу халыкка?

Мостафаның авыз эченнән генә шыңшыганы ишетелде.

Төн уртасы җиткәч бер кыз елый, Зәлхиҗәәә...
Яшь гомерем заяга үтә-ә-ә-ә ди-и-п.

Ә бу вакытта бер кыз, чыннан да, мендәрен тешләп елый иде. Бу елау рәхәт тә, газаплы да, сагышлы да, шатлыклы да иде. Кыз баланың нәрсәдән елаганын кем белсен?

Мартның кояшлы көнендә кар тавы өстенә чыгып баскан бала каз шулай кинәт кенә кычкыра башлый. Шатлыктанмы ул? Кайгыданмы? Ул әле аңламый, тик әллә каян гына, түбәдән тамган тамчы суын борыны белән актарынгалап яткан тәҗрибәле ана казларның серле тавышы ишетелә, теге, узган ел җәйдә бибиләрне чукыштыргалап йөргән күк ата казның коңгылдавы яңгырап ала, март җиле томшыкны кытыклый, тамакка килеп керә һәм... кычкырып аласы килә. Нигә икән ул? Бала каз моны инстинкт белән генә эшлиме?

Ләйләгөл дә ник елаганын белми иде...

## XX

Авыл тып-тын. Тал песи чыгарган. Иртәнге кояш жылысына уянган умарта кортлары талны сырып алганнар. Шул тавыш кына дөньяда тереклек барын белдереп зыңгылдап ишетелә. Нибары ике сәгать йоклаган Рушад иртүк торды. Баш чатный, күз төбеннән маңгайны кимерә, авыз тәмсез, йөрәк кага. Нәрсә бу? Авыру башымы?

Ул сөлгесен, сабынын алды да бакча башына төшеп китте. Мунча буйларын яшь кычыткан баскан. Мунча нигезе инде иртәнге кояшта жылынып өлгергән, иске стена, иске мүк исенә жылы кычыткан исе кушылган. Монда да бөжәкләр, чебеннәр гөж килә, тереклек дөньясы кайный. Әйтерсең берни дә булмаган! Әйтерсең бу тереклек дөньясы үзенең бер егетен кичә кич шәфкатьсез рәвештә җәзаламаган!

Салкын су, зарядка үзенекен итте. Рушадның кәефе бераз күтәрелде. Әле барысы да югалмаган. Әле ул бүген көне буе мәктәптә булачак. Шунда тагын бер генә тапкыр булса да ул Ләйләгөлне күрәчәк. Нәрсә дә булса, нинди дә булса бер җылы сүз әйтәчәк...

Рушад кайтып кергәндә баскычта яткан почтаны күрде, кичәге, өченче көнге газеталарны берни дә булмагандай хат ташучы бөтенесен өя дә иртән кемнең ишек артына, кемнең баскычына ыргытып йөри. Баскычка утырып иртәнге һавада газет уку шулай да рәхәт, бик рәхәт. Менә конверт та бар икән. Университеттан җәйге сессиягә чакыру кәгазе. Әйе, бу — айныта торган кәгазь. Бу — сине күктә очкан жиреңнән тиз тартып төшерер. Тормыш — объектив күренеш. Ул сытык романтикларны яратмый.

Чолан түбәсеннән пырылдап кузгалып пар күгәрчен очып китте. Рушадның кулындагы кәгазьгә бәләкәй генә бер каурый килеп төште. Салават күперенең барлык төсләре дә кергән диярсең. Кызык! Бу каурый күгәрченнең кай җирендә була икән? Түшендәме? Мөгаен.

Рушад урыныннан торды. Миләүшә төсендәге каурыйны чакыру кәгазенең эченә куеп конвертка салды. Әйдә бер истәлек булсын әле. Университетны тәмамлап чыккач ул аны диплом катыргысы эченә салып саклар. «Бу күгәрчен каурые мең тугыз йөз фәләненче елда, фәләненче май иртәсендә минем кулымдагы чакыру кәгазенә килеп төшкән иде. Акбалык авылында тарих укытучысы булып эшләгәндә... Галиәхмәт картларның баскыч төбендә утырганда». Кызык бит!

...Мәктәпнең класс тәрәзәләре төбенә кадәр ачык. Унынчы класс укучылары бүген иң яхшы киемнәрен кигәннәр. Инде звоноклар юк, иртәгә имтиханнар башлана. Бүген кич районнан йөк машинасы килеп укучыларны төяп егерме чакрым ераклыктагы икенче мәктәпкә алып китәсе икән. Унынчылар ул мәктәптә сочинение генә язалар да, шуның нәтиҗәсен белгәч, монда кайталар. Димәк, дүрт-биш көнгә баралар. Ул мәктәпнең унынчылары бүген Акбалыкка киләләр икән. Мәгариф Министрлыгының күрсәтмәсе шундый. Рушад өчен тарихтан имтиханны директор үзе алачак. Бер мәктәптә бер фәннән ике предметник булу начар түгел.

Рушад бүген алтынчы класс белән бакчада эшләргә тиеш иде, балаларны җыеп шунда чыгып китте. Монда инде әллә кайчаннан бирле гөрләп, җырлап, дулап, йөгергәләп, Мостафа эшләп йөри иде, балаларны ул шау итеп каршы алды.

— Менә хәзер көрәкләр, тырмалар алып килегез, дусларым,— дип, ул малайларны утын лапасына җибәрде.— Алмагачларның төбен йомшартабыз. Көзгә искиткеч уңыш алачакбыз. Һәр кешегә көненә бер алма. Шуны ашаган кешегә докторның бөтенләй кирәге юк.

Була дөньяда оптимист кешеләр!

Мәктәп бакчасының рәшәткә буйларында — сиреньнәр, акацияләр. Анда унынчылар төркем-төркем булып утырганнар да сочинение тема-

ларын күнелдән сөйлиләр. Горькийның «Ана» романы, Чеховның «Футлярдагы кеше», Островскийның «Корыч ничек чыныкты» әсәрләре булмый калмас, диләр. Бөтенесе шуларны укый.

Рушад ике малай белән акацияләр арасындагы коеның механизмын рәтләргә китте. Пиджагын салып ташлады да коеның насосын актара башлады. Әскәрев, тагын бер малай, майга буялып, чын күнелдән ана ярдәм иттеләр. Дингезгә чыгасы тральщикны ремонтлыйлармыни! Эш күп кенә уйларны баштан куды. Ләкин тынычлык килмәде. Кайдадыр, кайсыдыр агач төбендә Ләйләгөл дә сочинение темасын өйрәнә иде. Бүген ул, һичшиксез, ялгыз утырырга тиеш иде. Әйе, әйе, төркем белән бергә утырырга аның хакы юк. Чөнки бу — актык көн. Рушад моны йөрәге белән сизде. Ләйләгөл менә шушы тирәдә генә булырга тиеш, башкача мөмкин түгел.

Рушад, кирәктәнме, кирәкмәгәннәнме, Гата янына кереп, аның шкафындагы швед ачкычын сорамакчы булды. Майлы кулларын пычкы чүбенә сөртә-сөртә, ул мәктәпкә таба китте. Малайлар болт-гайкаларны керосинда юа калдылар. Акацияләр арасыннан барганда Рушадның йөрәге дөп-дөп типте. Менә-менә, шушы тирәдә генә Ләйләгөл утырырга тиеш. Менә, менә... Кешедә алдан сизү юк, диләр. Рушад — бу кагыйдәгә буйсынмый. Ул сизә ала. Гашыйклар һәр вакыт сизә алалар.

Сары чәчәккә чумган карт акация төбендә китапка иелеп утырган Ләйләгөлне күргәч, Рушадның тыны кысылды. Ни гаҗәп! Дингездә вакытта ул ничә тапкыр фашист авиациясенең уты астында калган иде. Дингезнең кургаш суын миллиард бөртеккә әйләндереп, кара сыртын шәфкатьсез рәвештә елтыратып килгән үлем машинасы — торпеданы күргән иде. Берсендә дә шулай тыны кысылмаган иде. Дөрес, һәр очракта да курку була иде. Ләкин анда һәр чак синең янында иптәшең — терәгең була. Ә монда? Монда иптәш, терәк нәкъ менә кирәк түгел. Киресенчә, Рушад хәзер ялгызлыкка мохтаҗ...

Ләйләгөл күтәрелеп карады. Утырып калырга да, басарга да белмәде. Өстендә нәкъ Рушад беренче тапкыр күргәндәге кофта — акка ике тиенлек акча зурлыгындагы кара таңкә төшкән кофта иде. Шул кофта гына Рушадның тынычлыгын алды... Барысы да шуннан башланды.

Рушад юри кычкырып сүз башлады. Югыйсә, ул борчылганын сиздерәчәк иде.

— Укыйбызмы?

Ләйләгөл аны гүя ишетмәде.

Хәер, бу сүзләрнең нәрсә өчен әйтелгәнен Рушад үзе дә белмәде. Төп максат, ахрысы, бер генә минут булса да туктап тору иде.

Рушад чалбар кесәсеннән кинәт кенә бүгенге хатны тартып чыгарды. Ачты.

— Менә сез генә түгел, мин дә укырга китәм. Соңгы көннәрем...

Ләйләгөл торып басты, Рушад янына килеп конвертны кулына алды. Чакыру кәгазе эченнән кауры́й килеп чыкты. Рушад тавышын акрынайтты.

— Беләсеңме, нәрсә? Синең халык әкиятләреңдә укыганың бармы? Анда менә шундый хикмәтле кауры́й турында сөйләнә. Син моны ал. Имтиханга кергәндә үзең белән алып кер.

— Шпаргалка урынынамы?

Ләйләгөл беренче тапкыр Рушадка кешеләрчә тыныч эндәште. Елмайды.

— Әйе, талисман урынына. Аннан соң, болай килешик. (Рушад як-ягына каранды. Оялып куйды. Ничә көннәр инде ул каракларча яши!) Кайда гына булсак та, никадәр ерак китсәк тә, паролебез шушы булсын. Әгәр син миңа кайчан да булса «мин синеке» дип әйтергә карар

итсәң, конверт эченә тыгып миңа шушы каурыйны сал. Ә мин көтәрмен. Биш ел, ун ел, унбиш ел... Бүтән сүз кирәкми — каурыйны гына сал.

Ләйләгөл кып-кызыл булды, түбән карады. Йөрәге турысында кофтасы лепердәп тора иде. Рушад соңгы хәрәкәтен ясады: каурыйны Ләйләгөлнең кофта якасыннан сизелеп торган күкрәк уентыгына салды.

— Менә шунда сакла... Мин аның шунда сакланганын белеп яшәрмен...

Ләйләгөлнең кайнар тәне аның кул аркасын пешерде.

— Хуш, Ләйләгөл! Мин сиңа уңыш телим. Мин сине мәңге онытмам... Мәңге...

Рушад, сүзләре бутала башлавын сизеп, кызу-кызу мәктәпкә таба китте. Кулына дәреслек тоткан Ләйләгөл карт акация төбендә басып калды.

Гата консультация уздырып ята иде. Эшнең нәрсәдә икәнен сизенмәде. Ачкычын алып коридорга чыгарып биргәч кенә:

— Син, малай, нәрсә, әллә кичә миннән башка аракы чөмердеңме? Кулларың дерелди,— дип, бәйләнеп маташты.

Төштән соң машиналар килде. Балаларын озатырга дип ата-аналар җыелды. Алар арасында Разия Вәлиевна да бар иде. Рушад мәктәп тәрәзәсеннән машиналарны озатып калды.

Дөньяны бушлык басты.

Дөнья дигән инструментның ниндидер бик кирәкле, бик әһәмиятле бер кылы өзелде. Күк йөзен болыт каплагандай итте, бөҗәкләр тынды, караңгы төшкән сыман булды, каяндыр салкынча җил исте.

Бушлык, салкынлык, мәгънәсезлек...

Нишләргә? Тукта, дөньяда Гата бар. Гата — хәрәкәт кешесе. Тукта, нигә соң әле Рушад аның белән аралашмый башлады?

— Һо-о, туганкай, мин сине көткән идем,— дип каршы алды аны Гата ишек алдында.— Өйгә уз да рәхим итеп минем шатлыгымны уртаклаш. Телеграмма! «Выезжаю первого июня!» Бу вакыйганы билгеләп үтсәк дим, ә? Ну! Нәрсә борыныңны салындырдың? Фронтовик! Син мине ташласаң, гел шулай булачаксың! Ташлама, дустым!

Бер сәгатьтән Гата инде аккордеонын тарткалап өстәл артында җырлап утыра иде.

> Кто сказал, что надо бросить
> Песни на войне?
> После боя сердце просит
> Музыки вдвойне.

Дөрес әйткән шагыйрь! Дөрес сайлап җырлый Гата! Рушад өчен бу нәкъ менә «сугыштан соңгы» сәгатьләр.

...Китәсе көнне Рушад авыл белән саубуллашып йөрде. Инде җәй башланган иде. Инде мәктәп тоткынлыгыннан котылган кечкенә балалар дөньяларын онытып су керәләр, чыр-чу килеп уен уйныйлар. Бер төрлеләре (көзге сынауга калганнары) китап-дәфтәр тотып шушы эссе көндә мәктәпкә барган булалар. Юк инде! Буласы булса — кыш көне. Укуның иң ләззәтле вакыты — кыш. Тышта буран котыра, ул ярмалы кар боткасын тәрәзә пыяласына китереп сылый — ә син җылы класста рәхәтләнеп тарих, грамматика, Ньютон законын, Пифагор теоремасын, Везувийны өйрәнәсең... Дәрестән соң сборлар, түгәрәкләр, концертлар. Класс җылы, анда парта исе, китап исе. Ярымшарлар картасының үз исе бар. Аның үз йөзе, үз моңы бар. Зәп-зәңгәр океаннар. Карта — утыз бишенче елда басылган, латин хәрефләре белән. «Олы яки Тын океан» дип сузып-сузып язганнар. Чия буяулар арасында «Таһран» шәһәре. «Каспий диңгезе» түгел, ә «Каспий күле». Шул картага карыйсың да, ничектер, дөньяга, тереклеккә, табигать көчләренә ихтирамың уяна, фәнгә, гыйлемгә мәхәббәт кабына. Гомер буе укырга иде — гел

буран булсын иде, ә син гел укы иден, укып арыгач кына нәкъ менә быелгыдай җәй килсен иде һәм... күзгә калдырдык дип, балык чиртә торган шушындый җылы, тымызык көннәрдә сине газапламасыннар иде. Кая инде хәзер уку! Кая инде хәзер синә перфектлар, хәл фигыльләр, синуслар һәм эчәккуышлылар! Күзгә калмаган бәхетлеләрнең инде шушы өч-дүрт көн эчендә борыннарының тиресе туналды, борын тирәсен сипкел басты, аяклар күнгә әйләнде. Инде су буендагы сай гына дугайда беренче, икенче классны тәмамлаган малайлар үзләренең мәктәптә укыганнарын бөтенләй онытып су керәләр, бер-берсен батырышалар, су буеннан узып барган укытучыны бөтенләй санга сукмыйча, бер-берсенә шактый кыю сүзләр дә ычкындыргалыйлар.

— Нигамәт, батырма, фәлән итим...

— Син үзең фәлән...— дип чырылдашалар. Бичаралар! Беренче сентябрьне ник уйламыйсыз? Хәер, балалыкның бөтен бәхете — уйламауда. Уйлаган кеше — Рушад кебек яшьли картая. Әнә ул яр өстендә басып тора, ул да әле яшь егет. Ләкин аның шатланмаганына, көлмәгәненә күпме вакытлар инде.

Кечкенә малайлар «урта казык» кагып уйныйлар. Суга баш белән чумалар да, аякларын чыгарып бераз торгач, мәтәлчек атып барып төшәләр. Дугайның икенче бер читендә, бәйләгән зәңгәр штаннарын салмыйча, бәләкәй кызлар чүгә-чүгә су өстенә куллары белән бәреп тән чылаталар, көйләп такмак әйтәләр. Сузып-сузып әйтәләр.

Исәнлегем, саулыгым.
Тазалыгым — байлыгым.

Яр буенда суга керергә куркып торган башка кызларга кычкыралар.

— Кызый, кер, барыбер тәнеңне бака күрде!

— Тәнеңне бака күргәч кермәсәң — чирлисең!

Ул арада малайлар яр буена чыга, анадан тума бер халәтнең бөтен рәхәтлегенә чыдый алмыйча, коточкыч тизлек белән бер-берсен куышалар, кызлар янына килеп (әле оялысы юк, ни рәхәт!) аларны чыр-чу кычкырталар, чирәм өстенә салып калдырган күлмәкләренең җиңнәрен юешләп төйниләр — «каз боты» ясыйлар. Бәхетле бала чак!

Су буе гына түгел, капка төпләре, шомырт аслары, киртә буйлары тулы вак балалар. Барысы да дөньяларын онытып уйныйлар. Бер төркем малайлар таяклардан автомат ясап дер селкетеп фашистларны турый. Абзар артыннан кинәт килеп чыгып, хәтта Рушадка да кычкырдылар.

— Хэнди хох!

Рушад рәхәтләнеп көлеп җибәрде һәм кулларын күтәрде. Билләһи, ул шушы гөнаһсыз сабыйларга бирелер, аларның әсире булыр иде...

Миңҗамаллар капка төбендә такмаклы уен бара. Балалар капкага терәлеп басканнар да арадан берсе каршыларына басып чираттан һәрберсенең күкрәгенә төртеп такмак әйтә.

Кисәк-кисәк болыт килә,
Киселмәгән арыш килә.
Ахшару — Ахшару,
Ахшару атлы.
Суган алдым — суганым татлы.
Туганыма бер кыз алдым —
Каләмкаш атлы.
Каләмкашка туй тектердем —
Үзенә чаклы.
Якасына бал бастырдым —
Сөйләргә татлы.
Киявең шалкан урламасын!
Коймә аша сикермәсен!
Бадиян! Бадиян!
Тфү!

Әле кичә генә китап-дәфтәр күтәреп мәктәптә йөргән бәләкәй кызлар тыкрыкта ду китереп уен уйныйлар, көйле такмак әйтәләр.

— Ак тирәк!

— Күк тирәк!

— Күктә, күктәниләр бар?

— Чуар ала кошлар бар.

— Канатында ниләр бар?

— Җофар белән шикәр бар.

— Җофарынны миңа сатчы?

— Нигә сатыйм мин сиңа?

— Шикәреңне миңа сатчы?

— Нигә сатыйм мин сиңа?

— Елга астында елан бар.

— Ары килә, бире килә, сездән безгә кем килә?

— Кылычың булса — кый да чык!

— Кыйгак, кыйгак, кыйгак!

Монда да борчусыз, бәхетле, хәсрәтсез бала чак! Кара инде син кешене! Шушындый хәсрәтсез бала чагыңны ташла да үзең теләп гашыйк бул, үзең теләп ут йот, имеш!

## XXI

Кыш... Ничек әле читтән торып уку булган! Авыл укытучысы, югыйсә, бер урында ятып тәмам күгәреп бетәсе. Гел үзең генә укыту, өйрәтү дә туйдырып җибәрә. Менә, ичмасам, берничә атнага үзең укучы буласың, сине йөгертеп йөртәләр, ачуланалар, өйрәтәләр.

Рушад гостиницага урнашкан иде, бер көнне кич гостиницаның буфетында кефир эчеп утырган Даутовны очратты. Даутов, гадәтенчә, елмаеп күреште һәм тиз генә тагын бер стаканга кефир салды.

— Я, ничек, бөек тарихчы? — дип сүз башлады.— Марк Аврелийлар, Спинозалар кебек акыл иясе булдыңмы инде?

Даутов өлкә комитетының пленумына килгән икән.

— Район буенча икмәк тапшыру планын үти алмадык. Эш начар тора, миңа кызарып утырырга туры килде.

Рушад аңардан Ләйләгөлнең язмышы турында сорамакчы булган иде, тартынды. Ничек инде шундый борчулы вакытында кешедән семьясы турында сорашасың?

— Күрәсең,— диде Даутов,— кайбер баерак колхозлар белән сөйләшеп карыйсы булыр. Артта калган күршеләренең заданиесен бераз күтәреп булмасмы. Менә сезнең колхоз, мәсәлән. Запросто бер алты йөз центнер чыгара ала. Күрше «Ватан» өчен.

— Ул инде бик үк дөрес булмый бит, иптәш Даутов. Акбалыкта халык ничек эшли дә, «Ватан»да ничек. Җир бер, климат бер. Тырышсыннар. Югыйсә, гел бер эшләгәнгә эш, тик ятучыга — һаман шул иркенлек.

— Ие, шулай ул, үз манараңнан карап уйлаганда. Менә син кайда булдың? Эсминецтамы? Яхшы. Менә син ачык диңгезгә чыктың. Синең көчең кайда, үзеңдә генәме?

— Торпедалар, батареялар, миналар саны белән үлчәнә көч.

— Юк шул, туган. Менә монда инде синең офицер түгеллегең, матрос, иң күбе старшина икәнлегең ачылды. Син монда торпедист, артиллерист буларак кына сөйлисең. Ә мин — шул эсминецның командиры. Миңа әле синең торпеда аппаратыңның әйбәт эшләвеннән тыш яр буе артиллериясенең мине сак астына алуы, авиациянең әзер булуы, күзәтү һәм элемтә службасының мине бер секундка да ташламавы кирәк. Югыйсә, ялгыз көе мин — ноль...

— Ләкин һәр бер чагыштыру аксый бит...

— Уһу, котлыйм, син инде Ленинны яхшы ук өйрәнгәнсең. Ләкин Ленинның иң соңгы хезмәтләрен дә өйрәнергә тәкъдим итәм. Артта калган хуҗалыкны күтәрешү — алдынгы колхозларның изге бурычы. Аерым хуҗалык белән күмәк хуҗалыкның төп аермасы да әнә шунда. Безнең социалистик системаның мораль принцибының өстенлеге шунда. Кораллы көчләрдә моны «взаимодействие частей армии, авиации и флота» дип йөртәләр. Әмма, егет, без синең белән гел бәхәсләшәбез. Я, ярый, мәктәбеңдәниләр бар? ВУЗга ничә кеше бирдегез? Хезмәт резервларына ничә? Колхозда ничә?

Рушад белгән кадәресен санап күрсәтте. Сүз арасында гына иң кызыксындырган мәсьәләне кузгатты:

— Между прочим, иптәш Даутов, сезнең кызыгыз кая урнашты? Разия Вәлиевнадан сорарга да уңайсызландым. Әгәр, мин әйтәм, теләгән җиренә керә алмаган булса, нигә ана кешенең күңелен борчырга?

Боларны әйткәндә Рушад кызарды, ахрысы, җөмлә бик сәер килеп чыкты. Ләкин Даутов бу сорауны бик тыныч кабул итте.

— Ә нәрсәсе уңайсыз аның? Керә алмады и баста. Бер балл җитмәгән. Ул бит Николаевка киткән иде, кораблестроительныйга. Чит шәһәр, чит обстановка, бәлки каушагандыр.

— Ә хәзер нишли?

(Рушадның бик тә: «Ә хәзер кайда ул?» — дип сорыйсы килгән иде.)

— Ни эшләсен... Безнең янга кайтмады. Кыз бала бит — хурлана. Ничек инде ул, институтка керә алмадым дип кайтырга. Миңа калса — бу бик гади эш. Һөҗүм алдыннан, гадәттә, солдатлар белән әңгәмә уздырасың. «Иптәшләр, бу сугыш каты булыр, нык булыгыз, Ватан сездән егетлек, фидакарьлек көтә» дисең. Күреп торасың, сине тыңлап утырган егетләрнең байтагын иртәгә инде син күрә алмассың. Бәлки, бу сугыштан үзең дә чыкмассың. Арадан кемдер үләргә тиештер бит. Кем ул? Әнә шуны барлык солдат та аңлый. Син дә аңлыйсың. Ләкин бу турыда сөйләмисең. Сугышның диалектикасы шундый. Димәк, институтка да кемдер керә алмый, ә ни өчен ул кеше безнең кыз булмаска тиеш?

Рушад аның сүзләрен йотлыгып тыңлады.

— Ә нинди эштә соң ул?

— Штукатур. Менә дигән хезмәт хакы алып эшли.

Чәй калагын стаканга бәрә-бәрә күпме генә сөйләшмәсеннәр, Рушад бу кызның кайда, кайсы шәһәрдә икәнен сорый алмады.

— Тормышта кайчак шулай була,— диде Даутов.— Әйе, тормыш парадоксларны кирәгенчә сәхнәгә ыргытып тора. Бик яхшы укыган, намуслы, җаны-тәне белән гыйлемгә бирелгән бала — һәм бик яхшы хәзерлекле бала — институтка керә алмаска мөмкин. Мин, билгеле, үз кызымны андый дип әйтмим. Сүз гомумән бара. Ул бала әнә шулай оятыннан авыл җиренә кайтмый, кирпеч сугарга керә, мич ягучы булып керә, маляр булып йөри. Уртача гына укыган берәү тегеләй итә, болай итә — йөри торгач институтка эләгә. Диплом ала. Карыйсың — аспирантурада кала, диссертация язар өчен тема эзли.— Бу урында Даутов көлеп җибәрде.— Әй, шаккатам мин, шундый кешеләр дә була бит: мин, ди, аспирантурада укыйм, ләкин әле диссертациямнең темасы юк, ди.

Алар кузгалышып гостиницаның холлына чыгып утырдылар, тәмәке кабыздылар.

Рушад бу кеше янында үзен иркен тота башлады.

— Менә мин дә шул турыда уйланып йөрим, иптәш Даутов,— диде.— Миңа калса, һәркем тормышта үз урынын табарга тиеш.

— Әйе, әйе. Моны кем әйткән — беләсеңме?

— Беләм шул. Борынгы көнчыгышның акыл иясе Конфуций әйткән.

Дөньяда һәркем үз урынына куелганнан соң гына тулы тәртип булачак, дигән.

— Әйе, некомпетентность — безнең җәмгыять өчен куркыныч авыру. Кадрлар җитми, бернечә елдан мона чик куелачак. Әле менә бүген пленумда мин дә бер танышымны очраттым. Фронтовик, менә дигән сәләтле, оештыручы егет. Хет бүген горсовет председателе итеп куй. Кайда, кем булып эшли диген? Кызык! Журналистикага кереп киткән, редакциядә, ди. Ну инде, билләһи! Әдәбиятны бөтенләй аңламый, ләкин — редакцияли. Куйдылар бит, мин нишлим, ди. Шигырьләр ук язгалый, укып барам. Бер юлында бер гиенлек мәгънә, акыл, матурлык юк. Яза. Ә бит менә дигән оештыручы әрәм булып ята... Кеше үз урынында булсын, максимум файда китерерлек урын булсын...

Даутов сәгатенә карап алды.

— Ә син үз урыныңдамы соң, Конфуций?

— Ничек дип әйтергә инде... Болай, фәнемне яратып укытам мин. Ләкин тарихны сөйләргә генә яратам. Балалардан кабат сөйләтеп, журналга билгеләр куеп газаплануны бер дә сөймим. Аннан соң, мин бераз меланхолик бит. Менә хәрби хезмәттән кайтканнан бирле бер генә тыныч көн уздырганым юк. Һәр вакыт канәгатьсезлек. Нәрсәдер җитми. Ә бит тыныч тормышны никадәр сагынып кайткан идек. Мин, ахрысы, яшьлегемне сугышта калдырып кайттым...

— Һи-и, брат, синең яшеңдә аларны сөйләп тору — оят! — диде Даутов, нык кына итеп Рушадның җилкәсенә басып куйды.— Кстати, син нишләп ятасың әле шәһәрдә?

— Мин бит университетта заочно укыйм. Сессия вакыты.

— А... Әйдә, әйдә, тизрәк югары белем ал. Районда менә ничек кирәк сезнең халык.— Даутов ияк астына кул кырын сызып алды, Рушадка сынаулы караш ташлады.— Нәрсә, сугыш бетте дип әллә туарылырга исәп бармы? Юк, брат, авылны, районны торгызу, хуҗалыкны ныгыту шулай ук безнең эш. Әйе, нәкъ фронтовиклар эше.

— Минем эш билгеле инде,— диде Рушад, елмаеп.— Хаммурапи патша турында, Мисыр фиргавеннәре турында сөйләп кенә район хуҗалыгын ныгытырга мөмкин икән — мин әзер...

Даутов сүзне элеп алды.

— Дөресен әйтим, япь-яшь көе Ватан сугышы мәктәбен үткән коммунист егетнең бүгенге көнне Хаммурапи патша законнарын сөйләп ятуына мин бик үк риза түгел әчемнән. Аны хәзергә башка кеше дә эшли торыр. Ә менә район күләмендәге штурвалларның берсен киләчәктә сиңа тоттырмыйча булмас. Тулы нагрузка белән эшләмәгән двигатель бик тиз эштән чыга ул.

— Нәрсә, әллә ДОСААФ председателе итмәкче буласызмы?

Даутов ачу катыш көлде:

— Карап-карап йөрим дә, бер нәрсә сизәм мин, егет: кешене балачагага чыгарып, төрттереп сөйләшергә яратасың. Флоттагы шаярулярынны онытырга кирәк булыр. Ну, ярый, берәр курсыңны өстәп куй әле укуыңда. Тик шунысын әйтә алам: зуррак дингезгә чыгып, киңрәк алдырып йөзәргә туры киләчәк сиңа.

Разия Вәлиевнага сәлам әйтегез.

— Рәхмәт... Әйтермен.

Ләйләгөлнең адресын бирсәгезче, ул кайсы шәһәрдә? — дип сорыйсы килеп калды Рушадның. Ләкин Даутов — районның иң зур, иң дәрәҗәле кешесе. Аның белән чамалап сөйләшмәсәң, оятка калуың бар. Шуларның барысы өстенә Даутовның аны ифрат та үз күреп, иркенләп сөйләшүе егетнең күңелен җылытып, ихтирамын арттырып җибәргән иде, күңелендәге сагышын ул үзендә генә саклап калды, Даутовта шик тудырырга теләмәде.

...Сессия тәмамлангач, Рушад берәр кирәкле әйбер очрамасмы дип күргәзмә материаллар кибетенә килде. Анда ул доверенностьлар, счетлар күтәргән Нәркисне очратты. Нәркис калыная төшкән, юашланган. Битендәге сары тапларны каплар өчен шактый көч тә куйган иде. Каракулдән тегелгән затлы кин тун аның фигурасындагы үзгәрешне каплап тора иде. Ул бер генә мәртәбә дә Рушадка күтәрелеп карамады. Алар кайчандыр шушы кибеттә бергә плакатлар сайлаганнар иде бит. Нибары бер ел элек — ә икесе дә бик яшь иде әле ул вакытта!

Алган әйберләрне күтәреп кайтышырга дип Нәркис үзе белән Мәсрүрәне дә алып килгән икән. Ләкин алар бер-ике картадан бүтән берни таба алмадылар.

Кибеттән чыккач, Нәркис нәзакәт белән генә саубуллашып өйләренә кайтып китте. Аерылган вакытта ул соңгы ярты елда беренче мәртәбә Рушадка матур итеп күз сирпеде. «Без синең белән икенче тапкыр очрашканчы, беләсеңме, минем ниләр күрәсем бар әле?» дип әйтте шикелле ул.

Рушад шулай итеп Мәсрүрә белән бергә урамда калды.

— Я син кая да, мин кая? — дип елмайды ул Мәсрүрәгә.

— Миңа кая барсам да ярый. Дүрт ягым кыйбла,— диде Мәсрүрә, кемгәдер үпкәләгәндәй.— Берәрсенә ияреп циркка-фәләнгә барсам гына инде. Шәһәргә килгәч-килгәч...

Рушад аз гына вакытка күзен йомып уйланып торды. Мәсрүрә циркка алып баруны, әлбәттә, аннан өмет итә иде.

— Беләсеңме, нишлибез? Цирк түгел, икенче бер жиргә барып киләбез. Ризамы?

— Синең белән жир читенә дә барырга риза...— Мәсрүрә моны чын йөрәктән әйтте, ахрысы. Рушадка бу авыр ишетелде.

...Мөби яңа квартирага күчкән икән. Белешмәләр бюросы өч минут эчендә адресын язып бирде.

Мөбинең баскыч төбендә өч тәгәрмәчле машина «Инвалидка» тора иде. Тар коридордан борынга керогаз, кер сабыны, киез итек һәм башка төрле көнкүреш кирәк-яракларыннан чыккан ис бәрелде. Эчке бүлмәдә Мөбинең күптәннән таныш, ягымлы тавышы ишетелде.

Укыр идем ахшам —
бер тәмәке тартсам.
Ясигасын да укыр идем,
Бер яртыны каксам.

Мәсрүрә шикләнеп Рушадның кулыннан кысып тотты. Рушад исә кыю рәвештә ишек шакыды.

...Мөби дөньяда бөтен төрле көтелмәгән әйбергә әзер, әмма балалык дусты Рушад аны эзләп керер дип башына да китерә алмый иде. Житмәсә, ниндидер бер хатын-кыз белән. Бүген аның ял көне иде — өй салкын, күңелсез. Өстәлдәге кичәге дуслардан калган төпчекләр, суган кабыгы, ипи кисәкләре, каткан стаканнар, буш шешәләр...

Көтелмәгән кунакларны күргәч, ул каушап калды һәм иске диваныннан сикереп торып култык таякларына ябышты. Ул кырынмаган һәм кичтән эчкән аракы пары авызыннан бәреп тора иде.

— Биллаһи, әй! Карале! Синме бу, биллаһи! Менә дрикаумать! Һе!..

Алар кочаклашканда Мөбинең бер таягы шалтырап идәнгә барып төште. Беразга гына югалып калган Мәсрүрә таякны алып Мөбигә тоттырды. Үзе өстәлгә күз салып алды да чишенә башлады. Мәсьәлә ачык, өйне жыештырырга кирәк иде.

— Я син, нәрсә? Кырынмаган, юынмаган. Сиңа кунаклар килә — ә синең өстәлеңдә дуңгыз абзары. Тоже миңа — фронтовик. Фронтовик түгел, бактериологик корал син!..

— Әй, билләһи! Чисно! Көтмәдем. Мин хәзер. Айн момент. Мичкә ягабыз. Бәрәңге пешерәбез. Шәп балыгым бар. Мин бит эшлим — акчам иркен. Вот син, әй, дриаумать!

— Кем булып, кайда эшлисең?

— Сапожных дел мастер! Разрядлы. Үзенә менә дигән бер полуботинкалар тегеп бирәм, ахири! Мин хәзер мичне генә...

— Юк инде, туган, мичеңне үзем ягам. Кайда утын сараең?

Утын сараенда мичлек утын әзерләгәндә, Мөби кыскача гына хәлне аңлатты. Хәзер ул инде тынычланган, шактый шыпырт сөйли иде.

— Хатын белән расчет. Бик эт халык булып чыкты ул, малай. Ужымга йөрде. Хатын-кызның бөтен ягын гафу итеп була, әмма анысын булмый икән, малай. Ну инде шунысын аңладым: ир хатыны чит ир белән бер тапкыр гөнаһка кермәсен, аннары берни дә ярдәм итми икән.

Рушад ярган утыннарын кочагына күтәрде.

— Шулай ук ачыктан-ачык хыянәт иттемени соң ул? Ничек инде ул, син була торып? Аңламыйм.

— Шту син. Бер айгыры өйгә мин барында шешә кыстырып килә башлады. Шул кеше белән тотылды да. Янәсе, мине эчертәләр дә йоклаталар. Ярты кеше бит мин, янәсе!

— Ничек котылдың соң?

— Ничек булсын, военком янына бардым. Шулай-шулай, торыр урыным калмады, хатыным хыянәт итте, квартир аныкы, эчүгә сабыштым дидем.

— Шуннан?

— Шуннан шул: военком белән бер армиядә булганбыз. Давай, ди, без, ди, болай итик, ди. Син миңа бер-ике көннән, ди, тагын кер. Килдем — эш урыны, квартир бөтенесе собес белән сөйләшеп куелган иде. Менә ничек! Үзе — полковник! Сүкте мине. Ничек оят түгел сиңа, Сәгъдиев, шундый проституция эчендә эчеп ятарга, син фронтта булдыңмы, или аякларыңны поездда исереп йөреп өздердеңме? ди. Үзәккә үткәзеп әйтте, малай...

— Ә теге кайда соң хәзер? Күрешмисеңме?

— Ха! Аны кызык иттеләр. Ирсез хатын янына килмиләр шул хәзер. Птамушто — ирсез хатын янына йөрү — җаваплы эш ул. Иң көйлесе — ире булганда инде аның. Хәзер елый да елый, ди. Теге картны каргый икән. Имеш, тегенең сүзенә ышанып харап булган. Тегесе әйткән, янәсе, мин гинеколог, серләреңне миннән яшермә, дигән. Ха! Гинеколог, дриаумать! Коновал ул, беләсең килсә! Котчыккыч олы гәүдә, көрәк кадәр кул! Тыловик! Ела! Бик шәп! Чит ирнең тасма тәненә ышангансың икән, димәк, үз иреңне яратуың чамалы гына булган.

Бу хәлне Мөбинең кешегә иң беренче сөйләве иде, шуңа күрә ул кызды.

— Ялгыштым, имеш. Ялгышасың аны күңеленә шундый бозык исәп керсә. Кемдә нәрсә кайгысы бит! Мин йортны кайгыртам, продукт ташыйм, утынын, квартплатасын хәл итәм. Әзергә кайтып керә. Хатының дөрес юлда йөрсен дисәң, егерме дүрт сәгать йорт эше белән занят булырга тиеш. Белдеңме? Әле бит минем, беләсеңме, күпме пенсия килә? Ә башка льготалар? Хатын-кыз бер ычкынмасын.

..Мич томалаганчы Мәсрүрә өйне җыештырды. Мөби белән Рушадны кухняга куып чыгарды да плитада җылынган су белән идән юарга керешә. Күлмәкләрен кыстырып, җиңен сызганган яшь хатын су түгәргә чыккалаганда Мөби белән Рушадның сүзләре бүленеп кала иде. Мәсрүрә кечкенә квартирны ялт иттерде. Мактап кадәр мактап юып өйрәнгән яшь хатынга бу эш бөтенләй авыр тоелмады.

Җылы, чиста өйдә чәй янында көне буе аңгәмә барды. Мәсрүрә ике тапкыр якын тирәдәге кибетләрдә йөреп кайтты. Көндезге чәй кичке аш

белән тоташты. Мәсрүрә ашны әйбәт пешерә икән. Мөби токмачлы ашны тирләгәнче шопырды. Үзе шаярткалап алды.

— Безнең бабай әйтә торган булган: уңган хатын арыш оның кәбаб итәр, ялкау хатын бодай оның харап итәр, дип. Бик уңган киленгә туры килдек бит әле...

Кичен Мөбинең бердәнбер диванын Мәсрүрәгә бирделәр. Егетләр үзләре идәндә пальто, шинель җәеп яттылар. Сугыш хәлләре, фронтта күргәннәрен сөйләп ярты төн уздыл. Мәсрүрә кәне буе йөгереп шактый арыган, ахрысы, мендәргә башын тәртү белән, урынга сеңгән кебек, йоклап китте.

Мөби белән Рушад таңга чаклы сөйләшеп яттылар.

— Сиңа адәм төсле яши башларга бик вакыт,— диде Рушад, шинель астыннан пышылдап. Үзеннән олы кешегә киңәш бирергә аның мораль хокукы бар идеме? Мөби хәлендә калса, үзе нишләр иде? Тәҗрибәсезлеге белән ул анысына игътибар итмәде.— Сиңа кеше төсле яши башларга бик вакыт. Телисең икән — үзем димче булам. Менә дигән хатын. Гайбәт сатып йөрми. Эшкә булган, күп сүзле түгел.

— Мин куркам шул, малай. Тагын теге хәлгә калырмын дим. Чүштәки, инвалид бит мин.

— Хатын-кызның барысы да яман булмый. Менә мин егермеләгән хатын-кыз арасында эшлим. Гадәттә, аларны бер яманнан чыгып бәялиләр ирләр. Берсе бозык булса, ирләр ансат кына: һи, хатын-кызның барысы бер иш, дип хөкем чыгаралар. Ә нигә намуссыз бер хатыннан чыгып башкаларга да кара ягарга?

— Аның, малай, инде төрле вакыты булгандыр. Бик яшь бит әле. Каны уйнап тора. Кем гаеп итә ала аны! Әмма ат — нясенә килгәч аксамасын. Миңа шул житкән. Әйдә, каян килеп кая китмәгән, иртән син сүз салып кара. Өметле булса — калганын үзем сөйләшәм. Бәлки әле, дөбердәтеп туй итәрбез?

— Үһу, син байларча сөйләшәсең. Әле туй расходына, ихтимал, миннән әҗәткә сорап торырсың?

— Юк, парин, минем туйлык кына запас бар. Син әллә мине кичәгечә көн саен шулай кылана дисеңме? Кичә зарплата көне иде, иптәшләр белән утырдык. Аена ике тапкыр шулай утыргалыйбыз. Мин бит әле өйгә дә эш китертәм. Жыясыларым да бар. Кайберсенә бирәчәк тә юк түгел дә. Кыскасы, алачак — яфрактан күп, бирәчәк — туфрактан күп. Миңа нәрсә, бер башым да бер... җылап утырган сары чәчле малайларым юк ла минем.

Алар әйләнгәләп озак яттылар.

— Ну, парин, ничек кирә белдегез. Бильләһи! Бер сөйләшергә моңзар бит мин.

— Ничек инде алай? Ә кичәге компания?

— Юк, алар олы кешеләр. Алар сугышта да булмаганнар. Трудармиядә булган берсе. Әйбәт кешеләр, сүзем дә юк, ну, малай, фронтовиклар белән сөйләшү бөтенләй икенче. Ә беләсеңме, бәйрәм көннәрдә ничек эч поша? Узган ел тугызынчы май көнне жанымны кая куярга белмичә йөрдем-йөрдем дә ресторанга кереп утырдым. Күрше өстәлдә генә ике яшь егет кызлары белән утыралар. Жиңү көне өчен! Бәйрәм белән! — дип, рюмка артыннан рюмканы авыштырып кына торалар. Берсе — телгә бик остасы — сугыш вакытында үзенең күргәннәрен сөйли. Слюдадан чәч тарагын үзе ясап колхоз базарында сатып йөргән икән. «Понял, понял» дигән була сүз саен. Авызларында яхшы папирос, официантка яннарында бөтерелеп йөри. Ә мин тәмәкене суырып бер сәгать утырдым, борылып та карамадылар. Птамушто мин ямьсез, ярты гәүдә, ихтимал, сакалны да кырмаганмындыр. Бер сәгатьтән соң килеп әйттеләр: бу өстәлгә официантка юк икән, дризумать. Менә ничек!

— Стой, стой... Мин хәзер синең үзеңне гаеплим.

— Ике аякны Румыния җирендә калдырып кайткан өченме?

— Юк, юк. Җиңү көне диденме? Әә синең медальләрең бармы? Гимнастеркаң исәнме? Кырынырга бритваң бармы? Во! Менә син кырын, чиста гимнастеркаңа ак яка тек, орден-медальләреңне так та, теләсәң кая кереп: «Бәйрәм белән! Үзебезнең фронтовиклар бәйрәме белән!» дип тәбриклә. Югыйсә, кырынмаган һәрбер аяксыз әле ул Ватан сугышы инвалиды була алмый.

— Әй, син әллә кай җиреннән тотып аласың ла мәсьәләне. Син — учуный шул, безнең кара баш белән сөйләшүе сиңа ике тиен бер акча.

— Ну, ярый, алайса, йоклыйк. Подъемга кадәр тыныч йокы, иптәш ефрейтор!

— Есть, тыныч йокларга! Сезгә дә шуны теләргә рөхсәт итегез, иптәш старшина!

Калганы кинокартинадагы кебек тиз эшләнде. Рушадның шәһәрдә соңгы киче иде — Мөбинең квартирында тар гына күләмле туй мәҗлесе булды. Мөби нәкъ Рушад әйткәнчә киенгән: өр-яңа гимнастеркасына ак яка тегелгән, бер ордены һәм өч-дүрт медале тагылган, пөхтә итеп кырынган, чәчләре рәтләнгән иде. Мәсрүрә, мәҗлестә хатын-кызлардан үзем генә булам, дип оялып, мәҗбүри дип әйтерлек өстерәп Яңа бистәдән Нәркисне алып килде. Өстәл янына Нәркис тә кереп утыргач, Мөби бөтенләй каушады. Университет тәмамлаган бу гүзәл ханым Мөбине бөтенләй саташтырды, шатлыгыннан Мөби нишләргә белмәде, беренче тостны үзе әйтте һәм, ни өчендер, русча сөйләде:

— Наш долг — помнить тех, кого нет рядом с нами,— дип, ул култык таякларына гәүдәсен салып, морҗага терәлгән килеш тост күтәрде.

Нәркис чәкештереп каты чәй эчте.

Рушад мәҗлестә үзен кыю тотты, берничә тапкыр тост әйтте:

— Дустым, Мөбарәкша! Бәхетле булыгыз! Сезнең өчен мин бик шат! Әйдә, шау итеп бер яшик әле, картлач! Әйдә, үзең кебек шундый уңган хезмәт сөючән малайлар үстерегез, ул малайлар син теккән яхшы туфлиләрне киеп Германиягә, Румыниягә, Венгриягә кунакка барсыннар. Без дә синең белән ул вакытта эшсез ятмабыз! Чапаевны күреп белгән кешеләрне хәзер пионер сборларына гына йөртәләрме? Килачәктә без дә шулай йөрербез. Чөнки без — бөек вакыйгаларның шаһите. Сезнең бәхетегез өчен!

Соңгы тостының эчтәлегенә Рушад күңеленнән икенче төрлерәк мәгънә дә бирде... Үзе кычкырып: «Сезнең бәхетегез өчен!» — диде, үзе эченнән генә: «Ләйләгөл белән очрашу өчен дә» дип, тостның бурычларын арттырды...

Кияү-кәләш белән күрешеп чыгып киткәндә кичке унберләр иде. Рушад Нәркисне сак кына җиңеннән тотып барды. Урамда йомшак кар ява. Җиркомбинат морҗасыннан чыккан кызгылт-сары төтен урамга җир җиләге сабыны исен тутырган, комбинат тирәсендәге тротуардагы чуен плиталар өстенә төшкән кар бөртекләре парга әйләнеп торалар, ул плиталар өстенә трамвай көтүчеләр басканнар.

Калтыр-колтыр итеп ике вагонлы иске трамвай килеп чыкты, ачык ишектән кондукторның йокымсыраган тавышы ишетелде.

— Слидеющи — «Красный Восток».

— Әйдә, җәяү генә озат, трамвайда күңелем болгана минем,— диде Нәркис. Тар урамнардан барганда, Нәркис үзе Рушадның беләгеннән эләктереп алды. Яңа бистәгә алар әллә ниткән тар сукмактан — Бакалтай ягыннан керделәр. Бистә читендә эт тә юк иде. Беренче йортның коймасына житкәч, Нәркис тукталды, перчаткаларын салып чәчендәге кар бөртекләрен сыпырып төшерде. Ул авыр сулый иде.

— Я, сезгә... сиңа уңышлык телим,— диде Рушад, аңа карап.— Җиңеллек телим...

Нәркис дәшмәде, акрын гына хәрәкәт белән перчаткаларын кесәсенә

тыкты да кинәт кенә Рушадның муенын чорнап алды һәм, күз ачып йомганчы, аның иреннәренә ябышты. Рушад бу кыздагы андый халәтне бер мәртәбә инде очратканы булганлыктан, гаҗәпләнмәде, тик бу юлы кайнар иреннәре белән аның тынын буган кеше — ир хатыны иде. Нәркиснең бите бик, бик кайнар иде, ул беләк сөякләре шытырдаганчы Рушадны яңадан бер кысты да кинәт кенә борылып урамга кереп китте...

Аксыл болытларны тишеп, күктә ай күренде, саргылт ай җир өстендә таралып яткан Яңа бистәне, ары килеп-бире килеп йөргән маневр паровозларын, еракта каралып торган вокзалны һәм Ослан тауларын яктыртты. Нәрсәгәдер тагын күңел кителде, нәрсәдер җитми, нәрсәдер җимерелде. Нәрсә җитми? Ә! Шушы кар дингезе уртасында айга карап, Есенин әйткәнчә, көчек булып бер улыйсы килә икән! Ичмасам, бер күңел басылыр иде...

Кеше тормышы — нәкъ Яңа бистәдән шәһәргә йөри торган трамвай юлы. Карыйсың — тип-тигез кебек, утырып барасың — калтыр да колтыр. Аерма шунда гына, трамвайда барганда сиңа нинди тукталыш икәнен әйтеп торалар, ә тормышта — юк.

— Стануфкы «Угол Тукаева!»

Гостиницага кадәр Рушад җәяү кайтты.

## XXII

Мул булып йомшак кар яуган. Наратлар зур-зур кар мендәрләре күтәреп йокыга талганнар. Кыска көн үзе дә әле төнге йокысыннан айнып бетмәгән көе кичке якка авышкан кебек. Станция перронында бер генә пассажир да күренми, бары тик шунда яшәүче руслардан гына берничә кеше кар шыгырдатып юл аркылы чыккалап йөриләр. Моржалардан күккә төтен күтәрелә, дөньяга тозлы гөмбә, балык пироги исе чыккан. Бүген русларның ниндидер бәйрәмнәре бугай, урам тирәсендә кызарынган, чиста киенгән кешеләр күренгәли, бары тик фонарь, озын саплы чүкеч күтәргәннәре генә смена беткәнен көтеп, бер-берсеннән вакыт сораштыралар. Әллә нигә бер узып киткән поезд да бу станциядәге табигать идиллиясен боза алмый. Монда тынычлык, монда иминлек! Бер мичкә тозлы кыярың, дүрт-биш түшкә итең, кышлык утының, печәнең булса, эш урының булса — нигә җырлый-җырлый яшәмәскә? Университетта укып йөреп син дөрес эшлисеңме? Аның кирәге бармы? Даутов әйтә, укыган кешеләр кирәк, ди. Ә менә озын саплы чүкеч тотып вагон буксаларына суккалап тикшереп йөрүче кешеләр кирәк түгелмени? Шул кешедән башка поездлар йөри алмый бит. Нигә мондый мәшәкатьле юл сайланды әле бу тормышта? Нигә авылга кайтылды? Нигә, мәсәлән, шушы станциягә урнашып тормыш башламаска иде? Урнаш идең обходчик булып, өйләнеп җибәр идең шушы тирәдәге бер яшь сылу Машага. Булсын иде ул кыйгач кашлы, зәңгәр күзле, бәйрәм көннәрдә ул сине пирог пешереп каршы алсын иде, аннан өстәл янына утыргач, синең белән парлап берәр рюмка җибәрсен иде дә ап-ак муеннары, хуш исле чәчләре, тыгыз күкрәкләре, йомшак беләкләре белән сиңа сарылсын иде, тының буылганчы үпсен иде...

Менә бит бәхет! Син моны эшли ала идеңме? Әлбәттә. Димәк, бәхет һәркемнең үз кулында.

Ә син нинди юл сайлап алдың? Менә чемодан тулы китаплар, заданиеләр, контроль эшләр. Язга кадәр синең бер генә дә буш сәгатең булмас. Сине иртәгә алты сәгать дәрес көтә, җыелышлар көтә. Егет гомереңнең күпмесе сугышта узды. Калганы да мәхәббәт назыннан мәхрүм. Ир-егетләрдән дуслар таралышып бетте. Гата эш дөньясына чумды. Хәер, аны гаеп итеп тә булмый, мәктәп директоры бервакытта

да үз вакытына үзе хуҗа түгел. Анда өч смена укыйлар. Анда алтмышлаган укытучы. Гата энергиясенә урын тапты, ниһаять...

Директор, күргәзмә материаллар төяп Мәсрүрә дә кайта дип, ат җибәргән иде, чанада утырып кайткан Рушадның үзен генә күргәч аптырап калды.

— Бәрәч, техничканы күрмәдеңмени? — диде. Ул Мәсрүрәнең исемен кеше барында әйтмәскә тырыша иде.

Рушад «по-фронтовому» узган туй турында кыскача сөйләп биргәч, директор бүреген салып чәчләрен сыпыргалап куйды, бераз аптырап торды...

Завуч Бәлкыйс Рушадка кәгазьләр арасыннан иртәге көннең расписаниесен күрсәтте. Чиреклек расписаниене өйдә төзим, бүген кич эшләп бетерәм, диде. Тәнәфес булды, укытучылар берәм-берәм класслардан чыктылар, һәрберсе Рушад белән кул биреп күреште. Бары тик Хәлимә генә караңгы чырай белән ерактан исәнләште — Рушад моның сәбәбен белә иде, гаҗәпләнмәде. Мәктәпкә яңа гына килгән кызга, әле август аенда ул Рушадны күргәнче үк, коллективтагы бер-ике хатын бу егет турында яман хәбәр сөйләп куйганнар иде. Имеш, үзе заочно гына укып йөрсә дә, борыны бик югары, кызлар белән йөрми, йөрсә дә мыскыл итәр өчен генә йөри, имеш...

Ә Хәлимә аңа үзен мыскыл иттермәячәк, менә, борылып та карамаячак. Бер кочак алма ботагы күтәреп Мостафа килеп керде, җырлый-җырлый әйберләрен урнаштырды да Рушад белән килеп күреште.

— Бик вакытлы кайткансың, дустым, коллективта ирләр азайды, күңелсез,— диде. Сүзен ачыклап бетерер өчен:— Хәкимҗан да китеп барды, Гатаны да каядыр алырга итәләр бугай.

— Хәкимҗан?! Кая китте? — диде Рушад ашыгып.

— Магнитогорскига. Вербовка белән.

— Шулаймыни? Ничек кисәк кенә уйлады икән?

— Нишләптер Шәмсетдинов белән борчаклары пешмәгән. Ул аңа быел эш бирмәгән бугай. Гата район юлын тапты.

Рушад авыр гына көрсенеп куйды.

Мәсрүрәнең шәһәрдә кияүгә чыгып калуы шул тәнәфестә үк таралып өлгерде. Укытучылар гөр иттеләр. Төрлечә юрадылар. Кайтып барганда гына коридорның кешесез почмагында Рушадны директор хатыны куып җитте. Шат чырайлы Гөлчирә кызу-кызу килеп Рушадны култыклап алды да чын күңелдән кулын кысты. Гөлчирәнең, үзе әйтмешли, бит урталары кызарган, уч төбе кайнар иде.

Чирек минутлык бу очрашуның мәгънәсен алар икесе дә сүзсез аңладылар. Бу — Гөлчирәнең йөрәгеннән чыккан рәхмәте иде.

Гайнелвафа карчык Норильскига киләсе көзгә китәргә булган, ялгыз өйгә Рушад кайтып кергәч, бик шатланды. Кичке аш вакытында авыл хәбәрләрен сөйләп утырды. Бу атнада авылда зур җыелышлар буласы икән...

Планнар төзеп бетергәч, Рушад урамга чыгып китте. Тегермән буасында колхоз электр станциясенең әкрен генә гүелдәп эшләгәне ишетелә, электр керткән йортлардан кар өстенә нур көлтәләре сузылган. Кая барырга? Шәһәрдән соң авылга нәләнүе читен. Авылдан килгәч, шәһәрдә дә берничә көн шулай җаныңа урын тапмый йөдисең. Кая барырга? Кайда син, Хәкимҗан? Кайда син, Гата? Нинди күңелле көннәр бар иде узган уку елында!

Шәһәргә консультациягә барып йөрү өчен аңа я шимбә, я дүшәмбе көнне дәресләрдән азат булу кирәк иде — димәк, Бәлкыйсне кисәтеп куярга кирәк...

Бәлкыйс өй түрендәге өстәлдә ватман кәгазьләренә чумган иде. Ул чәчләрен шома итеп тараган, ситсы халат кигән, аякларында йомшак туфли. Рушад чишенеп түргә узды, шүрлектәге китапларны күздән

кичерде. Макаренко, Макаренко... Методик күрсәтмәләр. Башлангыч классларда арифметика укыту методикасы. Югары классларда тригонометрия укыту тәҗрибәсеннән. Методик журналлар. Педагогика дәресләре. Берәү, икәү, өчәү... Бу кеше ник укытучы булмасын? Бу шуның өчен туган, шуның белән яши. Моның башка дөньясы бармы? Әйтик, үз гомерендә егет кочканы бармы? Әллә аның сөйгән егете фронтта һәлак булган да, ул үзенең күңелен башкаларга сала алмыйча шулай кибәргә карар биргәнме? Бу кыз уен-көлке беләме? Бәлки, аның белән шаяртып сөйләшүче юктыр, завуч булгач? Бәлки, ул ирләр тарафыннан рәсми булмаган мөнәсәбәткә мохтаҗдыр? Тукта әле, кылын чиертеп карарга кирәк. Юри генә.

Сүз ара сүз чыкты. Егетләргә мөнәсәбәт турында да бераз булды. Катып калган түгел икән. Ләкин таләбе...

— Минем,— диде Бәлкыйс, юка иреннәрен фигуралап,— ир кешенең бер кимчелеген күрсәм, ана инде күңелем ята алмый. Карыйсың, әдәпле генә кеше кебек, укымышлы да, чибәр дә, ә пиджагының якасы майланган, чәченнән кавык коелган. Шуны күрден — бетте инде. Кайберсенең бар ягы килгән — ә чалбарының балагы сүсәргән. Я булмаса ботинкасына кыек баскан.

— Ә аракы исе килсә ничек? — дип шаяртты Рушад.

— Аракы исе килгән кешене тикшереп тә торасы юк. Беткән кеше ул.

— Я инде, сез бигрәк усал кыланасыз. Әйтик, кайгыдан, шатлыктан бераз гына булганда.

— Кеше кайгыда да, шатлыкта да үзенә хуҗа була белергә тиеш... Кеше аракыны эчмәгән көе дә шат, тулы күңелле булырга тиеш...

— Тиеш, тиеш... Аның аларын мәнди анасы да белә. Ә тормышта ничек?

Бәлкыйс шүрлегеннән бер китап алды. Кызу-кызу гына актарып, кирәкле урынны тапты да укып китте. Академик Павлов истәлеге. Павлов кәгазь, каләм алган да күзгә каршысына утырган. Стакан белән аракы алып, аннан бер йотым эчкән. Организмдагы үзгәрешләрне кәгазьгә яза барган. Аннан тагын... Шуннан соң ул исерткечнең баш миенә һәм сизү органнарына зарарлы тәэсир иткәнен белгән һәм аны гомерендә башкача тамчы да капмаган...

Алай... Менә ниләр белә бу кыз!

— Ә менә Антон Семенович Макаренко болай дип язган...— Бәлкыйс шүрлектән Макаренко китапларын алды.

Әңгәмә һич тә Рушад теләмәгән юнәлешкә кереп бара иде. Ләкин аны үзгәртүе инде кыен иде.

— Сезнеңчә, ничек дөрес? — дип сорады Бәлкыйс.— Макáренко дип әйтүме, әллә Макарéнкомы?

Рушадның бу турыда уйлап та караганы юк иде.

— Менә мин Мәскәү радиокомитетына хат язып җибәрдем әле,— дип сөйләп китте Бәлкыйс.— Ике тапшыруда басымны ике җирдә кулландылар. Радиокомитет булып радиокомитетта шундый грамотасызлык җибәргәч, нәрсә була инде ул?

Рушадның урамга чыгасы килә башлады. Грамоталылык ягына кереп китсәң — беттем диген. Алла сакласын, монда озаграк сөйләшеп утырсаң, өтерләргә дә барып житүең мөмкин.

Бәлкыйс расписаниедә дүшәмбене буш калдырырга вәгъдә бирде.

— Бүген тәзеп бетереп булмый, башым авырта, бер таблетка анальгин эчәм дә ятам,— дип калды.

Рушад урамга чыккач аның тәрәзәсенә күз салды. Өстәл лампасының яктысы өй түрендәге рәшәткәләрне яктырткан иде.

— Хәерле төн сиңа, коеп куйган педагог! Салкын түшәгеңдә тыныч йокла, бар җире дә килгән егетләр төшеңә керсен!

...Гайнелвафа карчык сөйләгән имеш-мимеш нигезле булып чыкты. Алты дәрестән соң ашап-эчеп укытучылар килгәндә, җыелыш инде кызган иде. Президиум өстәле янында — Сабир Ишмуратович, Бибисара, колхоз җитәкчеләре һәм алдынгы колхозчылар утыра. Клуб шыгрым тулы. Укытучылар иелә-бөгелә алга уздылар, алгы рәтләрдә буш урыннар калдырылган иде.

— Иптәшләр, җыелышның мондый юл алуына бары тик мин генә гаепле,— дип сөйләп ята Сабир Ишмуратович.— И, как президиум председателе буларак та, и һәм дә партоешма секретаре буларак та. Чөнки, иптәшләр безнең линияне бик аңлап бетермәделәр бугай, дим мин. Иптәшләр, менә колхоз идарәсенең, и һәм дә партия оешмасының да рекомендациясе буенча... рекомендациясе буенча без бүген колхоз председательләре курсына үзебезнең арадан бер лаеклы иптәшне күрсәтергә тиеш идек. Инде үзегезгә мәгълүм булганча, алда чыгып сөйләгән иптәшнең тәкъдиме бар: председательләр хәзерләү курсына үзебезнең авылда туган... үзебезнең авылда туган, әйеме, иптәш Сәмигуллин Хөрмәтне җибәрергә...

Зал гөжләп алды.

— Әйттек бит инде: риза түгел!

— Иптәшләр, тынычлык... Әйбәтләп кенә сөйләшик, киңәшик, аңлашыйк... Әйбәтләп кенә.

— Нәрсәсен аңлашырга? Риза түгел, вәссәлам!

Сабир Ишмуратович тегеләй итте, болай итте, сүзне Бибисарага бирде. Бибисара йончыган кыяфәт белән стаканнан су йотты. Аның тамагы карлыккан иде, күрәсең, икенче тапкыр сөйләве...

— Иптәшләр,— дип башлады ул сүзен,— иптәшләр! Миңа свиршынно аңлашылмый: ни өчен тәкъдим ителгән кандидатурага сез риза түгел? Бу бит аерым бер кешенең генә фикере түгел, бу бит авыл Советы идарәсенең дә, партия башлангыч оешмасының да фикере. Шулай булгач...

Бибисара аз гына саксызлык җибәрде, зал шуны эләктереп алды:

— Шулай булгач, нәрсәгә безне монда чакырып алдыгыз?

— Ие! Үзегез алдан решайт итеп куйгач, безнең нигә кирәгебез бар? Шул булдымы демократия!

Тавышлануучыларның бер-икесе фронтовиклар иде.

— Иптәшләр, даваегыз, тәртип белән генә...

Уң кулының яртылаш буш җиңен селкә-селкә, шинельле бер кеше алга таба узды.

— Тәртип белән булса, шул, иптәшләр. Без тегендә Ватан өчен кан койдык, Сәмигуллин монда ашап-эчеп рәхәттә йөргән...

Зал гөжләп алды:

— Аның ашказаны сәламәт түгел! Сәламәт булса, ул да фронтта булыр иде! Ул ягына кагылма!

— Сөйләсен, бүлдермәгез!

— Тавыш!..

— Кагылмаскамы? Ә? — Буш җиңле кеше калтырый башлады.— Ашказаны сәламәт булмагач, нигә ул без ут эчендә вакытта Фәйзрахман бабайга кереп җиде төн уртасында тавык суйдырган, эчәргә эзләткән? Ә? Кыскасы, минем фикерем шул, иптәшләр: финагент булган икән булсын, анысына сүзебез юк. Пока налог бар икән, агенты да кирәк. Менә илебезнең хуҗалыгын торгызыйк, налог җыюның да кирәге бетәр. Әмма ликин без ут эчендә вакытта мондый башбаштаклык эшләп йөргән кешене үзебезнең колхозга председатель булырга укысын дип, мин үземнең актык кулымны күтәрер хәлем юк...

Бибисара һаман да трибуна янында тора иде. Ул судан тагын бер йотым авыз итте.

— Иптәшләр,— дип дәвам итте ул,— иптәш Сәмигуллин район буенча бик зур эш башкара. Үзегез беләсез, районның финанс планын үтәмәсәк, без бүгенгесе көнне сезнең белән балаларыбызны укыта алмас идек, бырачлар ярдәменнән файдалана алмас идек. Аның бу өлкәдә хезмәте бик зур, иптәшләр...

— Ә ни өчен сез аны бик каты яклыйсыз?

— Иптәшләр, аның башка ягы да бар. Менә монда әле генә бер иптәш чыгып сөйләде: яла бит ул! Иптәш Сәмигуллин аракыны авызына да алмый. Аның ашказанында җәзбе бит!

— Кирәк түгел! Сәламәт ашказанлы кешене укытабыз!

Бибисара репликаларга инде игътибар итми башлаган иде.

— Кешелек сыйфатларына да карарга кирәк бит. Эчми, тартмый, дигәндәй, хатын-кыз артыннан йөрми, дигәндәй...

Соңгы җөмлә залны тагы да кыздырды.

Арткы рәттән соры халат кигән берәү күтәрелде:

— Алайса, Мохтарны сайларга кирәк: үзенә илле яшь, гомерендә хатын-кыз кулын тотканы юк, эчми, тартмый, сакал чыкмый...

Баягы тавыш тагын кабатланды:

— Ә ни өчен сез аны бик каты яклыйсыз? Башка лаеклы кеше беткәнмени?

Бибисара тагын бер хата ычкындырды.

— Соң бит, иптәшләр, район оешмалары алдында оят. Безнең ышанычны акламадыгыз дип әйтерләр...

Бу сүз утка керосин сипкәндәй булды.

— Ә-һә! Күрдеңме! Алдан килешеп эшен бетердегезмени? Дөрес сүзгә рәхмәт!

Тәрәзә төбендә утырган бер яшь хатын урыныннан кузгалды. Аның да өстендә соры халат иде, фермадан гына килгән.

— Бибисара апай! Бибисара апай! Менә син, хатын-кыз артыннан йөрми, диден. Син аны ышанып әйтәсеңме, әллә сүзеңнән чигенмәс өчен генә тырышасыңмы? Менә мин мисал китерсәм, нәрсә дип әйтерсең?

Җыелышның йөгәне ычкынды. Сүзгә хатын-кыз кушылды.

— Дөрес! Ишеткәнебез бар!

— Күргән кешеләр бар!

— Ие! Сәмигуллиннан чисти суфи ясап бетердең!

Бибисара йончыган кыяфәт белән аска, беренче рәткә, карады. Беренче рәттә Мостафа, Рушад, Миңҗамал, Хәлимә, Бәлкыйс утыралар иде. Бибисара күзләре белән ярдәм сорагандай итте. «Сез — агитаторлар,— дигән сыман булды ул Рушадка,— шушындый вакытта да безгә ярдәмгә килмәсәгез...»

Инде хатын-кыз шаулаша иде.

— Хәмит хатыны кайда?

— Ие, ие! Кайда Рузикамал? Үзе әйтсен!

— Я, җәмәгать, нишлисез сез? Иренең елы да тулмаган хатынны ник мәсхәрә итәсез? — Монысы ирләр тавышы иде.

— Әйтсен, әйтсен! Тол хатыннарны мыскыл итмәсен берәү дә!

Арттагы рәтләрнең берсендә гөж килделәр.

— Тор, Рузикамал, чык алга!

Теләр-теләмәс кенә атлаган бер чибәр хатынны уртадан алга алып килделәр. Хатынның өстендә кыек кисә кырыена күн куеп эшләнгән купшы зәңгәр сырма, башында кәҗә мамыгыннан бәйләгән кыйммәтле шәл иде. Алга килеп баскач, хатын башын түбән иде, битләре комач кебек яна башлады.

— Я, әйт, Рузикамал,— дип кычкырды аны җитәкләп килгән халатлы хатын.— Әйт хәзер теге көнне миңа әйткәненне! Килдеме төнлә ишек төбеңә Хөрми? Әйтеп бир әле шул Сәмигуллинның кем икәнен!

Рузикамал башын тагы да түбән иде. Кычкырып әйтергә кыюлыгы җитмәде — арткы рәтләрдәге балалар арасында аның малае булуы мөмкин иде. Шуңа күрә аның тавышы пышылдап кына чыкты.

— Килде,— диде ул, башын күтәрә төшеп.— Килде.— Шулай диде дә йөгереп кинәт кенә клубтан чыгып китте.

Бибисара да, Сабир да коелып төштеләр.

Трибунага яңадан сыңар куллы чыгып басты. Ярты терсәге белән трибуна читенә таянды. Тамагын кырды.

— Менә мин гаҗәпләнеп утырам. Җыелыш түгел бу, безобразие бу. Без фронтовикларга алай килешмәс бит. Мин шулай уйлыйм. Иптәш Сәмигуллин кандидатурасы турында күп сөйләнде, күп әйтелде. Иптәшнең төрле ягы бар икән. Дөрес, беребез дә алтыннан коелмаган. Бәндә хатадан хали түгел, диләр. Аннан соң шул ягы да бар бит әле: иптәш Сәмигуллин кеше янына «дай» дип килә. Ә «дай» дигән кешене аны яратуы кыенрак. Монысын барыбыз да беләбез. Инде без болай итик: колхоз җитәкчесе булырга кемне укытырга? Хезмәт ияләре арасындагы иң абруйлы, иң яхшы кешене. Без аннан эш таләп итәчәкбез. Ә безнең эшлисе эшләр күп. Колхозның яраларын төзәтәсе бар...

Зал тагын гөрли башлады.

— Дөрес!

— Яңа ферма саласы бар!

— Ат абзарлары искергән! Материал бирсеннәр, рәтлибез. Терлек абзарларының рәте булмаган колхозда башка эшнең дә рәте булмый.

Сыңар куллы яңадан сөйли башлагач, зал тынды.

— Инде без болай итик, иптәшләр: сүз күп булды, әмма бер нәрсә аңлашылды. Теләми бит халык бу иптәшне, курсларга җибәрергә теләми... Теләми, әйеме? Әгәр дә мәгәр, мин әйтәм, без, дим, председательләр курсына, дим, үзебезгә кайту шарты белән, сугышта катнашкан берәр батыр фронтовикны күрсәтсәк, дим... Ә?.. И мин үзебезнең фронтовиклар исеменнән шундый тәкъдим кертәм: давай без җибәрик укырга безнең мәктәптә эшләүче Тын океан диңгезчесе Заһирны!

Халык дуамалланып кул чапты.

— Прауелни! Заһир — башлы егет!

— Тәртипле егет!

Сыңар куллы президиумга җиңүле караш ташлады.

— Пускай ул бүгенгесе көндә мәктәптә эшләсен, ләкин без аңа менә шунда эшләгән көе үз халкыбызның дәвириесен җиткерик и укырга җибәрик. Үзе батыр диңгезче, үзе белемле, үзе җирне ярата. Дөрес әйтәмме мин, иптәшләр?

Залга мондый мөрәҗәгать барысын да хәл итте...

Бу вакытта Сәмигуллин директор Сабир өендә ишекле-түрле йөри иде. Җыелыш озакка сузылды, аның нинди юнәлештән китәсен алдан чамалап, ул җыелышка үзе катнашмады. Гөлчирә җыелыш барганда әллә ничә тапкыр өенә кайтып килде, барысын да сөйләп барды. Җыелышта әйтелгәннәр бары да дөрес иде. Әйе, Сәмигуллин гомере буе диярлек үз эшен намус белән башкарды, көн димәде, төн димәде — авылдан авылга чапты. Әйе, шулай йөреп, эш өстендә төннәр буе тәмәке тартып ул чирләде, аның куенында хәзер содалы шешә йөри. Әйе, Рузикамал аның иң беренче сөйгән кызы иде, ләкин ул Сәмигуллинны ташлап Хәмиткә чыкты. Сәмигуллин чыра кебек юка, кырыс телле сөйкемсез хатын белән гомер кичерде. Хәмит үлгәч, бер төнне ул Рузикамалның ишеген каккан иде. Ачмады. Ишек аркылы ул Рузикамалның куәт ташып торган гәүдәсен, тигезсез сулышын сизде, Рузикамалның тәнендәге кайнарлык ишек аркылы аңа бәрелгәндәй булды. Ачмады. Сәмигуллинның исә шул кечтә дөньяның бөтен финансларын, шыксызмамыксыз көйгән хатынын, содасын, ачы «Беломор»ларын онытып, бер-ике генә җылы сүз ишетәсе, аз гына булса да күңелен эретәсе

килгән иде. Рузикамал исә упкәләде, рәнжеде. Ләкин нигә инде шуны җыелышта әйтергә? Хәер, аны бит өстерәп чыгарганнар... Әмма берсе хаксыз сүз әйткән Сәмигуллин турында: үз гомерендә аракы сораганы юк аның эчәргә. Эчми бит ул, аңа килешми. Ә, теге вакытта, Фәйзрахман картларда... Рузикамал белән бер ишек алдында торалар бит алар... Нәсел... Әллә ничек шунда, ул төнне Рузикамалның тәрәзәсендә соң гына ут янды. Сәмигуллин ул төнне эче пошып урамда йөрде. Үзе урамда йөрде, үзенең колак төбендә Хәмит тавышы ишетелде:

— Ничек оят түгел сиңа, Хөрми! Мин ут эчендә вакытта минем иң газиземә күз салырга?

Әйе, әйе, ничек оят түгел!

Әнә шунда ул ачудан да, тәрәзә утына якынрак булганга да Фәйзрахман картка төнлә барып керде... Ләкин тавык ашау өчен түгел. Аракы эчәр өчен дә түгел.

Барысының да рәте бар.

Менә эчсәң — бүген.

— Гөлчирә! Бир бер стакан! Нәрсә булса да эчәм...

Җыелышны тәмамлап, Сабир өйгә кайтып кергәндә, аш пешкән, тәмле ит исе чыккан иде. Өстәл өстендә башланып аз гына авыз ителгән бер шешә тора, Сәмигуллин башын өстәлгә салган да үксеп-үксеп елый иде.

Сабир башын түбән иде.

Сәмигуллин урыныннан торды.

— Бу хурлыкка ничек чыдыйм, Сабир Ишмуратович, ә? Нишләдем мин, нинди хурлыкка калдым мин?

Бу сорауларны биргәндә Сәмигуллинның күңел төбендә әле сүнәрсүнмәс өмет чаткысы бар иде. Бәлки, җыелышта аны яклап чыкканнардыр әле? Шулай да ул түзмәде:

— Я, кемне җибәрергә булдылар? — диде.

— Заһирны тәкъдим иттеләр,— диде Сабир кулын юып яткан җирдән.— Бертавыштан...

Сәмигуллин өенә арт урамнан бата-чума кайтты. Куптәннән авызга алмаган нәрсә аның эчәгеләрен пычак белән турагандай итә иде.

Баскычта кар шыгырдауга хатыны аңа ишек ачты. Ичмаса, белмәгә дә чыгып китмәгән! Начар кәеф белән кайтып кергәндә яратмаган хатыны ишектә каршылаган ирдән дә бәхетсез ир юктыр...

## XXIII

Балалар — кошлар кебек сизгер. Хәрби хәзерлекнең яңа укытучы уздырган беренче дәресеннән үк Галәвиев качты. Чөнки кара егетнең сугышта гына түгел, армиядә дә булмаганлыгы аңлашылды. Галәвиевнең моңа күңеле рәнжеде һәм мәктәпне бөтенләй ташлады. Баланың мәктәптән китүе — директор өчен иң куркыныч нәрсә. Галәвиевнең өенә Нәсимә барды. Яңа укытучы Хәлимә барды — файдасы булмады. Директор эшнең нәрсәдә икәнен сизде — Рушадны чакыртып сөйләште.

— Бөтен ышаныч синдә, авыл Советына җиткермичә генә эшлик, чөнки сигезенче баласын мәҗбүр итеп булмый,— диде.— Балалар саны кимү — класс санын киметә, класс саны кимү — кесәгә дә суга.

Рушад килгәндә Галәвиев сыер абзарыннан тирес чыгара иде, укытучы килгәнгә гаҗәпләнмәде.

Рушад кулына сәнәк алды да караңгы абзардан тирес чыгарыша башлады. Балаларны алдый алмассың! Туганда ук җидене бетереп туалар дип юкка гына әйтмиләр аларны!

— Һи-и, абый,— диде Галәвиев,— юкка гына буяласыз. Укымыйм, и вчу!

— Ә мин әле һич тә син укысын дип буялмыйм. Просто, безнең беркайчан да үзебезнең сыер да булмады, абзар да. Сыер абзарын яратам мин.

Галәвиев эре тешләрен күрсәтеп көлде:

— Гы-гы-гы...

— Ә сиңа укымасаң да була. Чөнки җиде класс белемең бар, ә ул инде, брат, уен-муен түгел. Калганын укысаң ярый, укымасаң ярый.

Галәвиев мондый сөйләшүгә әзер түгел икән. Рушад акрынлап максатка якыная башлады.

— Тик сине мин хәрби училищега җыена икән дип ишеткән идем.

— Һи-и, исегез киткән икән. Армиягә барыбер алырлар әле. Шунда китәрмен.

— Анда инде сиңа иң күбе — полковая школа.

— Ә ул кемнәрне чыгара? Литинатлармы?

— Юк, бигрәк тагын син. Кече сержант, сержант. Ә лейтенант булу өчен, беләсеңме, күпме хәзерлек кирәк?

— Ун классмыни?

— Юк, нишләп алай гына булсын? Ун класс — анысы инде аның закон. Таза булырга, каты йөгерергә, чаңгыда шәп йөрергә, яхшы йөзәргә, авырлыкларга чыдарга һәм башкалар...

— Һи-и, авырлыкка безнең колхозник малайлары чыдамыймы соң?

— Белмим шул. Әле менә син ник укуны ташладың соң?

Абзар идәнен инде икенче тапкыр себерә башладылар.

— Ник дип... Күңелсез. Воянныйдан дәрестә утырасы да килми хәзер.

— Читенмени?

— Әйтәм бит: утырасы да килми дип.

— Ә, алай икән. Әле мин синдә ихтыяр көче бер дип уйлый идем. Аннан башка, билгеле, офицер булу мөмкин түгел.

Галәвиев себеркесен куеп тагын сәнәк алды. Бүреген арткарак шудырды.

— Беләм инде, беләм, абый, сез миңа яңадан мәктәпкә килергә кушасыз.

— Юк, кушмыйм. Ләкин мин синең урында булсам, һичшиксез, иртәгүк килеп керер идем.

— Бер ташлагач читен шул ул...

— Ә менә шул читенлекне җиңә белү — ихтыяр көче дип атала да инде. Я, ярый, монда ак простыня гына җәясе калды. Сау бул. Уку мәсьәләсен үзең хәл ит.

Абзардан чыгып киткәндә генә Рушад кире борылып килде.

— Беләсеңме, Владимир Ильич нәрсә дип әйткән. «Үзеңне үзең җиңә алу — иң зур җиңү!» дигән. Менә мин үземне үзем күп вакыт җиңә алам. Менә мин хәзер дәрестән кайтам, иртәдән бирле бер нәрсә капканым юк. Ләкин әгәр син теләсәң, мин-сиңа ай буе калдырган бөтен дәресләреңне хәзерләргә булыша алам. Теләсәң төн уртасына кадәр. Ике дә уйламыйча.

Малай икеләнде.

— Соң, абый, воянный дәресенең барыбер рәте юк бит...

— Ә син офицер булу өчен бары тик шул гына кирәк дип уйлыйсыңмы? Математика, әдәбият, чит тел, тарих, химиядән башка нинди офицер булсын хәзерге заманда?

Әлбәттә, Галәвиев дәрескә иртәгесен үк атлыгып килмәде. Бер көн уздырып килде. Беренче дәрес тарих иде. Рушад Галивиевнең арткы партада ризасызлык белән генә янтаеп утырганын күреп алды, ләкин игътибар бирмәде.

Дәресне кабатлаганда, берни дә булмагандай, Галәвиевтән сорады:

— Һиндстандагы Сипайлар восстаниесе турында сөйлә, Галәвиев...

Малай белми иде, Рушад салкын кан белән генә аңа икеле куйды.

— Алдагы дәрестә тагын синнән сорыйм, ни өчен чабата туздырып йөрисең! — дип орышып та алды.

Ләкин Галәвиев бу икелегә шатланды гына. Чөнки бу икеле аңа башкалар белән бер хокук бирү, аны коллективка янадан алу дигән сүз иде.

Галәвиевнең янадан мәктәпкә килүе Рушад өчен шатлыклы вакыйга булды. Хәер, тормыш гел эчпошыргыч вакыйгалардан гына тормый. Була вакыт — дәрескә килешенә иртән сине әллә нинди яңалыклар, күнел кузгатырлык хәбәрләр каршы ала.

Җирле советларга сайлаулар узуга, район Советының сессиясе булды. Гатаны үз авылларыннан депутат итеп сайлаганнар иде. Район газетын карасалар — Гата район Советы башкарма комитеты председателе булган. Район газеты ул көнне кулдан-кулга йөрде. Типография хатасыдыр дип уйладылар, икенче Сәләхиев бардыр диделәр — ләкин акка кара белән язылган — Гата Сәләхиев диелгән иде.

Хәер, Гата председатель буларак үзен тиз күрсәтте. Озак көттермәде. Җитәкче иптәшне күрим дисән — авылыңда зур җыелыш уздыр. Килми калмас...

Зур җыелышны уздырырга Акбалыкка Даутов белән Гата килде. Клуб алдына җыелган халык зурлап аларга сәлам бирде, кайберәүләр хәтта тәмәкеләрен дә карга ташлап, олтанлы итек белән бастылар. Акбалык халкы боларны ничектер үзенекеләр итеп карады — берсен районга килгәч тә үз авылларында торган өчен, икенчесен үзләре үстергән, үзләре күтәргән өчен...

Килүчеләр клубны әйләнеп чыктылар, аннан идарәгә кереп киттеләр. Халык әле җыелышып кына килә иде. Ял көне иде, авылда читтән кайткан кунаклар күренә, моржалардан тәмле исле төтен күтәрелә, акрын гына кар төшә... Клуб алды акрынлап халык белән тулды, ахырдан концерт та буласы дигәннәр иде. Җыелышта мөһим мәсьәләләр карал асы иде, халыкның йөзе җитди күренде.

Дөньяда һәр минут эчендә әллә никадәр хәл булып тора. Һәр кечкенә, зур авылда, шәһәрдә. Менә берәүләр клуб алдында тыныч кына тәмәке тарта, ә районның яңа председателе авыл Советы бинасында үзенең яңа постына имтихан тота. Ул стенадагы телефонны борды-борды, районны ала алмады.

— Бездә менә шулай ул, иптәш Сәләхиев,— дип, Бибисара елмаеп утырды. Ләкин Гата сүгенмәде, ә телефонистканы тотканчы тыныч кына борды һәм тотты.

— Бу кем, Нинамы? — дип сорады.

Нина да теге башта, күрәсең, төшеп калганнардан түгел, яңа председательне тиз таныды.

— Мине элемтә начальнигы белән тоташтыр,— диде Гата. Ул хром пальтосын чишеп җибәрде, чөнки телефон рычагын нәкъ егерме минут борып торган иде. Авыл Советындагы кешеләр бу сөйләшүне зур кызыксыну белән тыңладылар.

— Иптәш Хөсниевме? Саумысыз. Сез әле кайда? Кабинетта. Мин сезне бер ярты сәгатьтән Акбалыкта күрер идем. Әйе, әйе. Юк, калганын монда килгәч...

Гата өчен бу көн бик авыр, мәшәкатьле булды. Җыелыш башланыр алдыннан гына кошевкага утырып Хөсниев килеп җитте. Авыл Советына кереп толыбын салды, каушаган кыяфәттә Гата белән күреште.

— Миңа райисполкомны алып бирегез, шуның өчен чакырттым,— диде Гата тыныч кына. Хөсниев эшнең нәрсәдә икәнен тиз аңлады, тыгыз әйләнә торган аппаратны выж-выж боргалады, трубкага өрде, стенадагы агач тартманы ачып батареяларны тикшерде. Тагын борды. Берөзлексез кычкырды, муен тамырлары бүртеп чыкты. Пальтосын

салып ташлады. Гата ишек янынарак барып аңа карап торды. Хөсниев кып-кызыл булды.

— Нина! Центральная! Центральная! Нина! Бу нинди безобразие, понимаешь?

Авыл Советы бүлмәсе кычкырган тавыш, аппарат выжылдавы белән тулды.

Гата сәгатенә карады.

— Фронтта мондый безобразие өчен элемтә начальнигын хәрби трибуналга тапшыралар иде, иптәш Хөсниев,— диде.— Иртәгә сәгать унда миңа кереп районда элемтә эшенең торышы турында кыскача информация ясарсыз.

Гата кергәндә җыелышны башлап торалар иде. Ул сәхнәгә узды һәм Даутов янына урнашты. Колхоз председателе Гыйләҗ абзый җыелышны ачып сүз башлады. Җыелышның көн тәртибен раслатты. Аннан сүзне Гатага бирде. Гата хром пальтосын чишеп җибәрде, тамагын кырды. Сүзен башлый алмыйча торды. Аннары китель кесәсеннән блокнотын алды да сөйләп китте. Ул илебез хуҗалыгына сугыш алып килгән бәла-казалар турында сөйләде. Украина, Белоруссия җирләрендә көлгә әйләнгән авыллар, шәһәрләрне телгә алды.

— Мин,— диде,— сугышның нәрсә икәнен аңлау өчен сезгә, сугышта булмаганнарга, Орша шәһәрен генә күрсәтер идем. Беләсезме, шул шәһәрдән нәрсә калды? Беләсезме, шул узловой тимер юл станциясе — сугышка кадәр гөрләп торган станция — хәзер ни хәлдә? Анда әйләнәтирә кап-кара кисәү, шлак, кара янган фашист эшелоннары, кәкрәеп күккә күтәрелгән рельслар һәм пассажирларга билет сату өчен тактадан әмәлләп куйган бер будка бар. Ә фашистлар җир белән тигезләп бөтен халкын кырып бетергән Лидице, Пирчюпис авыллары турында ишеткәнегез бармы? Азат ителгән бер авылга барып кергәч, авыл Советы каршында спорт мәйданчыгындагы хәлне күреп мин акылымны җуя яздым. Анда безнең партизаннардан ике кешене аягыннан асып баганага элгәннәр дә тере көе овчаркага талатканнар....

Зал тетрәп китте. Аннан Гата соңгы елда илебез хуҗалыгын аякка бастыру өчен дәүләт үткәргән чаралар, авыл хуҗалыгының гомуми торышы турында сөйләде. Район буенча дәүләткә икмәк тапшыруның нәтиҗәләре турында информация ясады. Район икмәк тапшыру заданиесен үти алмаган. Районда артта калган колхозлар шактый гына. Безнең бурыч — бу колхозларны аякка бастырырга ярдәм итү, алар өстенә төшкән заданиене хәл кадәренчә күтәрешү.

Зал бу сүзләрдән соң гөжли башлады.

Гата төп мәсьәләгә килеп җитте. Күрше колхозларга ярдәм йөзеннән дәүләткә дүрт йөз центнер икмәк чыгарырга кирәк иде. Бу цифрны ишеткәч, залда тавыш купты.

— Бирмибез! Алар өчен нигә бирик!

Гыйләҗ абзый зур яшькелт графинга тагын карандаш белән суккалады.

— Иптәшләр, тәртип белән генә. Нигә буза куптарасыз. Аңлашыйк, сөйләшик...

Акбалык клубының бәхете — шау-шулы җыелышлардан икән. Гата маңгай тирен сөртте. Ул әле трибунада иде.

— Бирмибез, и вчу! Эшләсеннәр! Җир барыбызныкы да бер төсле. Нигә дип «Ватан» колхозына ярдәм итик без? Кыш буе ирләре итек басуда, хатыннары шәл бәйләп саталар...

— Иптәш Сәләхиев! Иптәш Сәләхиев! Сиңа аннан торып сөйләү ансат ул. Менә минем алты семья. Мин аларны киендерергә тиешме? Ә? Үзем дә, карчыгым да круглый гуд эштә. Без шәл бәйләмибез.

Итек басмыйбыз. Ике-өч пот онны базарга чыгарсам, минем балаларымның... кияргә ыштаннары була. Чыгармасаң — юк. Ярый ла син үзең әнә хром пальто киеп алгансың.

Гыйләҗ абзый өзлексез графинга сукты, ак мыек очларына тир бәреп чыкты. Сабир исә тегенә-моңа катнашмады. Сабыр итте. Ул әле кичә генә районда йөреп кайткан иде. Кичке хисләрдән арына алмыйча утыра. Җомга көн кич Сабирның ишегеи авыл Советы телефоны янында дежур торган Ситдика әби какты. Тешсез авызын метмелдәтеп:

— Шабир улым, шине иртәгә шәгать шигезгә милишиягә шакырдылар, икенше бүлмәгә,— диде.

Сабирның йөрәге урыныннан купты. Төн йокысы качты. Соңгы айлардагы бөтен тормышын җиз иләктән уздырды. Кайда нәрсә эшләнде икән? Таң алдыннан гына тиешле нәтиҗә ясалды. Узган атнада... Әһә. Шуны хәбәр иткәннәр. Юк. Әллә теге җәй көне мәктәп утынын китерткәндә?

Сабир иртән чытлы ризык капмады, ат җиктереп районга чапты. Теше тешкә бәрелеп милиция йортына керде. Икенче бүлмә — паспорт бүлеге икән.

— Син нәрсәгә кирәк безгә? — дип, бүлек мөдире көлде.

Сабир район үзәгендә селкенеп озак йөрде. Прокуратурага да керде — анда бүлмәләрнең номеры юк иде. Тагын әллә ниләр уйлап бетерде. Төштән соң раймаг янында военкоматның икенче бүлек офицеры аның белән исәнләшеп болай диде:

— Ай-яй, начар сезнең дисциплина, ә? Сәгать сигезгә дип без телефонограмма җибәрәбез, ә сез төштән соң гына киләсез. Переподготовкага җибәрмичә булмас сезне, болай булгач...

Сабир кайтканда эченнән юл буе Ситдика әбине сүгеп кайтты. Никадәр борчу кичерелде бит! Шуңа күрә бүген ул Гатаның речен юньләп тыңлый да алмады.

Руслар әйтмешли, беренче коймак төерле булып чыкты. Гата рече белән әллә ни уңышка ирешә алмады. Шулай да соңгы җөмләләре белән ул яңадан залны үзенә карата алды.

— Иптәшләр, бернәрсәне онытмагыз. Мин моны ирләргә карата әйтәм. Сугышта күргәнегез булгандыр: син һөҗүм итәсеңме, чигенәсеңме, шуышасыңмы — нәрсә генә эшләсәң дә бөтен солдат та бер тигез дәрәҗәдә булмый. Берәү арый, икенчесе яралы, өченчесенең кораллары авыр. Ләкин солдат берсен-берсе ташламый. Яки болай да була: бер рота ут эчендә калган, ә синең ротаңның эш көйле, син я берәр укрытие артында, я урман буенда. Шунда теге ротаның кырылганын карап торасыңмы, әллә ярдәмгә киләсеңме? Ә? Ничек, фронтовиклар?

— Син алай чагыштырма, иптәш...

— Дөрес әйтә, дөрес! Солдат солдатны бер вакытта да ташламый!

Гатага әнә шул борылыш вакытында туктарга кирәк иде — Даутов аңа ишарә ясады. Гата өстәл янына килеп утырды.

Аннан Гыйләҗ абзый сөйләде. Гыйләҗ абзый — сугыш вакытында председатель итеп куелган. Ул оста сөйләүче түгел, ләкин өзек-төтек сүзләр белән үз фикерен үтемле итеп халыкка җиткерә ала. Рус сүзләре кыстырырга ярата.

— Алай ярамый ул, Әкрәметдин туган. Ярамый, значит. Син круглый гуд эшлисең икән, значит, бик әйбәт. Әммаликин тегеләр дә шәп яши иде бит сугышка тикле. Сугыш бетерде бит, значит. Ярдәм итик, алай саран булмыйк. Күршеләр авыр хәлдә вакытта без инде корсак киереп нечкә иләктән иләп ашап ятыйкмы? Ярамый, значит. Атаң Шакир карт андый мәнесез кеше түгел иде синең...

Даутов елмаеп кына картны тыңлады, үзе блокнотына фикерләрен терки бардың. Гыйләҗ карт шактый озак сөйләде, халык аны ярата иде, шылт иткән тавыш чыкмады.

Сәгать ярым барган җыелыштан клуб эсселәнде, кешеләр кайры туннарын, сырмаларын чишеп җибәрделәр. Гыйләҗ абзый чирек сәгатьлек тәнәфес игълан итте. Клуб ишегеннән мунчадан чыккан кебек аксыл пар бөркелде, кар өсте ирләр белән тулды, яшьрәкләр урамга кадәр чыктылар. Мәктәп ягыннан клуб артына гармун күтәреп Нәсимә узды. Димәк, концерт та буласы. Җитди сөйләшүдән соң ирләр тынып калдылар, ашыкмыйча гына һәркем тәмәкесен суыра иде. Риза булыргамы? Юкмы? Уңыш бүлү әле тәмамланмаган. Дүрт йөз центнер. Ике мең дүрт йөз пот дигән сүз. Димәк, хезмәт көненә алачак уңышың кимендә йөз-йөз илле граммга кими. Шулардан синең келәтеңә керәсе потлар кими. Нишләргә?

Тормышта комедия була да тора! Күрә генә бел. Һич уйламаганда урамны гөрләтеп ирләр көлеп җибәрде. Көлгән тавышка хатын-кызлар да әсәреште.

— Нәрсә бар, нигә кешнисез?

Кибет ягыннан урам буйлап күлмәкчән генә көйгә колакчын бүрек кигән бер малай йөгерә. Ике кулында — ике шешә. Ул аларны болгый-болгый:

— Монысы Гата абыйга, монысы Даутов абыйга! — дип кычкырып узды.

Халык янадан гөр итеп көлде. Бу — директор малае Тәлгать иде.

Бичара Гөлчирә! Син теләсә кемне адәм мәсхәрәсенә калдыра аласың!

Тәнәфестән сон Даутов сүз алды. Даутов ышаныч белән сөйли иде, аның речендә еш кына юмор була һәм аңа кирәк вакытта шул ярдәм итә иде. Әмма халык өчен иң ошаганы — аның һәр вакытта да кыска, конкрет сөйләве иде. Бу сыйфатлар Даутовка бүген дә ярдәм иттеләр. Ул пальтосын салып урындык артына элде дә, трибунага килеп, тамагын кырды. Елмаеп залга карады. Акрын гына башлап китте, халык монысын да белә, акрын башлау — Даутовның ахырга таба куәт белән сөйләчәгенә ишарә иде.

— Мин,— дип башлады ул сүзен,— соңгы вакытта сезнең колхоз колхозчыларының җыелыш алып барырга остарганнарын беләм...

Халык кинаяне аңлап көлеште.

— Шуңа күрә мин әле сезнең алда бераз каушабрак сөйлим. Әгәр, мин әйтәм, миңа авыз да ачтырмасалар болар.

Залдан берәү кычкырды:

— Шту сез, иптәш Даутов! Без бит болай гына, надан баштан гына!

Бу реплика Даутовның сүзенә җай бирде.

— Аннан соң мин инде, иптәш Сәләхиев хәленә калмас өчен, пальтоны салып яшеребрәк куйдым, чөнки минем пальто да каракүл якалы бит. Һәм өстәл артында утырганда шуны уйлап утырдым. Бөтен районга бер кеше инде мин, бөтен район коммунистлары миңа ышаныч белдереп зур эш тапшырдылар, әллә, мин әйтәм, мин дә сезнең кебек сырма яки кайры тун киеп йөримме икән? Ә? Нигә, нәрсәсе бар аның, райком секретаре — кайры туннан? Ә? Нигә исегез китте, без фронтта вакытта, генераллар, маршаллар акка каккан тун киеп йөриләр иде — менә дигән!

Зал көлде. Даутов бераз тын алды.

— Әле тәнәфестә без менә иптәш Сәләхиев белән сөйләшеп тордык. Нигә, мин әйтәм, без шулай, ак карга төсле, массадан аерылып торабыз әле? Сөйләшә торгач аңлашылды: сарык асрамыйбыз икән без! Иптәш Сәләхиев белән безнең каккан казыгыбыз да юк икән! Торыр йортыбыз да юк икән безнең. Ә инде пальтоларга килсәк — минеке утыз тугызынчы елны алынган пальто — кесә турылары инде ялтырый башлаган. Шәп ел иде ул, мин ул вакытта яшь укытучы идем, илдә тыныч-

лык иде. Кыйммәтле товар, әйтәсе дә юк. Шулай яхшы әйберне яратам мин. Бер акыл иясеннән сораганнар бит: нигә син һаман кыйммәтле кием генә сатып аласың? Теге әйткән: минем, дигән, арзанлы кием алырлык чамам юк, мин ярлы дигән. Менә минем дә шул кешегә охшыйсым килә.

Клуб эскәмияләре шыгырдады, канәгатьлектән гөрләү китте, авызын ачкан бер егет хәтта кул чабып куйды. Даутов аның саен тавышын көчәйтте.

— Ярый, монысы шаяру иде, инде төп мәсьәләгә күчик. Менә монда бер иптәш — Гыйләҗ ага аны Әкрәметдин дип атады — бөтен залда бер үзе дигәндәй, җыелышка куелган төп мәсьәләгә каршы чыкты. Мин карап торам, башка иптәшләрнең фикере хәзер уңайга таба борылды. Инде, иптәш фронтовик, сезгә бер сорау бирергә рөхсәт итегез: менә бер взвод солдат маршта бара. Арадан бер солдат аягын дөрес атламый. Моны «не в ногу» дип атыйлар. Менә шунда аягын кем дөресләргә тиеш? Бу солдатка карап бөтен взводмы, әллә взводка карап бу солдатмы?

Авызын ачкан егет чыдый алмыйча тагын кул чабып куйды. Халык җиңеләеп китте, зал буйлап йомшак җил искәндәй булды. Даутов аның саен иркенәйде. Залда көлгән тавышлар ишетелде.

— Утырттыңмы үзеңне, Әкрәметдин!

— Кәнишне, аягын дөрес атласын!

— Минем әйтәсе килгән нәкъ ике фикерем калды, иптәшләр,— дип дәвам итте Даутов,— һәм мин биш минуттан тәмамлыйм.

— Сөйлә, сөйлә!

— Кичкә хәтле тыңлыйбыз! — дигән тавышлар ишетелде.

— Беренчесе: мин бервакыт сезнең мәктәпнең тарих укытучысы белән сөйләштем — ул егет менә биредә утыра.— Даутов урта рәтләрнең берсендә утырган Рушадка төртеп күрсәтте, халык аңа борылып карады. Рушад яшь кызлар шикелле кып-кызыл булды.— Менә шунда мин ул егеттән бер мәгълүмат алдым. Сезнең авылдан кырык беренче елның июнь — июль айларында барлыгы йөз егерме ир фронтка киткән. Колхоз тулысы белән хатын-кыз кулында калган. Уйлап карагыз: колхоз эше, йорт эше, бала тәрбияләү, картларны карау, печән-утын хәзерләү, хәрби чорның бөтен налогларын түләү — барысы да менә шушылар, безнең арада утырган җиңгиләр өстендә булган. Һәм кырык бишенче елның җәенә кадәр алар шул йөкләрнең барысын да күтәреп килеп, сезне саф вөҗдан белән каршы алганнар. Һәм, әйтергә кирәк, сугыш вакытында колхоз әйбәт кенә барган. Дәүләт йөкләмәләре үтәлгән, колхозчы ачыкмаган. Хәзер, мин тыңлап утырам, күрше колхоз өчен амбардан өстәмә рәвештә икмәк чыгару турында сүз киткәч, шаулаучы кешеләр нигездә ирләр булды! Шулай бит!

— Дөрес! — Залда хатын-кыз тавышы да яңгырады.

— Хәзер без болай итик. Күз алдына шундый картина китерик, картларча әйтсәк, фараз кылыйк: кырык беренче елда сугышка ирләр түгел, ә йөз егерме хатын чыгып китте, ди.

Халык шаркылдап көлде, Даутов стаканнан бер йотым су эчте, тынып торды.

— Менә шулай, без, ирләр, аларны озаттык, ди. Беләсезме, без кемнәр идек? — Даутов трибунаны янда калдырып сәхнә алдына таба килде. Ул инде һөҗүмгә күчкән бәхәсче кебек иде.— Иң беренче көнне, хатыннар киткән шатлыктан, без төтен чыкканчы бер эчәр идек.

Клубны шыбырдатып кул чаптылар. Клуб тәрәзәсе өстенә урнашкан күгәрченнәр эчтән килгән бу хикмәтле тавыштан куркып, пырылдашып күккә күтәрелделәр.

— Икенче көнне без баш төзәтеп көн уздырыр идек... Өченче көнне

ашарга сорап безне балалар борчый башлар иде. Мал карыйсы, кер юасы, су ташыйсы искә төшәр иде...

— Дөрес, молодец!

— Давай, давай, сөйләсен, бүлдермәгез...

Даутовның йөзенә житди кыяфәт керде.

— Ул көнне без инде кайгыдан эчәр идек... Ә бит, иптәш фронтовиклар, сезнең хатыннарыгыз алай эшләмәгән. Сез чыгып китте дип, балавыз сыгып утырмаганнар, ә сездән алып калган хуҗалыкны исән-имин көе саклап сезнең кулга тапшырганнар. Беләсезме, сез югында болар дәүләт амбарына күпме икмәк тапшырганнар? Мин кырык беренче елгысын юри кертмим, чөнки анда сезнең дә катыш булган. Мин алам кырык ике, кырык өч, кырык дүртне.— Даутов блокнотын актарып бер сан әйтте.— Менә бит ничек! Ә бүген без, кадәри хәл дип әйтик, карточкалар булсын, кадәри хәл ярдәм турында бәхәс алып барабыз. Бу икмәкне амбардан чыгару-чыгармау мәсьәләсе тулысынча сезнең үз кулыгызда. Моны колхозчыларның гомуми җыелышы гына хәл итә. Сез уйлый күрмәгез, Даутов белән Сәләхиев сезнең кул белән үстерелгән икмәкне кычкыртып алып «Ватан» колхозы өчен озаттырырга килгәннәр, дип. Мәсьәлә һич тә анда түгел. Дәүләтнең экономикасы сезнең дүрт йөз центнер икмәгегезгә терәлеп калмаган, үзегезчә әйтсәк, хөкүмәт аның белән генә үлми. Мәсьәлә монда сезнең карашыгызда. Социалистик системаның бөтен өстенлеге шунда ки, анда бер колхозчы ярлы, икенчесе бай, бер колхоз алда, икенчесе артта булган көе яшәү мөмкин түгел. Социалистик система ул — кешеләрнең дә, колхозларның да, өлкәләрнең дә, һәм, ниһаять, бөтен социалистик лагерь илләренең дә алга таба бергәләп, кулга-кул тотынышып барулары дигән сүз. Безнең бөтен өстенлегебез әнә шул бердәмлектә. Буржуаз идеологиядән бөтен өстенлегебез дә әнә шунда. Сезнең әле күптән түгел генә чыккан «Ак төннәр» дигән әсәрне укыганыгыз бармы? Яшь язучы, фронтовик Габдрахман Әпсәләмов әсәре. Әнә шунда бер кызыклы эпизод бар. Сазлык. Кешене суыра торган үлем сазлыгы. Шунда безнең бер солдат егылып төшә. Бата башлый. Иптәшләре дошманның борын астында шул солдатны үлемнән коткаралар. Актык минутында коткаралар. Зур газап белән, үлем куркынычы астында коткаралар. Ләкин шул ук сазлыкка бераздан фашист солдаты да килеп эләгә. Ул да бата башлый. Күзләрен мөлдерәтеп, ул да ярдәм сорый. Аның иптәшләре нишлиләр дисезме? Ярдәм кулы сузып карыйлар да, булмастаен белгәч, тегене батырып ук китәләр. Күрдегезме ике төрле моральнең аермасын? Я, ничек, Әкрәметдин иптәш? Колга сузабызмы, бау сузабызмы, кулыбызны бирәбезме авыр хәлдәге күршеләргә, әллә юкмы?

Даутов трибунага кире кайтты. Халык инде тып-тын калып тыңлый иде.

— Һәм соңгысы, иптәшләр. Районда, республикада сездән дә хәлле-рәк, сездән дә шәбрәк колхозлар бар. Сезгә әле алар артыннан куып житәргә күп кирәк. Ләкин күршедә генә ызандаш колхозыгыз авыр хәлдә. Сезгә нишләргә? Сезнең колхозның чагыштырмача алда булуы — сезнең намуслы хезмәтегез нәтиҗәсе. Мондый очракта борынгылар нәрсә дигән? «Югарыга карап фикер ит, түбәнгә карап шөкер ит».

Даутов урынына барып утырды. Халык аның чыгышы бу урында өзелер дип һич тә көтмәгән иде. Даутов үзенең чыгышында иң төп мәсьәлә — өстәмә икмәк чыгару мәсьәләсенә — иң аз вакыт, иң аз игътибар бирде. Берни дә сорамады. Ялынмады, янамады. Менә хәзер дә тыныч кына Гыйләҗ абзый белән сөйләшеп утыра. Гыйләҗ абзый урыныннан торды.

— Колхозчы иптәшләр... Значит, болай. Без бик озак утырдык. Әле концерт та бар, диләр. Мал карар вакыт житеп килә. Ферма эшче-

ләренең дә вакыты бетеп бара. Чыгып сөйләүчеләр булырмы? Юк... Значит, болай. Кем дә кем...

Бөтен зал ризалык белдереп кул күтәрде. Даутов папирос кабызды, тирән итеп бер суырды да сәхнә артына кереп китте.

Сәхнә артында мәктәп белән клуб арасында йөгереп алҗыган Нәсимә балалар белән мәш килә иде. Даутов аның белән исәнләште. Нәсимәнең ике бит уртасы кып-кызыл иде. Оялудан түгел, йөгерүдән түгел, иннек сөртүдән дә түгел. Юк, үзе генә белгән әмәле бар аның. Клубка керер алдыннан, сәхнәгә чыгар алдыннан ул һәрвакыт ике бит уртасын борып чеметә. Аның кызыллыгы озакка бара, андый кызыллык матур да була. Тик бу кызыллыкны Гөлчирә генә үзенчә аңлата.

— Бит уртаң кызыл булдымы — дөньяда торма инде. Тучны гына авыру билгесе инде ул. Әнә Нәсимә мескенне кара... — дип, җае килгәндә сөйләп ала.

Гөлчирә ялгышты. Концерттан соң район кунаклары аларга түгел, Рушад квартирасына киттеләр. Гайнелвафа карчык сарык итеннән тәмле аш әзерләгән, сөткә бүрттереп тары боткасы пешергән иде. Даутов монда килеп кергәч, райком секретаре икәнен онытты, аш янында гел уен-көлке сөйләде.

— Безнең, — диде, — армиядә вакытта полкның докторы бар иде. Гадәттән тыш ялкау. Шунысы кызык — бөтен төрле җәрәхәткә бер генә төрле дару — яшел мазь бирә. Әле шушы ботканы күргәч искә төште ул доктор. Аш пешкәч, устав буенча башта пробаны доктор алырга тиеш бит. Поварның журналына язарга тиеш. Фәлән-фәлән ризык, әйбәт әзерләнгән, личный составка бирергә рөхсәт дип кул куя. Аннан соң командир да яза. Бер вакыт полк командиры белән без дә проба алдык, журналны ачтык, докторның язуын карыйбыз. Һични аңлап булырлык түгел. Докторлар болай да адәм аңламаслык итеп язалар, ә монда гомумән, санскрит язуы. Тырыша торгач хәрефләрен таныдык. «Пш. кш. пр. хр. П. к. м/с Соловьев» дип язган да куйган. Командир дулый башлады — настроение начар — оборонада ятабыз бит. Ну-ка, мать вашу, докторны чакырыгыз, ди. Килде. Расшифруй, разгильдяй, дип кычкыра тегенә командир. Нәрсә килеп чыкты дип уйлыйсыз?

«Пшенная каша, приготовлена хорошо, подполковник медицинской службы Соловьев» дигән сүз икән.

— Монда утыруы бик күңелле, — диде Даутов. — Безгә юлга чыгарга вакыт түгел микән, иптәш председатель?

Кара чана җигелгән райком аты моннан кырык еллар элек Галиәхмәт үз кулы белән каккан капка бәйләнгән, аякларын алыштыргалап солы ашый иде. Капка ачылуга, каршы йорттан толыплар күтәргән кучер килеп чыкты һәм кошевка эчендәге коры печәнне аяк башына җайлап түшәргә тотынды.

Кара чана күздән югалгач, Акбалык ятим калган сыман булды. Рушадның өенә керәсе килми иде.

Менә шул чана артыннан чыгып йөгерергә иде, ат тизәкләре чәчелеп тапталган маяклы юлдан чабарга-чабарга, үпкә тутырып кышкы чиста һаваны суларга иде. Барырга, барырга, әллә ничә горизонтны узарга иде. Шул озын юлда битеңә бәреп буран чыксын, дөньяны буран томаласын иде. Шул буран эченнән ялгыз барган вакытта маяклар арасыннан карга баткан, керфекләренә буран сырышкан бер кыз бала чыксын да йөрәк өзгеч тавыш белән:

— Рушад аб-бый! Җан-ным-м! — дисен иде. Һәм, әлбәттә, ул кыз — Ләйләгөл булсын иде...

Караңгы төшеп килә. Җәяүле буран чыгарга маташа. Кырда шәптер! Анда маяклар шаулыйдыр, еракгагы авылларның утлары тылсымлы әкиятләрдәге кебек серле итеп җемелдиләрдер, кар диңгезе өстеннән авылга таба бүре киләдер, көр куяннар елга буйларындагы кар куыш-

ларына кереп буранны уздырырга жыеналардыр. Райком атының тоягыннан кучерның битенә кар кисәкләре атыладыр, ат юрткан көйгә аның дугасындагы божра шелт-шелт бәрелеп барадыр. Район үзәгенә кайтып житкәч, кучер башта Гатаны үз квартиры янында төшереп калдырыр, жылы якты өйдә Гатаны айның үндүртенче кичәседәй ялт итеп Эльза каршы алыр, өстәлгә табын әзерли башлар. Аннан Даутов та өенә кайтып керер. Разия Вәлиевна дәфтәр тикшереп утырган жиреннән кузгалыр, ишек янына ук килеп ирен каршы алыр һәм әйтер:

— Әтисе, Ләйләгелдән хат бар, — дияр...

Кайдан, кайсы шәһәрдән ул хат?

Их, буран булып жир өстен бер ялап узсан иде, яки маяк булып шул буранда бөтен жир шарына сызгыра-сызгыра бер жыр жырласан иде...

## XXIV

Сагыш — адәм баласының мәңгелек юлдашы. Бу ник шулай? Адәм баласы гомеренең кадерен, яшәүнең тәмен белсен өчен. Кеше үткән көнен, үткән атнасын, үткән елын сагына. Авырлык белән үткән булса да сагына. Бу — ник шулай? Чөнки кеше үзенең яшь вакытын сагына.

Елның иң сагышлы вакыты кайчан?

...Нәркис өчен, мәсәлән, иң сагышлы вакыт яз көне, ташу вакыты булыр, ахрысы. Ул инде отпускадан килеп эшли башлады, нәкъ Заһирның үзе төсле зур башлы бер малай тапты, укытучылар бүлмәсенә килгәч тәнәфестә бөтен сөйләгәне шул малай турында. Мостафа да, директор да, кара егет тә бу баланың ничә кило да ничә грамм булып тууын, беренче тапкыр әнисе янына алып кергәч аның ни форма китереп кычкыруын, соңгы көннәрдә кай төшләре бозылуын гадәттән тыш төгәллек белән беләләр иде. Бу хикәяләр бары тик Рушад өчен генә сөйләнми калдылар, тормышы никадәр генә бөтен булса да, вакыт-вакыт Нәркиснең йөрәге сулыгып-сулыгып сызлап ала иде, — баштарак ул моны бала тапканнан дип белеп йөрде. Аһ, шайтан! Һич тә аннан түгел, ә кайвакытларда теге, узган елны ут жибәргән язгы төн аның хәтеренә төшкәндә йөрәк сулыгып ала икән...

Кайвакытта вак соры яңгыр ява — бу көзен була — озак итеп, үзәгенә үтеп ява. Ул көне буе, төне буе, атна буе ява, күкрәүсез, жилсез гел бер үк төрле тамчылар белән, бер үк төрле кыеклыктан ява. Ул синең жәйге күңел ашкынуларыңны, тын бетәрлек рәхәт дулкынланулардан калган йөрәк сырларыңны күмә, тигезли, ул сине сыный. Тормыш ул вакытта тоташ вак яңгырдан гына тора — авылга хәтта почта да килми, мәктәп караңгы була, бер-береңнән туясың. Мондый көннәр Рушад өчен бик авыр була, ул жанына урын таба алмый аптырагач, биләмче хатындай, Мостафага китә. Мостафа — кайгысы никадәр генә зур булмасын — оптимист кеше, дәртле, темпераментлы кеше... иде. Әйе, әйе, иде... Менә тагын яз житте, тагын жир йөзе хәтфә уҗымнарын ләйсән белән юды, тагын алмагачлар чәчәккә бөреләнде. Мостафа Акбалык авылында инде кайнап торган энергиясенең нәтижәсен күрә башлаган иде: мәктәп алмагачлар эчендә утыра; һәр колхозчы, колагына тукый, питомниктан кайтарта торгач, унар-унбишәр төп алмагач утыртты, колхоз да тау буенда сигез гектарлык урында бакча үстерә башлады. Мостафа кайтарткан, аның киңәше белән утыртылган агачлар быел беренче мәртәбә чәчәк аттылар — Акбалык ак чәчәккә чумды. Шатлан, Мостафа, бу — синең еллар буе халык алдында укыган лекцияләрең, район газетасындагы вәгазьләрең, район, колхоз житәкчеләренең жанына тынгылык бирмичә йөргән көннәреңнең нәтижәсе. Син Акбалык авылын элек үзең яшәгән Ворошиловград өлкәсе төсле итеп күрергә теләгән идең — менә беренче нәтижәләр — ак чәчәкләр. Ләкин харап кына булды

Мостафа. Моны әле кеше белми, мона әле Мостафа үзе дә ышанмый. Тик белеп тора Мостафа, ана бу язда әллә ни генә булды, анын йөрәгенә хәсрәт белән каткан юшкын кинәт кенә чәрдәкләнде дә юк булды, йөрәккә урнашкан кара кан да сиздермичә генә бетте. Кан сафланды, Мостафага быелгы яз геруча зур дулкынлану алып килде, бу дулкынлану аны дәрестән соң кырга алып чыгып китә иде.

...Үжым басуыннан барасын, юл буйларында әле язгы сулардан калган җәрәхәтләр, әле язгы ташу эзләре. Еракта рәшә тирбәлә, басу уртасындагы ялгыз агач пенсиягә чыккан карт укытучыдай сина карап тора — ул сина шул басуларнын, күз күреме җирдәге авылларнын тарихын моң катыш сөйләргә әзер...

Юк, ни генә әйтмәгез, табигатьнең ин монлы, иң сагышлы вакыты — май ахыры. Бу көннәрдә кояш нуры әллә ниткән зәңгәр томан аша төшә, көньяктан җылы җил исә, ул җил дымлы балчык, балык тәңкәсе исе алып килә... Барасын, барасың, жилгә борынынңы куеп барасын, менә шунда еракта басу уртасында тирән ерганак күренә. Акбалык авылында әндый ерганакларны «коры елга» дип йөртәләр... Шул коры елга күрендеме — бетте инде! Яшел басу уртасындагы шул елганын көньяк яр буенда тирән кар катлавы калган. Калган һәм пычранган. Иллә дә үзәкне өзә шул кар катлавына карасаң. Анын өстенә инде тузан куптарып җилләр искән, ул кар инде тыгызланган, ямьсезләнгән, көнтөн саркың, тамчылап утыра — бер кызыгы да юк. Бу — узган гомер. Ләкин күнелегезгә тузан кунса, йөрәгегез тыныч, рухсыз типсә, чыгыгыз сез май ахырында кырга, эзләп табыгыз шундый кар тавын — билләһи, күнелегез кузгалыр, йөрәккә кан ишелеп-ишелеп килер. Әнә шул күренеш Мостафаны инде ничә көннәр буе дәрестән соң кырда йөртә, ничә көннәр инде Мостафа язгы җилгә авызын куеп йөрәк түреннән чыккан тавыш белән җырлый.

Чыгаем китием дагълар каршына,
Атымны ялгыз кабер ташыма.
Нилэр килер, кичәр егет башына,
    Сезгә мәгълүм улсын — алды гамь мине,
    Ашады, бетерде бу дәрт мине.

Авыр, бик авыр Мостафанын хәле.

Чөнки... ул гашыйк булды. Әйе, бер дә киметмичә әйткәндә, гыйшык утына чумды. Кемгә гашыйк булды? Нәркискәме? Я, бигрәк инде, ир хатынына гашыйк булырга башына тай типкәнме әллә анын? Хәер, гыйшык тегесен-бусын сорап торамыни ул? Синен ирепдә анын ни эше бар? Гөлчирәме? Юк ла, Мостафа бу хатынның җырлый белмәгән көе жырчы дигән дан күтәрергә тырышып йөрүен һич тә яратмады, гафу итә алмады. Миңжамалгамы? Әй, бигрәк тагы, әллә кайларда институт тәмамлап, әллә нинди җирләр күргән Мостафа нигә инде бала итәкле күлмәк кигән, маңгаена чыккан чәчләре онга, печән чүбенә буялган бу мәхлук хатынга күз салсын?

Мостафа гашыйк булды... Хәлимәгә!

Юктан гына башланды...

Хәер, зур эшләр зурдан башланамыни?

Иртәгесен булачак дәрескә Хәлимә приборлар хәзерли иде. Мостафа нигәдер, күрәчәгенә каршымы, анын кабинетына керде. Хәлимә янына килде һәм спирт лампасы кабызып торган кызның йомшак җилкәсенә кулын куйды. Куйды. Һәм шуннан ала алмады. Әлләниләр гена булды, әллә ниләр генә булды... Күрәсең, бу керү очраклы керү булмагандыр. Мостафаның алмагач кайрысы төсле булып беткән кулы да теге кызыйның җилкәсенә очраклы куелмагандыр. Моны Мостафа белеп, аңлап эшләмәгәндер, ләкин анын халәте рухиясе бу минутка күптән әзер-

ләнгәндер. Мостафа бу очракта күптән бөялеп килгән әнә шул хисләренең колына әверелгәндер...

Шул көннән башлап алар икесе дә үзгәрделәр. Хәлимә еш кына, бер сәбәпсезгә, елап ала торган булды, Мостафаның хәтере таркауланды, кеше сүзенә игътибары кимеде, кеше белән сөйләшкәндә бер сәбәпсезгә кинәт кенә кызарынып, каушап кала башлады. Моны сиздеҗләр, прогнозлар зур төгәллек белән бирелделәр һәм беркем дә шикләнмәслек бер нәтиҗәгә килделәр: Мостафа белән Хәлимәнең йөрәкләре арасында чит кеше күзенә күренер-күренмәс кенә булып ефәк җеп сузылган. Моңа башта аптырадылар, ахырдан көлделәр: мәхәббәт җәмал теләмәс, диләр. Ул арада Хәлимә дә бу хәленә иялəнеп сизелерлек рәвештә кыюланды, коридорда җырлап йөри башлады, үзенә сүз салып караган башлангычның кара егеткә кан дошман булды. Рушад белән сөйләшмәскә тырышты. Кызык инде бу кыз бала! Сөй сон, ярат, теләсәң кияүгә чык! Тик менә башка кешегә карата нигә мөнәсәбәтенне үзгәртергә?

Хәер, бу яңалыкка шактый сәерсенеп караучылар да булмады түгел. Минҗамал, мәсәлән, моңа чын йөрәктән рәнҗеде. Кыз бала икәнсең — ирләргә тимә! Егетләр беткәнмени? Мостафа кебек бәхетсезлеккә очраган тол ирләрнең язмышын хәл итешергә, аларга ярдәм итәргә тол хатыннар да бетмәгән бит! Мәсәлән...

Хушият карт, бу хәбәрне ишеткәч, бик әсәренде. Андый вакытта картның баш миендә яшен тизлеге белән бер генә сүз туа ала, ул сүз туганда ук, әле телдә фонетик яктан яңгыраганчы ук, орфографик хата белән туа. Хушият карт мондый очракларда «марал таркаулык» дигән сүзне куллана. Карт бер-ике тапкыр мәктәпкә килеп китте. Пенсионер укытучы тик торганда гына үзе эшләгән мәктәпкә килеп чыкса, көт тә тор — бер кыек ягыңны тапмыйча калмас. Өенә кайткач, карт кибеп беткән кара савытына самовардан җылы су агызды, каләмен әзерләде. Ләкин оныкны карау тулысы белән аның өстендә иде, һәм бәләкәй разбойник картка атналар буена ике-өч сәгать кенә булса да тыныч вакыт бирмәде — кара савыты яңадан кипте. Ә җәй башында исә киленнең яңадан бер онык алып кайтырга йөрүе мәгълүм булды — әйтерсең кайнатасының пенсиягә чыгуын гына көткән. Алты-җиде ел баласыз йөргән хатын шулай итеп элеккене кайтарырга кереште. Бала дигән нәрсә бер адресыңны белмәсен... Белеп алса — ут яктысына килгән күбәләк кебек инде алар. «Марал таркаулык» шулай итеп картның башында калды, кәгазьгә төшә алмады...

Хәлимә исә дөньяда мондый яман уйлар белән йөрүчеләр бардыр дип башына да китермәде, үзенең яңа хәленә тиз күнде. Аның күңеле, ахрысы, эчтән генә бу хәлгә күз буе, кыш буе әзерләнгән иде — узган көз үк инде кызый үзенең хисләрендә әллә нинди зур, котылгысыз борылыш булганын сизгән иде. Бу борылыш һич тә кешеләргә карата түгел, конкрет вакыйгага карата да түгел, ә табигатькә мөнәсәбәттә сизелде. Узган көз әллә ничек кенә үзенчәлекле булды. Октябрь бәйрәмнәре үтте, җиргә кар төшмәде. Айлар буе юлда тузан булды, ноябрьның салкын, кыска көнендә агачлар ап-ак бәскә төренеп утырдылар. Хәлимә шәһәргә кайтканда авыл белән станция арасын әнә шундый сихри декорацияле урман буеннан уза иде — күзгә кыска көннең сөрле тынлыгы, бәс кунган ак имәннәр, аяк астындагы тып-тын салкын туфрак күңелгә әллә нинди шом сала иде. Нәрсә бу? Табигатьнең үзгәрүеме? Хиросимадагы шартлатуның планета һавасына тәэсиреме? Хәлимәнең эчке дөньясындагы үзгәрешме? Шәһәрдән төяп тутырган сумкаларын агач төбенә куеп, Хәлимә урман читендә озак-озак уйланып утыра иде — менә әллә кайда гына, шомлы тынлык, ярым караңгылык патшалыгының тынычлыгын бозып, бер ботак сынып куя, кайдадыр еракта кыска ачы тавыш белән кинәт кенә карга кычкырып

ала, соры авыр болытлы һавада зираттан урманга очып килүче карт козгынның үзәк өзгеч шөбһәле тавышы яңгырап ала.

— Конкъ! Конкъ!

Ул арада иң биек агачлар гына сизәрлек талгын җил исеп куя, төпләре кызыл энә белән тулы, кәүсәләрен зәңгәр сакал баскан карт кара чыршыларның берсе котчыккыч чиркәнеч тавыш белән шыгырдап ала — ул я ике тармаклы булып үскән дә, картайгач аерылган, я ул гомере буе күршесе белән тар урынга сыеша алмыйча яшәгән дә картаймыш көнендә язмышыннан зарлана. Карт чыршы шыгырдый — әйтерсең лә җир шарының тешен суыралар...

Хәлимә әнә шулай үзе үскән шәһәр мөхитеннән акрынлап бизде, авылның тын урамнары, озын кичләре, томанлы иртәләре, белемгә атлыгып торган, колак тишекләренә балчык кунган малайлары аны әсир иттеләр, кызый үзгәрде дә үзгәрде. Инде, инде... Мостафа...

Хәерле генә булсын, берүк хәерле генә булсын бу эшнең ахыры...

Сагыш картларны бигрәк тә ярата. Карты үлгәч, Гайнелвафа карчыкның да көндәлек юлдашына әйләнде ул. Бар иде заманнар — ул вакытта әле сугыш та юк иде, әле балалар да үзләре янында иде, Галиәхмәт белән Гайнелвафа һәр җәй башында уҗым карарга чыгалар иде. Менә монысы беренче бригада арышы — инде калкып килә, Галиәхмәтнең күпме көче кергән бу арышка. Хәер, карчыгыныкы да. Карчыгы гомере буе амбарда эшләде. Менә ул арыш инде йомшак җилгә уйнаклап утыра, аның өстендә тургай моңы. Уҗым басуы уртасындагы юлдан барганда карчык үзенең яшь, таза вакытына — буй җиткән кыз вакытына әйләнеп кайткандай була. Уҗым басуыннан атлавы рәхәт! Бу дөньяда арыш үстермәгән җирләр бар, диләр. Ул халыклар нәрсә дип яши икән? Аннан урман... Басу түрендә генә чыршы, имән, өрәңге катыш урман. Агач төпләрендә күч-күч абагалар. Карт имән очларында күке. Карчык гомерен санатырга ярата иде.

— Күк-ке! Минем гомерем күпме?

Урман мәхлугы карчыкка карата һәрвакыт диярлек шәфкатьле булды. Һәр елның җәй башында Гайнелвафа карчыкка ул юмарт кына гомер вәгъдә итә иде.

— Күк-кү, күк-кү, күк-кү...

Ә менә Галиәхмәт карт бер тапкыр да күкедән гомер сорамады... Рәхәт, күңелле заманнар булган икән ул. Ул вакытта эч пошуның, сагышның нәрсә икәне дә беленмәгән икән... Балалы кеше ятим булмый дип сөйлиләр. Белеп әйтмиләр. Улың бар, асабаң бар, имеш. Чукрак кына булсын, акрын, пошмас булсын, ләкин йорт башы исән булсын икән. Белеп әйткәннәр: утыз улың булганчы, шыгырдык ирең булсачы...

Әйе, булсачы.

## XXV

Шәһәр читендә, тимер юлдан ерак түгел генә бер бушлыкта бараклар тезелеп киткән. Акшарга буялган шыксыз стеналар, толь белән япкан кара түбәләр. Беренче, икенче, өченче... сигезенче барак дип санап йөртәләр. Шул баракларның өч-дүрте «Яшьләр тулай торагы» дип йөртелә. Монда сугыш вакытында ФЗУга, хезмәт резервларына алынган авыл яшьләре торалар. Кайберләре инде өйләнешеп беткәннәр, дүрт кешелек бүлмәләрдә уртага простыня корып икешәр квартир ясаганнар. Монда тормыш арифметикасы бик гади, монда шапырынулы сүзләр юк. Сугышта җимерелгән илнең экономикасын аякка бастырырга кирәк. Хөкүмәт эшчеләр сыйныфыннан фидакарь хезмәт таләп итә. Тырышып эшләгән кешенең хезмәт хакы мул — эшлә генә. Парлылар квартир

алуны өмет итеп яшиләр. Инде эшкә чыкмыйча туры кин күлмәк киеп йөрүче, битләренә кара чатыр ябышкан яшь хатыннар да күренә. Өйләнгәннәрнең эше хутта: эштән кайтышына керогаз өстендә нәрсәдер чытырдап кыза, бөтен коридорны көнбагыш мае, балык, колбаса исе баскан, бераүләр инде гармун кычкырталар.

Ләйләгөл әнә шунда яши.

Киң комбинезон, тапочкалар киеп кызлар, егетләр белән бергә эштән кайта, якындагы ашханәгә кереп ашый. Аның бүлмәдәшләре алты-җиде класс тәмамлаган авыл кызлары — Ләйләгөлнең алар алдында абруе зур. Дөрес, кайвакытта аңа «начальник кызы» дип кырын карашлар булгалый, ләкин Ләйләгөл бер генә сүзе, хәрәкәте белән дә үзен алардан өстен куймый. Башкалар эшләгән акчаларыннан ата-аналарына өлеш чыгаралар, Ләйләгөлнең исә бөтен тапканы үзенә. Шуңа күрә кием-салым алырга кирәк булганда еш кына аннан акча сорап торалар, аның белән сер уртаклашалар. Тәзелешкә урнашып эшли башлауга нинди юллар белән аның кем кызы икәнлеген белеп алдылар, гаҗәпләнүчеләр аз булмады. Баштарак аңа «ак кул», «ак сөяк» дигән исем тагучылар да бар иде. Бераздан аның тирәсендә егетләр чуала башлады. Башта берсе, аннан икенчесе... Артык җинел уйлаучылардан берсе шулай бер вакыт кич белән ансат кына бүлмәгә килеп керде,— Ләйләгөл ялгызы гына физика дәреслеген укып утыра иде — егет күзләрен майландырып өстәлгә бер шешә чыгарып куйды. Ул арада җинүче кыяфәте белән Ләйләгөлнең муеныннан урап алып үзенә таба тартты. Аракы, тәмәке, одеколон исе Ләйләгөлнең борынына килеп бәрелде. Шунда яшь кызның үз гомерендә беренче тапкыр ачудан тыны кысылды. Егетнең кулыннан сельдь балыгыдай шуып чыкты да... бөтен көченә тегенең яңагына чалтыратып җибәрде. Аннары өстәлдәге теге шешәне алды да ачык тәрәзәдән тышка тондырды. Физиканың нинди законы нигезендәдер шешә ватылганда каты шартлау тавышы ишетелде. Кеше бер усалланмасын... Аннан барысын да көт. Әле тын да алмаган килеш егетнең җиңеннән тотты да ишекне ачып артына типте. Егет таза иде, ләкин көтелмәгән хәлдән югалып калды һәм коридорга чыккач кына айныды. Ишекне япканда Ләйләгөл инде тын алган иде, ясалма елмайды һәм егеткә:

— Курыкма, үзең сөйләмәсәң, мин беркемгә дә әйтмәм,— диде.

Ләкин егет намуслы булып чыкты, үзенең җиңелүен иптәш егетләренә сөйләде һәм шуның белән Ләйләгөлне күп бәйләнчекләрдән коткарды. Кыз бала үзен беренче тупас хәрәкәттән саклый белсен... Беренче сынауда алган билге кыз баланың бөтен гомере аттестатына чыга.

Бераздан Ләйләгөлне бригаданың комсоргы итеп сайладылар, физик эшкә күнекмәгән куллар инде нияләнде. Штукатурлык һөнәрен ул тиз үзләштерде. Аннары малярлыкка өйрәнә башлады. Яхшы сортлы буяу исе, лак исе аның башын әйләндерә иде, чөнки Николаевтагы кораб төзүчеләр институтына килгәч, консультация вакытында алар кораб макетлары куелган бер аудиториядә утырганнар иде. Буяуның иң затлы сортларын ул шунда күрде. Аудиториядәге яңа буяу исе аның канына, тәненә үтеп керде — шуннан бирле буяу күрүгә рәхәтлектән аның башы әйләнә торган булып калды. Алар яңа төзелеп ята торган заводның цехларында, идарәсендә, ашханәсендә эчке буяу эше белән шөгыльләнделәр — хезмәт хакы бик әйбәт килә иде. Шәһәр көннән-көн байый бара, сугыштан соң әле рәтләнеп җитә алмаган кибетләргә көннән-көн яңа товарлар чыга тора. Шуңа күрә яшьләрнең күңел көр иде. Баракларның берсе клуб итеп файдаланыла иде — көн саен дип әйтерлек трофей фильмнар күрсәтелә. Кыш җитүгә, төзелеш трестының комсомол оешмасы яшьләрне кичке мәктәпкә тарту буенча кампания ачып җибәрде. Ләйләгөл үз бригадасында шуның буенча эш башларга тиеш иде. Ничек? Укыгыз, белем алыгыз, дип коры агитациядәнме?

Сирәк кенә анын янына әтисе белән әнисе килә. Хәер, алар бервакытта да баракка килмиләр. Алар Ләйләгөлне эш урыныннан табалар да кичен үзләре янына гостиницага чакыралар. Ләйләгөлгә алар мондый адымы өчен бернинди үпкә белдермәделәр. Киресенчә, Даутов ана сокланып карый иде. Әтисе хәтта үзе генә килгән вакытларында кызыннан бер-ике тапкыр ун-унбиш сум акча да алып торды.

— Зарплата алмаган әле, аз акча белән килгән идем,— дигән булды.

Бу — үзенә күрә Ләйләгөлнең мөстәкыйль кеше икәнлегенә ишарә ясау иде. Сөйләшүләрнең берсендә Ләйләгөлнең комсорг буларак бурычлары, яшьләрне кичке укуга тарту юллары турында сүз куерды. Даутов төнгә таба, җәяүләп, кызын озатып куйды.

— Мин, синең урында булсам, эшне шуннан башлар идем,— диде.— Менә без районда комсомол секретаренннан уңмадык. Бик шәп оратор, менә дигән итеп карар проекты яза — хет БМОга эшкә ал — бөтенесен матур итеп сөйли белә. Трибунада сөйләгәнен тыңлап торсаң, шул хәтле оста, шайтан, районның бөтен уңышларын — урып-җыюмы ул, урман хәзерләүме, юл төзүме, мәгариф эшеме — барысын да ул оештырган булып чыга.— Безнең яшьләр здорово эшләделәр, без здорово тырыштык,— ди. Бөтен сүзе шул. Ә инде түбәндәге оешмаларга килсәк — эш юк. Авылларда тәрбия эше белән партия оешмасы җитәкчелек итә, комсомол взнос җыя. Менә син алай булма. Мин нишләр идем? Иң беренче — иптәшләрең арасында китапка, белемгә ихтирам уят. Сездә китап укыйлармы?

— Бик аз шул, әти.

— Шулай да менә синең бүлмәдәш кызларың нәрсә укый?

— Кыш буена «Әбугалисина кыйссасы» аунап йөрде инде.

Даутов көлеп куйды.

— Әбугалисинаны уку — начар эш түгел. Ә менә син бүлмәләргә китап керт. Китап үтеп керсен. Аннан соң театрларга ничә тапкыр бергәләп бардыгыз?

— Мин бер кыз белән генә йөрим.

— Ә син ун билет алып кайт. Тарат. Син онытма, алар — колхозчыкрестьян балалары. Аларның балалык вакытына сугыш афәте туры килде — культура ягыннан алар, әлбәттә, шактый артта калдылар. Менә шулайрак тәэсир итәргә кирәк. Безнең заманда коры лозунг белән берни дә эшләп булмый. Җанлы эш, нәтиҗәле эш кирәк.

— Әти... Партком секретаре әйтә сиңа, ди, партиягә әзерләнергә кирәк, ди.

Даутов кулын кызының җилкәсенә куйды, үзенә таба кысты. Алар инде шәһәр читенә чыкканнар иде.

— Ах, син тишек борын! Кара син аны, ә? Нинди исәп кергән бит. Мин сиңа рекомендация үзем бирә алам — мин сиңа ышанам. Ләкин син бик сыек бит әле. Син әле тал чыбыгы. Әйе, тал чыбыгы.

— Ул әйтә, төзүчеләр арасында партиялеләр катлавын үстерергә кирәк, ди. Минем хезмәт күрсәткечләрем дә әйбәт, әти.

— Теләгең изге, кызым, ләкин үпкәләмә, син әле бик сыек. Синең әле кыйблаң юк. Я, син кем булырга телисең? Төзүчеме?

— Юк, әти, ул мәсьәлә минем өчен хәл ителгән инде. Быел августта мин яңадан сынау бирергә барам. Мин хәзерләнәм. Минем инде елга якын стажым да була бит.

— Яхшы, барырсың. Төзелеш, димәк, синең өчен бер трамплин гына. Син монда партиягә кандидат булып кереп, шау-шу күтәреп, августта китеп барсаң, беләсеңме, синең турында нәрсә дип әйтәчәкләр?

— Качты, дипме?

— Юк, хуже. Институтка керү өчен партиягә керде диячәкләр. Тегендә дә шикләнеп караулары мөмкин. Аннан соң әле син монда рекомендация дә таба алмыйсың.— Даутов кыза башлады.— Беләсеңме,

халыкара коммунистик хәрәкәтнең күренекле эшлеклесе Инесса Арманд нәрсә дип әйткән? «Коммунистлык исеме кешегә бик күп бурычлар йөкли, ләкин бер генә өстенлек бирә, ул — революция өчен беренче булып көрәшү өстенлеге». Так что, үзенә файда эзләп кенә йөргән кешеләргә партия сафында урын юк.

Барак янында алар аерылыштылар. Кышның салкын төнендә барак ишекләреннән аксыл пар чыга, анда-санда ышыкта кочаклашкан парлар тора иде. Салкын күккә завод морҗаларыннан кызгылт төтен күтәрелә, еракта паровозлар ухылдый, шәһәрдә соңгы трамвайлар чырылдаганы ишетелә. Салкын төндә җир шары завод морҗалары, паровозлары, мәхәббәт сүзләре, озын, тәбәнәк бараклары белән бергә сулый иде. Ак томанлы ишеккә кызы кереп киткәнче, Даутов еpактан карап торды...

...Менә бервакыт яз житте, тагын яз житте. Ләйләгөл узган елның язында район үзәкләренең берсендә иде — менә күчәбез, менә күчәбез дип борчылып йөргән вакытлар. Яз — кыз бала өчен иң хәтәр вакыт, кыз бала язын табигатьнең күндәм бер кисәкчәсенә әверелә. Аңа кояшлы көн дә, беренче яңгыр да, язгы җил дә тәэсир итә. Ләйләгөлнең тынгысыз тормышка аяк басканына менә хәзер бер ел тулды. Алар яшәгән район үзәгендә олы юл өстендә йөз яшәр биек таллар бар иде. Март аенда имтиханга хәзерләнеп иптәш кызлары яныннан кайтканда Ләйләгөл шул таллар яныннан уза иде. Март төнендә аларның шаулавы... Бик биектән, өем-өем болытлар арасыннан яшькелт-сары ай карый, көнбатыштан җылы тыгыз җил исә, ул җил нәкъ менә шул карт өянкеләргә кагылып уза — ә алар шомлы итеп шаулыйлар. Бу тавышка әсәрләнеп Ләйләгөлнең тыны кысыла, тамак төбе чатнап китә, ул, сихерләнгәндәй, бер урында басып кала — ә өянкеләр аның саен көчлерәк шаулыйлар. Алар биек шул, яз киләсен алар кешеләргә караганда алдарак сизенәләр шул... Ул таллар шулай шауладылар, шауладылар да Ләйләгөлне борчулы, әмма ләззәтле тормышка озаттылар. Алар юкка гына шауламаганнардыр. Кызык, быел да шаулыймы икән алар? Агач шаулаганын ишетсә, шуннан бирле Ләйләгөлнең йөрәге кызурак тибә башлый, тыны кысылып ала, сагыш баса. Кичен барак-клубтан чыкканда ул еш кына айга карап тора — менә бит борынгылар дөрес җырлаганнар! Культурасыз, белемсез борынгы халыклар да шулай ярата белделәрме икәнни? Алар да шулай, сагынганда айга карый белделәрме икәнни? Ул заманда да шулай яратырлык, Рушад абый кебек сөйкемле, акыллы егетләр булдымы икәнни? Ул да хәзер айга карап тормыймы икән? Бер генә күрешергә иде. Бер генә...

Ләкин айга озак карап торырга ярамый. Күрешү сәгатен якынайтыйм дисәң, тизрәк бүлмәңә кер дә имтиханнарга хәзерлән. Ләйләгөл керү имтиханнарында сызым буенча өчле алды. Тизрәк өстәлең янына, китаплар, кәгазьләр янына... Бары тик шулар гына синең очрашу сәгатеңне тизләтә ала. Бары тик үзеңнең төп максатыңа ирешкәч — кораб төзүчеләр институтына кергәч кенә — син үзеңнең кайда икәнлегеңне Рушад абыеңа белдерә алырсың. Ә аңарчы ул өйләнсә? Бу уйны Ләйләгөл күңеленнән гел куып җибәрә, ләкин төшендә Рушадны ул һәрвакыт чибәр, сылу бер кыз белән култыклашып барганын күрә. Бер тапкыр аларның кочаклашып торганнарын да күрде. Андый төннәрне ул йоклый алмый, баш очындагы лампасын яндыра да физика дәреслеген карап ята. Иртәгесен ул барысыннан да иртә тора һәм ашап-эчүгә үзенең бөтен төсле буяулар тамган комбинезонын киеп ала, эшкә чыгып китәр алдыннан көзге янына килә, кыек яулык астыннан чыккан чәчләрен рәтли, язгы җил ашаган бит урталарын сыпыргалый да теге сылу кызга телен чыгарып күрсәтә. Эш, эш, эш... Кулга пумала алгач, барысы да онытылган сыман була.

...Ул арада җәй дә житте.

Яшьлек кайда да үзенекен итә. Бараклар янындагы такырлыкта кичләрнең берендә бер төркем егетләр тәмәке тартып утырдылар. Икенче кичтә монда гармун да килде. Ике-өч кыз да күренде. Һәм китте җырлы уеннар... Кызлар, егетләр шәһәрдә яшәгәннәрен онытты-лар, трофей фильмнарның да дәрәҗәсе калмады. Көне буе кран асла-рында, түбә сыртларында балта, көрәк, мастерок, пумала тотып эшлә-гән яшьләр дөньяның бөтен мәшәкатен онытып, кулга-кул тотынышып шау итеп җырлыйлар, бер-берсенә мактау сүзләре әйтәләр, таныша-лар, хисләрен белдерәләр. Дөньяда әйтерсең лә мәһабәт күтәрү кран-нары, үкерә-үкерә кирпеч ташый торган машиналар, иләмсез авыр тимер-бетон корылмалар, шыксыз басынкы бараклар бөтенләй юк, ә бары тик агым сулар, шомырт чәчәкләре, сөрмәле күзләр, нечкә биләр һәм кыйгач кашлар гына бар... Җырдан файдаланып, яшьләр бер-берсенә әйтәсе килгән сүзләрен яралар да салалар. Читтә басып торучыларга чакыру ташлыйлар.

Безнең авылның кызлары
Аклы күлмәк кимиләр.
Җырламаган кызларны да
Остабикә димиләр.

Шәһәрдә яшәсәләр дә, «безнең авыл» дип җырлыйлар. Димәк, бу — алар өчен вакытлы гына бер хәл икән. Уенга кереп, җырламыйча үкчә ышкып йөрүчеләргә дә тынгылык бирмиләр.

Нигә, кызлар, җырламыйсыз,
Акча сорыйсыз мәллә?
Ярларыгыз булмаганга
Ямаң сулыйсыз мәллә?

Тегеләре дә тик тормый, дәррәү күтәрелеп җавап бирәләр — бар сүзгә дә әзер.

Акча да сорамыйбыз,
Ямаң да суламыйбыз,
Сез ярлы дип, без ярсыз дип,
Сездән яр сорамыйбыз.

Бер-ике мәртәбә бу уенга Ләйләгөл дә барып карады, ләкин бер көнне авыл кызларын карарга килгән Акком асты урамы егетләреннән чуар түбәтәйле берсе уенга кергәнче үк аңа бәйләнде. Ләйләгөл кау-шап калды. Нәкъ шул вакытта чуар түбәтәй каршына теге, баракка шешә тотып кергән егет килеп басты. Чуар түбәтәйнең яңагына бер генә менеп тә төште. Ләйләгөлне — ай күрде, кояш алды. Ул бик каты курыккан иде — элдерде. Ул арада чуар түбәтәйнең бер-ике иптәше килеп житте. Ләкин теге егет шактый таза булып чыкты, берүзе өч егет-не, күз ачып йомганчы, иләп ташлады. Бөтен кызлар алдында теге егетләр җиңелгән көе таярга мәҗбүр булдылар. Егет булып яшәү бик авыр бу дөньяда! Гел генә җиңеп торып булмый бит. Ләкин әйтәсен әйтеп киттеләр:

— Паркта очрашырбыз әле, шунда бер мөселманча сөйләшербез,— диделәр.

— Җаныңны фәлән итим, башыңны култык астына кыстырып җи-бәрәм әле мин синең, «Чаткы» тирәсендә очратмаммы,— дип янады чуар түбәтәй.

Таза егет аңысын куа ук китте. Ләкин теге каты элдертте.

Шул көннән соң, әлбәттә, барак янында Акком асты малайлары күренмәс булды.

...Ләйләгөл өчен иң авыры — сабан туе атнасы булды. Якын-тирә районнардан килгән яшьләр сабан туе алдыннан таралдылар да бет-

теләр. Ләйләгөлләр бригадасы күптән түгел генә шәһәр эчендәрәк ике катлы таш йортка күчеп тора башлаган иде. Ләйләгөлгә элеккеге иптәшләре белән бергә икенче каттан балконлы бүлмә бирделәр. Ничә әйтсәң дә комсорг бит! Түбәндәге чокырдан поезд юлы уза, урамга чыгып карасаң, җир тигезлегендә паровоз төтене генә пуфылдап өзгәләнеп кала. Йортның алгы ягы гел яшел чирәм, кызыл авызлы бер юан хатын көн саен анда сыра сата, чирәмлектә ир-ат күп була. Менә районнарда иртәгә сабан туе дигән көн җитте, ике катлы тулай торак бушап калды. Ерактан килгән берничә кыз, бер-ике егет калдылар, кичке якта алар да җыенып паркка чыгып киттеләр. Менә Акбалык ягына соңгы поезд узып китте, аның баскычлары, түбәсе тулы халык иде. Вагон түбәләрендә тальян тавышы ишетелде. Җәйге җылы кич иде — бу поезд күздән югалуга, шәһәр ятим, кызганыч булып калды. Сабан туе көнне кайта алмыйча таш калада калган авыл баласының хәлен бу дөньяда кем аңласын! Ләйләгөлнең төзелештә эшли башлаганнан бирле беренче тапкыр күңеле тулды, ул үзен ятим, кирәксез кеше итеп сизде. Менә хыял ычкынды, йөгәнен салып ташлады... Район үзәге. Тактадан ясаган трибунага менеп әтисе халыкны тәбрикли. Кырык җирдә кырык гармун тавышы, нафталин исе килгән ефәк күлмәкле авыл кызлары, күн итеген сыдырып кигән авыл егетләре — барысы да көнбагыш ашыйлар. Менә сугыштан кайтканнар, орден-медальләрен тула белән ялтыратканнар, вәкарь белән генә күрешәләр, әдәп белән генә, яшереп, бер читкә китеп кенә төшереп алалар, арбадагы кибетчедән пешкән ит алып тиз-тиз чәйниләр. Зур-зур сыра мичкәләре янында изүләрен чишкән кызгылт битле ирләр, күрәш күзәтүче дәрәҗәле, абруйлы картлар. Малай-шалай, халыкны ерып, трофей велосипедларда куышалар, гимнастерка якаларын чишкән погонлы, погонсыз егетләр кызларын култыклаганнар, акрын гына атлап, еракка-еракка су буйлап китеп баралар... Әйтерсең бөтен җир шары бүген бәйрәм итә, бөтен җир шары шулай сөешә, әйтерсең галәм киңлегендә зур-зур дәүләтләр бил алышалар. Менә... менә, тау кырыеннан гына ике егет килеп чыгалар, бер-берсенә иңнәре белән бәрешеп, җайга гына сөйләшеп киләләр. Икесе дә ак күлмәкләренең җиңнәрен сызганганнар, берсе зәңгәр офицер чалбарыннан, икенчесе кара киң чалбардан, биләндә яссы каеш, каешында якорь... Болар — Гата белән Рушад — ахирәтләр. Аһ! Күбәләк булып кына болын буйлап очсаң иде дә, сабан туе мәйданына килеп, шул ике егетнең чәчләренә бәрелә-бәрелә уйнасаң иде...

Ләкин Ләйләгөлнең хыялы чынбарлыктан бик тә ерак иде...

Ул балконда басып торганда Акбалык ягыннан иске яшел вагоннар таккан поезд килде, чокырдагы тимер юл төтен белән тулды. Ишекләре, тәрәзәләре ачык бу вагоннарда кешеләр юк дәрәҗәдә аз иде — Ләйләгөл һәр вагонны күздән кичерде. Тик урта вагонларның берсендә, тәрәзә янында гәпләшеп килгән ике егетне ул күрә алмады — паровоз төтене вагонга уралып комачаулады.

Бу ике егет — җәйге сессиягә килүче Гата белән Рушад иде.

Нихәл итәсең? Акыл иясе Сөләйман, имеш, үзенең яраннары белән йөрергә чыккан. Бер кибеткә кергәннәр. Кешеләрдән берәү кибеттә озаккарак чыдамлы аяк киеме эзли икән. Моны күреп Сөләйман елаган.

Урамга чыкканнар. Бер фәкыйрь кулын сузып акча теләнеп утыра икән. Сөләйман моны күреп кычкырып көлгән. Бераз киткәч, яраннары сораганнар:

— Ничөн сез сатучы ханәсендә егъладыңыз, ә фәкыйрьне күрүдән көлденез?

— Без,— дигән Сөләйман,— сатучы ханәсендә шуна егъладык: бичара адәм озакка чыдарлык аяк киеме сорамыш, әмма үзенең гоме-

ре ун-унбиш дәкыйка гына (минут) калмыш иде. Фәкыйрьне күргәч көлүебезнең сәбәбе исә ошбу: мискин адәм бездин бер тиен сорап ялварып утырыр, әмма нәкъ ул утырган йирдә бер чирек тирәнлектә сандык илә ун бең (мең) алтын күмелмешдер — ул шуны белми...

Кайда син, Сөләйман? Нигә ара-тирә син тимер юл буендагы шушы ике катлы төзүчеләр тулай торагына килгәләп китмисең?

Ләйләгөл кебек жиргә ингән фәрештәләр газаплы сөю утында янганда аз гына да ярдәмең тиярлек булмагач, синең акылыңнан, зирәклегеңнән ни файда?

## XXVI

Рушадның Акбалыкка килгәненә ни гомер узды — быел инде университет тәмамлый, әмма эшли башлавының беренче елы кадәр хисләргә бай, дулкынландыргыч елы башкача булмады. Аның гомере кич утырып контроль эш язу, төннәр буе сессиягә хәзерләнү, клубта халыкара темага лекция сөйләү, политуку дәресләре белән узды. Ләйләгөл эзсез югалды, Даутовлар да районнан күчеп киттеләр. Ул кыз акрынлап ерактагы томан эчендә югала барды, Рушад аның инде тышкы кыяфәтен дә оныта бара иде. Тик, ара-тирә үтә дә күңел бушап калганда гына әкияттәге серле кыздай Ләйләгөл килеп чыга һәм, күңел кылларына кагылып, Рушадка ягымлы караш ташлый иде. Кем белә, бәлки, кайчан да булса тормыш аларны очраштырыр әле. Тормыш бит сюрпризлар ясарга ярата. Кем белә? Бәлки, син аның белән һич тә көтмәгәндә шәһәрнең берәр хуҗалык кибетендә ботинкаңа гуталин сайлап яткан да очрашырсың? Бәлки, син аның белән иске сумкаңа миллек кыстырып Болак мунчасына кереп барганда ишектә бәрелешерсең?

Тормышның ритмы һәркемнең үзенчә. Мостафа соңгы ике ел эчендә дер селкенде. Хәлимә белән алар кавышканга ел тулды дигәндә Ворошиловградтан Мостафа исеменә русча язылган бер хат килеп төште. Хат — Мостафаның олы кызыннан иде. Мостафа кинәт кенә сафтан чыкты, атна буе мәктәпкә килә алмады, аучылар тарафыннан кысрыкланып уртага кертелгән яралы арысландай үрсәләнде — чыдый алмыйча, колхозның алма бакчасына барып әллә ничә тапкыр тәгәри-тәгәри елады. Кыз үзенең хатында кечкенә сеңелесенең теплушкада барганда үпкәсе шешүдән, энисенең Дрезден янындагы бер станциядә тифтән үлүен язган иде. Хәзер ул — украин егетендә кияүдә, бер уллары бар, ире цех начальнигы, үзе нормировщица икән. Мостафаның адресын ничек табуы да гаҗәпләнерлек иде. Заводта болар белән бер цехта техучилище тәмамлап килгән бер егет бар икән. Аның белән танышып, аралашып сөйләшә торгач, ул егет үз авылларында алма үстерү белән шөгыльләнгән бер укытучы турында сөйләп ташлый. Сөйләшүләрнең берсендә бу укытучының скрипкачы һәм җырчы икәнлеген дә телгә ала. Нормировщица шул вакытта егеттән бу укытучының исем-фамилиясен сорый һәм... кинәт кенә аңын югалта. Яшь токарь Акбалыкның Закиров фамилияле егет икән.

Мостафа Ворошиловградка кунакка чакырулы иде. Ул анда, әлбәттә, ялгыз барды. Чөнки аның бу кызы Хәлимәдән бер яшькә олырак иде. И дөнья! Беркемнең дә гаебе булмаган көе, кайвакытта әллә ничә кеше газап чигә. Кайвакытта синең шатлыгың газаплы, ә кайгың ләззәтле була! Ворошиловградтан Мостафа әллә ниткән яңа сорт алма орлыклары төяп кайтты, район питомнигында ул хәзер, мәктәптән аерылмаган көе, баш селекционер булып эшли иде.

Башлангыч класста укыткан кара егетнең дә Нәсимәгә өйләнеп, Мәсрүрә торган мәктәп йортына күчүенә инде өч ел була. Нәсимә ул егеткә өч ел эчендә ике малай бүләк итте, алар сыер асрыйлар, егерменләп эре тавыклары, алты баш сарыклары, яшелчә бакчалары бар...

Заһир Акбалыкта колхоз председателе булып эшли, читтән торып институтта укый, күптән түгел генә аны республика Верховный Советына депутат итеп сайладылар. Бодайдан уңыш алу буенча колхоз идарәсе югары күрсәткечләр бирде — Заһир турында «Известия» газетасында зур мәкалә басылып чыкты. Алар Мостафалар семьясы белән кунакка йөрешәләр, Заһир белән Мостафа бер-берсенә «баҗай» дип дәшәләр. Шәһәр кияүләре бит...

Рушад апрель аенда диплом эше яклады. Диплом эшенә бишле куйдылар — егетнең өстеннән тау төште. Шәһәр урамында кая барып бәрелергә белмичә озак йөрде. Адреслар бюросына кереп Ләйләгәлне эзләтеп карады. Бәлки, ул берәр ВУЗда укып йөридер? Ләкин Рушад аның исеме белән фамилиясеннән башка берни дә белми икән. Туган елы? Кем сораган аны... Туган җире? Райком секретарьларының кызлары туган җирне, бар, эзләп кара син!

Бер-ике көн шәһәрдә кагылып-сугылып йөргәч, ул әнисе янына кайтты. Әнисенең ишек алдын иңләп гөрләвек ага, карт тополь башында өздереп-өздереп сыерчык сайрый иде. Дипломны юарга Каюм килде. Рушад белән ул кинәт кенә «сез» дип сөйләшә башлады, янәсе, университет тәмамлагач, ничек инде «син» дип дәшәргә?

— Син бүген фронтовикларча сөйләшмисең, агайне,— диде Рушад.— Син шуны онытма: без синең белән япь-яшь көе бер институтны тәмамлаган идек инде. Ул — солдат институты. Ул — гаделлек, бөтен җир шары халыклары өчен изгелек институты иде — аның исеме — фашизмга каршы көрәш фронты. Так что, мин менә шуның документын алып кайттым.

Сафура апа өстәлгә каклаган каз турый иде, сүзгә катышмыйча гына ике егетнең бәхәсен тыңлады. Аңа шатлык та, кайгы да иде бүген. Шатлык — улы югары белем алган, университет тәмамлаган. Кайгы — кинәт кенә аның улы олыгаеп киткән. Олы чырай кергән, җилкәләр киңәйгән, күзләр җитдиләнгән. Япь-яшь егет иде бит әле!

Рушадның диплом өчен алган ялы биш айлык иде, Акбалыкка ул хәл белә генә барды. Диплом яклагач, кешеләрчә бер ял итәсе, укытучылар янына барып, алар дәрескә кереп киткәндә диванда газит карап утырып каласы, шахмат уйныйсы килгән иде.

Булмаса булмый икән!

Юк, булмаса булмый икән!

Укытучылар бүлмәсендә Рушадка повестка ята иде. «20 апрельдә иртән 10 сәгатькә районвоенкоматка килергә». Рушад иртәгесен анда иде инде.

— А, диңгезчегә сәлам! — дип, өстәл артындагы лейтенант аны якын танышларча каршы алды.— Сезне көтәләр, әйдәгез, озатыйм.

Өченче бүлмәдә чандыр гәүдәле, саргылт йөзле капитан утыра иде. Рушад военкомат офицерларын гомер-гомергә өнәп бетермәде. Тәмәке төтененә баткан булырлар, кулларында карандаш булыр, мәктәптән кайтышлый кинога акча сорап малае яки кызы кергән булыр — харап! Офицер — сугышчан постта яхшы.

— Так, так,— дип башлады капитан, аңа күтәрелеп карап.— Утырыгыз әле, нигә басып торасыз?

Ниндидер җитди сөйләшү булырга тиеш иде.

— Университет белән эш ничек сезнең?

— Әле генә тәмамладым. Бер атна.

— Отлично! Сезнең специальность ничек әле?

— Тарих укытучысы.

Капитан көлде.

— Юк, мин ВУС буенча дим, ВУЗ димим.
— Ә... Военно-учетный стол дисезме? Мин — торпедист.
— Фронтовик?
— Бер ел чамасы.
— Кайчан кайттыгыз?
— Икенче демобилизация.
— А... Иртә эләккәнсез икән. Теге, педагогларга кагылышлы приказ бит әле. Партиядә инде, билгеле?
— Әйе, учебный отрядта кергән идем. Корабка килгәнче үк.
— Так, так... Сезгә менә мондый документларны тутырырга кирәк булыр. Һәм хәзер үк...— Капитан Рушад алдына бланклар куйды.
— Аңламыйм, иптәш капитан.
— Укыгыз!
— «Личный листок офицерского состава».
— Аңладыгызмы?
— Никак нет!
— Аңларга приказ бирәм.
— Есть.
Аннан икесе дә көлештеләр. Тәмәке кабызгач, капитан рәсмилеген киметә төште.
— Менә мин күптән сорамакчы булам: ни өчен безнең коры җир гаскәрләрендә «Тыңлыйм» дип әйтәсе, ә сезнең фронтта бөтен командага «Есть» дип әйтәләр.
Рушад үзенең «гыйлемен» күрсәтте.
— Сез академиядә нинди тел өйрәндегез, иптәш капитан?
— Һәй, кая ул академия! Минем академия — утыз тугызынчы елга кадәр партия райкомында инструктор, аннан — действительнидә, аннан — Мәскәү оборонасы, Сталинград, Днепр һәм Прага.
— «Есть» — инглизләрдән кергән. Флотта алардан кергән сүз шактый. Дөресе — «йес» булырга тиеш. Инглизчә «әйе», «шулай» дигәнгә туры килә.
Капитан җитдиләнде.
— Менә сездәй укыган кеше белән бер утыру — бер гомер. Сез инде алдыгыздагы кәгазьнең дә мәгънәсен аңлагансыздыр.
— Төшенә башладым, иптәш капитан. Ләкин нигә кирәге бар әле моның?
— Сабый булмагыз, иптәш старшина. Сезгә запастагы офицер исеме биреләчәк. Запас — димәк, «на товсь» дигән сүз. Сезнең специальность буенча безнең районда нибары ике дингезче. Шуның берсе сез — югары белемле. Фронтовик. Сез онытмагыз: бу сугыш мәктәбен үткән кешеләрнең сугышчан тәҗрибәсе еллар узган саен кадерлерәк булыр. Әнә шуңа күрә Хәрби Округ сез һәм сездәй егетләр белән кызыксына башлады...
Көрешкән вакытта капитан гәүдәсен турайтты, җитез, кискен хәрәкәт белән кулын сузды.
— Берәр айдан сезне йолдыз белән тәбрикли алырмын дип ышанам...
Акбалыкта ятуның мәгънәсе юк иде (барыбер ял итеп булмый!). Рушад әнисе янына кайтты. Ялан аяк чирәмдә йөрде, кояшта кызынды. Хуҗалыкта эш юк — теләгәнчә тик йөр. Авылдан авылга йөргән укытучылар картлык көннәрендә, гадәттә, бер җиргә төпләнәләр, бәләкәй генә йорт сатып алалар, җыйнак кына утын сарае әмәлилләр... Аларның хайваннары булмый, ишек алларын куе чирәм баса, аларның өйләре чиста, пөхтә. Өйләрендә почмакта китап шүрлеге, ул шүрлектә, гадәттә, утызынчы елларда ук чыккан китаплар, методик журналлар һәм, әлбәттә, бик кадерле фотоальбом була — альбомда ул укытучының яшь вакытын чагылдырган рәсемнәр, җәйге курсларда төшкән кол-

лектив фотолар була. Шуларны актарып утыру бик авыр да, хәсрәтле дә... Менә яулыгын өчкеллэп бәйләгән, күкрәгенә МОПР значогы таккан яшь кыз — пионерлар белән мәктәп бакчасында яшелчә утырта. Шунда ук быргы, барабан, байрак... Син альбомнан башыңны күтәрәсен. Синен алдында картайган, чәчләре агарган, битләре жыерчыкланган карчык тора. Анын күзләрендә тирән сагышлы караш. Йөзендә яшьлек куәтенен инде чаткысы да калмаган. Ул куәт минутлап, дәреслэп, чиреклэп, еллап акрын-акрын яшь буынга бирелгән. Куәт беткән — бары тик тирән карашлы күзләр генә калган. Әнә ул, сагышлы йөзенә елмаю чыгарырга тырышып, сина чәй ясый, өлкән яшьтәге укытучылар чәйнен яхшы сортлысын гына куе итеп ясап эчәләр... Авыр мондый йортта чәй эчүе, шактый авыр!

Көннәрнен берендә Рушадка Акбалыктан телефонограмма килде: аны военком үзе чакырта икән. Әнисенен эче пошты. Иртән сүзсез генә чәй эчтеләр.

— И бала, бала...— дип авыр сулады әнисе.— Синнән дә аерырга маташалар бит мине. Картлык көнемдә синен балаларынны карап юанырмын дигән идем.

— Нигә, әни, мине өйләндермәскә дигән приказнын чыкканы юк бит әле.

— Анысы юк та... Күнелем сизә — тотмыйлар сине монда, болай телгә кергәч. Дөньяда жиде бала үстер икән. Бер бала — гел хәсрәт кенә була икән.

Районнын хәрби комиссары — юан гәүдәле, аксыл чәчле подполковник — Рушадны каршысына утыртты. Звонокка басты, ялтыр итекле теге таныш капитан кереп өстәл өстенә бер личное дело куйды. Аннан, ялт борылып, житез генә чыгып китте. Комиссар личное делоны актарды. Озак укыды. Рушад үрелеп карады — үзенен почергын таныды. Подполковник дәшмәде.

— ВУС буенча сезнен специальность... Так, так. Димәк, торпедист. Хәтәр көч. Куркыныч көч. Так. Өйләнмәгән. Тоже хәтәр. Куркыныч. Кызлар өчен. Ә? Партиядә? Так. Фронтта. Яхшы. Япь-яшь көе. Ә? Ну, ничек?

— Кызыксынырга рөхсәт итегез, иптәш подполковник?

— Флот адмиралы Кузнецовны беләсезме?

— Так точно. Тын океан флотынын командующие.

— Менә, менә. Шул кеше мина хат язган. Шулай, шулай дигән, анда сезнен районда бер егет мәктәптә тарих укытып йөри икән дигән, бер-ике елга минем янга килеп яшь малайларны да укытмасмы икән, дигән...

Рушад та шаяруга күчте.

— Монда мин барын белми лә ул...

— Белгән, билләһи, белгән. Менә язу бар. «Корабль хезмәте кече лейтенанты Р. Сулимовка республика Хәрби комиссариатына килергә» дигәннәр. Менә бит ничек... Беләләр, а как же, дингезчеләр бездә бармак белән санарлык. Небось, бөтен район кызлары да беләдер әле үзегезне? Ә? Беләбез без сезнен кебек шыпырт егетләрне...

Подполковник житди тонга күчте. Бу хәтле барысы да бер төсле булырлар икән!

— Сезнен әниегез ялгызмы? Пенсионерка? Билгеле, без анын фикерен белергә тиешбез. Сонгы сүз, һәрхәлдә, анықы. Ләкин сез ана мәсьәләнен житдилеген анлатыгыз. Ихтимал, анын янына без үзебез дә барып чыгарбыз. Анлагыз, иптәш кече лейтенант. Ватан сезнен тәжрибәне, сезнен белемне, сезнен яшьлегегезне сорый. Купшы фразамы? Ә?

— Юк, мин алай дип әйтмим. Мин үземне тыныч хезмәт кешесе дип исәплим.

— Ә мин? Пижама киеп ят иден диванда, ә, кроссворд чишеп? Яки бакчада редискага су сибеп йөрер идем хәзер, ә?

— Сез инде үзегезне шуна багышлагансыз.

— Юк шул, брат. Кырык беренче елның июнендә генә кидем мин хәрби форманы. Ә беләсезме, кем идем? Иң тыныч хезмәттә — институтта чит тел кафедрасының доценты идем. Менә бит ничек. Я, ярый, димәк, сез минем яңга киләсез... киләсез...— Подполковник өстәл календарен актарды.— Димәк, нәкъ ике көннән. Әниегез белән сөйләшеп. Аңлатыгыз, Ватан, партия сорый, диегез...

Сафура апа Рушадны капка төбендә каршы алды. Бер-берсенә караштылар һәм... барысын да аңладылар. Ана авыр сулады.

— Ичмасам, өй түбәсен генә дә яптыра алмый калдым син барында,— диде.

— Әни! Нигә алай дисең? Менә синең белән сөйләшергә куштылар. Син риза булмасаң, алмыйлар. Син нәрсә әйтәсең? Исән булса, әти нәрсә әйтер иде?

— Әтиеңнең нәрсә әйтәсен беләм мин, улым. Менә мин син югында аның бер дәфтәрен эзләп куйдым әле. Әйдә, өйгә кергәч күрсәтермен...

Таушалган күн тышлы бу дәфтәрне Рушадның малай вакытта күргәне бар иде. Ләкин бервакытта да укылмаган, ахрысы, ул. Аш янында дәфтәрне кызу-кызу актарды. Көндәлек дәфтәре икән. Әтисе яшь вакытында ук язып барган. Егерменче еллар. Утызынчы еллар. Төрле кара, төрле шрифт, төрле почерк.

«Коммунисты — правящая партия, которая пилит дрова, сражается на фронтах, грузит вагоны, расстреливает своих собственных членов, если они оказываются негодяями. Идите, товарищи, в эту партию».

*«Правда», 8 окт. 1919.*

«...Һәркайда һәм һәркайчан коммунизм идеяләрен яклагыз, үзегезне идеяле коммунистлар итеп тәрбияләгез. Коммунизм кешелекнең иң зур күпчелеге өчен файдалы, һәм аның көче нәкъ менә шунда...

...Әгәр сез уртак эш өчен янып-көеп йөрмисез икән, моның өчен соңыннан үз-үзегезне кыралмаячаксыз. Шкурниклык кешене түгел, бәлки, ярым җаннарны гына канәгатьләндерә ала.

Башны югары тот, иптәш! Бу көрәш бөтен хезмәтчел кешелек интересларың өчен алып барыла. Һәм куркаклар, түбән җанлы кешеләр генә ул көрәштән качарга мөмкиннәр».

*П. Заломов хатыннан.*

«Лениннан берничек тә тайпылмаска тырышуны кагыйдә итеп алырга кирәк. Безнең кешелек шартларында бу кеше чиксез дөрес тикшерү инстанциясе булып тора».

«Ленин белән бул — һәм эшең уң булыр».

*А. В. Луначарский.*

Соңгысын әтисе кырык беренче елның июнендә язган.

Әтисенең җавабы ачык иде.

Ана улын юлга әзерли башлады. Өйдә ике-өч көн буе киеренке тынлык хөкем сөрде. Ризалык биреп районнан кайткач, Рушад Акбалыкка китте. Иң башта Гайнелвафа карчык елады. Көзгә малае янына китәргә ниятләнгәнен белдереп хат яздыртты. Мәктәптә соңгы имтиханнар бара иде — Рушадның китү хәбәрен ишетеп тынсыз калдылар.

Рушад бүш классларда йөрде, укытучылар бүлмәсендә утырды. Аңа я директор, я завуч эш кушмыйлар, я аны балалар эзләп кермиләр. Ул хәзер — кискән икмәк. Тиз генә, кыска гына итеп Миңҗамал елап алды. Мостафа гел авыр сулады. Моңайды.

— Бу ни хәл бу, безнең мәктәптә егетләрне тотмыйлар,— диде.

Нәркис, күзләрен тутырып, Рушадка моңлы караш ташлады. Кыза-

рынды. Аннан кызу-кызу атлап коридорга чыгып китте. Бәлкыйс күңелсезләнде. Гөлчирә исә Рушадның формасы белән кызыксынды.

— Безгә воянный формадан төшкән бер карточкаңны җибәрерсең,— диде.

Авылда сабан туе буласы атна иде — авыл тулы кунаклар. Арада Рушадның укучылары да байтак икән. Кара колаклы малайлар чиста, таза егет булып, торна ботлы чандыр кызлар түгәрәкләнеп, купшыланып кайтканнар. Рушад бер кичкә кунарга калды. Ярты көн телефонда Гатаны эзләде — Гата эшкә чумган, авылларда йөри иде.

Кичке якта Рушад белән күрешергә кешеләр килә башлады. Көтелмәгәннәре көтелгәннәрдән күбрәк булды.

Иң башта Хушият килде.

Керде, күзлеген сөртте, баскычка утырды, хәл-әхвәл сорашты. Ниндәндер тартынды. Картның янына утырып, Рушад тәмәке кабызды.

— Кәеф-хәтерләр ничек соң, Хушият абзый?

— Һи-и, безнең картларныкын беләсең инде. Әле бүген кибеткә кердем. Халык чират тора, әйбәт селедка кайткан. Мин дә бастым. Кибетче кыз, беләсеңме, нәрсә ди? «Әйдә, сина нәрсә кирәк, чиратсыз гына бирим, кибетнең шикелен кортып торма», ди. Билләһи!..

— Ну-у, бу инде әдәпсезлек.

— Юк, мин ана үпкәләмәдем. Картлык — матурлык түгел. Бөтен матурлык — яшьлектә.

— Өйгә керик соң, Хушият абзый.

— Юк, энем, рәхмәт. Мин, ни, күрешергә дип килдем. Син тиз генә кайта алмассың, минем гомер күп калмады. Рөхсәт итсәң, мин инде бәхилләшергә килдем.

Рушадка уңайсыз булып китте. Бу арада күпме сүз — күпме дулкынлану!

— Я, нигә алай үләргә ашыгасыз?

Хушият карт изүен чиште.

— Тыңларга вакытың булса, бер сүз сөйләр идем, энем.

— Тыңлыйм, Хушият абзый, рәхим итегез...

— Мин инде синең белән икенче күрешә алмам. Гафу ит дип әйтимме, әллә башкача әйтимме, анысын үзем дә белмим. Әмма мин гөнаһлы синең каршында, олан. Әтиең хәбәрсез югалгач, яман сүз таратка: кешеләрнең берсе мин. Ул — теге якта, дип сөйләп йөрдем. Узган ел әтиеңнең кайда күмелгәнен хәбәр иткәч, мин үземнең нинди әшәкелек эшләгәнемне белдем.

Рушад күзләрен йомды.

— Син миңа хәзер теләсә нәрсә әйт, олан. Ләкин үлгәнче минем шуны әйтеп каласым килде. Мин гаепле...

Карт башын түбән иде.

— Син мәктәпкә килгәч тә, мин үземә урын тапмадым. Дөресен әйтим, сине ярата алмадым. Чөнки мин синең алда гаепле идем, ә зыян салган кешесен кеше бервакытта да ярата алмый...

Рушад дәшмәде, тәмәкесен тирән-тирән суырды. Карт бик тә кызганыч кыяфәттә иде.

— Минем юньләп алган белемем булмады. Өстән-өстән генә йөрдем. Дөрес юлны гомер буе эзләдем. Колхоз оештырырга йөрүчеләрдән берсе идем — анда да надан башым белән партия оешмасына зыян ясадым. Колхозга керү турында беренче җыен буласы көнне мәчет манарасына флаг элдем. Шуның аркасында картлар дулап җыенны өзделәр. Әни карчыкны өстерәп алып чыгып, манарадан флагны алдырдылар. Мин качып калдым. Волостьта шуның өчен миңа шелтә белдерделәр...

— Хушият абзый, керик чәй янына...

— Юк, энем, син мине тыңла инде. Бу — минем беренче тапкыр кешегә сөйләвем. Мин хәзер аңладым. Коммунистлык ул лозунг кыч-

кыру, флаг күтәреп йөрү генә түгел икән. Мин менә шул киләчәк җәмгыятьне төзүчеләрне — сезне, яшьләрне күрдем. Сездәге хакыйкатьне, күңел пакьлеген күрдем. Мин хәзер аңладым: коммунистик җәмгыять пакь күңелләләр җәмгыяте булырга тиеш. Моны миңа сөйләшеп утырганда бервакыт Даутов та әйткән иде...

Карт кызганыч иде, Рушад аның белән авыр хушлашты.

— Минем сезгә үпкәм юк,— диде.— Сез гомер иткән кеше һәм, бөтен үткәнегезгә анализ ясап, үзегезне табарга тырышуыгыз — бу инде бер дә начар түгел. Соң булса да, уң булсын. Исәнлектә күрешкәнгә кадәр!

Карт китүгә, капкадан өч яшь егет күренде. Фырт кына киенгәннәр, бөтен рәвеш-кыяфәтләреннән яшьлек аңкып тора. Карасаң — Закиров, Әскәрев, Галәвиев икән. Закиров — зәңгәр теннискадан, яхшы чалбар һәм җәйге ботинкадан. Ябыграк йөзле, сирәк кенә булып сакалмыеклар тәрткән. Әскәрев — арзанлы костюмнан, шәһәрчә ботинкадан. Галәвиев — Хәрби һава Көчләре курсанты формасыннан. Баскыч янына килделәр, читенсенеп кенә кул бирделәр.

— Рушад абый, сезнең белән күрешергә дә, саубуллашырга да кердек,— диде Закиров.

Кешенең күңеле бер какшамасын! Рушад соңгы көннәрдә ничәнче мәртәбә инде бугазына төен утырганын сизде.

— Болай булгач киттек, егетләр. Бакча башындагы чирәмлеккә чыгып ятабыз. Я, кайсыгызда нинди яңалыклар бар? Кем кем булып чыкты бу дөньяда?

— Мин, абый, алтынчы разрядлы токарь. Ворошиловградта эшлим. Ялга кайттым, әби янына...

— Бик шәп, Закиров! Молодец! Ә син?

— Мин, абый, авыл хуҗалыгы техникумында укыйм. Тагын бер елым калды. Үзебезнең колхозга кайтам. Стипендияне колхоз түли.

— Шәп, Әскәрев, молодец! Ну, синеке билгеле инде, ә, жулик? Хәтерлисеңме мәктәптән качып йөргәнеңне?

Галәвиев нәкъ элеккечә көлде.

— Ыгы-гы-гы...— Ләкин тешләре элеккечә түгел, ә ап-ак иде.— Мин, Рушад абый, ул вакыттагы сөйләшү өчен сезгә бурычлы. Сезгә рәхмәт әйтүне үземнең бурычым дип саныйм.

— У-һу, син инде бөтенләй казенный җөмләләр белән генә сибә башлагансың. Армиядә шулай бит ул: кешеләр дисе урында «личный состав», ашадым дисе урында «азык кабул иттем», йокладым түгел, «ял иттем»...

Закиров шактый акча белән кайткан икән. Әбисенең йортын рәтләп бирмәкче. Ничә елдан бирле җыйган акчасын кайтарып тоттыргач, әбисе югалып калган.

— Моның хәтле акчаның рәтен дә, санын да белмим мин,— дигән. Үзе малайны орышып та алган.— Ник бер генә тапкыр посылка салмадың, шундый җимешлектә яшәп,— дигән.— Ичмасам,— дигән,— буш ящик кенә салган булсаң да, кеше арасында миңа никадәр күңелле булыр иде... Моның кадәр акча белән мин нишлим?

Яшьләр кызык! Оялчанлык белән тәвәккәллек аларда бергә үрелеп яши ала. Тегене-моны сөйләшеп утырдылар да туп-туры тәкъдим керттеләр. Сүзне Закиров башлады:

— Абый... без инде болай. Мәктәптә укыганда һәрберебез үзенчә укытучының канын эчкән кеше. Сез дә аны онытмыйсыздыр. Безгә ул вакытта мәктәп бернәрсә дә бирми кебек иде. Алай түгел икән.

Егет нәкъ олы кешеләрчә сөйли иде.

— Ә шулай да нәрсә бирган соң ул?

— Минем үземне,— диде Закиров,— мәктәп бер нәрсәгә өйрәтте: дөреслеккә буйсынырга. Мин бит буйсынырга яратмый идем.

— Ә мине чыдам булырга өйрәтте,— диде Әскәрев.— Хәтерлисезме, Рушад абый, безнең класста адәм рәтле бер дәрес уздыру өчен күпме көч түгә идегез. Никадәр чыдамлык кирәк аңа! Дөресен әйткәндә, сез безгә күп нәрсә бирдегез.

Рушад көлде.

— Я, егетләр, минем бүген монда актык кич, күңелнең болай да йомшак чагы, елата күрмәгез,— диде.

«Актык кич» дигән сүз Закировны тагын да кыюландырды.

— Рушад абый! Гаеп итмисезме?

— Я, нәрсә булды тагын?

— Менә, абый, сез теләсә нәрсә әйтегез, хет хәзер куып чыгарыгыз... безнең... ни барые...— Закиров бөрезлексез кепкасын бөтерде.— Давай, чыгар инде,— дип, ул Әскәревкә борылды.— Абый, билләһи менә, сезне ратканга күрә генә.

Әскәрев читенсенеп кенә кесәсеннән өч йолдызлыны чыгарып баскычка куйды.

— Я, сез разгильдяйлар белән болай булгач чишлисең инде? Әбиегезнең кастрюленнән бер-ике каз боты эзләмичә булмас...

Бакча башындагы чирәмлектә ярты төнгә кадәр сөйләшеп яттылар. Егетләр күп сөйләделәр. Дөньяда бервакытта да үзеңне-үзең таный алмыйсың икән. Читтән карагандa үзеңнең кем икәнеңне белми йөрү ул — кешенең бәхете дә, бәхетсезлеге дә, ахрысы.

— Шул елда мәктәпкә сез килеп кермәсәгез, безнең мәктәпнең яртысы таралганые,— диде Закиров.— Безнең бөтен укучылар Гата абыйга, сезгә, Нәркис апага гашыйк булдылар. Сез безгә Ватан сугышының зур, изге тойгысын алып килдегез. Ә Хәкимҗан абый! Аның кадәрле саф күңелле кеше!

— Ә Мостафа абый, Мостафа абый! — дип кушылды Әскәрев.— Аны без инде «Алмагач абый» дип кенә йөртә идек.

— Ә Бәлкыйс апа... Вәт математик шундый булсын икән ул. Мин аның кем икәнлеген училищега кергәч кенә белдем,— диде Галәвиев.— Мин бит математиканы бишлегә бирдем.

Рушад һич тә алай дип уйламый иде. Укучылар мәктәптә йөриләр, йөриләр дә бервакыт, мәктәптән киткәч, барысын да оныталар, дип уйлый иде ул. Алар исә барысын да — һәр укытучының аерым сүзләрен, хәрәкәтләрен хәтерләп калалар икән. Һәр укучының һәр укытучы турында үз фикере була икән...

Егетләр белән аерылышканда бакчага салкын чык төште, инде таң яктылыгы беленә башлаган, табигать тынып калган иде. Рушад, бакча киртәсенә сөялеп, бу авылда актык таңын каршылады. Бер-бер артлы йолдызлар сүнде, ай да тоныкланды. Күңелдә әйтеп бетермәслек моңсу хисләр белән нинди-дер ләззәтле җинел, якты уйлар бутала иде.

«Кеше нәрсә? — Картлык колы, узгынчы юлчы, өендә кунак.» Юк, феодаллар фәлсәфәсе дөрес түгел. Урта гасыр рыцарьларына мәктәптә әнә шулай өйрәткәннәр. Мин кол түгел. Мин көрәшче. Мин үземнең Ватан өчен файдалы кеше икәнлегемә бүген ышандым. Мин бүген моннан китәм. Ләкин мин тормышта юлчы түгел. Мин кунак та түгел. Хәер, бу дөньяның мине әле бер тапкыр да түргә утыртып кунак иткәне юк...

«Ай нәрсә? — Төннең күзләре, чык бирүче, һава хәбәрчесе».

«Йолдыз нәрсә? — Күк чуарлыгы, дингездә йөрүчеләргә юл күрсәтүче, төн матурлыгы».

«Үлән нәрсә? — Җирнең киеме».

«Тамыр нәрсә? — Докторларның дусты».

Ах сез, феодаллар! Никадәр өстән генә шуып сез философ булып кыланасыз. Менә сез җавап бирә алмассызмы? Мәхәббәт нәрсә? Тормышта икенче, өченче кешене яратып буламы? Теге елда, әгәр Ләйлә-

гөл бу мәктәпкә килмәгән булса, ничек булыр иде? Рушад һаман аны эзләр идеме, әллә башка бер кешегә күңелен салыр идеме? Шулай булгач, ул чын мәхәббәт буламыни? Димәк, мәхәббәт хисе бар кешедә дә була, ләкин ул якынча туры килерлек субъект кына эзли. Субъект килеп чыгуга, ул аңа юнәлә һәм эзләгәнен тапкан сыман була. Тукта! Моны кем әйтте әле? Әйе, әйе, теге елда, ут җибәргәнне карап йөргәндә, Нәркис әйтте. Белинскийдан диде. «Мәхәббәт кирәклек, әгәр дә юнәлер әйбере табылса, еш кына мәхәббәтнең үзе булып танылa; каршылыклар аны газаплы дәрткә әвереләдерә, ә канәгатьләндерү юк итә».

Барыбер аңлашылмый. Киртәләр күп булды — хисләр, йөрәк янды. Очрашсаң, шулар сүнәргә тиешмени?

— Ю-у-у-к! Ишетәсезме, ю-у-у-к!

Авылда әтәчләр кычкыра башлады.

...Ә иртән капка төбендә Заһир җибәргән ат тора иде. Рушад бушап калган мәктәпкә соңгы тапкыр кереп, озак кына йөреп чыкты. Бер-ике класста консультация бара икән, балалар гөҗли. Класста рус теленнән кычкырып-кычкырып бер малай сөйли. Рушад моны тавышыннан таныды. Директор малае Тәлгать. Нәкъ элеккечә, сүзләрне, авазларны алыштырып, ашыга-ашыга сөйли. Үзе бөтен коридорга ишетелерлек итеп кычкыра. «Доска почета... поска дочета... в переводе это означает... означает... тактау мактасы... әй... Тактау :: Мактау тактасы».

Бу — Рушад мәктәп эчендә ишеткән иң соңгы аваз иде...

## XXVII

Июньнең егерме бише иде.

Вокзал тирәсендә плащ бөркәнгән, зонтик тоткан халык йөгерешә, Мәскәү поездын озаталар. Җылы, парлы яңгыр ява, һава тын алырлык түгел, бөтен атмосфера катлавын су тамчылары гына алган сыман.

Такси тотканчы шактый вакыт узды.

Ниһаять, бер шофер сүз тыңлап утыртты. Рушад чемоданын багажникка урнаштырды.

— Хатынны эштән алып кайтыш, буш йөргәнче, вокзал аркылы узыйм дип әйттем,— диде олы яшьтәге шофер.

Рушад арткы утыргычка урнашты. Юеш плащына төренә төшеп, йомшак урынга сеңде. Яңгыр астында асфальт кап-кара булып ялтырый иде. Рушад сул ягында утырган юантык кына хатынга күз салды. Хатынның алдында дәү генә сумка һәм ул сумкадан... сарык бәтиләре башларын чыгарган иде. Рушад сискәнеп читкәрәк елышты.

— Бойнида эшлим мин,— диде теге хатын, сорауга җавап биргәндәй.— Бер буаз сарык әләккән. Бичара, бүген генә бәтиләде. Менә өйгә алып кайтам. Нишләтәсең инде аларны, ятимнәр бит...

Ул арада бәтиләрнең берсе үрмәләп сумкадан чыкты. Ап-ак ефәк көдрәдән төрелгән. Шомырт кебек кара кечкенә күзләр. Юеш борынының, дәү колакларының очында кара төрткеләр. Әтиләре чибәр егет булган, күрәсең. Бәти чыгынкы маңгаен төрткәләп Рушадка таба үрмәләде, алдына керде. Аннан башка да күңеле тулып ташкан кешегә бу җитә калды. Рушад аны кочагына алды да битенә кысты. Мәхлук бәти, юеш борынын Рушадның яңагына, ирененә төрткәләп, пуф-пуф килде, иснәде. Рушад, бөтен дөнья мәшәкатен онытып, аны үзенә кысты, бәтинең йөрәге чыгарга җитешеп дөп-дөп килә иде. И гөнаһсыз сабыйлар! Бу дөньяда сезнең әле беренче генә көнегез. Шулай да юньле бәндәләргә юлыккансыз сез. Сарыклар дөньясы тарихында бөтенләй булмаганча, сез беренче көнне үк таксида йөрисез. Тын океанга китеп баручы диңгезченең янәгын ялыйсыз. Бу дөньяның сюрпризларын кем белеп бетерсен!

Мөбиләр йорты янында машинадан чыкканда сарык бәтие Рушадның битен тагын бер иснәп алды. Сау бул, агайне! Үсегез, җир өстенә чыккач хәтфә үләннән авыз итегез, сикерә-сикерә чабыгыз. Сарык халкының эш рәхәт — аларның уйлыйсы юк...

Көтелмәгән хәлгә Мөби балаларча шатланды. Юк, Рушад белән күрешкәнгә генә түгел, ә Рушадның яңадан хәрби хезмәткә алынуына.

— Менә син, әй! Шәп бу, шәп, дриаумать! Әйдә, бер дөнья гизеп йөр әле! Һи-и-и, аякларым булса... Бөтен Советлар Союзын әйләнеп чыгар идем. Рота командиры әйтәдерие миңа: сугыш беткәч, сине армиядә калдырабыз, Сәгъдиев, дип әйтә иде. Кулың алтын синең, дип мактап бетерә алмый иде. Аякларым булса, мин нишләсен белер идем, дриаумать...

Мәсрүрә монда да мәктәп караучы булып урнашкан икән. Ул, айвайга карамыйча, төне буе утырып, бер пар йон оекбаш өлгертте. Рушад башта бик нык каршы килгән иде, файдасы тимәде.

— Безнең татар халкында әүвәл-әүвәлдән килгән гадәт инде ул,— диде Мәсрүрә,— армиягә китүче кешегә бер пар оекбаш, бер пар бияләй бәйләп бүләк итү. Бияләенә өлгерә алмыйм инде, бигайбә.

Мөбинең яңалыгы да бар икән.

— Син бу арада газит укыйсыңмы? — дип сорады ул Рушадтан.

— Дөресен әйтим, өч көннән бирле юк. Әле мин хуҗалык эшләре белән шөгыльләндем. Ниләр бар?

Мөби шифоньер өстеннән өч-дүрт газета алды.

— Менә «Известия»дә бер кызык әйбер бар. Сразы берничәне сатып алдым. Син сөйләгән егет турында бит бу.

Рушад газетаны кулына алды. «Орден хуҗасын тапты» дигән исем белән анда Хәкимҗан турында бер мәкалә бар иде. Яралануырга бер атна кала Хәкимҗан бер мәртәбә хәтәр операциядә катнашкан икән. Аларның отделениесе алгы сызыкта немецларның бер отрядын коралсызландыра. Фашист офицерының планшеткасыннан командование өчен кыйммәтле документлар табып алганнар. Хәкимҗан Өченче Дәрәҗә Дан орденына тәкъдим ителгән булган, ләкин күп тә үтмичә госпитальгә эләккән һәм орденын ала алмаган.

Хәзер орден хуҗасын тапкан. «Ватан сугышы батыры корыч коючы Хәкимҗан производствода югары күрсәткечләр бирә»,— дип яза хәбәрче. Аста рәсеме. Шул ук күзләр, шул ук беркатлы елмаю. Шул ук сабыйларча сафлык, эчкерсезлек. Ул туп-туры төбәлгән күзләре белән:

— Нихәл, туган, китеп барышмы? — дип, Рушадтан сорый сыман. Фронтта булган егетләрдә әллә ниткән, кеше аңламаслык мөлаем дә, җитди дә, тирән дә бер караш була. Нидән бу? Әйтүе кыен.

Газетаның берсен Рушад чемоданына салды.

Таң беленгәндә генә йокыга яттылар. Рушад ике көн буе авылда Каюм белән бергә такта ышкылаган иде, әнисе түбә яптырырга калды, калганнарын такта әзерләп куйдылар. Куллар, беләкләр ут булып яна иде, йокы тиз алды...

Иртәгесен көн документлар рәтләп үтте. Владивостокка кадәр самолет билеты инде әзер иде. Комиссариат тирәсендә Рушад үзе кебек запастан китүчеләрне шактый күп очратты. Ләкин барысы да диярлек сугыштан офицер исеме белән кайткан кешеләр иде.

Тормышның бер кузгалса кузгала икән.

Кайвакытта тормышның һәр сәгате әллә никадәр яңалык алып килә.

Егерме алтынчы июнь көнне иртәнге сәгать җидедә самолет китәсе иде. Мөби әле быел гына тәэминат органнары биргән «Москвич»ын сәгать биштә үк кабызды, яхшы киемнәрен киде, медальләрен такты. Машина янында Мәсрүрә дә хуҗаларча йөгереп йөрде, радиаторга су салды, тәрәзә пыялаларын сөртеште...

Рушад арткы урынга кереп утырды да, иртәнге шәһәр урамнары белән саубуллашып, сүзсез генә барды. Бөтен дөньяны июнь кояшы иңләгән, машинаның ачык тәрәзәсеннән юка чәчәге исе кереп бара иде.

Аэропортка килеп житү белән билетны регистрацияләделәр. Алгы якка, ачык һавага чыккач, Рушад сискәнеп китте. Самолетларга чыгу юлында кулларына төргәкләр тоткан Гата белән бер хатын басып торалар иде. «Эльза!» Рушад берьюлы аларның икесенен дә кочагына атылды. Самолетка кергәнче ярты сәгать вакыт бар иде — кызу-кызу сөйләштеләр. Шулай, күптән күрешмәгән өч дус кинәт кенә буфетта очрашсалар кызык була. Сөйлисе сүз шул кадәр күп — эчкә сыя алмыйча тамак төбенә менә дә тыгыла. Сүзнең рәтенә төшә алмый торалар. Менә бер заман буфетта алынган сыеклык үз юлын таба, чама белән бертигез вакыт үтүгә бертигез куәт белән баш миләренә бәрә, ул арада телгә җан керә.

— Стой, стой... Кырык өченче елда Сталинград кырында безнең батальонда мондый хәл булды...

Тегеләрнең, әлбәттә, моны тыңларлык чама юк. Чөнки һәркемнең сөйлисе килә.

— Маршал Жуков килде безгә. Сугыш беткәч. Смотр уздырырга. Беләсеңме ничек булды...

Монысын да тыңламыйлар. Чөнки өченчесенең дә темасы бар.

Гата да, Рушад та мондый хәлләрне күп күргән.

— Тукта, тәртип белән генә сөйлик, һәр минут алтын,— диде Рушад.

— Тәртип беләнме? Алайса шул, тыңла. Гата абыең сине куа китә. Безнең районнан барлыгы өч офицер чакыртыла запастан. Һәм дөрес эшлиләр. Вакытында монда бездәй кадрлар кирәк иде — хөкүмәт безне срогыннан элек кайтарды. Хәзер Ватан безне яңадан хәрби хезмәткә чакыра. Безгәме соң шуңа колак салмаска? Без бит — кырык бишенче ел егетләре!

— Купшы фразаны бик ярата инде безнең Гата,— дип, Эльза иренә елышты.

— Бер дә купшы түгел. Аннан икенчесе: мин сине эзләп Акбалыкка килдем. Китеп баргансың. Сиңа анда ике хат бар иде, ала килдем.

Шактый табышмаклы ике конвертны Рушад кесәсенә салып куйды.

— Өченчесе: кичә төштән соң ук газик белән своим ходом шәһәргә чаптык. Әлбәттә, җиңгәннең сине озатуда катнашасы килде. Хәрби комиссариатка кереп, синең кайсы рейска билет алганыңны белдек. Дүртенчесе: менә монысы җиңгәң күчтәнәче, узган елгы каен җиләге вареньесы.— Гата мәхәббәт тулы елмаю белән Эльзага карады.— Ә менә бусы — миннән. Бер «Столичная» һәм, ниһаять, бишенчесе: мин дә нәкъ бер атнадан китәм. Ерак Көнчыгыш хәрби округы карамагына. Димәк — маршал Малиновский үзе эзли Гата абыеңны.

Рушад барысы белән дә кочаклашты.

Посадка башланырга унбиш минут вакыт бар иде. Рушад кызыксынып кесәсендәге конвертларның берсен ачты. Машинкада басылган кәгазь. «Университетның тарих бүлеген быел читтән торып тәмамлаучыларның очрашу вакыты нәкъ өч елдан, июньнең соңгы шимбәсендә, Лобачевский бакчасында сәгать дүрттән бишкә кадәр. Очрашуны оештыру бюросы». Кызык!

Репродуктор соңгы хәбәрләр тапшыра иде. Бер хәбәр барысын да сагайтты. «Егерме бишенче июнь көнне Вашингтондагы хуҗалары кушуы буенча Ли Сын Ман гаскәрләре. Төньяк Корея территориясенә басып керделәр. АКШ империалистлары ачыктан-ачык интервенция юлына бастылар һәм бүген үзләренең короллы көчләренә Корея территориясенә керергә приказ бирделәр».

Левитанның көчле, җан тетрәткеч тавышын аэропорт радиочелтә-

реннән чыккан ачы тавыш бүлдерде: «Свердловскига оча торган... рейслы самолетка пассажирларны утырту башлана».

— Күрдеңме? Ишеттеңме? Во! Менә ул империалистларның чын йөзе! — Гата үзенә басып торыр урын тапмады.— Ну, ничего! Без үзебезнең сүзебезне әйтербез бу турыда. Без — кырык бишенче ел егетләре...

И бу дөнья! Левитан тавышы — хәтәр, шомлы тавыш. Я ул синң Ватаныңның язмышы куркыныч астында икәнлеген хәбәр итә, я ул җиңү шатлыгы турында сөйли. Планета атмосферасында тагын Левитан...

«Пхеньян радиосы Төньяк Корея Эчке эшләр министрлыгының түбәндәге белдерүен тапшырды:

Көньяк Корея курчак хөкүмәтенең «милли оборона» гаскәрләре 25 июньдә иртә белән иртүк бөтен 38 параллель сызыгын буйлап Төньяк Корея территориясенә һөҗүм башладылар. Дошман Төньяк Кореяга кинәт һөҗүм итеп, 38 параллельдән төньяктарак, Хядюдан көнбатыштарак районда һәм Кымчон, һәм Червон районнарында Төньяк Корея территориясенә бер километрдан ике километрга кадәр эчкәрегә керде».

Эльза Рушадны үзенә кысып үпте. Күзләрен сөртте. Мәсрүрә ике куллап күреште. Елый башлады. Мөби һаман шат, ачык чырайлы иде.

— Ефрейтор Сәгъдиевтән Тын океан диңгезчеләренә сәлам әйт. Әгәр, диген, аяклары булса, ул Ли Сын Манны нишләтәсен белер иде, дриаумать, безнең Мөбаракша, диген. Хат яз!

Ирләрчә каты итеп кул бирештеләр.

Рушад самолетка кереп китте.

Таш плиталар өстендә аның эчкерсез дуслары басып калды. Самолет урыныннан кузгалганчы шактый вакыт үтте. Рушад кесәсендәге икенче конвертны да алды. Җибәрүчесенең адресы юк, печатендә Николаев шәһәре дигән сүз бар иде. Шикләнеп кенә конвертны ертты. Конверт эчендә кәгазьгә төргән нәрсәдер бар иде. Рушад йөрәге типкәнен ишетеп аны сүтте. Сүтте... һәм башы әйләнеп китте. Кәгазь эчендә күгәрченнең түш каурые иде...

Мотор эшләвеннән самолет дерелди башлады. Рушад аны ишетмәде. Конверт эчендә кечкенә генә бер язу да бар иде. Рушадның куллары калтырады. Хәрефләр йөгерделәр.

«Рушад абый! Сез инде дөньяда мин барын онытканс ыздыр да. Мин егерме сигезенче июньдә Казан аркылы узам, этиләргә кереп чыгам. Әгәр вакытыгыз һәм теләгегез булса, мин сезне шул көнне университет каршындагы Лобачевский бакчасында 12 дән кичке дүрткә кадәр көтәм. Әгәр килә алмасагыз, минем адрес (вакытлыча, практика чорында) Владивосток, главпочтамт, до востребования. Мин Николаев шәһәрендә шул үзем хыялланган институтта укыйм. Быел Ерак Көнчыгышта практика узабыз.

Сезне күрәсем килә, гаеп итмәгез».

Имза юк. Авыл җирендә кеше-фәлән алмагае дип курыккандыр инде. Йөрәккә ургылып-ургылып кан куылды, тын алуы авырлашты. Хатны ул кат-кат укыды. Ләйләгөл! Күгәрчен каурые! Әкияттәгечә булсын дип сөйләшенгән иде бит! Димәк, ул инде Казанга дип юлга чыккан! Күгәрченкәем! Рушад каурыйны иреннәренә тидерде...

Самолет кузгалганда гына рәшәткәләр буенда басып калган дуслары исенә төште. Гата фуражкасын, Эльза белән Мәсрүрә яулык болгыйлар иде. Бер читтәрәк озын таякларга кинчә гәүдәсен элеп куйган Мөби тора — аның култык астына бер куч газета кыстырылган иде. Самолет бетон буйлап йөгерде... Әллә кайгырасы, әллә шатланасы шунда!

Тормышта шундый минутлар була — синң газап көтәсең — рухыңны шатлык катыш ләззәт чолгап ала. Син аны әле миең белән тотып эш-

кәртерлек, анларлык хәлдә түгелсен, ләкин тәнең аны инде сизгән, гәүдәннең бөтен күзәнәкләре бу рәхәтлекне инде кабул иткән, тәнең һәрбер атомы инде миеңә шатлыклы сигнал бирә.

Самолет жирдән аерылды да кояшка таба күтәрелде. Яшел ужымлы басулар янтайдылар, жир өсте авышты. Барысы да аста калды. Дуслар да, эш тә, мәшәкать тә, ялгыз карт ана да... Ләкин нигәдер авыр түгел. Син кемгәдер кирәк. Кайдадыр синең хезмәтеңә мохтажлар. Син бу тормышта чуль түгел. Менә кайчандыр син капчык асып, кара шинель киеп бер авылга укытучы булып килгән идең. Димәк, син, Гата әйткәнчә, шунда кирәк кеше идең. Хәзер син әнә тегендә — дөньяның икенче бер читендә кирәк. Болай булганда яшәргә дә яшәргә!

Самолет әле тиешле биеклекне алмаган иде, Рушад игътибар белән аска карады. Ни күрсен! Аста тимер юл, таныш разъезд. Әйе, әйе, шул, урман арасында. Әнә ужым басуы эчендәге коры елгага сузылып утырган кечкенә авыл — Рушадның әнисе төпләнгән авыл. Әнә авыл читендәге сабын тартмасы кадәр генә йорт — түбәсенең яртысын инде яңа такта белән япканнар. Тамак төбе жыерылып китте, бугазга төен утырды. Авыр бит, авыр, һич тә жиңел түгел. Әнә Акбалык авылы. Күпме мәшәкать, шатлык, ләззәт, борчу, хисләр ташкыны китергән авыл. Авыл уртасында зур бина, аның калай түбәсендә флаг жилфердн. Аста июнь иртәсенең талгын жилендә аның лепердәп торганы сизелә. Самолет биеклек алды, бәрысы да топография картасындагы шартлы билге сыман шакмакларга әйләнде. Туган жир артта калды. Шулай да рух жиңеләеп китте. Алда билгесез мәшәкатьләр, билгесез кешеләр, билгесез очрашулар көтә иде.

Узган гомер... Кисәкләп үткән гомер. Щуның һәрбер кисәге үткән саен борылып карыйсы, үткәннәргә бәя бирәсе килә. Сугыштан кайтканнан алып бүгенге көнгә кадәр нәрсәләр эшләнде соң? Шул турыда уйларга хәзер вакыт бар... Күк йөзе чиста, пассажирлар тын гына газета-журнал карыйлар, берәүләр йокымсырый. Жир өсте кояшка коена.

«Кояш нәрсә? — Шарның ялтыравы, күкнең матурлыгы, табигать бәхете, көннең намусы, сәгатьләр бүлүче». Урта гасырлар фәлсәфәсе шулай дип өйрәтә.

Ерак Көнчыгышның кырыс табигате! Тын океанның дәһшәтле штормнары! Куәтле жилләр, өермәләр! Мәрхәмәтле булыгыз, сезнең якка тыныч хезмәттән аерылган бер егет килә...

Сез аңа сугыш утын кабат күрсәтмәгез.

Ул егетнең әле сөйгәнен очрагасы бар.

Аның әле Алтын Мөгез бухтасының ярына басып сөйгән кызына мәхәббәт турында сөйлисе бар. Ул сүз авыл кырыендагы шомырт агачлары янында моннан берничә ел элек июнь төнендә өзелеп калган иде. Аннан... аннан ул кыз Рушадны бухтада озатып калыр. Кораб ачык диңгезгә чыкканда, аның командасы күе тыгыз стена булып палубага басар. Шул команданың бер кырыенда кулын чигәсенә куйган Рушад та булыр. Диңгездән искән жил яр буенда басып торган Ләйләгөлгә аның сөю сүзләрен сөйләр. Куәтле кораб корыч күкрәге белән диңгезнең авыр дулкыннарын ярыр, артта күбекле юл калыр. Ләйләгөлнең тирән карашы, сагышлы йөзе караңгы төннәрдә Рушад өчен маяк булыр. Аңа берни дә куркыныч булмас.

Рушадның миен татлы уйлар басты. Аста кара чыршы урманы белән капланган Урал таулары күренде. Тау үзәнлекләрендә жәйрәп яткан заводларның моржалары ачык зәңгәр күккә төтен баганалары сузганнар иде.

Азия кыйтгасына килеп керүгә, самолет түбәнгә таба юнәлеш алды...

*1970*

*Бетте*

## Камил Мостафин

# Тачанкалар

Еллар нәрсә?
Утлы юллар алар,
көрәшчеләр язган җырлар алар.
...Ел исәбен онытып, кырлар буйлап
һаман йөри икән тачанкалар.

Пулеметлар әнә тынып калган.
Юл читендә үскән яңа урман...
Кожанкалар кигән командирлар,
әйтегезче,—
кайда сезнең дошман?

Йөгереп чыгам таңда такыр юлга,
чыгып басам әрем үскән кырга.
Тачанкалар,
утыртыгыз мине!
Тачанкалар,
очыртыгыз мине!

Чаба атлар, ә таң һаман да ал.
Тачанкалар,
сезне илтә хыял.
Аннан көлә, аны таптый
мещан...
Тачанкалар,
исән сезнең дошман.

Атларыгыз узган юллар якты,
тояк тавышы йөрәгемә какты.
Мин ишеттем бүген:
кемдер тагын
газиз Ватаныма ташлар атты.

Йөгереп чыктым бүген такыр юлга,
чыгып бастым җәйге, эссе кырга.
Тачанкалар,
утыртыгыз мине!
Тачанкалар,
очыртыгыз мине!

...Без очабыз,—
безне өнди илһам,
ат тоягы әремнәрне еккан,
Калтырансын дошман!
Тачанкалар,
мин ут ачам сезнең пулеметтан.

## Йөгән

Ат кешнәде...
Дустым, ишетәсеңме,—
малай чакта
яшь болында
син атланып йөргән ат кешнәде...
Ә йөгәне синең кулыңда.

Җиз тәңкәләр белән бизәкләнгән
ул йөгәнне еллар саклаган,
син баткансың суда,
син янгансың,
ә ул исән калган.

Синең куллар
борган штурвалны,
балта сабын кыскан,
мылтыкны.
Ә бу йөгән һаман
югалмаган,
җиз бизәге һаман тутыкмый.

Безнең тормыш — киң колачлы очкыч,
Бах аккорды,
Шопен этюды,
безнең йодрык кадәр йөрәкләргә
бөтен дөнья сыйды.

Уйларыбыз инде
ак ватманга
кырыс чертеж булып
яттылар.
Тик һаман да
аның сызыклары
үсмер чакның серен саклыйлар.

Ә күктәге кояш —
ерак көндә
өй янында үскән көнбагыш...
һәм зур залда Бах аккордын өзә
ат кешнәгән тавыш...

## Өмет

Өмет туа,
нидер вәгъдә итеп,
адәм балаларын яратып...
Өмет йолдызлары,
күктә
сезне
кем кабызган,
безгә каратып?

Сез кем яклы?
Кемне терелттегез?
Бүген төнлә якты кайсыгыз?
Дусларымның качкан өметләре,
дусларыма кире кайтыгыз!

Җыерчыклар төшкән
маңгайларын
сез сыйпагыз әле сак кына.
Елмайтыгыз әле дусларымны
мәңге сүнмәс тормыш хакына.

Кырык беренчедә
авылыбызны
кочаклаган чакта көзге төн,
тәрәзәмдә
утлар сүнсә сүнде,—
тик сүнмәде җирдә
өметем.

Без ышанып үстек.
Өметсездән
һәм хыялсыз җаннан көлдек без.
Хезмәт дигән
шанлы һәм зур цехка
өметлеләр булып кердек без.

Бәрсәләр дә
тормыш сәмумнары,
елатса да кайчак
хаталар,—
мин һичкайчан
кыен тормышымны
кара язмыш диеп атамам.

Туган ягым...
Монда
урман тыңлый
өмет хәбәрчесен — курайны,
монда миңа
таныш кара күзләр,
бәхет вәгъдә итеп,
елмайды.

Мена шушы җирдә
мин куандым,
шатлык бүләк итеп
бүтәнгә.
Шушы җирдә,
йөгерек атлар кебек,
ак көннәрем минем үтәрләр.

●

Егетләр ул шундый халык:
йөрәкләрен уткэ атып,
канаттырып
һәм аттырып,
бүреләрдән талаттырып,—
аларны
гүзәл кызларның
учларына салалар.

Ә кызлары — алалар,
алалар атылганнарны,
алмыйлар сатылганнарны.

●

Әниләрнең исендәдер
беренче сулышыбыз.
Ә безнең хәтердә кала
беренче сугышыбыз.

Килә көн, яшендәй балкып,
кеше намусын барлап.
Чаң суга, һәм без басабыз,
йодрыкларны йомарлап.

Без беренче бәрелештә
астан өскә карыйбыз,
Без баштан ук явызлыкны
һәм ялганны таныйбыз.

Ә ялган өстен чыккалый,
явызлык бездән көлә.
Беренче бәрелештән соң,
борыннардан кан килә.

Тураябыз,
канны йотып,
аякны терәп ташка.
Тураябыз.
һәм дошманга
карыйбыз өстән аска!

Без яши башлыйбыз
башта
беренче сулыштан соң,
аннан —
хаклык өчен барган
беренче сугыштан соң.

## Чабыш

Юлга баскан кызның ак яулыгы
хәзер минә күздән югалыр...
Син ялына атның иелгәнсең,—
кайда илтә сине бу айгыр?

Уңда — атлар, сулда — тагын атлар,
әллә алар барысы очамы?
Кара яллы атны кочкан егет,
җилләрне дә, әйдә, коч әле!

Тизлек, тизлек, диеп пышылдый җил,
Битләреңне юа вак яңгыр...
Таныш түгел кызның ак яулыгы
тиздән, тиздән күздән югалыр.

Атың әйбәт, ай-һай, әйбәт атың,
ияреңдә — алтын бизәкләр.
Син беренче килсәң, җитез егет,
олы дөнья сине бүләкләр.

Нинди кыен борылып караулары,—
шундый шашып чаба бу айгыр...
Кара чәчле кызның ак яулыгы
хәзер, хәзер күздән югалыр.

Менә — җиңү... Артта тизлек калды
һәм ашыгып узган юл калды.
Сине тәбрик итә иптәшләрең...
Ә теге кыз
инде югалды.

## Салисә Гәрәева

### Урал

Урал, дибез, ул борынгы таулар
Шундый авыр төсле...
Өсләрендә күксел болыт ята —
Килер давыл төсле.

Урал, дибез, күпме эшче атлый
Завод юлларыннан;
Татарстан!
Кырларыңны гизгән
Тракторлар — моннан...

Чал Уралда, тимер ташкын төсле,
Машиналар шавы:
Советларның корыч күкрәге ул
Данлы Урал тавы.

### Чиләбедә — танк

Чехлар илен, поляк, мадьяр илен
Азат иткән безнең танклар.
Җиңү көне килгәч, башняларын
Чәчкәләргә күмгән халыклар.

Европаның чүеп тузаннарын,
Алар кабат кайткан Уралга.
Һәм арадан берсе һәйкәл булган —
Безнең көчкә — безнең коралга.

Ул ыргылыр төсле кинәт алга —
Антеннасы күккә төбәлгән;
Урал эшчәннәре горурланып,
Сөеп карый аңа түбәннән.

Имин булсын дөнья, иген иксен,
Хәр яшәсен өчен халыклар,
Пьедесталда тора һәйкәл булып
Сугышларны кичкән танклар.

●

Таганайга төшеп Ай чайкала,
Таган итеп куксел болытны.
Кырыс Урал, таштан юнган сымак,
Чыныктыра, чарлый холыкны.

Куллар каты, учлар сөялләнгән,
Беләкләрдә мускул уйнаклый;
Яшел малахиттан уелган Ай
Таганайга төшеп кунаклый...

Сүзләрдә дә Урал кырыслыгы —
Авыр, салмак алар, тимердәй;
Кирәк була икән — көйдерә ала,
Мартеннарда янган күмердәй.

Табигать тә, кешеләр дә монда,
Нәкъ Уралча — кырыс, олылар.
Авыр чакта мин учларым белән
Урал ташларына орынам.

●

Син киләсең. Күзләреңә күлеп карыйм.
Чәчләреңә тартыла кул ирексездән;
Белгертмәмен, дигән идем, сөюемне —
Сизгән дуслар, әллә каян дуслар сизгән.

Күзләремнән түгелгәндер ялкыннарым,
Йөрешемнән сизелгәндер — адым дәртле.
Карашымда гыйшкым кояш кадәр булса,
Йөрәгемдә яратуым — диңгез хәтле...

Син киләсең. Күзләреңне күргән саен
Иртән кояш күргән кебек канатланам;
Ярты гомер узган, әмма сине сөеп,
Дәрләп торган яшьлегемдә кабатланам...

●

Ак болыттан ап-ак карлар явып тора
Оеп кына, әкрен генә, талгын гына.
Синең якты күзләреңнең зәңгәр нурын,
Күңелемә кояш итеп алдым гына...

Ак тәңкәләр коелсыннар, коелсыннар,
Аларда сер, аларда моң дулкынлана...
Серләрне дә, моңнарны да үзенә җыеп
Ике күзең ике йолдыз булып яна.

Яусын әле тәңкә карлар, тирбәлсеннәр,
Алар миңа нидер сөйли, сүзсез генә;
Яз килгәч тә эреп беткән карлар кебек,
Язмышымнан киталмассың эзсез генә...

## Нурия Измайлова

### Язлар килгәч

Язлар килгәч, серле язлар килгәч,
Гыйшык уты салып дөньяга,
Яз дөньяны сөйгән кебек сөя
Уналтысы тулган кыз бала.

Язлар килгәч, чәчәкләрен ачып,
Мәхәббәттән галәм исергәч,
Шук тамчылар урман буйларыннан
Умырзая исен китергәч,

Иске карлар, бозлар агып киткәч,
Елгаларга кушылып, суларга,
И чумарга иде шулар белән,
Ярсу ташкыннарга чумарга!..

...Язлар килгәч, яшел язлар килгәч,
Алтын нурлар тулгач дөньяга,
Антын мәңге бозмас кебек сөя
Уналтысы тулган кыз бала.

Язлар килгәч, яңа язлар килгәч,
Җан кертергә яңа хисләргә,
Ах! Төшәргә иде түгелеп-түгелеп,
Яңа ташкыннарга төшәргә!..

## *ГАЛИ ХУҖИ*

*(1912—1966)*

# «УЗСЫН ГОМЕР САГЫНЫП СӨЙЛӘРЛЕК...»

Җиде ел буе солдат лямкасы тартканнан соң, кемнең-берәүнең студент чакларына кире кайтасы килмәс. Уку бик тә тансык, сагынылган була. Җитмәсә, Мәскәү ВУЗы, илдәге бердәнбер әдәбият институты...

Ләкин ике елдан соң язмыш миңа аркасы белән борылды. Сәламәтлегем начарлану сәбәпле, институтны вакытлыча калдырырга мәҗбүр булдым. Барлык хыялларым, тартылган кыл шикелле, чыңлап өзелделәр. «Табигать кочагына, урманга китегез,— диделәр врачлар,— нервларыгыз ял итсен. Хәтта урманчы булып эшкә керсәгез дә ярый...» Урманчы булу өчен дә бит белем алырга кирәк. Ә минем хат укырлык та җаем юк. Язулы кәгазьне күрү белән күз алларым караңгылана башлый. Хәзер кая барып сугылырга?

1951 елның җәендә мин шундый авыр уйлар белән Казанга кайтып төштем. Дөресрәге, «сугыласы» гына булдым, чемоданым Мәскәү — Свердловск поезды белән Урал ягына китте. Татарстан язучылар союзы мине укырга җибәрде, башкала культурасы белән аралашсын, диде. Хәзер нинди киңәш бирер?

Минем күз алдыма, ни өчендер, беренче булып шагыйрь Гали Хуҗи килеп басты. Атаклы «Россия» поэмасы һәм тагын берничә поэманың, Салих Сәйдәшев музыка язган «Халисә» җырының авторы, утләр-сулар кичкән солдат, яшьләрне үз итүче бик кече күңелле кеше. Хәтеремә ул шулай карап калган. Икенче көнне, батырлыгымны җыеп, «Яшь Сталинчы» газетасы редакциясенә юнәлдем. Шагыйрь Гали Хуҗиның редактор чагы иде. Аның кабинетына секретариат бүлмәсе аша үтәргә кирәк.

— Редактор гранкалар укый,— диде бер яшь иптәш, миңа сабыр итәргә кушты. Шуны әйтүгә, ябылып җитмәгән ишектән Гали абыйның көлемсерәгән йөзе күренде.

— Кер, кер, Әдип! — диде ул күтәренке тавыш белән.

Ул мәһабәт гәүдәсен турайтып, өстәл арасыннан чыкты, гаҗәеп бер җылылык белән көлә-көлә исәнләште:

— Ялга кайттыңмы? Әйдә, утыр әле.

— Мөгаен, бөтенләйгә булыр,— дидем мин,— «табигать кочагында» яшәргә киңәш итәләр...

Тавышымда өметсезлек билгесе сизеп булса кирәк, Гали абый тынып калды. Ул өстәл янына килде дә, күзләрен чекерәйтеп, юеш гранкалар өстенә иелде. Ниләрдер

тезэткәләп, газетага кул куйгач, миннән сорады:

— Әйберләрең, чемоданың мондамы? Безгә кайтырбыз...

— Поездда китте, туган ягыма,— дигән җавапны ишетүгә, Гали Хуҗи каядыр почмакка сәер генә карап, мондый сүз әйтте:

— Шаяртасың?!

— Юк, шаяртмыйм, Гали абый, чемоданымны сары чәчле бер кызга биреп җибәрдем.

Редактор өстәлдәге балкып торган графинадан бер йотым су салып эчте, папиросын кабызды. Аның ачык, мөлаем йөзе кырыслана, уйчанлана барды.

— Кайтасыңны ишеткән идем,— диде ул һәм кинәт сорап куйды: Өйдә кемнәрең бар?

«Кемнәрең» сүзен мин «таянып кемең» мәгънәсендә аңладым һәм сорауга ачыктан-ачык җавап бирдем:



— Әти карт белән әни карчык. Яннарында мәктәпкә йөри торган алты малай һәм тагын ике бәләкәй кыз...

— Син җиденче «малай» буласың,— диде Гали абый, күзлек пыяласын сөртәсөртә,— карәле, алай ярамый бит инде. Уйлашыйк әле...

Гали Хуҗиның кеше язмышы турында борчылып хәсрәткә төшкән, кара кайгыга калган чагын күрү мине хәтта тетрәндереп җибәрде. Ил язмышы белән яшәгән кеше, күрәсең, аерым шәхесләргә карата да битараф кала алмый. Бераз уйланганнан соң, ул миңа шундый тәкъдим ясады.

— Ике урында хәбәрчеләр кусты оештырабыз. Бөгелмәдә, Минзәләдә.— Мәсьәлә обкомда хәл ителгән. Кайсын сайлыйсың?

Мин борчуга төштем. Маңгаемнан бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты. Бу хәлемдә хәтта бер юллык хәбәр дә яза алмаячагым турында әйтергәме, юкмы? Әйтмәсәң — алдау була. Төкми-чәчми барсын да сөйләп бирдем. Сүземне йомгаклап, болай дидем:

— Редакция сотрудниклары җилкәсендә яшәп булмас, Гали абый. Бигрәк тә сезгә әркаланып. Куандыра алмам...

Шуны ишетүгә, ул кабинет тәрәзәсен иңенә ачып җибәрде, «хәзер менә тәрәзәдән ыргытам үзеңне», дигән сыман кискен хәрәкәт ясады:

— Ташласана!

Ул кабинет буйлап йөренеп алды. Үзен бераз тынычландыргач, әйтте:

— Кәнфитләнү безгә килешми. Без солдатлар.

Гали абый аннары, көлемсерәп, аягымдагы ак киндер туфлиләремә күз төшерде, иң гади материалдан тегелгән пиджагымның якасына күзен терәп, костюмымны мактаган булды:

— Ничево бу, малай, өйләнергә була... Я, нишлибез соң?

Гали Хуҗи Минзәлә якларын, ямьле Ык буйларын мактарга тотынды. Ахыр чиктә ул мине шунда «табигать кочагына» китәргә ризалаштырды. Үзе аннары, хәзер керәм, дип каядыр чыгып китте.

Киемнәремә игътибар итте. Әдәбият институтына япон галифиеннән, каты кирза итектән китүемне хәтереннән чыгармаган, күрәсең. Гали Хуҗи ул чагында Буада яши, «Кызыл Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе булып эшли иде. Ул Казанга килгәндә, без аның белән вакыт-вакыт очрашкалый идек.

Гали абыйниндидер кәгазьләр тотып кереп тә җитте. Җитди, эшлекле кыяфәт белән сүз башлады:

— Безнең егетләр сине нефть чирәменә кодаламакчы,— диде ул, бераз икеләнә төшеп,— дөрес сөйли алар. Ул яктан безгә материал тамчылап кына килә...

Булачак редакторым кулындагы кәгазен, авырлыгын үлчәгән сыман, бераз селкеткәләп торганнан соң, кискен карарга килде:

— Ярый, бая уйлаганча килештек. Әлмәт шәһәре туып житкәч тә сине шунда күчерербез. Менә сине эшкә алу турында приказ. Монысы шәһәр Советына, квартира мәсьәләсендә... Борчылма барысын да рәтләрбез.

Ул минем беләгемнән кысып, үзенә генә хас якты, эчкерсез бер елмаю белән елмаеп куйды:

— Чемоданыңны куып житәрсең инде. Сары чәчле кызга бездән сәлам әйт. Башта сөйләшкәннәр ике арада гына калсын. Ничево, рәтләнер, малай, дөнья ул...

Шагыйрь Гали Хуҗи кешеләргә нык ышанучан, төрле ясалма формальностьләр колы булудан ерак тора иде. Минзәләгә килеп урнашкач, беренче атналарда мин борчуга калып, аптырабрак йөрдем. Редакциядән звонок юк та юк. Башта ул безнең ничек урнашуыбыз, хәл-әхвәлләребезне телефоннан сорашып белеште дә шуннан барысы да тынды. Берәр бүлеккә шалтыратсам: «Үзебез дәшербез», дип кенә куялар. Соңрак моның сере ачылды: редактор мине кирәккә-кирәкмәскә борчымагыз дигән икән. Районнар белән танышa торсын, дигән. Иң курыкканым да шул иде: хезмәт хакы алып, эшсез йөрү. Каләмдәш иптәшләрең алдында ни йөзең белән күренерсең?!

Ярый, алга таба һәммәсе үз җаена төште. Иң кыен чакларда мораль таяныч табу, тормыш урынын, яшәү рәвешен үзгәртү һәм ямьле Ык буе табигате — барысы бергә, күрәсең, үзенекен иткән. Тора-бара редакциягә кергәләп ешрак була һәм бер-бер артлы мәкаләләрем дә күренә башлады.

Гали Хуҗи яшьрәк авторлардан бер миңа гына шулай игътибарлыдыр дип уйласам, бик нык ялгышкан булыр идем. Шагыйрьнең дуслары күп, яшьләр аны өлкән туганы шикелле күреп, якын итеп йөриләр иде. Ул өметле күренгән һәрбер яшь язучыга ярдәм кулын сузарга әзер торды. Гали Хуҗи — комсомолда тәрбияләнгән һәм яшьлеген комсомолга багышлаган шагыйрь. Бәлки шуңадыр, ул тормышының соңгы көннәренә кадәр яшьләр белән бергә булды, алар шатлыгы, алар борчуы белән барды.

Хәбәрче юлларында минем Әлмәт тормышым башланды. Гали Хуҗи бу вакытта Татарстан язучылар союзы каршындагы консультация бюросында эшли иде, ахры. Шагыйрь Әлмәткә килеп чыкты.

— Әсәрләрегездә бүгенге көн сулышы җитми, иптәшләр,— диде ул, әдәбият түгәрәгендә ясаган бер чыгышында,— хикәя, шигырь туганын гына көтеп йөрсәң, кысыр калуың да мөмкин. Мәкалә, зарисовкалардан башлагыз. Шулар сезгә тормыш пульсен тоярга ярдәм итәр.

Фронт газеталарында зур мәктәп узган, сугыштан соң республикабызның яшьләр газетасын яңадан аякка бастырышкан өлкән язучы, «азаулы» журналистның бу хак сүзләренә без колак салмыйча булдыра алмадык, әлбәттә.

— Язмасагыз — җилкәгездән төшмәм, егетләр,— ди ул бер вакыт, үз итеп кенә,— мин әйттем диярсез.

Һәм сүзендә торды. Тавыш-тынычбыз чыкмый башласа, безне, Әлмәттәге әдәбият түгәрәге членнарын, камчылап хатлар язды, телефоннан шалтыратты, очерк таләп итеп, хәтта телеграммалар биргән чаклары да булды. Менә истәлекле бер хат. Ул 1958 елның гыйнварында язылган:

*«Әдип туган!*

*Яңа ел котлавыңны һәм хатыңны алдым. Игътибарың өчен зур рәхмәт. Дипломны (сүз Мәскәүдәге әдәбият институтын читтән торып тәмамлавым турында бара — Ә. М.) уңышлы яклавың белән чын күңелдән котлыйм... «Усу юлы»н «Юность» форматында елга 3—4 тапкыр чыгарырга уйлыйбыз. Очерк бик кирәк иде бит. Бу турыда Гариф белән Фазылга да телеграмма биргән идек. Белеш әле, алар берәр нәрсә язалармы икән? Ахыр чиктә Шамилне кур. Ул төзүчеләр турында берәр очерк бирә алмасмы? Таш ярып булса да, 15—20 гыйнварга кадәр бер очерк җибәрегез. Кабатлап язам, түгәрәктә уйлашыгыз әле, безгә альманахка кем нәрсә һәм кайчан бирә ала. Җавап көтәм.*

*Сагынып — Гали абыегыз.»*

Шагыйрь Гали Хуҗи нефть якларында яшәүче әдәбиятчыларның иҗатлары белән гел кызыксынып торды, аларның уңышларына куанды, язмый башласак — борчылды.

«Поэмаңны кайчан төгәлләргә уйлыйсың?» «Яшьләр газеталары конкурсына катнашасы иде. Әлмәт сынатмаска тиеш!» «Шамил, ни өчендер, һаман кульязмасын җибәрмәгән икән әле. Тоткарлык нидә?»

Мондый искә төшерүләр аның һәр хаты саен диярлек була иде. Ләкин шагыйрь хатларын үгет-нәсихәт өчен язмады. Хатлар аша ул, янәшәңдә утырган шикелле, үз итеп сөйләшә, киңәш-табыш итешә, хисләрен, тойгыларын уртаклаша иде. Ә бәйрәм һәм яңа ел котлаулары һәрвакыт шигырь белән язылган булыр.

1964 елны каршылаганда җибәргән котлау хаты:

Ни дисәк тә гомер китәр үтеп,
Киртәләр дә очрар юлларда.
Йөрәкләрне сүнмәс факел итеп,
Бергә атлыйк яңа елларга.

Заман безне, ә без аны айдап,
Узсын гомер сагынып сөйләрлек:
Булсын яшьләр безнең үрнәк белән
Янып яшәп, сөелер-сөярлек!

Гайшә, Гали.

28. XII—63».

Әлмәткә адреслап «Исән-имин кайтып җиттем», дип язган соңгы хаты юлда калды, газеталардагы кара каймалы некрологы безгә алданрак килеп җитте...

Гали Хуҗи «Зәй» колхозы хезмәтчәннәре турында күләмле поэма язган иде. Шуны тагын да җанландыру, «кешечә итү» өчен дип, 1966 елның октябрендә Әлмәткә командировкага килде, «Нефтяник» гостиницасында тукталды. Күңеле аның бераз төшенке, кәефе юк чагы иде. Каяндыр табып, аягына иске кирза итек кигән. Ябыккан, йөзе агарынган.

— Зур җыентыгымны төгәлләдем,— диде ул. Аннары «Зәй» турында сүз чыгарды:

— Икәү барыйк әле, малай, син дә бераз җилләнеп кайтырсың. Поэманы бу килеш кенә бастырасы килми иде бит...

Ләкин «Зәй»дән без көткән машина күренмәде. Гали абый икенче көнне сәламәтлегеннән зарлана башлады.

— Гостиница артында төне буе бер эт улап чыкты, йокы-мазар бирмәде,— диде ул.

Шагыйрь «Казанны сагындым» дигән сылтау белән кайтырга җыена башлады. Күңеле алдан сизенгән, күрәсең...

Таксига утырып аэропортка барганда, ул нефть яклары пейзажыннан күзләрен алмады. Ерактан күрмәсә дә, чекерәеп карарга тырыша. Ләм-мим дәшми, уйга чумган. Лениногорск чатына җиткәндә Гали абый телгә килде:

— Шамилгә әйт, ялкауланмасын. Дөнья күргән малай ул...

Ул моны өлкәнлек хокукы буенча әйтте, яратып, якын күреп. Аның бу сүзләре һәммәбезгә дә кагыла иде. «Язгыз, ялкауланмагыз». Ягъни тормыш тәҗрибәсе, сәләте булган язучы бүгенге чынбарлыкка битараф калмаска тиеш.

...Ике моторлы самолет, күзгә күп шикелле моңсу, арыган юлчыны төпсез биеклеккә, зәңгәр күк катына алып менеп китте. Бу безнең соңгы саубуллашуыбыз булган. Җирдә моңсу тынлык калды. Колакта мотор тавышы һәм шагыйрьнең кайчандыр әйткән сүзләре калды:

«Узсын гомер сагынып сөйләрлек»...

Тормыш юлын кирза итекләрдән ерып үткән искиткеч кешe җанлы шундый шагыйрьне сагынмаска мөмкин дә түгел.

ӘДИП МАЛИКОВ

## Съезд ачылганда

Без Кремльдә. Аның Зур Сарае.
Кояш белән тулы иркен зал.
Иркен залны иңләп җыр яңгырый,
Күңелләрдә чиксез дәрт, хыял.

Әйтерсең лә яз чагыла бүген
Елмаюлы якты йөзләрдә.
Ул-кызлары итеп, зал түреннән
Ильич карый безнең күзләргә.

Күрәм: аталарча күз карашы
Ягымлырак бүген тагын да.
Әйтә йөрәк:
— Ильич, сез тордыгыз
Комсомолның бишеге янында.

Чыгардыгыз безне олы юлга,
Бөркет канатлары бирдегез.
Бары алга, бары югарыга! —
Девизыгыз шушы,— дидегез.

Үтәдек без сезнең васыятьләрне,
Домна арты домна кабыздык,
Буйсындырдык Амур киңлекләрен,
Идел тутырып саллар агыздык.

Цемент койдык яңа ГЭСлар өчен,
Һәм буйсыныр дала җире дә.
Без — яшьлеге илнең, киләчәге
Безнең белән бүген бирeдә
Ул-кызлары утыра Корчагинның,
Матросовның утыра дуслары.
Күрәм гүя алар арасында
Юнгштурм киган Мусаны.

Күрәм гүя таныш якты йөзен,
Шат тавышын гүя ишетәм,
Һәм мин аны бүген үзебезнең
Фучигыбыз итеп хис итәм.

Җитә безнең көтеп алган минут,
Зал түрендә — һәркем күзләре.
Һәркайсыбыз тыңлый дулкынланып,
Партиянең котлау сүзләре
Кайгыртучан газиз анабызның
Сүзе булып керә күңелгә;
Һәркайсыбыз Аңа солдатларча
Тугры булып калыр гомергә.

# ЙӨРӘК КАНЫ БЕЛӘН, ЙӨРӘК УТЫ БЕЛӘН

Моннан берничә ел элек матбугатта шагыйрь Хисам Камалов иҗаты турында үз фикерләремнә әйткән идем. Бу мәкаләдә аларның кайберләре кабатланса, укучылар мине гафу итәрләр. Чөнки бер үк иптәшнең әсәрләре турында сүз бара бит.

Безнең арабызда Юлиус Фучикның сайланма әсәрләрен укымаган кешеләр аздыр. Чех культурасы турындагы хезмәтендә ул, һәртөрле бөек сәнгать көрәштән үсеп чыга, ди. Иң бөек сәнгать — җиңелү ачысын татыганнар сәнгате икәнлеген, чөнки аларның әсәрләре йөрәк каны белән, көрәштә алган яралардан ага торган кан белән язылуын әйтә.

Әйе, чын сәнгать әсәрләре һәрвакыт ихлас күңелдән, йөрәк каны белән, йөрәк уты белән языла. Моны шагыйрь Хисам Камалов иҗатына карата да әйтергә мөмкин. Әле мыек та чыгып өлгергәнче сугыш кырында канын койган һәм фронттан гомерлек авыр яра белән кайткан бу иптәш безнең поэзиябезгә кырыс тормыш мәктәбе үтеп килде. Шагыйрьнең бөтен иҗатында моның тирән йогынтысы сизелеп тора.

Хәтеремдә әле, педагогия институтында укыганда Хисам Камалов яшьләр газетасы редакциясе каршындагы әдәбият түгәрәгенә йөри, аның эшендә актив катнаша иде. Аның беренче шигырьләре дә безнең яшьләр газетасында басылдылар. Сугышта каты яралангач, «көрәш сукмагыннан ыргытылып, бетеп калуым шушыдыр» дип әрнегән яшь кеше яңадан сафка кайта. Хисам йөрәгенә төшкән яра сызлауларын җиңеп эшкә тотына:

**Тормыш белән атлыйм,**
**Юк, сөймимен**
**Мин кемнең дә булса аявын.**
**Ә көчсезләр әйдә еласыннар,**
**Оптимизм минем байрагым,—**

ди.

*(«Ак каеннар тәкъә шәм шикелле...»)*

Хисам Камалов минем берничә җыентыгымның редакторы булды. Аның белән әле дә еш очрашырга, аралашырга туры килә. Без, аның каләмдәш дуслары, бу киң күңелле иптәшне иҗатта, хезмәттә, үзара мөнәсәбәтләрдә таләпчән һәм гадел булуы, авырлыкларга сыкранмавы, башкаларга яхшылык эшләргә һәрвакыт әзер торуы өчен яратабыз һәм ихтирам итәбез.

Күп санлы әсәрләреннән күренгәнчә, Хисам Камалов үзенең туган ягына күңел тамырлары белән тоташкан.

**Әллә ничек бигрәк тәмле була**
**Җирдән күтәрелгән язгы пар.**
**Гүя анда минем тормышымның,**
**Яшәвемнең җылы тыны бар.**

Авторның туган як, туган ил турындагы шигырьләре тормышчан поэтик детальләргә, эмоциональ көчкә бай. Аның күңеленә туган җирнең гөлләре, имәннәре, каеннары тамырланып үскән. Ул, туган илдән мәңге аерылмас өчен, аның салкын чишмәсе булып агарга, таулары, күлләре булып, басуларны эссе җилдән саклый торган имәне булып әверелергә әзер.

Хисам Камаловның иҗади үсеше, поэзиянең олы юлына чыга баруы нәрсәдә чагыла соң?

Табигый ки, яшь һәм фронтта авыр фаҗигагә очраган шагыйрьнең беренче шигырьләрен туплаган «Яңадан сафка» һәм «Чияле тау» җыентыкларында авторның шәхси кичерешләре, туган авылы, анасының үлеме өчен әрнү мотивлары рамкаларында беркадәр чикләнгәнлек сизелә иде.

Соңрак Х. Камаловның «Лирик шигырьләр»е дөньяга чыкты. Аларда инде автор кешенең тормыштагы урыны, яшәү мәгънәсе турында төплерәк һәм тирәнрәк уйлана. Мәсәлән, аның «Партиягә гариза» шигыре олы гражданлык тойгылары белән тулы:

**Ачык сезгә минем эчем, тышым,**
**Бәпәсез һәм минем үткәнне.**
**Мин үтенәм: мине җәлләмичә**
**Авыр эшләр миңа йөкләүне!**
**Кыен еллар кичергәндә илем,**
**Бер кабым да аерым капмадым.**
**Россия каршысында минем**
**Йөзем-битем сөттәй пакь калды.**
**Кешеләргә файдам тисен иде,**
**Сезнең белән телим атларга...**

Шагыйрь кешеләрнең рухи дөньяларына һаман тирәнрәк үтеп керергә, үз әсәрләрендә кешеләр язмышын җырларга омтыла. Бу яктан аның «Бер сагыну турында шигырьләр»е гыйбрәтле. Аларда автор үткән сугышта үзенең гомер дустын югалткан бер ханымның еллар буе көтеп зарыгуларын, аның фаҗигале үлемен күңел тетрәтерлек итеп тасвирлый.

**Каберенә килдем беркөн Ландышның мин.**
**Тишелеп үскән анда ике зәңгәр чәчәк:**

**Гүя Ландыш күзләре бу, шундый охшаш!**
**Моңсу гына карап тора нурын чәчеп...**

**Карап тора гүя тере... әх, шул, телсез.**
**Һаман нидер көтә төсле бу ике күз!**

Дөнья тыныч түгел. Сугыш чукмарлары яңадан башларын калкыталар.

**Нишләргә соң! Алар сагыш татымаган,**
**Ябь-яшь килеш салкын җиргә күмелмәгән.**
**Янып, көеп кайнар күз яше коймаган!**
**Шуңа алар белми җирдә яшәү хакын,**
**Кеше хакын, сөю хакын, яну хакын!..**

Үткән ел «Литературная газета» битләрендә поэма жанры турында фикер алышулар булды. Мин бу бәхәсне башыннан ахырына кадәр кызыксынып күзәтеп бардым һәм моңарчы да билгеле булган бер хакыйкатьне үзем өчен тагын да ныграк ачыкладым. Проза һәм драматургия әсәрләрендәге кебек үк, поэмада тормышчан конфликт, тарихи һәм социаль шартларда алынган характерлар бәрелеше булу зарури. Әнә шундый тормыш материалыннан әдәби әсәр тудыру (аның сюжетын һәм композициясен төзү, үзенчәлекле тасвирлау чаралары табу, геройларның рухи дөньяларын ачып бирү, поэтик гомумиләштерүләр ясау) шагыйрьнең бу кыен бурычларны ни дәрәҗәдә оста хәл итә алуына бәйләнгән. Әмма бер нәрсә ачык: нинди генә жанрда һәм нинди генә алым белән язылса да, һәрбер әдәби әсәрнең бурычы — заман вәкилләре була алырлык, истә калырлык образлар тудыру.

Соңгы елларда Хисам Камалов берничә поэма иҗат итте. «Мәхәббәт хакы» әсәрендә Әлмәттәге төзүче яшьләрнең эшләре һәм рухи дөньялары, Зилә белән Инсафның мәхәббәте, алар арасында урынсыз килеп туган аңлашылмау һәм аны хәл итүдә коллективның ярдәме сурәтләнә.

Безнеңчә, бу — Хисам Камаловның хисләргә һәм поэтик фикерләргә иң бай, иң әйбәт әсәрләреннән берсе. Поэманың төп геройлары, бигрәк тә Зилә образы, истә калырлык итеп тасвирланган.

Шагыйрьнең «Зәй буенда» (Девон җыры) исемле поэмасын шулай ук кызыксынып укыйсың; яңа геройлар белән очрәшасың, әсәрнең азагына кадәр алар белән якынаеп, дуслашып өлгерәсең. Шагыйрь үз характерлары, үз омтылышлары, үз ким-

челеклэро булган тормышчан образлар тудырган (мәсәлән, Зөбәй, Динә, Гриша). Әсәргә күңел күзе белән караган кеше моны күрмичә һич тә үтә алмый.

Авторның кимчелеге шунда: ул, урыны-урыны белән, производство детальләрен кирәгеннән артык җентекләп тасвирлауга бирелеп киткән. Мәсәлән, яшьләр кичәсеннән кайтканда Зөбәйнең Динә белән сөйләшүендә, буровойдагы аварияне бетерү процессын тасвирлаганда бу хәл үзен шактый нык сиздерә иде.

Ә «Туган җирдә» исемле поэмасында инде автор алдагы әсәренең җитешсезлеген кабатламаган; беренче планга кешеләр язмышын куйган; аларның хезмәтен, теләк һәм омтылышларын шактый тулы сурәтләүгә ирешкән.

Әсәрдә төп конфликт итеп тормыштагы, кешеләр аңындагы искелек калдыклары белән яңаның көрәше алынган. Иске тип работник Гафаров һәм үзенең исәбен күздә тотып, хисләрен теләсә кайсы якка бора белгән, йөзендә ясалма нурлар балкыган Лира белән яңа буын вәкилләре Миннияр һәм Сөмбеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә бу ачык күренә.

Шагыйрьнең яңа әсәре дә үзенең туган ягы Әлмәт кешеләре мисалында, Әлмәт җирләрендә язылган.

Автор үзенең туган шәһәре, аның кешеләре, аларның эшләре һәм тормышлары белән танышып йөри. Шушы гади генә сәяхәт әсәрнең сюжет корылмасын тәшкил иткән. Безнеңчә, поэмадагы иң катлаулы, иң кызыклы характерның берсе — Харис. Яшьлек дустына үзенең тормышын, эшен, гадәтләрен сөйли дә, ул болай ди:

**Хет яманла мине, начар диген,**
**Күңелем акка кенем ак минем,**
**Туган җирнең һәр нәрсәсен җәллим,**
**Бар ла шундый начар як минем!..**
**Кул бирә ул тагын, бармаклары**
**Чөерләнгән, янган чырае.**
**Бу тормышны**
**Җилкәсендә илтә**
**Тик шундыйлар гына, мөгаен!..**

Поэмадагы Сөмбел, Илсур һәм сыңар куллы агай образлары да истә кала. Чөнки әсәр поэтик яктан көчле һәм төгәл итеп эшләнгән. Автор үзенең әсәре өчен сайланган тормыш материалы белән таныш. Ул күп кенә тормышчан детальләр, оригиналь охшатулар, поэтик бизәкләр тапкан. Мәсәлән:

**Үткән яшьлек тарта иске Әлмәткә,**
**Хәзергесе тарта — Яңага,**
**Яңа белән иске тартышалар,**
**Аркан тартышкандай мәйданда.**

Сугыш уты башка үренгәч, төрлесе төрле якка ташланган иптәш малайларын хәтерләп, шагыйрь туган шәһәренә «кут алырга» кайтуын болай дип аңлата:

**Шулар рухы әллә тарта, Әлмәт,**
**Әллә тарта туган туфрагым,**
**Сиңа кайтам, бәхетем кирелэнеп,**
**Сүрелгәндә тормыш учагым...**

**...Диңгезләрдә йөзгән пароходка**
**Моллюскалар ябыша, шулардан**
**Чистарттыру өчен һәр судноны**
**Кертәләр бит төче суларга.**
**Шулай мин дә ябышкакларымнан**
**Арынам бары синең суыңда...**

Шагыйрьнең бу поэмасы һәм «Рәхмәт сиңа, кеше» исемле яңа җыентыгы, шулай ук, аның иҗади үсеше, поэтик тавышының ныгый баруы, торган саен тулырак һәм

күтәренкерәк сулыш алуы турында сөйлиләр. Аларда Хисам Камалов иҗатының төп сыйфаты, төп үзенчәлеге — әсәрләренең чын күңелдән язылган булуы тагын да тулырак ачыла. Шагыйрьнең рухи хәләтен чагылдырган күпчелек әсәрләре оптимистик моң, гражданлык пафосы, романтик һәм героик тойгылар белән сугарылган.

«Рәхмәт сиңа, кеше» җыентыгында да төп урынны автор замандашларыбызның эшләрен, теләк һәм омтылышларын, мәхәббәт, иптәшлек һәм дуслык мөнәсәбәтләрен тасвирлауга биргән. Аларда поэзия өчен иң мөһиме — укучы йөрәгенә һәм акылына тәэсир итәрлек фикерләр һәм хисләр бар. Болар — шагыйрьнең туктаусыз эзләнүе, әдәби осталыгының үсә баруы нәтиҗәләре. Менә берничә мисал:

Артык яшьләй кул астына кердек,
Кызлар билен түгел,
Сабан билен күбрәк кочтык без.
Еллар ачылыгын алабута
Ипие белән бергә йоттык без.

(*«Камы егете»*)

...Мин ук булсам, син каты җәя бул,
Теләгемә илтеп иреш тер.
Тиргәшсәм мин дөнья, дуслар белән,
Барсы белән мине килештер.

(*«Мин җир булсам»*)

Арышлар җитеп килгән чакта чыр-чыр сайраган тургайларны автор офыкның зәңгәр дугасына элеп куйган нечкә моңлы кыңгырауларга охшата.

Арышларның тәмам җитүе өчен
Гүя
Тургай моңы кирәк һәркайчан,
Шул моңнардан башка
Арыш ипие тәме
Булыр иде гүя башкача.

(*«Ипи тәме»*)

Авторның шагыйрь Сибгат Хәкимгә багышланган «Ул борчулы» шигыре тормыштан детальләргә һәм поэтик табышларга бай булуы белән аерылып тора.

Очрашкач та гәпкә керешә ул
Һаваларның торышы хакында:
Ел килеше ничек игеннәргә,
Кар ятымы ничек басуда!
Тәҗрибәле, уңган игенчедәй,
Бураннарны бер дә тиргәми;
Буран! Димәк, быел тары уңа,
Алтын бөртек ява җиргә, ди.

...Авырып йөри кеше кайгысыннан,
Үз кайгысын әйтми бүтәнгә.
Яхшы кеше дөнья йөген һәрчак
Башкалардан күбрәк күтәрә!

Сүз уңаенда Хисам Камаловның тагын бер яхшы ягын әйтеп үтәсем килә. Ул, шушы шигырьдә телгә алынган тәҗрибәле, уңган игенчедәй, поэзиябезнең яшь шытымнарын тәрбияләп үстерү турында чын күңелennән кайгырта; аларга армый-талмый иҗади ярдәм күрсәтә. Нәҗип Мадьяров, Ринат Рәхимов, Касыйм Фәсәхов, Абдулла

Сәләхетдинов һәм башка күп кенә яшь шагыйрьләрнең беренче китаплары аның булышлыгы белән дөньяга чыктылар.

Сөйләнгәннәрдән күренгәнчә, Хисам Камалов зур әдәбиятыбызны тудыруга үзенең лаеклы өлешен елдан-ел күбрәк кертә бара. Диңгез тамчылардан җыела, ди бит халык.

1965

## ХАТЛАРДАН

Әдип, Гариф һәм Фазыл!

Хатларыгызны алдым. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт! Һәммәгезне дә кызыксындырган мәсьәләләр турында Сезгә шушы уртак хатны язарга булдым.

Хәзер күпчелек язучылар Казанда юк. Ноябрьда балалар әдәбияты буенча киңәшмә үткәрү күздә тотыла. Шунлыктан правление семинарны 10 декабрьга чакырырга карар бирде. Татарлар һәм руслар — барлыгы 30 дан артык кеше чакырыла. Әлмәттән 5 кеше (Фазыл, Илдар, Мөдәррис, Шамил һәм Клара) килергә тиеш. Гариф, синең хатны мәсьәлә правлениедә хәл иткәч кенә алдым. Энҗене семинарга чакыру мәсьәләсен уңай якка хәл итеп булмады. Сөйләшеп тә караган идем, әйберләре бераз басылсын, алдагы елга чакырырбыз, диделәр. Поэмасы миндә әле, тагын бер тапкыр карап чыгып, «Үсү юлы»на яки «Азат хатын»га (журнал тиздән чыга башларга тиеш, диләр) тәкъдим итәргә уйлыйм.

Семинарга кадәр әле вакыт бар. Иптәшләргә әйтегез, яңа әйберләрен хәзерләп җибәрсеннәр яки үзләре белән алып килсеннәр. Әлмәт сынатмаска тиеш!

Яшьләр газеталары конкурсына катнашырга кирәк. Жюрида Зәки белән мин дә бар икән. Кичә генә жюри утырышы булды. Телгә алып әйтерлек әйберләр күренми әле. Аларны сездән — Әлмәттән көтәбез.

Әдип! Безнең егет янында булуың өчен тагын бер тапкыр рәхмәт! Син аны онытып бетермә инде. Ул юк-бар белән сезне борчымасын. Әйт, яхшы булсын.

Кульязмаңны секциягә тапшырдым. Озакламый тикшерерләр. Зәки сиңа бу турыда хат язды бугай. 4—5 октябрьда ОК пленумы булачак. Рафак белән сөйләштем. Ул сине пленумга чакырырга каршы түгел. Рекомендация бирүчеләр таптым. Әгәр секциядә кворум җыелса, сине обязательно чакырту чарасын күрермен. Бу план барып чыкмаса, бераз соңгараккa калдырып торырга туры килер инде. Синең турыдагы мәкалә наборда ята. Белмим, кайчан дөнья күрер. Редакциядә материал бик күп, диләр. Көтәргә калгач, көтәбез инде.

Гариф! Газиз абый сиңа хат язган икән. Җавабыңны соңлатма. Әлмәттән бик яхшы тәэсир белән кайттым һәм сезне сагынып та өлгердем инде.

Семьяда исәнлек. Үзем бер килеш эшләп ятам. Хәзергә хушыгыз. Сәҗидәгә, Саниягә һәм балаларга бездән — миннән һәм Гайшә ханымнан — күп итеп сәлам тапшырыгыз. Мине сораган иптәшләргә дә сәлам әйтерсез.

Хат көтәм.

Ихтирам белән,

Гали абыегыз.

P. S. Шамил, ни өчендер, һаман кульязмасын җибәрмәгән икән әле. Тоткарлык нидә?

*26 сентябрь, 1957 ел.*

---

Хатта очраган исемнәргә аңлатма. Әдип — Әдип Маликов, Гариф — Гариф Ахунов, Фазыл — Фазыл Мостафин, Илдар — Илдар Әхсәнов, Мөдәррис — Мөдәррис Ибраһимов, Шамил — Шамил Бикчурин, Клара — Клара Булатова, Энҗе — Энҗе Мөэминова, Сәҗидә — Сәҗидә Сөләйманова — болар барысы 1957 елда Әлмәттә яшәүче яшь язучылар.

Зәки — Зәки Нури, шагыйрь.

Рафак — Рафак Тимергалин, журналист.

Газиз абый — Газиз Иделле, язучы, Татарстан язучылар союзында озак еллар әдәби консультант булып эшләде.

Сания — Сания Мостафина, «Татнефть» берләшмәсендә инженер.

Гайшә ханым — Гали Хуҗиның хатыны. Ред.

**Равил Вәлиев**

# КАУРЫЙЛАР ЧЫНЫККАНДА

## Күршеләр[1]



Ниһаять, Чаллы җирендә үзебез салачак беренче йортның нигезенә аяк басар көнебез җитте! Йорт нигезенең беренче блокларын монтажлый башлау хокукы безнең звенога бирелде.

Чаллы шәһәренең көньяк-көнбатыш читендәге җиденче кварталның төзелә генә башлаган чагы иде әле. Беренче көнне эшкә чыгу белән үк үзебезне бирелдәге төзелеш ыгы-зыгысының нәкъ уртасында торып калгандай хис иттек. Алда — безнең участокта эшләүче Кави Хәйруллин бригадасы ташчылары үзләре салачак йортның кырыенда кран юлы сузалар. Уңда һәм сулда эре панельдән бишәр катлы йортлар төзелә.

Янәшәдән генә, тасмадай сузылып, озын юл үтә. Ул Кама автомобиль заводының төзелеш мәйданнарына алып бара. Юлдагы машиналарның кайберләре, барган уңайларыннан борылып, безнең дүртенче төзелеш участогына юл тоталар. Әнә, хәрби өйрәнүләргә чыккан ракета установкасын хәтерләтеп, күтәрү краны килә. Әнә, тугызынчы йорт яныннан сузылган тимер юлда башнялы кранны күтәртеп яталар. Әйтерсең космик кораб галәмгә старт алырга әзерләнә! Бер якта субай суктыру машинасы, «катюша»лар залп биргән вакыттагы кебек, салыначак йортның нигезенә бетон баганалар кага. Юан, озын карандаштай субайларга аның авыр тукмагы гөрселдәп килеп төшкән саен аяк астындагы җир селкенеп китә, участок конторасы урнашкан зәңгәр вагонның пыялалары зыңгылдап куя.

Участок начальнигы Сәет Җамалетдинов та бу көннәрдә әле Хәйруллин бригадасы ташчылары арасында, әле безнең янда бөтерелде.

---

[1] Башы 2, 3 саннарда.

Әйе, шатланыр урыны бар иде Җамалетдиновның. Ул җитәкләгән участокның төп көчләренә моңарчы гел бер-берләреннән аерылып эшләргә туры килде. Кави Хәйруллин бригадасы күзәнәкле бетон заводы поселогында тулай торак салды, ә Вазих Мәүлихов егетләре төзүчеләр поселогының дүртенче кварталында ашханә төзеделәр. Түбә ябучы кызлар бригадасының эшләре дә ал да гөл түгел иде: агач ботакларындагы тиеннәр кебек, бер түбәдән икенчесенә гел күченеп йөрделәр.

Бригадаларның болай аерым эшләве төзү материаллары белән тәэмин итүне читенләштерә, төп көчләргә җитәкчелек итүдә, үзара ярышып эшләүне оештыруда өстәмә кыенлыклар тудыра иде.

Хәзер менә барысы да күз алдында. Бригадаларының икесе өчен дә эш шартлары бер үк төрле: катлаулы Липецк ысулы белән йөзәр квартиралы берәр йорт салырга кирәк. Менә кайда ул ярышып эшләр урын! Хәер, рәсми төстә белдерелмәсә дә, бу ярыш башланган иде инде. Бер-беребезнең ничек эшләгәнен икенчеләребез «шыпырт» кына күзәтеп йөри.

Үзара танышып китүебез шактый кызыклы булды. Безнең бригадага изма китергәндә, аларның изма көтеп, эштән туктап торган чаклары иде. Ринат Кисюшев белән үзбушаткыч әрҗәсе төбенә ябышып калган изманы көрәп төшерергә дә өлгермәдек, Хәйруллин бригадасыннан, носилка күтәреп, ике егет килеп тә җитте. Аларны күрү белән, Ринат сөрән сала башламасынмы:

— Безнең изманы алырга килгәннәр. Вазих, кара әле боларны! Изма беткәч, аннан үзебез тик утырыйкмы?

— Бер үк шәһәрне салабыз бит! Әллә безне Америкадан килгән дип уйлыйсызмы? — дип карасалар да егетләр, Ринатның үз туксаны — туксан.

Безнекеләрдән кемдер Ринатны якларга маташкан иде дә, хәзер нишләрсез икән, кәрап карыйк әле, яңа танышлар, дигәндәй, мыек астыннан гына бер кырыйда елмаеп торучы участок начальнигын күргәч, тынып калды.

— Ярар, алыгыз инде, булмаса! — дип, бераздан Ринат та чигенергә мәҗбүр булды.

Беркөнне күңелләре төшеп киткән Хәйруллин бригадасы членнары, җыелышып, участок конторасына килгәннәр иде. Төшмәслек тә түгел шул. Менә ике атна инде кран юлы сузуның серен, тәртибен белеп җиткермәгән егетләр (ни дисәң дә, алар тимер юлчылар түгел, ташчылар бит!), кырмыскалар шикелле, тимер юл шпаллары арасында кайнашалар. Әмма эшнең очы-кырые күренми әле. Участокта махсус эш кораллары җитеп бетми. Моның өстенә ташчыларның йорт саласы алтын вакытлары әрәм була. Инде йортның нигезе өлгереп тә килә. Измәсе бар, кирпече бар. Җиңнәреңне сызган да, рәхим итеп, йортның стеналарын күтәрә башла! Тик юк шул — кран әзер булмау бу егетләрнең кулын тота.

Участок начальнигы Сәет Җамалетдинов ул көнне мәсьәләнең җитдилеген, берәүнең дә читтән килеп бригада өчен кран юлы төзергә җыенмавын аңлатып, аларны яңадан эшкә рухландыра алмады алуын. Ләкин егетләрнең борчылуы урынлы иде. Әйе, күтәрү краннары өчен тимер юллар төзү — ташчыларның теңкәсенә иң тигән мәсьәлә.

Әгәр бу эш белән шөгыльләнүче махсус төзү бригадасы булдырылса, дәүләт өчен дә, төзүчеләрнең үзләре өчен дә ничек файдалы һәм уңайлы булыр иде.

Кайчандыр бу нәкъ шулай да булган. Ләкин күптән түгел төзелешне механикалаштыру идарәсе җитәкчеләре кран юллары төзү эшеннән котылу юлларын тапканнар.

Ә крансыз — төзүче ике кулсыз. Күрше бригада ташчыларына, ихтыярсыздан, менә шулай «башка төшкәч башмакчы» булырга туры килде.

Без саласы йортның кырыена ниндидер рәхимле бәндәләр кран юлы сузып куйган иде инде. Күршеләрнең чиләнгәннәрен күреп, сөенешеп киткән идек.

Юк икән, иртәрәк шатланганбыз.

Нигез ташларын монтажлый башларга керешеп, берәз эшләп алырга да өлгермәдек, Саша Чернобровкин идарә иткән күтәрү краны кинәт туктап калды. Астан карагәнда озын агачка кадакланган сыерчык оясы кебек кенә булып күренгән кран кабинасының тәрәзәсеннән җирән чәчле башын чыгарган да, кулындагы ниндидер дәфтәр белән тимер юл шпалларына ымлап, безгә нидер аңлатмакчы була:

— Инструкция...

Ләкин, тугыз катлы йорт биеклегеннән аның сүзләре ишетелми һәм кранның нигә шулай кинәт кенә туктап калуына без һаман да төшенеп җитә алмыйбыз.

— Нинди инструкция ул? — дип гаҗәпләнәбез.

Ул арада Саша кранның текә баскычлары буйлап аска төшә башлады. Кранчы егет тимер юлга сикереп төште дә әле бер, әле икенче шпал башына кирза итекләре белән дөп-дөп басып, безгә якынлашты.

— Шпалларны ныгытмыйча торып, кран урыныннан кузгалмаячак! Минем дә баш ике түгел... Мондый тимер юлда эшләргә инструкция рөхсәт итми,— диде ул, дәфтәрен баш очында болгап.— Ишетәсезме, инструкция диләр моны! Ул шаярганны яратмый...

Һәм аннары, килеп чыккан өзеклек турында акт яздырырга дип, төзелешне механикалаштыру идарәсенә китеп барды.

Нишлисең, блокларны монтажлауны туктатып торып, безгә дә, белер-белмәс баштан, кран юлын ремонтлау эшенә алынырга туры килде.

Күршеләрдән бер дә артык җиребез юк хәзер: көне буе шпаллар арасында казынабыз.

Рельсларны домкрат белән күтәртеп, какшаган шпаллар астына бик тырышып чуерташлар тутырдык, аннары ныгытып төйдек, тыгызладык һәм менә, бер тәүлек дигәндә, кранына җан керде.

Ләкин иртәгесен үк кран проблемасы безнең алда икенче ягы белән килеп басты.

## Кран проблемасының дәвамы

Участок мастеры Булат Шакиров кранчының путевкасына «Вынужденный простой» дип кул куйган иде. Чернобровкинның моңа һич кенә дә риза буласы килмәде.

— Эшләгән итеп яз! Мин гаепмени? Үзегез ич...— дип, мастерның колак төбендә безелдәп йөрде.

— Итекчедән пешекчегә әверелеп, ташчылар әнә кран юл суза. Әлеге простойларның җил-яңгыры нишләп сезне генә читләтеп үтәргә тиеш? Аңлашылмый...— диде мастер һәм, сүзне беткәнгә санап, күрше бригадага китеп барды.

Ләкин сүз бетмәгән, киресенчә, яңа башланып кына киткән икән әле.

— Кранчыга аңа ни? Окладка утыргач...

— Кертергә иде аларчы бригада составына, туләргә иде эш башыннан. Узына алмаслар иде ул чакта,— дип шаулаштылар бригада членнары.

Кранчы егет ачуының ачысын беренче булып Хәбир Нәбиуллин татыды. Ул көнне Хәбир дежур стропачы хезмәтләрен башкара иде.

Менә ул әле яңа гына килеп туктаган машина әрҗәсенә менеп басты да, андагы блокларны бушатырга ниятләп, монтаж элмәкләренә кран кармакларын киертә башлады.

Эләктерәселәрен эләктереп бетерде дә дирижер кебек уң кулын өскә күтәрде.

— Вира!

Ләкин кран ягы селкенмәде дә.

— Төш машинадан!.. Йөкне күтәрткәндә кран астында бер җан иясе дә торырга тиеш түгел... Инструкция...

Нишләсен комсоргыбыз? Түзде. Бер блокны бушаткан саен, машинадан җиргә сикереп төшәргә, аннан кабат машинага үрмәләргә мәҗбүр булды. Әмма ахырдан, югарыга карап, йодрыгын селки башлады.

— Уф-ф, косарсың кыланышыңнан! Инструкция, имеш... Синең капризларың аркасында әнә машина тикле машина тик тора.

Кранчы тимер баскычлар буйлап йөгерә-йөгерә төште дә, әтәчләнеп, Хәбирнең бу эштә эшләргә рөхсәт бирә торган таныклыгын тикшереп менеп китте. Бәхеткә каршы, ул бар иде... Кранчының кирелеге моның белән генә бетмәде әле

...Тимер-бетон конструкциялер заводында блоклар гел бер озынлыктагы калыпларда гына коела. Ә йортның нигез ташларын монтажлаганда подвал ишекләре һәм тәрәзәләре өчен аларның төрле үлчәүдәгеләре кирәк. Шул блокларны кистерә алмыйча аптырап беттек. Компрессор чүкече белән дә ваттырып карадык. Юк, ватылган кисәкләр без теләгәннән я озын, я кыскарак була яки теткәләнеп бетеп, бөтенләй ярамас хәлгә килә. Менә шулай нишләргә белми торган чакта, Николай Курицин әйтә куйды:

— Блок диләр аны... Шикәр кебек теләгән җиреңнән китеп төшерә алмыйсың. Безнең Саратов шәһәрендә нулевиклар менә болай эшли торганнар иде,— диде ул, кулына ике лом алып. Аларның берсен җирдә яткан блок өстенә аркылы салып калдырды.— Менә шуның өстенә ватыласы блокны куябыз да, астына икенче ломны тыгып, кран ярдәмендә аны бер башыннан күтәртәбез...

Бер башы күтәрелгән блок, астагы блок өстендә яткан ломга килеп төшеп, без теләгән урыннан кителде дә китте.

— Бер ни дә әйтеп булмый. Чиста башкарылган эш! — дип, мастер Булат Шакиров та елмаеп куйды.

Әмма бу ысул һич уйламаганда киртәгә юлыкты.

— Инструкциядә мондый эш каралмаган,— диде кранчы Саша.

Утыр да ела шунда! Китап укып утырган булуын кәра син аның!

Мастерыбызның да сүзе үтмәде, кран кабинасы тәрәзәсеннән җирән чәчле башын чыгарган да:

— Ә-ә-ә, мастер иптәш! Таяк менә шулай ике башлы була ул. Дәреслекне без дә бик яратабыз аны,— дип, киная белән елмаеп торуын белә.

Шул чак участок начальнигы Сәет Җамалетдинов күренде.

— Кирәкми безгә мондый кранчы, Җамалетдиныч! Аның кыланышларына түзәрлек түгел,— дип каршы алдык без аны...

Ташчылар һәм монтажчылар, штукатурлар һәм буяучылар, кранчылар һәм мотористлар арасында әледән-әле кабынып торучан мондый бәхәсләрнең асылы шунда: алар бер үк объектта эшләсәләр дә, төрлесе төрле идарәгә буйсыналар. Хезмәткә түләү дә төрлесендә төрлечә.

Кранчылар һәм мотористларны, бергә эшләү чорында гына булса да, үзләре хезмәт күрсәтүче бригада составына кертергә һәм аларга коллективның ничек эшләвенә карап түләү системасына күчәргә кирәктер, мәгаен.

## Истәлекле көн

Җиденче сентябрь.

Нуль циклын тәмамлап, Чаллы җирендә үзебез төзиячәк беренче йортның беренче кирпечләрен сала башладык.

Беренче кирпеч! Ташчы булып өлгергәнлеккә, егетлеккә беренче имтиханны тота башладык дигән сүз иде бу.

Имтиханнар, имтиханнар! Үз гомеремдә кешегә аларны күп тапшырырга туры килә. Башта мәктәп имтиханнары, аннары — тормышныкылар... Берәүләре җиңел, икенчеләре авыр һәм үтә җаваплы.

Бүгенге Чаллыны «яшьлек полигоны, ирлек-кыюлык полигоны» дип юкка гына атап йөртмиләр, күрәсең. Без дә бүген бирейдә имтихан тотабыз. Беренче йорт — Чаллы җирендә безнең бригада тапшырачак тәүге имтихан ул.

Моны аңлау безне тагын да көчлерәк итә төсле. Ә көч дигәннәре бу көннәрдә, кирпечләрне катлаулы Липецк ысулы буенча салу алымы белән беренче мәртәбә күзгә-күз очрашыр алдыннан, безгә бик, бик тә кирәк иде.

Липецк ысулы дигәннәре, дөрестән дә, бик хәтәр нәрсә булып чыкты. Бу алым белән эшләгәндә, кирпеч араларындагы җөйләрнең калынлыгы миллиметрлар белән исәпләнә. Беренче рәт кирпечләрен салганда калдырылган вертикаль җөй, линейка белән сызылган кебек, түбәгә чаклы бер үк турыдан сузылып менәргә тиеш. Салынган йортның бөтен матурлыгы менә шушы җөйләрнең тигезләгенә, турылыгына бәй-

ләнгән. Беренче рәт кирпечләрен салганда инә очы кадәр генә ялгыштыңмы, эш бозыла дигән сүз. Чөнки нигездән башланган җөйнең, бии-бии менеп, кәрнизгә җиткәндә, ярты метрга чаклы авышып куюы да бик ихтимал.

Яңа алым турында бөтен белгәннәребез менә шушы инде. Таш эшендә теше чыккан Николай Курицинга беренче йортның беренче кирпечен салырга туры килде. «Таш эшен синнән дә күп белүчебез юк. Коткарсаң син коткарасың, дядя Коля»,— дип салпы ягына салам кыстыра-кыстыра, йорт нигезенең уң почмагына китерәп бастырдык үзен. Ә калганнарыбыз, ярым түгәрәк ясап, аның ничек эшләгәнен күзәтеп торабыз, йомырка чебешне өйрәтмәсә дә, «акыллы» киңәшләребезне биргән булабыз:

— Җөйнең калынлыгы бер сантиметрдан артмаска тиеш...

— Калынрак булса да мишәйт итмәс: югарырак менгәч, ялгыша башласак, запас миллиметрлар булыр.

Николайның эшләгәнен карап тору үзе бер рәхәт.

Менә ул, сул кулы белән үрелеп, янәшәдәге өемнән шикәр төсле ак силикат кирпечне алды, изоляция толенә салычган измә өстеннән, күз иярмәс тизлек белән, уң кулындагы мастерогы йөгереп үтте, тигез итеп җәелгән измә юрганы эченә теге кирпеч кереп ятты. Шык-шык бәрелеп, аның өстеннән тагын ташчы чүкече йөгереп узды.

Николай салган стена ялт итеп кала. Бармак башы зурлыгындагы кирпеч ватыклары да әрәм булмый — ул аларны, мастерогы белән кәрәп алып, стенаның уртасына тутыра. Кирпеч ватыклары — әйтерсең аның өчен ипи валчыклары!

Беренче йортыбызның беренче кирпечләре салынды! Бәхет-бәрәкәт иңсен бу йортка! Шуны теләп, пачь теләкләребездәй ак кирпеч өстенә челт-челт бәрелеп, якяктан бакыр акчалар очты.

Ул арада булмады, Балык бистәсе районыннан килгән керәшен егете Борис Давыдов, батырланып, нигезнең икенче почмагына барып басты. Ләкин ул бер рәт салып чыгарга да өлгермәде, уртада, Николай Курицин белән очрашкан урында, Борис салган кирпечләрнең вертикаль рәткә дерес ятмаулары беленде. Башын кашый егет. Аптырагач, кулына линейка алып, үзе салган кирпеч араларындагы җөйләрнең калынлыгын да үлчәп карый.

— Төп-төгәл... Белмим инде, хикмәт нидә?

— Балык бистәсе түгел син болай булгач, тел бистәсе! — ди Йосыф, аның кулыннан линейканы суырып алып.

Һәм бераздан... Үзе дә башын кашый башларга мәҗбүр була.

Эшнең херти булуын күреп, Николай да туктап калды.

— Үлчибез, үлчибез, тик берни дә чыгара алмыйбыз.

— Җамалетдиновичны чакырырга кирәк. Я булмаса, мастерны,— диде шунда кайсыбыздыр.

— Алар да каян белсен инде? Бу бит яңа алым әле. Менә без дә теориясен белгән кебек идек бит. Нигә килеп төртелдек соң алай булгач?..

Липецк «табышмагы»н чишә-чишә, әбәт вакытын да уткәреп җибәрә язганбыз. Тиз генә якындагы ашханәгә кереп тулдык. Чиратта басып торганда да, өстәл артына утыргач та безнең миләрне һаман шул бер уй бораулый: ничек ватарга бу каһәр төшкере Липецк «чикләвеге»н?

Ринат Кисюшев әбәттән ярты сәгатькә соңга калып килде. Әле генә финиш сызыгын үтеп чыккан йөгерешче кебек әлсерәгән, көчкә-көчкә сулыш ала.

— Раскладка... Геворгян... раскладка...

Атаклы ташчылар бригадиры, Татарстанның атказанган төзүчесе Геворг Геворгян — безнең өчен авторитет. Ләкин чигә шулай Ринатның теленә без һич уйламаган вакытта килеп керде соң әле ул? Бу «раскладка» дигәннәре ни аңлата тагын?..

Бераздан, куен кесәсеннән кирпеч рәсемнәре төшерелгән кәгазь бите чыгаргач, Ринатның әбәттән ни өчен соңга калып килүе ачыкланды.

Ул күзәнәкле бетон заводы поселогында эшләүче Геворгян ташчылары янына барып кайткан икән. Бригадада килеп туган хәлне түкми-чәчми тегеләргә сөйләп биргән.

Исәбендә ялгышмаган Ринат: өйрәнеп кайткан.

Бөтен хикмәт әнә шул «раскладка» дигән сүздә икән инде. Эшне башка вакыттагыча почмакларны күтәрүдән түгел, ә стенаның буеннан буена һәр кирпечнең кая, ничек урнашачагын аерым-аерым билгеләп чыгудан башларга кирәк икән. Ягъни җиде кат үлчәп, бер мәртәбә кисәргә кирәк икән бу ысул белән эшләгәндә.

Ринат өйрәткәнчә эшкә керешкән идек — син күр дә мин күр, тигез җөйләр барлыкка килә башлады.

Кич җиткәндә, аяк-кулларыбызны кузгата алмаслык дәрәҗәгә җитеп арыган булсак та, күңелләр күтәренке иде безнең. Кайтыр алдыннан үзебез салган стенага хозурланып карап тордым. Күрә белгән кешегә күп мәгънә бар икән бит бу гап-гади кирпечләрдә дә!

Алар хәзер гади кирпечләр генә түгел инде, алар бер стена! Бар, куптарып кара син ул стенадан бер кирпечне!

Кирпечне кирпечкә тоташтырып стена өйгәндәй тату коллектив та аерым кешеләрдән тора. Хис-теләкләр, янып-көюләр, омтылышлар да бер, уртак анда.

# Өмә

Комсомолның өченче съездында Ленин сөйләгән речькә илле ел тулу хөрмәтенә Чаллының барлык яшь төзүчеләре якшәмбе өмәсенә чыктылар. Берәүләр шәһәр урамнарын, яңа кварталлардагы йорт тирәләрен яшелләндерүгә катнаштылар, икенчеләр, шул исәптән безнең бригада да, үз объектларында эшләде.

Шул ук гадәти, күптән ияләшеп бетелгән эшне башкарсак та, күңелләр күтәренке иде безнең. Телне гел шаян сүзләр кытыклап, каршы йорт түбәсендәге репродуктордан агылучы көй авазларына кушылып, гел җырлап җибәрәсе килеп торды.

Төштән соң «Чулпан» кинотеатрында өмә нәтиҗәләренә багышланган тантаналы җыелыш булырга тиеш иде. Шуңа күрә көндезге икеләрдә эшне бетереп, эшләнгән кадәресеннән (көндәгедән бер сәгатькә кимрәк эшләсәк тә, норма үтәлгән иде инде) тирән ләззәт һәм тәм табып, өйләргә кайтырга чыктык.

Төзелеп бетеп килүче бишенче, алтынчы кварталлардагы яңа йортлар әйләнәсенә җәелгән кара туфракка утыртылган яшь агачларны күргәч, үз күзләребезгә үзебез ышанмадык. Әле иртә белән генә, без эшкә барганда, бирелә төрле кирпеч ватыклары, каткан измә калдыклары аунап ята иде. Ә хәзер... КамАЗ урнашачак мәйданнан җыеп алынган уңдырышлы кара туфракны таратып та өлгергәннәр.

Тулай торакларыбызга кайтырга, ашап-эчеп, киенеп-ясанып алырга никадәрле генә ашыксак та, безнең кебек ук яшь төзүчеләр тарафыннан тудырылган менә бу гүзәллеккә — яшь үсентеләргә онытылып карап торудан тыелып кала алмадык. Ниндиләре генә юк аларның биредә! Мәңге яшел, сабыр холыклы чыршы-наратлар һәм шигъри җанлы назлы каеннар, әрсез, талымсыз өрәңгеләр һәм көяз топольләр дисеңме — барысы да бар.

Яңа туфрак. Ерак җирдән күчереп утыртылган яшь үсентеләр, яшь тамырлар...

Бирешмәгез, каеннарым! Әле ныгып та җитмәгән тамырларыгыз белән яңа җиргә, яңа туфракка ныграк ябышыгыз!

Баш имәгез, наратларым! Әнә кешеләрдән үрнәк алыгыз!

Бер тернәкләнеп китсәгез, яшел бульварлар, аллеялар үсеп чыгар. Үзегез кебек үк яшь парлар, мәхәббәтләре турында сөйләшә-сөйләшә, сезнең арада йөрер. Талгын җилдә лепер-лепер селкенүче яфракларыгыз аларның бер-берләренә биргән вәгъдәләрен тыңлар...

Без барып җиткәндә, «Чулпан» кинотеатры алды гөж килеп тора иде инде. Төрле лозунглар язылган кызыл комачлар эленгән автобуслар, әсләре ябулы вахта машиналары әледән-әле килеп тукты.

Танырлык та түгел бер-беребезне: әле генә эш киеменнән йөргән кешеләр бәйрәмчә киенгән. Бригада членнары эштән соң әле беренче мәртәбә бергә җыела. Шуңа күрә кинәт менә мондый «ят» иткән киемнәрдә очрашкач, шактый сәер булды үзебезгә.

— Син бигрәк инде, бөтенләй директорга охшап киткәнсең,— дип шаярта Николай, Ганс Нәбиевнең ак якалы, кара галстук тагылган күлмәгенә, соры драп пальтосына һәм шундый ук төстәге эшләпәсенә карап.— Култык астыңа кыстырырга бер сары күн портфель генә җитеп бетми.

— Шаярма син Ганс белән,— дип сүзгә кушыла шунда Ибраһим.— Менә үзебез төзегән йорттан бер дигән квартира алып җибәрсен әле. Түбән Тагилдан игезәк кызлары белән сөекле Тәнзиләсен дә чакыртыр. Махсус контейнерда пианиносы да килеп җитәр. «Жигули»га чираты да якынлаша. Дөньясы түгәрәк. Безгә сәлам дә бирмичә, өр-яңа машинасында выжылдатып кына китәр әле ул Ганс абзаң.

«Чулпан» эченә кереп тулдык. Без утырышкан арада, оркестрантлар да килеп җитте. Кино пәрдәсе эленеп торган сәхнәнең бер кырыена урнаштылар да инструментларын көйли башладылар. Менә таудан агып төшкән чишмә агышын хәтерләтеп ялгыз скрипка кыллары чыңлап куйды. Бераздан аны виолончель авазлары күмеп китте. Ул да булмады, флейталар уйнап җибәрде...

Ул арада аскы рәттә утыручылар композитор Фрадкинның «Комсомольцы-добровольцы» җырын башлап җибәрделәр.

Москва елгасы буйлары;
Таңнарда сандугач җырлары.
Яшьләрнең — тынгысыз уйлары;
Без — кырыс заманның уллары.

Безнең бу минутлардагы рухи хәлебезгә гаҗәп аваздаш, һәрберебезгә яхшы таныш булган әлеге көйнең дулкыннары акрынлап астан өске рәтләргә үрмәләде һәм, озакламый, бөтен залны биләп алды.

Комсомоллар, комсомоллар,
Чын дуслык белән без көчлебез.
Кирәксә, утларны кичәрбез,
Өр-яңа якты юл салырга.
Комсомоллар, комсомоллар,
Ышаныч һәм сөю җаннарда,
Яктырсын ал кояш таңнарда —
Тик шулай чын бәхет табыла.

Күз алдыбыздан, кинофильм кадрларыдай, Амурда Комсомольск шәһәрен төзүчеләр үтеп китте.

Бүгенге Чаллы яшьләре дә Амурдагы Комсомольск шәһәрен салучыларга тиң бит. Шул турыда уйлап, шушындый зур төзелештә катнашуыбыз белән тагын бер мәртәбә горурланып куйдык.

Бөтен залны тутырып яңгыраган җыр, кул чабулар астында президиум членнары сәхнәдәге үз урыннарына үттеләр. «Камгэсэнергострой» идарәсенең ВЛКСМ комитеты секретаре Юрий Титов — яшьлек дәрте ташып торган озын гәүдәле егет — тантаналы җыелышны ачып җибәрде... Бу көнне аеруча тырышып эшләгән коллективларга, комсомол членнарына төрле бүләкләр тапшырылды. Бүләкләнүчеләр арасында безнең бригада членнары Әлфинур Әхмәтова, Борис Давыдов, Ганс Нәбиев һәм Анатолий Кононов та бар иде...

## Егерме алтынчы ташчы

Бригадага яңа ташчы килде.

Эшкә иң соңыннан алынса да, табель исемлегенә аның фамилиясе беренче булып язылды. Төзелештә беркайчан да күренгәне юк үзенең. Ләкин көнлек норманы безнең белән беррәттән үтәп бара. Алай гынамы әле? Ул килгәч, бригаданың бер көйгә генә аккан тормышы бөтенләй үзгәреп, җанланып китте, ташчыларга канатлар үсеп чыккандай булды.

Бригадабызның бу егерме алтынчы ташчысын без эшли торган «Жилстрой-1» идарәсендә генә түгел, бөтен илдә, бөтен дөньяда да бик яхшы беләләр. Ул — Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил!

...Барысы да бригадага ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре А. Василец килүдән башланды. Аның белән «Камгэсэнергострой», «Жилстрой-1» идарәләренең комсомол комитеты секретарьлары Юрий Титов һәм Юрий Завьялов, Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше штабы начальнигы Валерий Стекольщиков та бар иде.

— Я ничек, егетләр, буламы? — дип башлады сүзен өлкә комитеты секретаре, безнең һәрберебез белән кул биреп күрешеп чыккач.— Эш турында сорашып тормыйм инде: ул күз алдында. Иң беренче булып комсомол путевкалары белән килеп төшкән Казан егетләре исеменә тап төшермисез икән. Рәхмәт, егетләр, рәхмәт!.. Ә менә эштән буш вакытларыгызны ничек үткәрәсез соң? Бригадагыз белән бергәләшеп кинога булса да барганыгыз бармы икән?

— Юк бугай...— диде арабыздан берәү.

— Кафеларда кичәләр үткәрәсезме?

— Ял көннәрендә җыелышып табигать кочагына чыккалыйсызмы?

— Юк, дуслар! Болай ярамый. Хыялланып, канатланып яши белергә кирәк. «Хыялсыз кеше — канатсыз кош» дигәннәр бабайлар. Менә, мәсәлән, нигә дип Муса Җәлилне бригадагызга почетлы член итеп алмаска?..— Сезнең бригада кебек яңа оешкан коллективның ныгып җитүе өчен көндәлек эштән тыш ниндидер бер гомуми мәсьәлә өчен яну да кирәк. Бригадагызның тарихын язып барсагыз да бик әйбәт булыр иде.

Бу сөйләшү күп булса ярты сәгать дәвам иткәндер. Аннары кунакларыбыз, ашыгып, Кама автозаводы төзелеше мәйданнарына китеп бардылар.

Шулай да, рәхмәт сиңа, иптәш секретарь!

Югыйсә, бер төрле гадәти эшләргә күнегеп, йөрәкләребез йокымсырап бара иде. Иртән торып аннан-моннан гына капкалап аласың да эшкә чыгып чабасың. Менә көндезге ял вакыты җитә. Бирелгән бер сәгать вакытка сыешыйм, эшкә соңга калмыйм дип, тизрәк ашханәгә йөгерәсең, бормаланып сузылган чиратның ничек тә алгы очынарак эләгү ягын карыйсың. Аннары тагын эш. Тулай торак, йокы. Иртәгесен тагын шушы бер үк төрле тормыш: эш — ашханә — тулай торак — эш. Чаллыга килгәндә вагонлап төялгән энтузиазм акрынлап кими, романтика атлы кайнар җилләр исүдән туктый, борыннар салына, йөрәкләрне юшкын баса башлый.

Юк, болай яшәргә ярамый иде. Чаллыга, яшьлек шәһәренә, көчебезне кызганмыйча эшләргә, вакытында ашарга-эчәргә һәм йокларга да килмәдек бит инде...

Дөрес әйтә иптәш секретарь: коллективның ныгып җитүе өчен айлык норманы 140—150 процентка үтәп бару гына җитми, ә бригада членнарының ниндидер бер гомум мәсьәлә, гомум эш өчен янып, канатланып яши белүләре дә кирәк шул.

Бригадага кемне алу турында әлегә зурдан кубып сөйләшү булмаса да, ташчыларның күңелләре урыннарыннан купкан, килгән кунакларыбыз сибеп киткән «орлыклар», уңдырышлы туфракка төшеп, борын төртә башлаганнар иде инде. Тәмәке көйрәтеп алырга тукталган араларда булсын, эштән кайтышлый булсын — бригаданың почетлы членлыгына кандидатлар турында сүзләр әледән-әле чыккалап торды.

Соңгы көннәрдә Чаллы магазиннарында Казан тәмәке фабрикасы эшләп чыгарган яңа төр сигарет сатыла башлады. Аның чытырдавык кәгазьле тышына Казан Кремле каршындагы Муса Җәлил һәйкәле төшерелгән.

Беркөнне иртән, эшкә керешер алдыннан, будкабызда гәп сатып утырганда:

— Я, бер көйрәтеп алыйк, булмаса,— дип, Анатолий Турцев кесәсеннән әнә шул сигарет кабын чыгарды.

Тартмаса да, ни өчендер, ул капны Толядан Хәбир Нәбиуллин сорап алды. «Безнең комсоргка бүген нәрсә булган?» дигән сыман барыбыз да аңа караштык.

— Яле, дядя Коля, әйтеп кара әле! Менә бу капның тышына кем һәйкәле төшерелгән? — диде ул бераздан, дәрес аңлаткан укытучыдай, уң кулындагы сигарет кабын өскә күтәреп.

— Муса Җәлил ич... Бухенвальд төрмәсендә утырган диләрме әле аны?

— Моабитныкында,— дип Хәбир кызартып куйды Николай Курицинны.

Ләкин сүз барышында таякның икенче башы Хәбирнең үзенә дә тиеп алды. Җәлил турында үзе башлап җибәргән утның очкыннары кире аның үзенә килеп тиде:

— Ну, Хәбир, молодец та икәнсең! Комсорг итеп юкка гына сайламаганбыз үзеңне...

— Шулаен шулай. Тик минә комсомол членнарыннан взнос җыю белән чикләнә шул.

— Булмый болай, комсорг! Кызыклырак итәсе иде... Тормышны дим. Обком секретаре ничек кызартып китте үзебезне!

— Бер мин генә нишли алам? — диде Хәбир, акланырга тырышып.— Тотынып бергәләшеп, аннары карарбыз менә...

Озакламый айлык эш нәтиҗәләрен тикшерүгә багышланган бригада җыелышы булды. Хезмәткә түләүнең яңа системасы — тырышлык коэффициенты кертелгән көннәр иде бу. Соңыннан бригадага почетлы член алу турындагы мәсьәлә дә тикшереләчәк иде.

Җыелышны башлап җибәрергә дип бригадир Вазих Мәүлихов торып баскан гына иде, һич көтмәгәндә, будкабызга ВЛКСМның Чаллы шәһәр комитеты секретаре Кузьмин һәм комсомол өлкә комитеты вәкиле Гатауллов килеп керделәр. Кулларында бер кочак китап. Аны Казан театр училищесы студентлары бүләк итеп җибәргәннәр икән. Алар автомобиль заводы төзелешендә катнашучы яшь эшчеләрне шефка алган дусларыбыз. Китапларның титул битләрендәге язулар шул турыда сөйли иде.

Ләкин бүләк китаплар белән танышудан туган шатлыгыбыз озакка бармады.

Килгән кунакларыбыз берәз хәлләребезне сораштырып утыргач, сүз иярә сүз чыгып, безне оялтып алдылар.

— Шушындый пычрак будкада ничек түзеп утырмак кирәк? Ә үзегез комсомол-яшьләр бригадасы тагын.

Чыннан да, ял итү өчен билгеләнгән шырпы кабы чаклы гына будкабызның идәненә пычрак каткан, аңа юеш мунчала тиеп карамаганга да биш былтыр булган иде инде.

Кунакларыбыз оялттылар да, өметләндерделәр дә.

— Әгәр Җәлилне бригадагызга алу идеягез барып чыкса (каян ишетеп өлгергәннәр диген?), сарай кебек зур будка бирербез үзегезгә. Зеленодольск шәһәренең яшьләре, янга калдырылган материаллардан, Чаллы комсомоллары өчен мебель эшләп җибәрергә булганнар. Алардан да өлеш чыгарырбыз.

Әйе, менә диген итеп бизәр идек яңа будканы. Бирсеннәр генә. Кунаклар алып килгән китаплардан бригада китапханәсен дә оештырып җибәрер идек.

Әмма Җәлилне бригадага алу буенча барыбыз да бер төрле уйланмыйбыз икән әле.

— Башкаларга түгел, үзебезгә дә җитәрлек акча эшләп булмый әле,— ди икән Анатолий Свеженцев диген егетебез.

Свеженцевның, гомумән, чын йөзе ачыла бара. Ул эштә болай сынатмый үзе. Дүртенче разрядлы ташчы, бригаданың ветераны. Әмма һәр яңалыкка каршы чыгар ул.

Беркөнне дә:

— Бетерергә кирәк ул тырышлык коэффициентын, бригада членнарын ызгыштырудан башка файдасы юк аның,— дип сөйләнеп торды.

Бер Свеженцев кына тартәгә тибеп, әллә ни эш кыра алмас анысы. Кирәк икән, почетлы членыбыз нормасын аның өчен башкалар тутырышыр. Ләкин арабызда шундый иптәшнең дә булуы барыбызның да эчен пошырды.

Җыелышның беренче көн тәртибе буенча һәр бригада членының айлык эше эчә кузеннән үткәрелеп, куеласы коэффициентлар куелып беткәч, килгән кунакларыбыз китеп бардылар. Шундый мөһим мәсьәләне хәл иткәндә, «чит-ят күзләр»дән башка гына иркенләп сөйләшә, бәхәсләшә алсыннар өчен бригада членнарының үзләрен генә калдырасылары килде инде, күрәсең.

Икенче көн тәртибе буенча сүз комсорг Хәбиргә бирелде.

— Почетлы член итеп кемне алу мәсьәләсенә килгәндә,— диде ул,— минемчә, безнең бригада өчен Муса Җәлил кулай булыр. Татар халкының комсомол тәрбияләп үстергән батыр улын Татарстандагы иң зур төзелештә эшләүче комсомол-яшьләр

бригадасының почетлы ташчысы итеп алу, минемчә, нур өстенә нур гына булачак. Аннары Чаллы шәһәрендә патриот-шагыйрь исемен йөрткән урта мәктәп, районда Муса Җәлил исемендәге колхоз бар. Икесе дә — алдынгы коллективлар. Алар белән дә бәйләнешкә керергә мөмкин булачак.

Шуны да онытмыйк, эш исемдә генә түгел бит, иптәшләр! Муса Җәлилне бригадабызга алдык та — шуның белән эш бетте дигән сүз түгел. Егерме алтынчы ташчыбыз өчен көнлек норманы үтәп бәрырга да тиеш булабыз әле. Һәр айның билгеле бер көнендә, әйтик, рәттән ике смена эшләргә мөмкин. Бу смена, бәлкем, киләчәктә «Муса Җәлил сменасы» дип аталып йөртелә башлар. Шагыйрь исемендәге урта мәктәпнең кайсы да булса бер классы укучыларын шефлыкка алырбыз. Укучылар моңа, билгеле, теләп риза булачаклар. Берьюлы өч куян атачакбыз бит: герой якташыбыз сменасында эшләп, яшь буында патриотизм хисе тәрбияләнә. Бу булдымы — бер. Аннан соң укучылар җирдә аунап яткан кирпечләрне поддоннарга гына өеп китсәләр дә, бригада өчен, төзелеш өчен нинди зур файда булачак. Менә булды — ике. Һәм өченчесе: бер үк вакытта укучыларда төзүче профессиясенә карата мәхәббәт тә тәрбиялибез — бәлки аларда нәкъ менә Муса Җәлил сменасында эшләгән чакта төзүче булу теләге уяныр.

Җәлил өчен түләнәчәк акча кая китә дисезме? Аның бер өлешен тынычлык фондына җибәреп торырбыз. (Без бит төзүчеләр — иң тыныч хезмәт кешеләре!) Ә икенче өлешен бригаданың культура ихтыяҗларына тотарбыз. Бригада членнарының туган көннәрен билгеләп үтү өчен берәр сум акча җыеп йөрергә туры килмәс инде моннан соң, зурлабрак, башкачарак итеп үткәрербез. Һәрберебезгә «Юность», «Комсомольская правда», «Казан утлары», «Социалистик Татарстан» һәм башка газета-журналларга еллык подписка бүләк итә алырбыз. Әлегә ташландык хәлдә яткан будкабызны бизәп, анда «Муса Җәлил почмагы»н оештырып җибәрербез, шашка-шахмат алырбыз. Хәтта баяныбыз да булыр, бая гына иптәш Кузьмин вәгъдә иткәнчә, якын-тирәдәге шәһәрләргә, әйтик, Ульяновскига, Казанга, Алабугадагы Шишкин музеена су буйлатып кына, экскурсиягә барырбыз...

— Менә эшләр шулай тора,— диде Вазих, комсорг сөйләп бетереп урынына утыргач.— Бу бик җитди мәсьәлә. Муса Җәлилне бригадабызга алып, без үзебезгә зур җаваплылык йөклибез. Һәрберебезгә булган таләпләр дә арта төшәчәк. Җәлил эшләгән бригада члены прогул ясый алмый, эшкә соңга калмый, кушылган заданиене яхшы сыйфат белән һәм һәрвакыт арттырып үти... Ныгытып уйлашыйк, киңәшик. Иртәгә чаклы нинди дә булса бер уртак фикергә килик.

— Нигә иртәгә сузарга? Без бүген үк риза инде,— диде Николай Курицин.

— Риза, бригадир, риза! — диештеләр бүтәннәр дә.

— Бригаданы простойда тотып, Муса Җәлилне эшсез яткырып карасыннар менә хәзер!..

— Егетләр, карагыз әле: беренче кар... Беренче кар бөртекләре төшә бит! — дип кычкырып җибәрде шунда тәрәзә янында утырган Ганс Нәбиев, балаларча шатланып.

Барыбыз да, этеша-төртешә, будкабызның кечкенә тәрәзәсенә ябырылдык.

Ә тышта чынлап та ак күбәләкләрдәй тирбәлешеп, таңкә-таңкә кар ява иде.

Мамык кебек йомшак, күбәләктәй җиңел, чиста кар! Быелгы көзнең тәүгә кары! Беренче октябрь кары!

Бу көннәргә байтак вакыт үтте. Хәзер безнең сарай кебек иркен «Культура йорты»быз бар. (Аны будка дип атарга тел дә бармый хәзер.) Аның эченә керсәң, кире чыгасың килмәс.

Ишектән керү белән, түр як стенага эленгән Муса Җәлил портреты күзгә ташлана. Аны безгә Чаллының яшь рәссамы Хөрмәт Халитов ясап бүләк иткән иде. Аз гына астарак, «Спецстрой»ның 21 нче төзү идарәсеннән Виктор Шатунов җитәкчелегендәге бетончылар бригадасы башлап җибәргән ярышта җиңеп чыгып, «КПССның XXIV съезды исемендәге бригада» дигән мактаулы исемне яулап алуыбыз өчен бүләк

итеп бирелгән радиоалгыч шаулатып сөйләп тора. Икенче почмакта — үз китапханәбез. Шүрлекләрдә — рус әдәбияты үрнәкләре, Тукай, Җәлил томнары. Бригада китапханәчесе Әлфинур Әхмәтованың тырышлыгы аркасында, ул шүрлекләр гел тыгызлача, авырая торалар.

Бер як стенада — бригада ташчыларының фидакарь хезмәте белән яулап алынган күчмә вымпеллар, мактау грамоталары, «Мастерок» исемле стена газетасы. Икенче якта... Ә икенче якта — бригада членнарының тулы исемнәре. Бирегә килүчеләрнең игътибары башта, гадәттә, әнә шул исемлеккә беренче булып, кызыл кара белән язып куелган егерме алтынчы ташчыбызның исем-фамилиясе турысындагы анкета мәгълүматларына юнәлә: кайчан килгән — Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булды; ничәнче разряд белән эшли — өченче; партиялелеге — коммунист; башкарган җәмәгать эше — бригада членнарының киңәшчесе.

Киңәшче!

Әйе, бик дөрес әйтелгән сүз бу! Илнең КамАЗ төзелеше кебек гаять зур сынау кырында үтеп булмастай тоелган кыен киртәләр белән очрашсак, ирлеккә, өлгергәнлеккә имтихан тота-тота буыннар эстафетасын киләчәккә алып барганда арып-талып калсак, без кулыбызга Җәлил шигырьләрен алабыз. Аның яшәү ялкыны бөркелеп торган әсәрләре безгә бирешмәскә куша. Һәр сүзе каныбызга сеңгән таныш юллар кабат күз алдыннан йөгереп үтәләр.

Син яшәмә җирдә, файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомерең, маяк булып,
Үзеңнән соң килгән буынга.

Беләкләрдә көч артып китә. Һәм яңадан алга омтыласың.

Без ташчылар! Безнең исемнәр дә киләчәккә язылып кала. Алар — безнең салган йортлар! Яшьлек шәһәре Чаллыда, яңгырдан соң чыккан гөмбәләрдәй, калкып торучы бишәр-уникешәр катлы таш пулатлар — килер буыннарга без язып калдырган автографлар бит ул. Ә бу автографларны безнең белән бергә бригадабызның иң хөрмәтле ташчысы Муса Җәлил дә язышa.

## Марсель Зарипов

# ДИССЕРТАЦИЯ

*Колхоз авылы проблемалары*



Партиянең Тәтеш райкомы беренче секретаре Федор Андреевич Хохлов диссертация яклады. Диссертациянең эчтәлеген сөйләп тормыйм. Бу өлкәдә эшләмәгән кешегә аның әллә ни кызыгы булмастыр, ә крестьян эше белән кызыксынучылар диссертациянең исемен әйтү белән үк эшнең нидә икәнен аңлап алырлар. Хезмәтнең исеме болай: «Хуҗалыкның үз эчендә специальләшүе, авыл хуҗалыгы производствосын бер җиргә туплау һәм аның экономик файдасы».

Исеменнән күренгәнчә, диссертация беркадәр авыррак телле, әмма фикерләре бик төпле, аңлаешлы, темасы да актуаль. Хикмәт, әлбәттә, исемендә түгел, җисемендә. Барыннан да бигрәк бу диссертациянең ничек тууы, авторның саннар-фактлар өстендә уйланганда, гомуми нәтиҗә ясаганда нинди максат күздә тотуы бик мөһим.

Тагы шул ягы да бар: Федор Андреевич башкалар тәҗрибәсеннән чыгып эш итмәгән (яшерен-батырын түгел — бездә әле диссертацияне читтән торып, тыныч китапханә залларында гына язу очраклары да еш була), ә үз практикасыннан чыгып язган, үзенең хуҗалык алып бару, кешеләр белән эш итү принципларын анализлаган, уңышлары хакында сөйләгәндә ялгышларын да яшермичә туп-туры ачып салган.

Иң элек диссертациянең төп положениесенә тукталып китик. Производствоны специальләштерү һәм бер җиргә туплауны ничек итеп тизрәк, яхшырак тормышка ашыру, ничек итеп файда бирүен арттыру — «райондагы капитал төзелешне вакытлыча туктатып торып булса да, акча һәм материаль ресурсларны бер җиргә туплау» дип формалаштырылган ул.

Игътибар итегез — «бер җиргә туплау» диелгән. Бу — заман рухына ияреп кенә әйтелгән сүз түгел, производствоны моңарчы булмаганча эреләндерү, ягъни бер төбәккә туплауның нигезендә искиткеч зур потенциал көч ята. Диссертациянең аргументы — Хохловның яшәү һәм эшләү принцибы, күп еллык практика нәтиҗәсе ул. Аның белән килешмәскә, бәхәсләшергә мөмкин. «Төзелешне нигә туктатып торырга? Алайса, аны бөтенләй төзи башламау яхшырак ич!» — дип, гаеп ташларга да мөмкин. Әмма мондый сәер хәлнең кызыклы ягы шул, диссертациянең авторы, эше һәм авторитеты белән районда иң зур кеше,— хәзерге экономика законнарына тамчы да каршы килми торган дөрес фикердә торса да, кәнд әлек эштә, тормышта шуны биш куллап якласа да, практикада ул теләгәнчә килеп чыкмый.

Бу — минем фикерем генә түгел. Хохлов үзе шулай уйлый. Без аның белән күптәнге танышлар. Бер-беребезне Әлмәттән үк беләбез.

Шулай бер очрашуда мин аннан туп-туры сорадым: «Диссертациядә яклаган прин-

цибыгызны көндәлек эштә тормышка ашыра алдыгызмы соң?» — дидем. Ул бераз уйланып торды да күрсенеп: «Юк шул әле. Алай була калса, мин докторлык диссертациясе дә язар идем»,— диде.

Теория белән практиканың туры килмәү сәбәбен билгеле бер дәрәҗәдә Хохловның холкы, сабырсызлануы, эшне тизрәк булдырырга ашкынуы белән дә аңлатырга мөмкин.

Ашыгу кайвакыт файдага булмый. Сабырсызлыгы аркасында Хохловка вакыт-вакыт кыенга да туры килә. Әйтик, Тәтештә сортлы орлык булдыруны бик ашыктыралар. Ләкин сортлы орлыкны сынауның ныклы үз тәртибе бар, селекционерлар һәр яңа сортны иң элек аерым тәҗрибә участокларына җибәрәләр, анда аны үстереп сынап карыйлар, шуннан соң сортлы яңа орлык тәҗрибә кырларына күчә, тик шуннан соң гына колхоз-совхозларга таратыла. Очеркта моны ике юлда да әйтеп була, ә тормышта бу эшкә ун еллап вакыт китә. Күпме гомер әрәм була бит!

Газета-журналларда, әйтик, син чәчә торганнан яхшырак яңа сортлар турында язалар, ә син хәзергә берни эшли алмыйсың, яңа сортның сыналу узганын көтеп утырасың. Игенчегә, әлбәттә, инде искереп барган орлык белән эш итүе файдалы түгел, чөнки ун ел эчендә селекционер галимнәр уңышны тагы да күбрәк бирә торган яңадан-яңа сортлар китереп чыгаралар.

Хохлов чират җиткәнне көтми, кайдадыр яңа сорт ашлык чыгарганнарын я кешеләрдән ишетеп, я газета-журналлардан укып белә дә, иренмичә барып, алып та кайта. Мәсәлән, Ульяновск өлкәсендә «рамонский» дигән яңа сортлы борчак чыгаруларын ишеткәч, шундук барып алып та кайталар. Хәзер районның барлык колхозы яртылаш шул борчакны чәчә, аны чәчү файдалы: «рамонский» борчагы башка сортларга караганда өч көн алданрак өлгерә. Ә борчакны өч көн иртәрәк җыеп алу — зур файда ул, чөнки өч көн эчендә бөтенләй борчаксыз калуың да мөмкин. Эссе көннәрдә кипкән борчак кузаклары чырт-чырт ярыла башласа, басу өсте кар яуган төсле ап-ак була. «Рамонский» сорты исә бу бәладән котпара, аны чабып, суккан арада башка борчаклар нәкъ өлгереп кенә җитә... Белгород өлкәсеннән «валтицкий» дигән арпа кайтарткканнар, гектарыннан 40 ар центнер уңыш бирә. Куйбышев өлкәсеннән көзге бодай алдырганнар... Хәзер районда селекционерлар гына белә торган уннарча яңа сорт ашлык бар. Алар колхоз-совхоз басуларына иң тиз дигәндә дә биш елдан соң гына таралачак әле.

Тәтеш игенчеләрен, партизанчылык белән шөгыльләнәсез, ашыгасыз, басуларны сыналып җитмәгән сортлар белән чүплисез, дип гаепләрләр, ә Хохловның бу мәсьәләгә үз карашы бар. Карашы шактый төпле аның. Райкомның беренче секретаре итеп Хохлов сайланганга кадәрге җиде ел эчендә район кырларында уңыш 2 центнерга гына арткан булган, ә соңгы биш елда 6 центнерга артты. (Республика буенча узган биш еллыкта уңышның артуы 4,7 центнер.) Федор Андреевич дәүләт куйган тәртипләрне бозарга ярамаганлыгын, әлбәттә, белә, ләкин ул тәртипләрне бозарга мәҗбүр булмау турында алданрак уйлау яхшырак түгелме икән?

Мин Хохловтан: «Орлык мәсьәләсендә андый башсызлыкка барырга ярыймы? Әгәр дә уңыш булмаса?» — дип сорагач, ул, күзләрен кыса төшеп, миңа текәлеп карады, дипломат булыргамы, әллә туп-туры әйтергәме дип уйланып торды да:

— Дөньяны тынгысыз кешеләр яңарта,— диде.

Тынгысызлык сортлы ашлык булдыруда гына түгел. Игенчелек эшендә әле һаман кояш белән яңгырга да өмет итәргә туры килә. Игенне быел быелтыргыдан азрак җыеп кара, сиңа шундук әйтерләр: «Ә-ә, чәчү орлыгы белән шаярып маташкан идең, булдыргансың икән»,— диярләр һәм әйбәт кенә итеп шелтә дә чәпеп куярлар. Ә бит уйлап карасаң — һәр яңа сорт элеккесеннән яхшырак була. Булган сорттан начаррагын дәүләт комиссиясе кабул итми, селекционерга да начар сорт чыгаруның мәгънәсе юк. Кеше өчен гайре табигый эш бу. Куркыныч — орлык булдыру мәсьәләсендә түгел. Иң мөһиме — җирдән күңелең бизмәүдә.

Юк, теория белән практиканың туры килеп бетмәвен диссертантның гадәт-холкыннан гына чыгып аңлату дөрес булмас. Мин үзем Ф. А. Хохловның йөз процентка дөрес идеясен тормышка бик кыенлык белән генә ашыруыннан канәгать булмавының сәбәбе теләк белән чынбарлык, кирәк белән мөмкинлек арасындагы каршылыкта дип карыйм. Бу каршылыкның һәм объектив, һәм субъектив сәбәпләре бар.

* * *

Җырдан сүзне алып ташлап булмаган кебек, очеркта да юкны бар итеп язып булмый.

Федор Андреевич Хохлов үзе шушы Тәтеш районында, Кече Бисәр дигән чуваш авылында туып үскән. Малай чагында төннәрен кырда ат саклаган, үсә төшкәч, сука сукалаган, чәчү чәчкән. Агрономнар мәктәбендә укып чыкканнан соң, үз гомерендә беренче тапкыр чәчү әйләнешен төзегән. Аннары армиядә хезмәт итеп кайткач, МТСта партия оешмасы секретаре булып торган, икенче бер җирдә район авыл хуҗалыгы инспекциясендә эшләгән, Әлмәттә партиянең шәһәр комитеты секретаре, авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы да булган. Туган ягына инде Ф. А. Хохлов кырыкка якынлашкан, тәмам җитлеккән ир булып, агрономия, хуҗалык һәм партия эшләрендә зур тәҗрибә туплаган кеше булып кайтты.

Шулай да бу — аңа бик тә таныш, өйрәнелгән, күнегелгән тормышка кайту түгел иде. Хохлов «дөнья гизеп» йөргән арада крестьян тормышы бик күп үзгәргән, халыкның теләк-омтылышлары да үсә төшкән, мөмкинлекләре дә арткан икән. Ничәмә еллар буе авылны бөтен дәүләт, бөтен халык кайгыртып яши бит инде. Әнә шул елларда инде фән-техника революциясе китергән казанышларны социалистик хуҗалык тудырган яхшы яклар белән органик рәвештә кушарга, фән белән производствоны кушканда социализмга хас үз формаларыбызны табарга мөмкинлек бирердәй нигез салына.

Тәтеш — бөтен Идел буена хас бер авыл районы. Шул ук күп тармаклы хуҗалык, кырларында хәзерге заман агрономиясенә билгеле булган барлык төр ашлыкны үстерәләр. Фермада да җаның нинди терлек теле — шул бар. Мәсәлән, 46 фермада уртача 138 баш сыер асрыйлар, 55 авылда — бозау, 32 авылда — дуңгыз, 27 авылда — сарык. Башта күп итеп иген чәчәләр, терлек үрчетәләр, аннары, ничек булды икән бу? — дип уйлана башлыйлар. Ә менә, ничек булыр икән бу? — дип алданрак уйланганда акыллырак эш иту булмас иде микән?!

Ни чәчсәң, шуны урырсың, дигәннәр.

Эшнең оешкачлыгы район колхозларының, басу һәм фермаларда эшләүче меңләгән кешенең хезмәт нәтиҗәсендә дә чагылмый калмый. 1959 елдан 1967 елга чаклы, ягъни сигез ел вакыт эчендә, райондагы иген уңышы 2 центнерга, бәрәңге 11, шикәр чөгендере — гектарына 80 центнердан 118 центнерга хәтле генә арта. Фермаларның продуктивлыгы да акрын үсә. Ә продукция җитештерүгә китә торган чыгымнар тагы да арта. Бер процент сөтнең бәһасе 9 сум 70 тиеннән 13 сум 59 тиенгә, сыер ите — 72 сум 80 тиеннән, 100 сум 31 тиенгә, дуңгыз ите — 94 сумнан 118 сум 93 тиенгә күтәрелә. Шул вакытларда, КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы карары белән, барлык колхозларда да совхозлар дәрәҗәсендә гарантияле хезмәт хакы да кертелә. Хезмәт хакын түләүгә китә торган чыгым ун мәртәбә диярлек арта — 1959 елда бер көнлек кеше хезмәте 33 тиен булса, 1970 елда 2 сум 70 тиенгә җитә. Техника тоту, страховой чыгымнары да ике ярымга арта.

Федор Андреевич Хохлов, туган ягына кайтып, райкомның беренче секретаре булып сайлангач, статистик саннар эченә кереп чума, күп еллар буена җыелган акылтәҗрибәдән чыгып, крестьянча һәр ягын уйлап, иртәгәсе көнгә күз салырга тырыша. Нишләргә? Моннан ары эшне ничек алып барырга? Һәр елга ирешелгән кадәресеннән артыграк план кабул итеп, элеккечә генә дә эшли бирергәме? Әмма болай иткәндә, иң яхшы дигәндә дә, сан ягыннан гына үсү булыр, эшнең асылы үзгәрмәс, хезмәт җитештерүчәнлеге артмас, эш шартлары яхшырмас иде...

— Әлбәттә, иске киемне ямау салып төзәтеп булыр, тик аңа карап кием яңармас бит.— Алдагы көн турындагы уй-исәпләрен сөйләгәндә Хохлов үзе әнә шулай диде.— Иң яхшысы — киемне яңарту. Хикмәт — бер урындагы терлекне икенче урынга күчерү, кечкенә-кечкенә биш ферма урынына бер зурны булдыруда гына түгел. Без инде хәзер айга очабыз, ә фермада һаман көрәк-сәнәк белән эш итәбез әле. Терлекчелекне машинага көйләргә кирәк. Сыерны кул белән түгел, машина белән саусыннар, терлек караучылар урынында азыкны механизм белән җибәреп торучы операторлар эшләсен. Безнең техника заманы авылның һәр тармагында чагылырга

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ ◆ ДИССЕРТАЦИЯ ◆

тиеш, фермадагы эш шартлары завод-фабрикалардагы шикелле булсын. Бу мәсьәләнең хуҗалыкны оештыру, үстерү ягы гына түгел, политик, социаль ягы да бар...

Хохлов әнә шулардан башлап фикер йөртә, узган еллардагы тәҗрибәдән нәтиҗәләр ясый, кеше кешеләр белән сөйләшә, экономистлар белән бәхәсләшә, районны, һәр колхозны үстерүнең иң яхшы вариантын эзли, дүрт елдан соң диссертациясенең нигезе булачак принциптан — производствоны бер җиргә туплау һәм специальләштерү принцибыннан чыгып уй йөртә. Ул кадәр күп вак фермалар нигә кирәк? Нигә һәр колхоз нәселле таналарны үзе өчен үзе үстерә? Мәшәкате дә күп, аннары һәркем ул бозауларны яхшы сыер булырлык итеп үстереп җиткерә дә алмый. Ике йөз-өч йөз баш сыер күпме файда китерә? Әгәр бер-ике хуҗалык бөтен район өчен сыер ите, тагын бер-ике колхоз дуңгыз ите, сөт җитештерсә, өченчесе сарык ите, йон бирсә, дүртенчесе нәселле терлек үрчетсә, яхшырак булмасмыни?..

Болай эшләүнең файдалы икәнен күрсәтә торган бер мисал китерик. Тәтеш районы Буадагы шикәр заводы өчен бик күп чөгендер үстерә. Районның колхозлары һәр көзне заводка 450—500 мең центнер чөгендер тапшыралар, ә заводтан бер центнер чөгендер бәрабәренә 50 шәр килограмм түп — бик яхшы терлек азыгы — алып кайталар. Үзенә тиешле түпне һәр колхоз барып ала, кыш буе кар-буран ерып заводка машина, тракторлар җибәреп тора. Якынрак колхозларның эше җайлырак, ә ерак торучыларга җитмеш-сиксән километр җир йөрергә кирәк. Кайтарасы түптән күбрәк бензин әрәм итәсең. Әгәр завод янына зур бер промышленность комплексы салдырып, бөтен түпне шунда гына ташысаң? Түпне ташу чыгымнарын киметеп кенә дә меңләгән, миллионлаган сум акча файда итеп була бит...

Исәпләп карагач, бу программа әллә ни катлаулы булып тоелмый, ә чынбарлыкта эшне иң беренче нигезеннән башларга — фермалар төзергә, элекке зур сарай шикелле фермалар түгел, бөтенләй яңа типтагы биналар салдырырга кирәк. Аларда азык цехлары, конвейерлар булсын, иң авыр эшне машиналар эшләсен.

Башка бер җирдә бу мәсьәлә, бәлки, бик тиз хәл ителер иде, әмма Тәтеш кебек эчкәрге бер районда аны хәл итүе ансат түгел. Районда бернинди төзү индустриясе юк. Материалларны әллә кайдан, Казаннан кайтарырга кирәк. Төзүчеләре дә бик көчсез: «Межколхозстрой» гына; кечкенә генә бозау абзарын да өч ел сала. Читтән килеп ялланучылар эшләвен тиз эшли дә, ул чагында икенче бер кыенлык килеп туа — аларга материал җиткереп булмый.

Диссертация мәсьәләләрен кәгазьгә язганчы, аларга теоретик җавап кына бирмичә, практикада, тормышта эшләп күрсәтергә кирәк иде.

Хәер, Ф. А. Хохлов диссертациясен, кайбер кешеләр кебек, ансатрак юл белән дә яза алган булыр иде: берәр институтта темасын планга кертер, булган тәҗрибәне тикшереп, нәтиҗә-йомгаклар ясар иде дә, менә сезгә — рәхим итегез, укып, акылкиңәш алыгыз!» — дияр иде. Хохловка мондый юл ошамый, ул моңа кызыкмый, чөнки аны диссертациядән бигрәк, эшнең үзен тормышка ашыру кызыксындыра. Ә шул хакта инде башкаларга да сөйләп бирү, уңышларын уртаклашу, булырдай ялгышлар турында искәртеп кую теләге соңрак, эшне башлаганнан соң гына туа.

* * *

Федор Андреевич Хохлов үзе болай ашыгучан, сабырсыз кеше булса да, ашыкпошык кына нәтиҗә ясарга яратмый, мәсьәләне һәрьяклап уйлый. Кешеләр белән сөйләшкәндә ул йодрык та төяр, ныклыгын, принципиальлеген югалтмыйча, дипломат та була белер. Хохлов республиканың Министрлар Советына, партия өлкә комитетына килеп, районда «производствоны бер җиргә туплау һәм специальләштерү» мәсьәләсен кузгатуларын әйткәч, аңардан бу мәсьәләне ни рәвешле күз алдына китерүен, нипар кирәк булачагын сорыйлар. Хохлов өч нәрсә кирәк икәнлеген әйтә: акча, материал һәм төзүчеләр.

Аның фикере белән килешәләр, шулай да искәртеп әйтеп куялар:

— Белеп торыгыз: мондый үзгәртеп коруга бернинди антракт бирелми. Икмәк, ит, сөт, йон, бәрәңгене киметмичә, ел саен арттыра барып, бөтенесен эш уңаенда эшлисез... Шуңа ризамы? — диләр.

Хохлов хәлне аңлый, «риза» дип баш кага.

Әлбәттә, ул вакытта инде «фатиха» алуы әллә ни кыен түгел иде. Хохлов үзенең районында «эш куптарырга» җыенып йөргәндә, специальләштерү, производствоны бер җиргә туплау мәсьәләләре, терлекчелекне промышленностька нигезләп оештыру, крестьян хезмәтен завод-фабрика эшчеләре хезмәтенә якынайтуның төп шарты буларак, көн тәртибенә генә басып калмыйча, беренче чираттагы бурычка әйләнгән иде. Партиянең XXIV съездында Л. И. Брежнев алдагы елларда авыл хуҗалыгы эшендә специальләштерүнең тагы да үсәчәген, ит, сөт һәм башка азык-төлек җитештерү эшенә индустриаль ысуллар кертеләчәген тагын бер тапкыр әйтеп киткән иде. Моның шулай булырга тиешлеге билгеле — чөнки сүз безнең авыл хуҗалыгының киләчәген билгели торган процесслар турында бара. Партия бигрәк тә шунысына басым ясап әйтте: бу бик зур, бик мөһим эшне тормышка ашырганда без ялгышу, ашыгулар булдырмаска тиешбез. Специальләштерү эшен тагы да көчәйтү һәм авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерүне промышленностька нигезләп кору һәр конкрет очракта экономик яктан нигезле, һәр яктан өзерләнгән булырга тиеш, диде.

Шулай итеп, кайнар табигатьле, тырыш Хохловка бу эш бик вакытлы туры килә. Аның ниятен хуплыйлар, халык хуҗалыгы планына кертәләр, ә планга кертү инде ул — акча, материал һәм кешеләр бирү дигән сүз. Һәр хәлдә, шулай булырга тиеш, калган ягы инде бу планның ничек итеп тормышка ашырылуына карап эшләнә.

Ләкин «өстән» килгән планнан башка, эшнең тагын шул ягы да бар: секретарьның бу планына якташлары ни дип әйтерләр, аңа ышанырлармы, тормышка ашырырга риза булырлармы? Идеяне җитәкчеләр уйлап чыгарса да, аны халык тормышка ашыра бит.

Авыл хуҗалыгының бик күп мәсьәләләрне тормышка ашыруга юл ача торган берничә үзенчәлекле ягы бар. Мәсәлән, билгеле бер экономик сәбәпләр аркасында, әйтик, җитештерелгән продукцияне сату бәясенә карап, бер төрле эш белән шөгыльләнү файдалы, икенче төрлесеннән файда аз, ә өченчесеннән, күпме тырышсаң да, табыш алып булмый. Сарык асрау, хуҗалыктагы башка тармаклар шикелле үк, файдалы дип, экономист галимнәр күпме генә язмадылар! Әллә инде сарык дигән аңсыз хайван галимнәрнең язганнарын укып аңламаган, әллә колхозларда бу акыллы киңәшне тотмаганнар — сарыклар һаман да хуҗалыкны бөлдерә киләләр. Председательләр сарык ите, йон сату планын күпсенеп зарланалар, әмма тәртип, кирәклек дигән нәрсә үзенекен итә — алар, бу зыянны хуҗалыкның башка тармакларыннан килә торган файда бәрабәренә каплап булса да, сарык асрарга мәҗбүр булалар.

Ә менә хәзер, районда яңача эш кузгаткач, кемнәргәдер дуңгыз асрарга, ит, сөт җитештерергә, икенче берәүләргә хуҗалыгыңны тәмам бөлдерә торган сарык үрчетергә туры киләчәк. Кыскасы, берәүләргә — сөенеч, икенче берәүләргә — көенеч булачак. Ә мәсьәләнең асылы шул — сарык башка бәла булмасын, бүтән мал-туар шикелле үк колхозга файда китерсен.

Райкомга «Дружба» колхозының председателе Павел Федорович Захватовны чакырталар. Захватов председатель булып эшләгән дәверендә ветеринария академиясен тәмамлаган, тәҗрибәле, белдекле хуҗа ул. Районның киләчәктә специальләшү программасы буенча Пролей-Каша авылы сарыклар белән шөгыльләнергә тиеш, диләр аңа. Ун мең баш сарык үрчетеп, бөтен район өчен сарык ите һәм йон тапшырып барырга тиешсез, диләр.

— Нинди гаебебез өчен безгә ул бәлане тагасыз, Федор Андреевич?! — дип, Захватов аптырап кала, урыныннан ук тора.— Эшкә ярамыйм икән, азат итегез, тик колхозны бөлдермәгез. Сарык асрап, дәүләткә бурычка кермичә бер тиен дә хезмәт хакы биреп булмаячак. Минем дә бит кешеләрем бар: аларны ашатырга, киендерергә кирәк, мәктәп, культура сарае җиткерәсе бар.

Бу сүзгә каршы нәрсә дисен соң Хохлов? Пролей-Каша балалары өчен мәктәп салдыру, колхоздагы һәр семьяның таза яшәве турында мин дә уйлыйм, дисенме,

сарык ул баш исәбе аз булганда гына хуҗалыкка зыянлы, дисенме, сарык үрчетүне файдалы эш икәнен дәлилләп күрсәтсенме?

Хохлов шулай дип җавап бирә дә:

— Без сезнең колхозыгызны бөлдерергә җыенмыйбыз, киресенчә, баетырга уйлыйбыз,— ди.

Захватовның үз исәбе:

— Ничек итеп баетасың аны? Былтыр һәр сарык колхоз кассасына ун сумлык зыян китерде. Ун мең баш сарык — йөз мең сумлык зарар дигән сүз бит ул.

— Без ул эшне икенче төрле итеп оештырабыз. Фабрика-комплекс төзибез.

Захватов кулын гына селкә:

— Һәй, без инде ул — комплекс төзүче! Биш ел буе гади бер сыер абзары да өлгертә алмыйбыз.

Шулай дип Захватов үз сүзен сөйли, Хохлов үз фикерен куәтли:

— Сезнең сарыкларны алмаштырабыз, Ставропольдән мериносклар кайтартабыз. Бездәге сарыктан ике килограмм йон алсак, алардагы — биш килограмм бирә.

— Ставропольдә безнең өчен сарык үстереп куйдылармы икән соң? — ди Захватов һәм, әметен өзеп, урынына утыра.

Башкалар ничек уйлый торгандыр, миңа калса, Хохловның теоретик фикерләренең нигезле булуы аның практика белән ярашлы булуында, кечкенә генә бер нәрсәнең дә эшнең уңышлы яисә уңышсыз килеп чыгуына сәбәп булырын аңлауда, райком секретареның үзенә турыдан-туры кагылмаса да, һәрбер вак-төякне дә күрә белүендә. Ә тормышта без моның киресен бик еш очратабыз бит: берәр зур эшкә керешкәндә кем нәрсә эшләргә тиешлеген бәйнә-бәйнә итеп билгеләп куябыз, ул эшке инде тормышка ашыра башлагач эшне башкаручылардан эш таләп итү белән генә чикләнәбез.

Федор Андреевич Хохловның эш принцибы бөтенләй башка — эшнең иң авыр өлешен ул үз өстенә ала...

Алар үзара болай дип килешәләр: Захватов Белгород өлкәсендәге «Страна Советов» дигән колхозга бара, андагы хуҗалыкның ничек итеп бары тик сарыклар белән генә эш итүен, колхозның бөлмәвен, киресенчә, хәлләнеп, баеп баруын күреп кайта, ә Хохлов атаклы Ставрополь мериносларын кайтарту мәшәкатен үз өстенә ала.

Эш уйланганнан да җайлырак килеп чыга. Алдан ук килешеп, ставропольлеләр өчен дәүләткә ит тапшыралар, кулларына квитанция тотып, анда баралар. «Шушы квитанция бәрабәренә өч мең баш сарык бирегез»,- диләр.

Гадәттәгечә, партия райкомының пленумыннан соң, һәр хуҗалыкны специальләштерү планын колхозчыларның гомуми җыелышларында, урындагы партия оешмаларында тикшерәләр. «Дружба» колхозында коммунистлар, колхозчылар Ф. А. Хохлов тәкъдимен кабул итәргәме, юкмы дип фикер алышканда беренче кеше булып аны... Захватов үзе яклап чыга.

Дөньяда могҗиза булмый, диләр диюен, ә шулай да коньяк мериносларны юлда да әйбәт кенә кайталар. Идел буеның салкын кышына да түзәләр, хуҗалары көткәнчә, бишәр килограмм йон да бирәләр, ләкин колхозны черетеп баетмыйлар әле. Уйланган эш әле азагына хәтле эшләнеп бетмәгән, сарык абзарларын салып бетерәсе бар, баш исәбе дә бик күп түгел, тик шулай да дәүләткә йон сатып кына да колхоз 37 мең файда ала, эшнең инде терәлеп калмаячагы күренеп тора. Пролей-Кашага кайтарган меринос көтүенең даны шул кадәр зур — киләчәктә бу ферма нәселле сарык үрчетү урынына әйләнер шикелле, ә нәселле терлек гади терлектән ике-өч-дүрт мәртәбә кыйммәтрәк., Мин барында Ф. А. Хохловка Казаннан шалтыраттылар, сүз арасында гына:

— Федор Андреевич, сайлаучылар нәселгә сезнең сарыкларны кайтарырга дип наказ бирделәр. Булышыйк әле шуларга,— диделәр.

«Сезнең сарыкларны» диләр!

Әлбәттә, Хохлов фәрештә түгел, аның артык кызыбрак китә торган гадәте дә бар. Ул аны үзе дә белә. Кайвакыт кешеләрне «Тизрәк, тизрәк!» дип ашыктырудан көчкә тыелып кала. Әмма, районның үз эчендә специальләштерү, производстводы

бер җиргә туплау, хуҗалыклар арасында уртак экономик кызыксынуга нигезләнгән яңа мөнәсәбәт идеясе өчен көрәшә-көрәшә, аның Чапаевча командалык итү гадәтләре кими, аек акыл белән исәпләп эш итү, һәр директива, тормышка ашырган вакытта мораль стимул белән генә түгел, экономик кызыксындыру белән дә ныгытылган булса, йөз мәртәбә яхшырак үтәлүен аңлавы арта бара.

Мәсәлән, Кләш авылындагы промышленность комплексын башка объектлардан тизрәк өлгертәләр. Монда Буадагы шикәр заводыннан кайтарткан түпне ашатып, елына ун мең баш үгез бозау симертү күздә тотыла. Элегрәк ун ел эчендә дә бу кадәр бозау симертелмәгән. Колхозның ул кадәр үз терлеге юк, шулай булгач, бирегә районның башка колхозлары бозаулар тапшырып торачак, ә монда аларны дүрт йөз килограмм авырлыгына кадәр җиткерәчәкләр. Бик шәп эш бит бу. Бирегә кайсы колхоз күпме бозау тапшырырга тиешлеген әйтеп, бик әйбәтләп язалар, «үтәргә» дип директива җибәрәләр, ә бер ай да узмастан, комплексның хуҗасы Ибраһим Садыйков райкомга шалтырата:

— Абзарлар буш. Терлек китермиләр, симертер мал юк,— ди.

Нишләргә? Ит фабрикасын төзеделәр, бөтен эш кнопка, моторлар белән генә эшләнә, меңләгән бозауны нибары ике кеше карый, күпме акча, материал, вакыт әрәм иттеләр, ә фабрика эшләми. Хохлов үзе төзеткән комплекска үзе терлек юнәтергә тиеш була. Бер тапкыр бозау җыялар, ике тапкыр, ике мәртәбәсендә дә «кысып» алырга туры килә. Өченче тапкырында бу «үз сүзле» председательләр янына Федор Андреевич үзе чыгып китә. «Заря» колхозына килә, бераз карап-танышып йөри, кешеләр белән сөйләшә, аннары китәр алдыннан колхоз председателе Гатауллиннан:

— Кара әле, Равил Салихович, нигә сез Садыйковка каршы тырпайдыгыз?— дип сорый.

— Садыйковка тырпаймыйбыз, үз мәнфәгатьләребезне яклыйбыз. Без сыерларны карыйк, бозаулатып, бозауларны аякка бастырыйк та шуннан соң Садыйков аларны ит итеп сатсынмы, без эшләгәннән табыш алсынмы? Аннан безгә ни файда?

— Бозаулар өчен ул сезгә ун процент арттырып түли бит. Инструкциядә әйтелгәнчә...

— Бозау башына ун сумның артыклыгы!.. Аларны илтеп тапшыру кыйммәткәрәк төшә безгә. Ә бозауларны үзебез үстереп сатсак, безнең кулга ун сум гына түгел, йөз дә ун сум табыш керә. Кайсысы файдалырак? Садыйков белән берләшүме, әллә эшне үзебез ахырына кадәр җиткерүме?

Кызык кына килеп чыга шул: район өчен, димәк, дәүләт өчен файдалы эшнең шуны эшләүчеләргә файдасы юк. Чыннан да, нинди хуҗа үзенә тиешле файданы тикмәгә генә күршесенә бирергә риза булыр икән? Һәркайсына да файда китерерлек уртаклыкны эзләп табарга кирәк. Ике як та инструкциягә төзәтмә кертергә дип килешәләр: комплекс бозауларны бер ярым бәясенә сатып ала, өстәвенә, барлык транспорт чыгымнарын да түли. Хохлов башта Садыйков риза булмас, «Тиешле ун процентны өстәп түләрмен, шуннан артыгын өмет итмәсеннәр», дип әйтер дип курка. Шулай булганда инструкцияне үзгәртү өчен көрәшергә туры килер иде. Ә бер тапкыр кабул ителгән параграфны яңадан үзгәртүе ансат эш түгел! Күпме вакыт, көч исраф итәрсең.

Шулай да эш моңа барып җитми. Садыйков акыллы хуҗа булып чыга, ун процент дип карышып, шундый зур комплексның яртысын гына эшкә җигү файдалымы, әллә партнерларына артыграк түләп, комплексны тутырып мал симертү табышлыраккмы икәнен уйлый да соңгысына риза була.

Һәр нәрсә үз урынына утыра: бозауларны комплекска югары оешмаларның күрсәтмәсеннән башка да китерә башлыйлар, чөнки «Путь Ильича» колхозы сатып алган бозауларның хакын гына түләп калмый, ала торган табышын да партнерлары белән уртаклаша. Болай итү ике якка да файдалы. Мәсәлән, «Путь Ильича» колхозы терлек симертү комплексын төзүгә бер миллион ярым акча тоткан. Әлеге килешүдән соң аларның эшләре бик тиз җайланып китә, саф табышлары ике миллион сумга җитә. Бусы әле колхоз бозау бирүчеләргә түләгән акчадан башка гына.

Әнә шулай да була икән ул!

* * *

Хәзер инде төп сүзгә кайтыйк. «Хуҗалыкларны специальләштерү, производствоны бер җиргә туплау» программасы һәм экономик фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәдә алу өчен хезмәт язган кешенең үз эшеннән канәгать булмавы. Берәр төрле каршылык юкмы бирәдә?

Әлеге дә баягы, хикмәт — кешенең нindилегендә, фактларны, саннарны ничек бәяләвендә, күрәсең. Ф. А. Хохлов үзенең диссертациясендә азык-төлек җитештерүне специальләштерелгән хуҗалыкларга туплауның никадәр файдалы икәнен раслый торган уңай саннарны күрсәтеп кенә дә кала алган булыр иде. Чыннан да, һәр тармакта үсеш бар. Районлагы бөртекле ашлык уңышы өч ел эчендә генә дә ун центнерга арткан. Шул ук басуларда елына бер миллион пот икмәк артык җыеп алына. Шул вакыт эчендә ит җитештерү 41 процентка, сөт — 16, йон 108 процентка үскән.

Ләкин Ф. А. Хохлов — үз-үзенә бик таләпчән кеше, уңышлары өчен ул мактау көтми, бәлки кимчелекләрен табарга тырыша. Бер очракта сабырсызлыгы, ашыктыруы эшкә файда китергәнлеген дә, икенче бер очракта зарар икәнлеген дә күрә. Хуҗалыкларны специальләштерү һәм производствоны бер җиргә туплауның бик зур отышлы эш икәнлегенә, моның озаклэмый тормышка ашачагына башкаларны да ышандырырга тырышып, бу эш белән ул иң элек үзе дәртләнеп-янып йөри, эшне башлап кына җибәрергә кирәк, азагын ничек тә очлап чыгарбыз дип уйлый. Эшне алар бер нисез, бөтенләй юктан башлыйлар. Тәтештәге комплекслар республикада иң зур эш булыр, төзү материаллары, техника-мазары беренче чиратта безгә килер дип уйлыйлар. Берьюлы җиде җирдә, ундүрт миллион сумлык эш кузгаталар.

Ләкин бу төзелеш Тәтеш районындагыларга иң зур, иң беренче эш булып саналса да, республика күләмендә ул зур программаның бер өлеше итеп кенә карала, Чаллыда, Түбән Камада, нефть районнарында да бик зур төзелешләр бара. Шулай итеп, Тәтештәге комплексларга әле кеше, әле материал җитми: җыелма тимер-бетонны, мәсәлән, Ульяновскидан кайтарталар, торба мәсьәләсендә нефтьчеләр ярдәм итә.

Уйланган план буенча әлеге комплекслар — бик шәп азык кухнялары, биналарны җыештыра, азык җибәреп тора торган конвейер линияләре, эшләүчеләр өчен тудырылган уңайлы шартлары белән — сокланып карарлык үрнәк бер нәрсә булырга тиеш була.

Ә чынлыкта алай уйлаганча килеп чыкмый. Хәтта комплексларны иң алдан төзегән «Путь Ильича» колхозында да фермалар көнкүреш биналары җиткерелмәгән хәлдә эшли башлый: кызыл почмагы да, ял бүлмәсе дә, душлары да булмый. «Октябрьның 50 еллыгы» дигән колхоздагы сөт комплексында, азык цехы булмый торып, сыерлар, бозаулар асрый башлыйлар. Аларның запас печәннәре дә булмый, булган кадәресен бозауларга гына бирәләр. «Новый мир» колхозында дуңгызларны суыктан саклап кала алмыйлар. 65 мең сумлык дуңгыз баласы үлә. Комплекс төзүгә ике миллион сумлап акча тотып, өч ел эчендә нибары 95 мең сум гына табыш алалар.

Комплексларны төзи башлауның беренче елында 1 миллион 314 мең сум акча эшкә аша. Икенче елда исә 300 мең сумга артыграк була, өченче елда инде ике миллион сумны узып китә... Дүртенче елда эшләр ничек барыр? Төзелеп бетмәгән җиде комплекс бар иде, аларның кайсысына гына җитешеп бетәрсең. Барысын берьюлы эшлим дип комсызланмыйча, бөтен материаль-техник көчне туплап, башта берсен, аннары икенчесен, өченчесен төзеп бетерергәме?..

Ф. А. Хохлов диссертация яклаганда мин дә шунда булдым. Гыйльми совет әгъзалары тавыш биреп, тавышларны санаган арада, мин Хохловтан: «Әгәр тагын шундый зур эш кузгатырга туры килсә, алыныр идегезме?» — дип сорадым. Ул уйлап та тормады. «Әлбәттә. Алыныр идек, теге ягын, бу ягын уйлабрак. Хәер, нигә «алыныр идек» дим, — алынабыз! Бу комплекслар — производствоны үзгәртеп коруның башы гына бит әле. Башка хуҗалыкларда да шул ук эшне эшлисе бар. Аннары авылларның үзләрен әйбәтләп төзү эшенә керешәбез. Авылда да шәһәрдәге кебек булсын. Тормыш сабагы ярап куя икән ул, шулаймы?» — диде.

Уйлабрак карасаң — шулай шул. Кешенең акыл байлыгы калын-калын китаплардан укып җыйган белеме белән генә түгел, үзе эшләп җыйган тормыш тәҗрибәсе белән дә үлчәнә икән!

**Хатип Госман,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ЭМОЦИОНАЛЬ ТӨЕНЛӘНЕШЛЕ ШИГЫРЬ

Муса Җәлилнең «Кызыл ромашка» исемле шигыре бар. Ул хәзер дөньяның кай якларына гына барып җитмәгән икән! Син аны тагын бер ачып укыйсың, ул сине тагын дулкынландыра, тагын тирән уйларга алып кереп китә, көрсендерә... Ә бит төп вакыйгасе сугыш шартлары өчен иң гадәти бер хәл.

**Төнлә, минем яныма**
**Ятып батыр сугышчы**
**Атты дошманнарына,—**

дип сөйли кызыл ромашка үзенең кардәшләренә. Шигырьнең эчтәлегеннән күренгәнчә, егет берүзе унбиш фашистка каршы сугышкан, әмма чигенмәгән. Кулбашы яраланып, бик нык хәлсезләнгәннән соң гына ул сугышчан постын калдырып китәргә мәҗбүр булган, аның яра каны әлеге ромашкага тамып калган. Шушы вакыйганы шагыйрь, тугыз юлга сыйдырып, беренче карашка яхшы ук гадәти, хәтта шактый коры тестә сөйләп чыккан. Хәлбуки, шагыйрьнең төп максаты шушы вакыйгада: ул безне сугышчының батырлыгына сокландырырга һәм хисләребезне ул эшләгән эшнең тирән мәгънәсенә илтеп җиткерергә, безне әсәрләндерергә һәм дулкынландырырга тели. Төп вакыйгане хәбәр иткән шушы тугыз юлдан гына торса, шигырь безне, мөгаен, дулкынландырмас иде.

Хикмәт нәрсәдә?

Шигырь — эмоциональ сөйләм, диелә. Бу—кичерешле, дулкынланулы сөйләм дигән сүз. Әлеге тугыз юлның үзен генә аерып алып укысак, аңарда эмоциональ дулкын хәрәкәте сизелми, текст укучы аңыннан гади хәбәр, гади информация булып кына үтеп китә. Әмма инде шигырьне башыннан алып ахырына кадәр бербөтен итеп укып чыксак, шул ук тугыз юл безгә бөтенләй башка тәэсир ясый, безне дулкынландыра,

безне әсәрләндерә. Бу юлы инде әлеге тугыз юл үзенең эмоциональ дулкын көче белән тирәнгә үтә, укучының күңеленә керә, аның рухи дөнья чоңгылының төбенә үк җитеп, анда басылып, тынып яткан күңел сизгечләрен уята, кузгата, аларны җанлы хәрәкәткә китерә, укучының рухи дөньясын алар уяткан дулкыннар биләп ала.

Моңа шагыйрь нинди юл белән ирешә соң? Аңлатырга җайлы булсын өчен, шигырьне өч өлешкә бүлеп карыйк.

Беренче өлешне, шигырьнең башыннан алып, «Ромашкалар бар да ак, аерылмый бер-береннән» дигән юллар; икенче өлешне «Ничек болай берүзе...»дән «Нидән алсу төсләрең?» дигән юл һәм өченче өлешне «Әйтте кызыл ромашка»дан ахырга кадәр булган юллар тәшкил итә.

Беренче өлештә тасвир тыныч сөйләм белән алып барыла, монда буяулар йомшак, ак чәчәкләр иркә, бер-берләренә мөнәсәбәттә нәзлы, ваемсыз, иртәнге һавада аларның сулышлары да җиңел һәм үтә саф кебек. Шагыйрь бу тасвиры белән укучы күңеленә, аның хыялларына сафлык сирпи, гүяки зур хисләре кузгалып, ташып китүенә комачау булырдай очраклы, вак-төяк нәрсәләрдән укучы рухын арындыра, гүяки көтелмәгән канлы вакыйгага хикәясе аңа көчле тәэсир итсен өчен, аның күңелендә контраст халәт тудыра. Һәм кинәт... чукларына кан савып кызарган ромашка! Бу — гадәттән тыш хәл! Бу урында укучының күңеле әллә нинди хәвеф-хәтәр сизеп, сискәнеп китә. Укучы да җыелып килгән ромашкаларның сорауларына кушыла, аны да гаҗәпләнү, сагаю биләп ала:

**«...Син, сеңелкәй,**
**Ник үзгәрдең! Нишләдең!**
**Нидән кызыл чукларың!**
**Нидән алсу төсләрең!»**

Шушы сораулар әсәрнең икенче өлешен тәшкил итәләр. Шушы урында шигырьгә көтелмәгән икенче хис, икенче тойгы, хәвефле борчылу хисе килеп кереп, катлаулы кичерешләр тәэнен тудыра. Шигырьнең барышында кискен борылыш ясала. Укучы да күңеле бик сагайган, бик дулкынланган хәлдә әсәрнең өченче өлешенә керә. Әмма ул инде, баштагы кебек, үз хисләрен уятып җибәрер өчен, шигырьдән куәт алу белән генә калмый, бәлки киресенчә дә эшли: ул инде уянып, куәт алып җиткән үз хисләренең ташкыны белән шигырь юлларын үзеннән дә сугарып, үзе дә баетып бара башлый. Югарыда әйтелгән яхшы ук кырыс тугыз юлның публицистик информациядән эмоциональ сөйләмгә, сәнгатькә әверелүенең сере дә әнә шунда булса кирәк. Кечтеки хикәя гади информациядән шигъри кичерешкә әверелә:

**Егет китте, мин калдым**
**Канын саклап чугымда,**
**Көн дә аны сагынып**
**Балкыйм мин таң нурында,—**

дип тәмамлый кызыл ромашка үзенең гыйбрәтле хикәясен.

Зуррак күләмле проза һәм драма әсәрләре турында сөйләгәндә сюжетка туктамый үтмиләр. Аның алты буыны бар: экспозиция (кереш), төенләнеш, үстерелеш, кульминация, чишелеш, постпозиция (бетем). Без бу очракта төенләнеш дигән буынны аерып алыр идек. Кыска шигъри әсәрдә, бигрәк тә лирика белән сугарылган шигырьдә, сюжет буыннарының һәммәсе дә кулланылмый, әлбәттә. Ләкин биредә дә бер буын үзенчә вазифа башкарып үтә. Бу — төенләнеш. Ләкин бу инде вакыйгалар, коллизияләр төенләнешеннән аерыла төшә. Бу — **эмоциональ төенләнеш** диярие идек без. Дөрес, терминның мондый мәгънәдә әдәбият фәнендә кулланылганы юк әле. Әмма шигырьләрнең үзләрендә эмоциональ төенләнеш — бар нәрсә. Үзе булгач, шартлы рәвештә булса да, исем бирергә кирәктер. «Кызыл ромашка»да эмоциональ төен-

ленеш, безнең күзәтүебезчә, «Син, сеңелкәй, ник үзгәрдең?..» дигән строфада, ягъни әсәрнең икенче өлешендә. Тулаем татар поэзиясенә күз салсак, лирика катнашкан шигырьләрдә эмоциональ төенләнеш чарасының бигрәк тә Бөек Ватан сугышыннан соң көчәя баруын танырга мәҗбүр булырбыз. Моның үз мәгънәсе бар.



...Без поэзиябезнең борынгысына күз салсак һәм бигрәк тә лирикага игътибар итсәк, анда фәлсәфи уйлану төсендәге шигырьләрне, хикмәтле сүз, афоризм әйтүләрне күбрәк очратырбыз. Таланты зур, иҗтимагый күз күреме киң, фикер дөньясы бай һәм тирән булганда, шагыйрь бу жанрларда мәңге үлмәс кыйммәтле әсәрләр иҗат итеп калдырган. Ләкин бу сыйфатлары зәгыйфь булганда шигырь язучыдан ялыктыргыч нәсихәт сүзләре генә чыга алган, аның иҗатын коры дидактика басып китә торган булган. XVIII гасыр ахырларында безнең поэзиябездә дөньяви мотивлар көчәя башлый. Алар күбрәк шул ук фәлсәфи уйлануларда, хикмәтле сүз әйтүләрдә яңгырыйлар. Ләкин шуның белән бергә, шигырьдә фәлсәфи уйлану түгел, хикмәт әйтү түгел, бәлки кешенең кичерешләре хәрәкәтен гәүдәләндерү омтылышы да күренгәли.

Менә безнең алдыбызда билгесез авторның шигъри әсәре. Ул безнең заманга 1793 елгы күчермәдә килеп җиткән [1]. Шуннан бер өзек китерик:

**Ай-һай ла көннәр яз булды,**
**Китәр лә юллар саз булды,**
**Без гариплэрнең төшкән җире**
**Чыкмас ла тирән баз булды.**

**Казанга барган бар микән!**
**Казандин килгән бар микән!**
**Казан да дигән шәһәрдә**
**Безне дә белгән бар микән!**

**Казандин килгән солдатның**
**Сач кенәсе ла тәрмәдер,**
**Казанда булган туфырак**
**Күз генәмә лә сөрмәдер.**

**Казан да дигән хуш шәһәр**
**Бездин ла калды күп ерак,**
**Казанда булган җаннардин**
**Арада булды әлфиракъ.**

**Таңрем лә канат бирсәче,**
**Канатым кагып очсамчы,**
**Газиз дә Казан шәһәренә**
**Очып та барып төшсәмче...**

---

[1] «Казан утлары» журналы. 1967 ел, 1 сан. 147 бит. Шигырьне бастырган Н. Исәнбәт аның авторы хатын-кыз булырга тиеш, дип таба. Бу фараз безне шикләндерә. Пугачев җитәкчелегендәге халык хәрәкәте бастырылгач, күпләрне асканнар, кисканнар, күпләр сөргенгә, солдатка куылган. Шигырь авторы шундыйларның берсе түгелме? «Казандин килгән солдатның сач кенәсе ла тәрмәдер»,— дигәне Казаннан килгән солдатның часть (гаскәри бүлеге) кенәсе лә — тәрмә (тоткынлык дигән сүз) түгелме! Болай карганда, әсәр бөек халык сугышының шигъри бер авазы булыр иде. **Х. Г.**

Бу һич тә фәлсәфи уйлану яки хикмәтле сүз әйтү шигыре түгел. Монда автор үзенең бөтен рухи дөньясын тотырып кайнап килгән хисләрен ачып сала, эмоциональ ташкынның үзенә юл бирә, шигырьгә аның үзен чыгара. Шушы ягыннан ул — XVIII йөз татар поэзиясендә бөтенләй яңа күренеш, яңа бәреп чыккан чишмә. Соңрак без аның Г. Кандалый иҗатында үсеп киткәнен күрәбез. Шулай да ул заманда эмоциональ төенләнеш билгеләнеп, өлгереп җитми әле. Хис шигырьләре чыннан да кичерешләрнең ихтыярлы ташып баруын гәүдәләндерәләр, шуңар да алар еш кына артык озынга сузылалар, бөтенлек киртәсеннән чыгып китәлиләр. Мондый очракта аларның сәнгатьчә сыйфатына зарар килә.

Чыннан да без хәзерге шигырьдәге эмоциональ төенләнешне төрле яктан игътибар беләнрәк карасак, аның эстетик вазифасы шактый бай икәнен күрербез. Бу чараның, дияр идек без, бик көчле бер сыйфаты — шигырьнең барлык өлешләрен үз тирәсенә шактый кискен кырыслык белән җыеп алуында. Әйтерсең ул магнитлы үзәк, шигырьнең бөтен эмоциональ куәте аңа төбәлгән, аңа бәйләнгән. Яки, тупасрак димәсәләр, шигырьнең кендеге, кучәре дияргә мөмкин. Шигырь текстына ул тик аның үзенә бәйләнгән юлларны гына кабул итә, бәйләнмәгәнен кире кага, төшереп калдыра. Шуның өчен дә безнең заманда эмоциональ төенләнеш белән язылган шигырьләр өчен, кагыйдә буларак, күләм ягыннан кыскалык хас. Бу исә шагыйрьдән зур иҗат культурасы, зур сәнгать осталыгы сорый. Мондый культура, мондый осталык та кинәт кенә килеп чыкмаган. Ул татар поэзиясенең дәвамлы үсеше, һәр яңа тарихи чорда яңа сыйфатларга ия була баруы нәтиҗәсендә туган. Татар шигыренең XX йөздәге үсеш юлына күз салыйк.

1905 елгы халык революциясе белән күтәрелеп чыккан талантлар татар шигырен яңа заман таләпләренә җавап бирерлек итеп эшкәртәләр, күптән искереп тә һаман әле әдәбиятка ябышып, өстерәлеп килгән нәрсәләрне шигырьдән кисеп калдыралар, элек яралып та, үсә алмый кысылып яткан бәпчекләргә мул итеп заман азыгын бирәләр, шигырьне алга киткән халыкларның сәнгать тәҗрибәсе белән баеталар. Кызыксыз нәсихәт кысрыклана, поэзиядә җанлы кичереш агымына, эмоциональ ташкынга киң юл бирелә. Моны гамәлгә ашыруда һәр шагыйрь, талант үзенчәлеге сораганча, төрле алым куллана.

Габдулла Тукай, мәсәлән, эмоциональ агым тотрыксызланып, иксез-чиксез җәелеп китмәсен өчен, күп очракта шигырьгә символ-образ кертә. Бу — шигырьнең эмоциональ үзәге, магнитлы ноктасы. Калган бөтен чаралар, элементлар шушы ноктага төбәлгән, аңа омтыла. Нәтиҗәдә, шигырь түгәрәкләнә, җыйнаклача. Мәсәлән, «Күңел» шигырендә мондый үзәк — кешелеген җуймас өчен күп газапланган күңел, «Көзге җилләр»дә — елаучы ил, «Иһтида», «Ваксынмыйм» һәм «Өмит» шигырьләрендә җәмгыятьнең идеалсыз, черек элементларына каршы куелган Кояш, Фикер кояшы.

С. Рәмиев башкарак юл тота. Ул күбрәк кабатлауларга игътибар бирә: «Мин», «Күлмәк җыры» кебек әсәрләрендә шигырьләрнең эмоциональ үзәген тәшкил иткән строфаны ул үз әсәренең бетем өлешендә, рефрен итеп, яңадан кабатлый, шуның белән кичереш агымына очсыз-кырыйсыз җәелеп китәргә ирек бирмичә, аны бер киртәгә кертә, түгәрәкли, сәнгатьчә тәгәлләнгән нәфис формага сала. Бу алымның серле үзенчәлеге шунда: шигырьнең бетем өлешендә эмоциональ үзәк юлларын кабатлау укучының хис-тойгыларын баеган, тирәнәйгән хәлдә яңадан эмоциональ ноктага кайтара. Бу алым, гадәттә, сюжет төсмере бигүк анык булмаган, авторның субъективлыгы өстенлек алган әсәрләрдә күренә.

Эмоциональ төенләнешле шигырьгә сюжет төсмере хас. Аларда билгеле күләмдә динамика шәүләләнә, кешенең рухи халәтен пластик, ягъни гәүдәле чынлыгында яктыртып алу хас. Аңардан соң шигырьнең эчтәлек хәрәкәтендә кискен борылыш туа. Дәрдмәнд үзенең «Видагъ» шигырендә эмоциональ төенләнешкә бик якын килгән. Шигырь зур түгел:

**Тәгәрәп, уйнап,**
**Буй үскән**
**Туган илем, исән бул!**

Чәч кузгатып,
Җай искән
Таңгы җилем, исән бул!
Йөгереп-йөгереп
Туктаган...
Яулык болгап,
Сыктаган
Нәзкәй билем, исән бул!

Соңгы строфада үз-үзен белештермичә йөгергән һәм, тыны беткәч, кинәт туктаган, шунда да кулын югары күтәргән, ак яулыгын болгаган яшь кызның еракта калган сурәте бик ачык, бик чынлыклы һәм бик дулкынландыргыч булып күз алдына баса.

Искесез яңа булмас, ди татар халык мәкале. Безнең Бөек Ватан сугышыннан соң өлгергән эмоциональ төенләнешле шигырьебез дә буш урында юктан бар булмаган. Аның орлыгы XVIII гасырда, бәлки, аннан да элегрәк халык кузгалышларында катнашкан кешеләр күңелендә яралган, җәмгыятьтә явыз көчләр хакимлегенә каршы чыккан шәхесләрнең, фикер ияләренең хисләреннән азык алган, үскән, җитлегә килгән. Дәрдмәнднең югарыда китерелгән шигырендә без аның яңа эстетик вазифа үтәү чигенә килеп терәлгәнен күрәбез һәм аның яңа вазифасы безнең сугыштан соңгы поэзиябездә ачылып китте дә. Дәлилләрдән берсе — С. Хәкимнең «Фазыл чишмәсе».

Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем;
Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем.

Өздереп нигә карадың,
Ник тоттың чиләгемнән!
Суларым түгел, ялкыным
Түгелде йөрәгемнән...

Кызарып янган шәфәкътән
Күзләрем алалмадым...

Өзек хәрефләр белән бирелгән юллар шигырьдә, һичшиксез, эмоциональ төенләнеш тудыралар. Бу юллар әсәргә сюжет төсмере кертә, алардан соң шигырьнең барышында кискен борылыш туа, вакыйга лирик геройның ике строфалык күңел монологында сөйләп бирелгән.

Туфанга мөрәҗәгать итик. Аның «Кырда ике ак канат ята» исемле шигыре бар. Кырда ике ак канат ята. Шул тирәдә һавада, моңлы итеп кычкыра-кычкыра, ялгыз аккош әйләнә. Ә җирдә, бер кырыйдарак — төлке, ул аккошның үз мыегына сыланып калган каннарын ялый-ялый, яңа корбан турында хыяллана. «Ята җирдә ике ак канат»:

Кемне чакыра аккош төн ката!
Освенцимда үтерелгән кыздан
Салдырылган ак күлмәк сыман
Җирдә ике ак канат ята...
Кемне чакыра аккош төн ката!

Бирелә интонация кинәт үзгәреп китә, шигырь юллары хәвефле яңгыраш ала. Шушында эмоциональ төенләнеш барлыкка килә. Шигырьнең агышында кискен борылыш туа.

**«Балакаен җуйган кош сыман**
**Моңаясың,— диләр,— кем өчен!»**
**Йөрәгенең зәңгәр көзгесен —**
**Күзләрен мин аның юксынам,**
**Балакаен җуйган кош сыман...**

Эмоциональ төенләнеш строфасы шигырьне икегә аерып тора: аңар хәтле булган беренче өлеш, аңардан соң килгән икенче өлеш. Гадәттә, беренче өлеш белән икенче өлеш бер-берсенә карата я контраст («Кызыл ромашка») яки янәшәлек («Кырда ике...») тәшкил итәләр. Аларның интонациясе дә ике дәрәҗәле. Эмоциональ төенләнеш строфасының үзендә, аның да үзәгендә бөтен шигырьнең тау башы булып торган образ бирелгән. Ул, кара төндәге яшен кебек, хыялыңда кинәт гөлт итеп, һич көтелмәгән картинаны балкытып ала, рухи дөньяңда бүтән беркайчан да туа алмас оригиналь ассоциация барлыкка китерә, сине гаять тирәннән дулкынландырып ташлый. «Фазыл чишмәсе»ндә бу образ — «Суларым түгел, ялкыным түгелде йөрәгемнән», «Кырда ике ак канат ята»да — «Освенцимда үтерелгән кыздан салдырылган ак күлмәк сыман җирдә ике ак канат ята» юлларында.

Хикәя яки романда төенләнеш — каршы көчләрнең беренче очрашып, беренче бәрелешкән һәм, бәйләнешеп, бер-берсе белән көрәшкә керешкән ноктасы. Аларның бәйләнеше топ-томалга гына түгел, алар нинди дә булса бер зур мәсьәләгә бөтенләй капма-каршы ике төрле мөнәсәбәттә, ике төрле караштa булганлыклары белән якалашып китәләр. Әсәрдә тасвир ителгән көрәш вакыйгалары барышында, әгәр әсәр прогрессив позициядән язылган булса, ике якның кайсы хаклы, кайсы хаксыз икәнә ачыла. Ниһаять, көрәш иң югары, хәлиткеч ноктага күтәрелә һәм ике якның берсе файдасына хәл ителә (кульминация һәм чишелеш). Игътибар итегез: төенләнеш иҗат ителә торган әсәрнең **проблематика төенен** китереп чыгарса, чишелеш аның тасвир ителгән тарихи-иҗтимагый шартларда **ничек чишелү ихтималын** ачып сала. Лирик зат авызыннан сөйләтелгән кечкенә күләмле шигырьдә, әлбәттә, төенләнеш үзенә бу хәтле катлаулы, киң вазифа ала алмый. Ул лирик затның кичерешләр агымы белән эш итә, башта билгеле бер юнәлеш алып, тыныч кына кузгалып китә дә, үзенә бәйләнешсез нәрсәләрнең барысын да исеңнән чыгартып, аларны онытгырып рухи дөньяңда бер үзе хаким булып ала, күңелеңне нечкәртә. Шул җиргә җиткәч, аңа кинәт икенче кичереш агымы килеп кагыла, ике агым гүяки кинәт бәрелештә һәм, бер-берсе белән бәйләнеп, төенләнеп, үтә киеренке төс ала. Лирик кичерешнең кинәт яңа, ләкин төп темасы ачылып китә. Кичереш тирәнгә керә. Лирик сөйләмнең интонациясе үзгәрә... Киеренке кичереш озак дәвам итми. Ул диңгезнең, кинәт ярсып, югарыга ыргылган, кинәт, башкалардан аерылып, үрә баскан һәм аннан тагын диңгез чоңгылына кайтып төшкән ялгыз дулкынын хәтерләтә. Әсәрнең соңгы юлларында без лирик затның рухи ныгып калганын, тирән, ләкин бу юлы ярсусыз, сабыр уйларга чумганын («Кырда ике...») яки кичерештән билгеле бер тәвәккәллек алып чыкканын («Фазыл чишмәсе») күрәбез.

Эмоциональ төенләнешле шигырь бездә әле танылып, бәяләнеп җитмәгән. Югыйсә, аның туганына байтак вакыт үткән инде. Шуның аркасында, кызганычка каршы, ул үрли алмаган, яшь талантлар аны элеп, ишәйтеп алып китмәгәннәр. Без «Казан утлары»ның соңгы 3—4 елда чыккан саннарын актарып карадык. Эмоциональ төенләнешле шигырь таләпләренә тулы җавап биргән әсәрләр, ничектер, очрамады. Дөрес, бер шагыйрь моңа шактый якын килә. Без М. Әгъләмовның «Еракка китеп кара» исемле шигырен күздә тотабыз. («Казан утлары», 1968 ел, 11 сан, 84 бит.)

**Еракта н— кәшмир яулыклы**
**Бер карчык карап тора,—**

дигән юллардан соң бирелә эмоциональ төенләнеш көтелә. Әмма шагыйрь, ни өчендер, киресенчә, хис ташкынын сүрелдерә торган строфа китереп кертә:

Бу яктагы көнкөремнең
Соңгысы җитеп бара...

«Үз халкыңның киләчәген...» дигән строфага шагыйрь үз укучысын тирәнрәк эмоциональ дулкынлану белән алып керсә, әлбәттә, яхшырак булыр иде кебек.

Эмоциональ төенләнешле шигырь безнең поэзиябезнең тарихи үсешендә яңа баскыч билгесе булса кирәк. Татар поэзиясе XX йөз башында, 1905 елгы революция нәтиҗәсендә, дидактизм белән арасын бик кыю өзеп, күтәрелеп китте. Бездә шәхеснең рухи дөнья хәрәкәтен, аның диалектикасын, хис, тойгы ташкынының үз сурәтен ачып сала торган поэзия үсә башлады. Совет чорында бу яңалык тагын да алгарак китте. Монда Һади Такташ поэзиясе зур роль уйнады. Эмоциональ төенләнешле шигырь — шушы юнәлештә табылган яңа казаныш. Аңарда һичнинди үгет-нәсихәтчелек, дидактизм сизелми, ул баштанаяк шәхеснең җан хәрәкәтен, җанның тилпенешләрен, аның ашкынуларын сурәткә күчереп ачып салудан тора, укучы аңында, эмоцияләрендә көтелмәгән ассоциацияләр барлыкка китереп, аның кичереш һәм хыялларына мәгънәле эчтәлек бирә, күңелендә дулкын кузгатып, басылып яткан кыйммәтле рухи сыйфатларын хәрәкәткә китерә, уйландыра... Бу шигырь бөтендөнья поэзиясенең иң гүзәл үрнәкләре белән тиңләшә ала. Шулай да ни өчен үрчеп китә алмый соң ул? Аны үрчетеп җибәрер өчен зур шигъри талант көче һәм шагыйрьнең чорыбыз сәнгате процессларына мөнәсәбәттә гаять зирәк булуы кирәк. Алай гына да түгелдер. Монда тагын тәмам өлгергән, тәмам җитлеккән сәнгать осталыгы, чын мәгънәсендә бик югары культура, үзенең асылы белән үк нәфасәт хәзинәсен тәшкил иткән иҗат культурасы кирәк. Болар бездә юкмыни?! Эмоциональ төенләнешле шигырь үсәргә тиеш. Ул үсәр әле дигән өмет бар бездә.

**Гомәр Бәширов**

# УЙЛАНУЛАР

Мин «Совет әдәбияты» журналының моннан утыз биш еллар элек чыккан саргылт битләрен актарып утырам. Бераз моңсу, бераз сагындыра, юксындыра. Яшь вакытлар бит...

Миңа менә шушы журнал хакында мәкалә язарга кирәк. Язмасаң, яхшы түгел. Мин бит журналда җаваплы секретарь булып та, вакытлы редактор һәм җаваплы редактор булып та, сугышка кадәр дә, аннан соң да берничә мәртәбә эшләгән кеше. Аннан да бигрәк, мине матур әдәбиятка алып кергән иң беренче сукмак шушы журналда башлана. Хикәяләрем һәм «Сиваш» повесте иң беренче шушы журналда басылды. Ләкин нинди мәкалә язарга? Кайсы еллар турында?

Менә шулар хакында картларча озын, озак итеп уйланып йөргәндә, элек бер бүлмәдә, бер союзда, бер партия оешмасында эшләгән өлкән иптәшләр, бере артыннан бере, күз алдыма килә башлады. Кыюсыз гына тамак кыргалап, үзеннән кечеләр янына да, хәтта бүлмә эче шау-гөр килеп торганда да ишек шакымыйча керми торган әдәпле Шәриф абзый Камал. Калын кара портфелен култык астына кыстырган хәлдә, матбугат йортының ыгы-зыгылы озын коридорларыннан бераз бөкерәя төшеп, беркемне дә күрмичә, ашыгыч адымнар белән атлый-йөгерә узып китүче, кырсрак кыяфәтле журнал редакторы Гомәр Гали. Озынча буйлы, саңгыраурак тавышлы, басынкырак холыклы профессор Галимҗан Нигъмәти...

Ләкин бу күренешләр мәкаләгә сыймыйлар бит... Шунда мин икеләнә башладым. Бәлки, миңа мәкалә язмаскадыр? Ул елларда нинди әсәрләр басылган, әдәбиятта нинди карашлар, нинди көрәшләр булган? Кайсы агым җиңеп чыккан да, кайсысы җиңелеп калган? Ул хакта галимнәр язар, бусы — аларның «икмәге». Ә мин әдәбияттагы ул агымнарга бер вакытта да артык игътибар итмичә, гомер буена талантлы әсәрләрнең үзләренә, совет чынбарлыгын олы итеп сурәтли белгән язучыларына сокланып яшәгән кеше. Әдәбиятта узган кырык ел гомер мине бер нәрсәгә өйрәтте: әдәбиятта төрле юнәлешләрнең һәммәсен дә бел, әмма үзеңчә яз. Галимҗанны да, Хемингуэйне дә өйрән, ләкин барыбер үзеңчә яз! Беркайчан да кочәнмә, күңелең ни тели, шуны яз! Фәкать шул вакытта гына яхшы әсәр чыгарга мөмкин.

Нәрсә бу? Очеркмы? Истәлекме? Нәрсә язылса, шул булыр.

1936 елның көзендә бер көнне иртән, шактый ук дулкынланып, матбугат йортының бишенче катына менеп киттем. Гаҗәп кызык уеннар уйный бу язмыш. Моннан дүрт-биш ел элек халык тикшерүчесе һәм халык хакиме булып эшләгәндә кем башыча китерә алган бу хәлне? Бала чактан ук матур әдәбиятка, аны иҗат итүче әдипләргә гашыйк булып яшәгән бер кеше менә хәзер «Совет әдәбияты»ның җаваплы секретаре булып менеп бара. Бу бит әдәбиятның нәкъ үзәгенә, кайнап торган казанына барып керү дигән сүз.

Минем каршымда журнал редакциясенең дәрәҗәсе һәртөрле парламентлардан да, мәһабәт сарайлардан да югарырак иде. Дулкынланудан мин шундый ихтирамга лаек оешмага ни сәбәпледер шушы биш катлы мәһабәт йортның йөз сиксән биш бүлмәсе арасыннан, юньлерәк урынынан кинрәк бүлмә табылмавына да, аның бишенче каттагы иң кечкенә бүлмәгә сыеп калуына да артык игътибар итмәдем. Кайбер язучыларның безнең бүлмәне «карлыгач оясы» дип атаулары да шаярту булып кына ишетелде. Редакциядә эшли башлаган көннәрдә минем күңелемне һәрвакыт бер сорау бимазалап торды: нинди гали затлар дип, бүтәннәр буе җитмәслек нииндер бөек идеаллар белән рухланып яшәүчеләр итеп күз алдыңа китергән әдип һәм шагыйрьләр тормышның үзендә дә шулаймы? Гадәтемчә, мин аларны артык күпертеп, идеаллаштырып җибәрмәдемме икән? Минем матур хыялларым тетен булып очмас микән?

Дөрес, мондагы шартлар күңелдәге хыялны шактый ук шиңдерде. Редакциянең бүлмәсе фәкать берәү генә. Дүртебез дә — Гомәр, Гали, Хәсән Туфан, Абдулла Гомәр һәм мин — бергә җыелганда эшләве бик кыен, бөтен игътибарны кульязмага туплап булмый, килгән кешеләр белән иркенләп сөйләшергә дә мөмкинлек юк иде.

Дөрес, тиздән үк шул бүлмә эченә, редакторның махсус үзе өчен генә, пыяла белән фанердан тагын бер бүлмә әмәлләдек. Тик аңа кен яктысы керми, йомыш белән килгән кеше генә кереп чыгарлык бик тар иде. Эшләнеп бетү белән үк ул бүлмәгә «Гомәр Гали кетәге» дип шаян исем дә тактылар.

Кыскасы, мондагы шартлар хыялдагы күтәренкелеккә бик үк муафикъ түгел иде. Тик мин, күрәсең, әдәбиятның язмышы шулайдыр инде дигән фикергә килдем. Бөтен дөньяга мәгърифәт нуры тараткан борынгы китапларның күбесе салкын мәгарәдә язылган. Габдулла Тукайның бөтен чорны яктырткан шигъри энҗеләре бер тәрәзәле кечкенә бүлмәдә барлыкка килгән.

Әмма мине иң мавыктырганы — бу кечкенә бүлмәдәге кешеләрнең зур ваем белән яшәүләре булды. Алар һәр уңышлы әсәргә генә түгел, истә калырдай һәр яңа образга куанып, әдәбиятның якты киләчәге белән рухланып яшиләр, үзләрен тормышның вак-төягеннән өстә тоталар иде. Шушы ук рух күтәренкелеге озакламыйча миңа да йокты, мин дә һәртөрле уңайсызлык белән эшнең кыенлыгына игътибар итмәс булдым.

Кешеләре белән дә, аларның алга куйган якты максатлары белән дә күңелләргә тирән булып уелып калган гаҗәп дәрәҗәдә катлаулы да, четерекле дә бер чор иде ул. Европа өстенә фашизмның дәһшәтле карачкысы булып дар агачлары күтәрелгән, моңарчы мәдәниятнең алдынгы сафы дип саналган илләрдән яндырылган китапларның көек исе килә башлаган чак. М. Горькийның «Кем белән сез, культура остазлары?» дип бөтен дөньяга ташлаган нидасы меңнәрчә зыялыны тирән уйга салган заман иде. Болар һәммәсе дә күңелләргә шом сала, уйландыра, борчый, сугыш куркынычының якын тирәдә генә йөрүе дә сизелми түгел иде инде.

Шулай да без әле ул вакытта шул көтелгән сугышның прелюдиясе һәм үзе ил өстенә шундый афәт булып ябырылачагын, миллионнарча корбан сораячагын һич тә ул кадәр итеп күз алдына да китерә алмый идек.

Язучылар союзы оешканга әле күп тә үтмәгән. 1934 елда булып узган беренче съездда матур әдәбиятның киләчәгенә якты ишекләр ачылганнан соң язучыларның һәрберсе үзен тулы хокуклы иҗат кешесе итеп хис кыла иде. Кыскасы, тормышның, көнкүрешнең төрле кыенлыклары чыгып торса да, без якты идеаллар белән яши идек.

Шулай да Шәриф абзыйның 1936 елдагы бер тәнбиһен соңыннан гыйбрәтле бер хәл итеп күп мәртәбәләр хәтергә алгаладым. Шулай, һәрвакыттагыча, әдәпле генә килеп керде дә, сәламәтлек сорашып, озак кына күзлеген сөртеп, тамагын кыргалап алганнан соң «Гомәр Гали иптәш»нең кайдалыгын сорашты. Ул булмагач, миңа мөрәҗәгать итте. Журналда кайбер зат алмашлыклары зур хәрефтән киткән икән дә Шәриф абыйга шул ошамаган икән.

— Сез беләсездер, Гомәр иптәш, секретарь булгач, тел гыйльмендә андый кагыйдә юк бит.

— Әйе, беләм, Шәриф абзый...

— Шулайдыр, элек, мәсәлән, динчеләр алланы гына шулай зур хәрефтән язалар иде. Ходай тәгаләне генә... Анда да һәммә диндә дә түгел. Бу миңа бик гаҗәп тоелды. Нигә хәзер дә шул искелекне кулланасыз икән?

Ул журналның типографиядә миңа кадәр үк җыелуын әйтергә, акланырга мөмкин иде. Ләкин мин акланырга уңайсызландым. Аның мәгънәсе дә юк иде. Чөнки ул елларда аерым кешеләрне күкләргә чөю, аларга мәдхия уку гадәте зат алмашлыкларын дөрес язу белән генә тукталачак түгел иде. Әмма Шәриф абзыйның әдәбиятта булсын, тормышта булсын, гомумән, мактау, мактануны җене сөйми, шунлыктан аның киңәшен игътибарсыз калдыру да мөмкин түгел иде. Мин аңа киләчәктә мондый хатаны бирмичек тә җибәрмәскә вәгъдә иттем. Әмма үзем бу сүзләремнең гамәлгә ашачагына бик үк ышанмый идем.

Шәриф абзый, журналда үз әсәрләрен бастырудан тыш, Казандагы иң олкән һәм иң зур стажлы коммунист язучылардан, мөхтәрәм әдипләрдән берсе буларак (ул вакытта Галимҗан Ибраһимов Ялтада яши иде), редакция эшенә киңәшләре, рецензияләре белән дә якыннан катнашып килде. Редакция утырышына ул үзенең кайсыдыр юбилеенда бүләк ителгән әйбәт ак фетрын киеп, галстуклар тагып, гомумән, чакырылган мәҗлескә баргандагыдай, пөхтә киенеп, нәкъ вакытында килеп җитә дә бик әдәп белән тыңлап кына утыра иде. Әмма әгәр дә әдәби кыйммәте шикле булган берәр әсәрне журналга кертергә тәкъдим итүче булса, ул шунда ук кискен телле тәнкыйтьчегә әверелеп китә. Шәриф абзый кемнең дә булса хәтерен саклау дигән әйләнеш юлларны белми, ул гаделлек һәм чын хакыйкать кешесе иде.

Ул елларда журналны һәм, гомумән, татар совет әдәбиятын әйдәп баручылар журналның җаваплы редакторы Гомәр Гали, редколлегия членнары Галимҗан Нигъмәти, Гумир Толымбай (кайберәүләр язганча, Гомәр түгел), Кәрим Тинчурин, Кави Нәҗми, Шәриф Камал булдылар.

Кәрим абзый Тинчурин барлык көчен, дәртен һәм зур иҗат талантын Татар академия театрына, үз әсәрләрен язуга сарыф иткәнлектән, пьесаларны укудан башкага вакыт таба алмый иде. Әмма бүтән жанрдагы әсәрләрнең язмышын хәл кылган вакытларда да Кәрим абзый беркайчан битараф калмады. Әсәрнең журналда басылырга тиешлегенә тәмам ышанып җиткәннән соң гына ул үзенең «мәслихәтен» әйтеп куяр иде.

Редактордан кала, минем аеруча игътибарымны җәлеп итүчеләрдән тагын берсе — профессор Галимҗан Нигъмәти булды. Бу хөрмәтле кешене мин редакциягә килгәнче үк беркадәр белә идем инде. Чөнки «Сиваш» повестен язган вакытта без аның белән Васильево ял йортында бергә булдык. Повестьның аерым бүлекләрен, бик дулкынланып, дөресен генә әйткәндә, шактый ук шүрләп һәм каушап, язучылардан иң беренче мин аңа укыдым. Үз көчеңә ышанып җитмәс борын әсәреңне әдәбият профессоры хөкеменә китереп салу һич тә уен эш түгел ул. Дөрес, профессор, үзенең холкына хас рәвештә, минем әсәремне күккә чөеп мактамады. Әмма мин аның күз карашыннан, кайбер урыннарны укыганда, нәрсәнедер язып алырга омтылгандай, өстәлгә үрелеп куюыннан, бигрәк тә мәзәк кенә итеп иңнәрен җыергалап алуыннан әсәрне ошатуын сиздем. Ул вакытта монысы да бик зур шатлык иде.

Ә инде кич белән наратлар арасындагы тар сукмакта сөйләшеп йөргәндә профессор миңа дөньяда иң яхшы күңелле, иң галим, иң изге кеше булып күренә башлады. Чөнки ул минем әсәремне гражданнар сугышы турында язылган башка кайбер китаплар белән чагыштырып, берничә җылы сүз әйтте. Яшь язучыны шуннан да зуррак тагын нинди бүләк күтәргә мөмкин?

Аңа кадәр Галимҗан Нигъмәти безгә, бер төркем язучыларга, марксизм-ленинизм институтында укыган елларда, кичләрен әдәбияттан лекцияләр укып китүе белән дә бик истә калган иде. Шулай ук аның әдәбият мәсьәләләрен яктырткан мәкалә һәм китапларын заманында кем генә укымый калды икән? Редакциядә эшли башлагач, минем Г. Нигъмәтигә ихтирамым тагын да артты.

Журнал эшенә әсәрләре һәм киңәшләре белән иң актив катнашучылардан тагын берсе Толымбай булды. Зур, таза бәдәнле, төрпә телле бу кеше, күбесенчә ирония белән сөйләшеп, һәрвакыт нәрсәдәндер, кемнәндер көләр иде. Ифрат эшлекле, хәрәкәтчән кеше Толымбай, Бер үк вакытта ул авыл тормышыннан хикәяләр дә, әдәбият

тарихыннан мәкаләләр дә, гыйльми хезмәтләр, рецензияләр дә яза, җыелышларда җаваплы докладлар белән чыгарга да, халык иҗатын җыярга да һәм аны матбугатта чыгарырга да өлгерә, гомумән, ул тик торуны белми, аның көче һәм иҗат дәрте ташып тора иде. Толымбай мине яшьләй үк катлаулы тормыш юлы узуы, бигрәк тә кыю холыклы булуы белән кызыксындырган иде. Ул уналты яшендә Петербургда извозчик булып эшләгән, унтугыз яшендә партия сафына алынган, гражданнар сугышына ирекле булып киткән кеше. Толымбай, үзлегеннән укып, заманы өчен зур белем алган, Язучылар союзы идарәсендә, гажурда, китап нәшриятында җаваплы эшләр башкарган, ТКУда, пединститутта укыткан галим һәм язучы. Ниһаять, Мәскәүдә кызыл профессура институтын тәмамлап профессор исемен алып кайтканнан соң марксизм-ленинизм институтында һәм педагогия институтында яңа көч, яңа дәрт белән тагын әдәбият укытырга керешкән иде.

Г. Толымбайның әдәби язмышы миндә бер үк вакытта кызгану һәм гаҗәпләнү хисе уята. Таланты һәм гаҗәеп эшчәнлеге белән заманында беренче биш язучы исәбендә йөргән, барлы-юклы унбер-унике еллык иҗат гомере эчендә утыз биштән артык китап чыгарган бу галим һәм әдип әдәбиятта нигә сизелерлек эз калдырмады? Ничек ул шул кадәр тиз онытылып өлгерде? Аның әсәрләре вакыт сынавын үтә алмаслык сыек, зәгыйфь булдылармы? Әллә алар ясалма иделәрме? Бәлки, шулайдыр? Ихтимал, Толымбайның сулагай якка кизәнүен, Фатих Әмирханны тартып-сузып һәм көчәнеп буржуаз язучысы ясавын, чамадан тыш кызарып китеп, телне сыйныфларга бүлеп ташлавын тарих гафу итә алмагандыр? Ихтимал, шулайдыр. Бу бик гыйбрәтле хәл. Һәм, минемчә, җентекләп өйрәнелергә тиешле мәсьәлә. Әдәбиятның һәм сәнгатьнең халык һәм ил тормышы белән табигый рәвештә үрелеп үсеше юлына, халыкның табигый мәнфәгатьләренә каршы нинди киртәләр өелмәсен, нинди генә ясалма буалар корылмасын, иртәме-соңмы иҗтимагый яшәеш хакыйкате аларны барыбер җимерә, барыбер үзенең табигый агымы белән китә. Бу бик тә гыйбрәтле сабак.

Мин журналда эшләгән вакытта исә Г. Толымбай редколлегиянең иң актив членнарыннан берсе иде.

Бу танылган әдип һәм галимнәрнең редколлегия утырышында теге яки бу әсәргә мөнәсәбәтләрен мин бер үк вакытта минем әдәби зәвыгыма имтихан итеп тә аңлый идем. Чөнки кульязмаларның күбесен редколлегия утырышына, журналның җаваплы секретаре буларак, мин хәзерли идем.

Шундый бер хәл бик нык истә калган. Яңарак вакытта мин журналның кайсыдыр санына кемнеңдер чаңгы шуу хакында яңа шигырен тәкъдим иттем, шигырьнең башлачагына җитди шигем булмаганлыктан, аның бик оригиналь булуын, җиңел укыла торган матур шигырь икәнлеген дә әйтеп салдым. Хәзер ул шигырьнең кемнеке икәнлеген дә, исемен дә хәтерләмим. Әмма ул утырыштан алган сабак әле дә булса бик нык күңелдә калган.

Шигырьне яңадан укып чыкканнан соң, башта «һем» дигәләп, бер-берсенең кылына тарткалап байтак вакыт сүзсез генә утырдылар да, ниһаять, тора-бара, бөтенләй ачылып киттеләр. Сөйләшә торгач, мин тәкъдим иткән шигырьнең, бичараның, итен иткә, сөяген сөяккә аерып ташладылар да, аны бөтенләй оныттылар. Ул да түгел, хәзерге шигырьдә заман сулышының ничек чагылуы, аның интонациясе, андагы эчке байлык, гармония, фәлсәфи тирәнлекләргә кереп киттеләр, тагын әллә нәрсәләр кузгаттылар. Редактор өстәле артында әле Гомәр Галинең җанланган йөзе, елтырагач зәңгәр күзләре күренеп китә, әле Г. Нигъмәтинең саңгырау тавышы ишетелә. Ул да түгел, «ничек әйтергә мөмкин?» дип, Гомәр Хәям дип, Хәсән Туфан сөйли башлый. Аны тыңлап та бетермәстән, каударланып торып китә дә Г. Толымбай үз фикерен куәтли. Мин тәкъдим иткән шигырьне әдәпле генә, рәнҗетмичә шаяртып кына кире кагуларына да кимсенмим. Мине хәзер зуррак мәсьәлә дулкынландыра башлаган иде. Менә нәрсә икән бит ул чын шигырь? Мин шунда шигъриятнең берникадәр аристократия сыйфатлары барлыгын да, аның тел белән әйтеп булмастай гаҗәеп хасиятьләре, тылсымлы көче, моңарчы күңелнең әллә кайсы яшерен бер урыны белән сиземләп кенә йөргән күкләргә күтәрү, яисә күз яше китерү дәрәҗәсендә дулкынландыру сәләтен, аларның сәбәбен дә беренче мәртәбә тирәнрәк итеп, бәлки, шунда төшенгәнмен.

Икенче бер кичне Мирсәй Әмирнең шул елны гына чыккан «Агыйдел» повесте хакында да истә калырдай кызыклы һәм ялкынлы әңгәмә булып алды. Ни сәбәпле бу әсәрне яшьләр кулдан төшермичә укыйлар? Нәрсәдә аның көче? Ул повесть әдәбиятка нинди яңалыклар өстәде?

Бик тә кызык һәм файдалы иде мондый әңгәмәләрне тыңлавы. Андый утырышлар эштән соң кичен генә уздырылып (чөнки редколлегия членнары кайда булса да эшлиләр иде), бик соң тәмамланганлыктан, ахырга таба һәммәбез дә ачыккан һәм арыган була идек. Шулай да төнлә белән япа-ялгыз үземнең Акком асты урамындагы кечкенә булмәмә кайтып барганда мин үземне дөньяның иң бәхетле кешесе итеп, җиде кат күктә итеп хис кылам. Чөнки мине нинди дер гаҗәеп тирән һәм нәзакәтле нечкә хисләр дулкынландыра, моннан соң минем тагын да тирәнрәк мәгънәле, тагын да нәфисрәк, яхшырак итеп язарга көчем җитәчәгенә ышанычым арткан-нан-арта бара, болар мине канатландыра иде. Әйтәчәкмен мин аларны, әйтәчәкмен, һичшиксез!

Менә хәзер утыз биш ел вакыт узып, тормыш безне дәһшәтле сугышлары белән дә, башка фаҗигаләре белән дә төрлечә сынап караганнан соң, үземә дә җитмеш тулып киткәч, күңелем белән яңадан шул вакыйгаларга әйләнеп кайтам. Күптән үк безнең икенче туган өебезгә әверелгән шул матбугат йортының шау-шулы коридорларында да, эшлекле кабинетларында да туктамастан, мондагы йөз сиксән биш булмәнең иң гадиенә, әлеге «карлыгач оясы»на күтәреләм. Өстәл лампасының сүрән яктысы тирәсендә кич буе дөньяларын онытып бәхәсләшеп утыручы ул фидакарь кешеләр, аларның кайнар бәхәсләре яңадан исемә төшә. Шунда башыма ап-ачык булып бер нәрсә килә. Алар, минемчә, бер-берсе белән шундый кайнар бәхәс ачып, хакыйкать эзләгәннәр, беренче съездан соң колачын тагын да киңрәк җәя башлаган яшь совет әдәбиятының яңа казанышларын һәм төп кимчелекләрен тирәнрәк белеп, барысын да күреп торырга, шул хакта фикерләрен чарларга, иң дөрес юл сайларга тырышканнар. Чөнки ВКП(б) Үзәк Комитетының матур әдәбият хакындагы мәгълүм карарларын гамәлгә ашырганда, бер яктан, искелекнең кирәкмәс калдыкларыннан арына барырга кирәк булса, икенче яктан, яңаның ничек үсәргә тиешлеген алдан ук күрә белергә кирәк иде бит. Шоп-шома такыр юлны берәү дә хәзерләп куймаган иде.

Журнал редакторы Г. Гали белән профессор Г. Нигъмәти әдәби хәрәкәтнең башында торучы күренекле галимнәр буларак, партия карарларын тормышка ашыруда зур тырышлык һәм принципиальлек күрсәттеләр, әдәбиятның үсешенә тоткарлык итә торган натурализм, формализм кебек зарарлы агымнарга каршы аяусыз көрәшеп килделәр. Аларның авторитеты ифрат зур иде. Әгәр язучылар җыелышында чыгышлары көтелсә, зал һәрвакыт тулы була, аларның чыгышлары әдәбиятта җитди бер вакыйгага әверелә, чөнки алар әдәбиятның һәрвакыт җитди мәсьәләләрен күтәреп чыгаралар, яңа фикер әйтәләр иде.

Г. Галинең безнең әдәбиятыбызга нинди таләпләр куюын бераз гына булса да күз алдына китерү өчен, аның 1936 елда булган бер җыелышта формализмга каршы юнәлтелгән чыгышыннан бер өзек китерүне кирәк санадым:

«Безнең социалистик матур әдәбиятыбыз иң югары идеяле, үзенең формасы белән иң бай, иң матур әдәбият булырга тиеш. Шуның белән бергә, аның бу байлыгының, бу матурлыгының нигезендә халыкчыллык булырга, бу байлык һәм матурлык хезмәт халкы йөрәге белән тоташкан булырга тиеш»[1].

Минемчә, ифрат дөрес, җыйнак һәм матур әйтелгән. Ул вакыт өчен бу кечкенә эш түгел. Минемчә, бу фикер астына әле хәзер дә теләсә кайсы фәннәр докторы бик теләп имзасын куяр иде.

1937—38 елларга кадәр җыелышларда кәгазьгә карап сөйләү гадәте юк иде. Шунлыктан бу галимнәрнең күп чыгышлары бер җирдә дә теркәлмәгән. Шулай да Гомәр Галинең редколлегия утырышында яисә җыелышларда әйткән кайбер фикерләре, тирән мәгънәле афоризмнар кебек, әле хәзер дә онытылмый.

Журналда актив эшләү, гомумән, матур әдәбиятта әйдәп баручылар булу белән бергә, Г. Нигъмәти Казан дәүләт педагогия институтының профессоры, Г. Гали медицина институтында татар филологиясе доценты, ягъни педагоглар буларак та зур

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1936 ел. 4 сан.

эшчәнлек күрсәттеләр. Алар әдәбиятка бөтен көчләрен, сәләтләрен бирделәр, үз өсләренә йөкләтелгән вазифаның катлаулы һәм хөрмәтлелеген тирән аңлап, халык һәм партия каршында үзләрен җаваплы санап эш иттеләр. Г. Нигъмәти җитәкчелек иткән елларда педагогия институтында М. Мамин, Я. Агишев, Х. Ярми, Җ. Вәзиева кебек әдәбият галимнәре хәзерләнеп чыкты. Г. Нигъмәтинең шәкертләре хәзер фән докторлары булдылар. Күренекле шагыйрь Сибгат Хәким һәм башка кайбер әдәбият әһелләре — шушы профессордан дәрес алган кешеләр. Ул елларда педагогия институтында яшь язучылар, яшь галимнәрне үзләренә җәлеп иткән әдәбият түгәрәкләре, семинарлар һәрвакыт эшли, институт болар белән гөрләп торэ торган иде.

Журнал редакциясендә эшләгәндә элек әсәрләре белән таныш булган әдипләрнең үзләре белән очрашу миндә ифрат бер тирән кызыксыну уята торган иде. Чөнки автор турында әсәрен укыганнан соң туган фикерең белән аның үзен күргәч калдырган тәэсир кайвакыт бөтенләй туры килми торган була. Мәхмүт Галәүнең шул елларда чыккан мәшһүр әсәрләрен укыгач, мин аны зур талант иясе дип таныдым. Журналның 1936 елгы бишенче санында Габдулла Тукайга илле яшь тулу уңае белән язган кыска гына истәлеге бу фикеремне тагын да куәтләбрәк җибәрде. Г. Тукай турында язылган истәлекләрнең күбесендә аның йомыграк холыклы, шәкерт сыман кыюсызрак кеше булуына басым ясыйлар да аның әсәрләреннән алган тәэсират белән шәхесе арасында зур аерма килеп чыга торган иде. М. Галәү шушы өч битлек истәлегендә Тукайның истә калырдай җанлы образын бирә алган, аның гадилегендә бөеклеген күрергә мөмкинлек тудырган иде.

Мәхмүт Галәү Мәскәүдә яшәсә дә, Казанда еш булгалый, килгән саен безнең редакциягә кермичә китми торган иде. Бу килүендә журналга нинди кульъязма тәкъдим итүе хәзер исемдә калмаган. Ләкин килеп керүе белән үк ул миндә бик яхшы тәэсир тудырды. Ул да Казан артыннан, Ташкичү авылыннан булганлыктан, мин аның белән аеруча кызыксындым.

М. Галәү мәһабәт гәүдәле, кап-кара куе чәчле, каратут йөзле, бик пөхтә киенгән, ачык чырайлы, яхшы мөгамәләле кеше иде. Редактор үзенең бүлмәсендә юк иде шикелле. Сөйләшә торгач, кунакның минем якка карап елмаюына игътибар иттем. Миңа уңайсыз булып китте.

— Сезгә нәрсәдер мәзәк тоела, ахрысы? — дидем.

— Гаҗәеп бер совпадение, мин дә, нәкъ сезнең кебек, кул астына чиста кәгазь куеп язам. Әйбәт гадәт ул.

— Шулай дисезме? Рәхмәт инде, алайса.

Ул тагын көлеп куйды.

— Ни сәбәпле шулай димәкче булам? Чөнки алай язганда күңелең тыныч була. Пакь кәгазьгә гел саф фикерләр генә төшереп барам дип ышанасың. Шөбһәләнмичә язасың!

Мәскәү интеллигентының шушы гади генә бер нәрсәгә мондый тирән мәгънә бирүе миңа бик ошады, кәефне күтәреп җибәрде. Минем исә андый нечкәлекләр башыма да килгәне юк. Чиста кәгазьгә пөхтә итеп язуны тормыш үзе таләп итә иде. Чөнки редакциянең үз машинисткасы булмаганлыктан, кайбер материалларны без типографиягә кулдан язган килеш кенә төшереп бирә идек. Кульъязмаң пөхтә булмаса, аннан кире менгерәләр. Фәкать шул гына.

Ул арада редактор кайтып керде дә безнең әңгәмә өзелде. Г. Гали янынан чыкканда кунагыбыз караңгы чырайлы иде. Ул вакытта мин аның сәбәбен төпченмәдем, болай гына чамаладым. М. Галәү заманында «Кармак» исемле юмористик журнал чыгарган, нәширлек белән дә шөгыльләнгән, халык арасында мәгърифәт тарату максаты белән, аз-маз китаплар да саткалаган, диләр иде. Г. Гали исә, сыйнфый мәсьәләләргә бик сизгер һәм җитди караучы ифрат туры коммунист булу сәбәпле, язучының кайчандыр чит сыйныф әһелләренә хас эш белән шөгыльләнүен гафу итә алмагандыр, күрәсең.

Журналга язышучылардан Фатих Сәйфи-Казанлыда да кием-салымда пөхтәлек ягыннан М. Галәүгә охшашлык бар иде. Ул да шулай ук теләсә нинди шартларда да пөхтә киенеп йөри, мөстәкыйль фикерле, хәр күңелле кеше буларак, хәтта кызу бәхәс вакытларында да үзенең тәрбияле интеллигент икәнлеген беркайчан да онытмый, үзен ифрат горур тота иде.

Ул елларда хикәяләр, повестьләр бик аз языла иде. Журналның киләчәк саннарына да басарга хикәя булмау сәбәпле, башка язучылардан үтенгән кебек, Ф. Сәйфи-Казанлыга да мөрәҗәгать итәргә тиеш идем. Матбугат йортында берничә мәртәбә очраткаласам да, башта мин аңа үтенечемне әйтергә кыенсыныбрак йөрдем. Моның сәбәбе шул, берәр ел чамасы элек аның «Корби иптәш» дигән повесте тикшерелгәндә, кызулык белән фикеремне тупасрак, кискенрәк итеп әйтеп ташлавымны сизеп калган идем. Җыелышка җитәкчелек итүче Г. Толымбай нинди усал телле, турыдан ярып торган кеше инде. Бу чыгышымны хәтта ул да ошатмады. Эш шунда иде ки, Ф. Сәйфи-Казанлының элегрәк язган хикәяләреннән «Крушниклар» дигәнен аеруча яратып укыганлыктан, аның авторына ихтирамым бик зур иде. Грузчиклар эшенең кыенлыгын, аның нечкәлекләрен шул кадәр тирәнтен белеп, шундый тетрәткеч итеп язарга кирәк бит! Миндә хәтта ул кайчандыр үзе дә грузчик булып эшләмәде микән дигән фикер дә туган иде. Шуның өстенә хикәянең минем якташларым — Арча ягындагы Кәче егетләре тормышыннан алып язылган булуы да мине бик дулкынландырган иде.

Менә шундый талантлы әсәрнең авторы, минемчә, «Корби иптәш» дигән озын хикәясендә үзенә-үзе хыянәт иткән кебек тоелды. Минем карашымча, бу әсәрен язганда ул бөтен иҗат көчен файдаланмаган, күзгә бәрелеп торырдай тупас кимчелекләр җибәргән кебек иде.

Әмма соңыннан шушы кискенлегем өчен мин үземне байтак вакытлар шелтәләп йөрдем. Бу чыгышым күңелемдә җиңел холыклы кешеләргә хас бер дорфалык булып уелып калды. Чыннан да үкенерлек бар иде шул. Ф. Сәйфи-Казанлы революциягә кадәр үк теоретик мәсьәләләр язып чыгучы, югары уку йортларында дәрес бирүче күренекле тарихчы, әдәбиятчы, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе булып танылган илле яшьләрдәге мөхтәрәм бер кеше иде. Ә мин кем? Әле моңарчы әдәбиятка бер җитди әсәр дә бирмәгән, әдәбият дөньясында үзен бер яктан да чынлап торып танытмаган кечерәк кенә бер язучы кисәге...

Күтә торгач, Фатих абзый бер көнне кичкә таба редакциягә үзе килеп керде. Калын тавышы белән бөтен бүлмәне тутырып:

— Уф, редакцияне тагын да берничә кат өскәрәк күтәрә алмадыгызмы соң? — диде.

— Әле һаман да тиешле югарылыкка менеп җитмәгәнмени? — дидем.

Әйбәт пальтосын ишек янындагы урындыкка салып элде дә ап-ак күлмәк якасын һәм шәп галстугын бүлмә пыяласына карап төзәтеп алды.

— Яңа сәркатипмени? Бик хуп,— диде, исәнләште дә Г. Галинең күрше бүлмәдән керүен көтеп, түргә барып утырды. Журналның җәйге саннарында аның «Зәбәрҗәт» исемле яңа драмасы басылган иде, шуңа бәйләнешле хатлар юкмы дип сорады.

Ул үзе сүз башлагач, мине борчыган әлеге мәсьәләгә киная ясаргамы, юкмы дип баш ватарга туры килмәде. Чөнки бу мөгътәбәр язучының кайчандыр, кемдер тарафыннан эшләнгән очраклы бер дорфалык өчен кинә тотучы вак кеше түгеллеген шунда ук аңладым. Чыраеның әледән-әле караңгыланып китүенә, тынгысызлануына карагандa, аны нидер борчый, ул редактор янына да нинди дә булса җитди бер мәсьәлә хакында сөйләшергә яки бәхәсләшергә килгән иде булса кирәк. Ф. Сәйфи-Казанлы бәхәсләшмичә генә үз фикереннән кайта торган кеше түгел иде.

Минем үтенечемне ул хуплап каршы алды.

— Бар минем, бар журналга бирәсе әсәрләрем. Ләкин тәмамларга вакыт җитми. Вакыт кисә муенны,— диде.

Тик шул вакыт бүлмәгә берничә талант әсәре булмаса да төрле астыртын һәм әшәкелек сукмаклары белән әдәбиятка борынын тыгарга йөрүче бер җәнҗалчы килеп керде. Аның Фатих абзый әсәрләрендә дә казынганы бар, соңгы айларда җыелышларда да тел тидергәли башлаган иде. Фатих абзый кинәт торып басты да ишеккә таба китте. Теге кешегә карамыйча гына, шактый ук кырыс тонда:

— Гомәр кайтса әйтегез, мин союзда булырмын! — диде, пальтосын иңенә салып чыгып та китте.

Әмма вәгъдә иткән әсәрен тәмамлап бирә алмый калды. Редакциягә бүтән килгәне булмады.

Аннан соң күп вакытлар үтте инде — утыз биш ел! Яшь чакларым яңадан күз

алдыма килүгә дулкынланып, мин саргайган журнал битләрен актарам. Заманында татар совет әдәбиятын тәпкә җигелеп сөйрәгән, шәхси мәнфәгатьләрен әдәбият һәменә фида кылган, һәр талантлы әсәр өчен куанып, әдәбияттагы һәр кимчелек өчен борчылып яшәгән ул фидакарь затлар күбесе юк инде. Бераз моңсу, юксындыра, сагындыра.

Әмма шул ук вакытта күңелдә горурлык хисе дә уяна. Алар белән эшләвем бәхет булган икән. Минем бала чак хыялым ялгышмаган булып чыкты. Шунча еллар үтеп, тормышның шундый рәхимсез сынауларын узганнан соң да алар һаман да халык бәхете, туган ил, коммунистик идеаллар өчен көрәшүче фидакарь көрәшчеләр, чын коммунистлар булып калдылар. Гадел тарих аларны яңадан үз урыннарына кайтарды.

Әгәр мин үз гомеремдә әдәбиятка нидер бирә алган булсам, минем хезмәтләремдә бу затларның да өлеше бар.

Уйлана-уйлана журнал битләрен актарам... Шул саргайган битләр аша каршыма үрә басып торган каты кара чәчле, кератут йөзле, көләч күзле, хәрәкәтчән Фатих Кәрим килеп баса. 1936 елның соңгы саны чыгар алдыннан әтнәсенә ничә мәртәбә генә кереп чыкмады икән ул! «Аникин» исемле поэмасының басылып чыгуын ул балаларча түземсезлек һәм шатлык белән көтеп алды.

— Журнал кайчан чыга? Ничегрәк чыга? Журналда поэма ничә бит булды икән?..

Поэманың иң соңгы юлларын ул болай тәмамлаган иде.

> **Мин үзем дә батырларның юлын**
> **Хыялымнан бик еш үткәрәм,**
> **Алар биргән тойгы-ялкыннарын**
> **Факел итеп өскә күтәрәм.**

Шагыйрьнең пәйгамбәрлеге, бервакыт килеп, хакыйкатькә әверелдә. Шул факелны бөтен иҗаты буенча балкытып алып барды да, ниһаять, ул аны халыклар азатлыгы өчен барган изге сугыш мәйданында, мәңге сүнмәстәй итеп, немец җирәнде кабындырып калдырды.

Күзләрем журналда, ә күңелем ерактагы шул юллардан безнең заманга сузылгач тагын шундый иҗат җепләрен эзли.

Журналның 1937 елгы 11 санында яшь шагыйрь Сибгат Хәкимнең зур әдәбият дөньясына аяк басканда иҗат иткән «Йәрәккә язылган исем» дигән лирик шигырә бар.

> **Алмагачлар чәчәк атты инде,**
> **Яшел кием киде топольләр.**
> **Салмак кына җилпеп канатларын**
> **Кыр казлары җырлап үттеләр...—**

ди ул анда. Күптән түгел шагыйрьгә алтмыш тулды. Аның күкрәгендә хәзер Ленин ордены балкый. Киек казлардан да өскәрәк күтәрелеп, хәзер бөтен ил өстендә яңгырый торган иркен сулышлы, киң канатлы шигъри аһәңе аның да башта журнал битләреннән күтәрелеп киткән иде бит.

Шул ук елда яшь язучы Габдрахман Әпсәләмовның журналда «Мәһинур» дигән беренче хикәясе басылды. Хәзер ул 6—7 роман авторы, бөтен Советлар Союзына танылган мәшһүр язучы. Нинди сикереш! Нинди адымнар!

Әгәр хәзер әдәбият дөньясында берсеннән-берсе яхшы әсәрләр пәйда була икән, әгәр безнең әдәбиятыбыз тагын да югарырак баскычка күтәрелгән икән, бу күтәрелештә журналның да өлеше зур. «Казан утлары»н безнең әдәби әсәрләребезнең беренче бишеге дип атарга мөмкин. Чөнки нигезсез йорт, баганасыз капка була алмый. Орлык чәчелмәгән кысыр туфрактан берни дә тишелми.

Халыкның һәм аның әдәбиятының тарихын, аның көрәш юлын никадәр яхшырак белсәң, алга таба шул кадәр ышанычлырак атлыйсың. «Казан утлары» татар әдәбиятының йөзләрчә еллар элек үк башланып киткән гуманистлык, халыкчанлык кебек яхшы сыйфатларын өзлексез дәвам иттерде, аларны эстафета рәвешендә буыннан-буынга тапшырып килде.

Журналның киләчәге тагын да матуррак, бәрыр юлы яктырак, адымнары тагын да үрчемлерәк һәм кыюрак булсын!

Әнвәр Шәрипов

# «МӨҺИММӘТ ЭЗ-ЗАМАН» КЕМ ӘСӘРЕ?

Әгәр әдәбиятыбызның бай тарихы, бигрәк тә аның борынгырак чорлары белән якыннан кызыксына башласак, без тормыш һәм иҗат юллары ныклап өйрәнелмәгән әдипләрне, шулай ук авторлары төгәл ачыкланмаган әдәби әсәрләрне шактый очратырбыз. Халыкны әдәп, әхлак кагыйдәләренә өйрәтү максаты белән язылган «Мөһиммәт эз-заман» шундый әсәрләр рәтенә керсә кирәк. Безнең әдәбият фәнендә ул XVIII йөз шагыйре Габдерәхим Утыз Имәнигә нисбәт итеп йөртелә. Мондый нәтиҗә нинди дәлилләргә нигезләнеп ясалган соң? Иң элек шуларны ачыклап үтик.

1889 елда Казанда «Мөһиммәт эз-заман» исемле бер шигырь китабы басылып чыга[1]. 24 битле ул китапның титул битендә шундый аңлатма да була:

«Габдерәхим әл-Утыз Имәни хәзрәтләренең иҗат иткән хезмәтедер. Сәүдәгәр Мөхәммәтҗан бине Минһаҗетдин әл-Кәрими акчасына Казан шәһәрендә Вячеслав типографиясендә һиҗри белән 1309 елда (хәзерге ел исәбе белән 1889 елга туры килә — Ә. Ш.) бастырып чыгаруга әмер бирелеп, заманыбызның зур галиме әл-Мәрҗани хәзрәтләре шәкерте Кашшафетдин бине Шаһимәрдан әл-Минзәләви әс-Сөлүкинең редакцияләве белән Казанда мәдрәсәбездә карап чыгылды»[2].

1898 елда китапның икенче басмасы чыга. 1889 елгы басмадан аермасы шунда гына: әгәр беренче мәртәбә китап сәүдәгәр Мөхәммәтҗан акчасына басылса, бусы аның туганы Шәрифҗан әл-Кәрими акчасы белән Чирков типографиясендә басыла.

Әсәр китап булып чыга, ләкин әдәбият тарихы буенча хезмәтләрдә 1889 елга кадәр дә, аннан соң да «Мөһиммәт эз-заман» турында бернинди мәгълүмат китерелми. Шулай еллар уза. Бары революциядән соң гына ул яңадан телгә алына. «Мәгариф» журналының 1927 елгы 12 санында Г. Толымбайскийның «Татар әдәбияты тарихына яңа материал» исемле бер мәкаләсе урнаштырыла. Мәкалә авторы Утыз Имәни иҗатының бөтенләй өйрәнелми ятуына ачына һәм «Мөһиммәт эз-заман» әсәренең әдәбият тарихында үзенә тиешле урынны ала алмыйча, читтә калуы турында борчылып, болай яза: «...Без иске язма әйберләрне эзләргә генә бирелеп, менә шушы «Мөһиммәт эз-заман» кебек басылып чыгып, борын төбендә яткан әһәмиятле әйберләргә күз салмый торгалыйбыз. Бу нәрсә, әлбәттә, зур җитешсезлек».

---

[1] «Татар поэзиясе антологиясе»ндә (1956 ел) бу җыентык беренче тапкыр 1870 елда басылып чыга дип күрсәтелә (75 бит). Ләкин без, кызганычка каршы, китапханәләрдә әсәрнең бу нөсхәсен таба алмадык.

[2] Текст хәзерге телгә тәрҗемә итеп бирелде.

Г. Толымбайский журнал укучыларын җыентыкның гомуми эчтәлеге белән таныштыра һәм әсәрдән аерым өзекләр китерә. Әлеге мәкаләдән соң «Мөһиммәт әз-заман» әсәренә игътибар арта. Әсәрнең гади, аңлаешлы тел белән язылуын искә алып булса кирәк, аны мәктәп укучыларына да тәкъдим итә башлыйлар. Беренче тапкыр ул 8 нче класс өчен чыгарылган әдәбият дәреслегенең 1938 елгы басмасында телгә алына. Шул еллардан алып бүгенге көнгә кадәр «Мөһиммәт әз-заман» мәктәпләрдә Утыз Имәни әсәре буларак укытылып килә.

Габдерәхим Утыз Имәни иҗатын тикшерүгә багышланган борынгы материалларны өйрәнгәндә без бер кызыклы детальгә игътибар иттек: танылган әдәбият галимнәре һәм тарихчыларыбызның Утыз Имәни турында язылган мәкаләләрендә язучының «Мөһиммәт әз-заман» исемле шигъри әсәре беркайчан да телгә алынмый. Мәсәлән, К. Насыйри «Казан календаре»ның 1877 елгы санында урнаштырылган мәкаләсендә Утыз Имәни иҗат иткән 13 әсәрнең исемен китерә һәм аларның ничек башланып китүләрен дә теркәп куя. Ләкин алар арасында «Мөһиммәт әз-заман» әсәре юк[1]. Ш. Мәрҗани[2], Р. Фәхретдинов[3], М. Рәмзи[4] хезмәтләрендә дә шундый ук хәл.

Бу урында тагын шуны искәртеп үтәсе килә: кайбер әдәбият белгечләре «Мөһиммәт әз-заман» белән «Рисаләи Мөһиммә»нең икесен бер үк әсәр дип исәпләләр. Һәм үзләренең бу фикерләрен раслар өчен К. Насыйриның «Казан календаре»ндагы мәкаләсенә таяналар. Каюм Насыйри исә болай яза (хәзерге телгә сүзгә-сүз тәрҗемә итеп бирелә): «Һәм тагын халык кулында кулланыла торган «Рисаләи Мөһиммә» дигән бер рисалә бар, ул — Габдерәхим мулланың халык өчен иман, әхлак турында үгет-нәсыйхәт рәвешендә рифмалы чәчмә сүз һәм вәзен белән иҗат иткән гаҗәп бер игелекле китабыдыр. Бу рисаләне, башына ниндидер бер зур каза төшеп, төрмәдә тоткын булган хәлдә иҗат иткәне билгеледер». (К. Насыйри. Казан календаре. 1877 нче елга. 45 бит.)

Безнеңчә, «Рисаләи Мөһиммә»нең «Мөһиммәт әз-заман» белән бернинди бәйләнеше юк. Аларның икесе ике әсәр. «Мөһиммәт әз-заман»нан аермалы буларак, «Рисаләи Мөһиммә» рифмалы проза (сәҗгъ) белән язылган һәм беренче тапкыр 1840 елда Казан өязе Яңа Кишет иленең сәүдәгәре Рәхмәтулла Әмирхан улы тарафыннан Казан университеты типографиясендә чыгарылган[5].

Кызык кына хәл килеп чыга: бер яктан, Ш. Мәрҗани шәкерте Кашшафетдин бине Шаһимәрдан 1889 елда «Мөһиммәт әз-заман»ны Утыз Имәни әсәре дип бастырып чыгара. Әдәбият белгече Г. Толымбайскийның мәкаләсеннән соң бу караш фәнни әйләнешкә кереп китә һәм бүгенге көнгә кадәр үзгәрешсез яшәп килә. Икенче яктан, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри кебек күренекле галимнәр Утыз Имәнинең ул әсәрен белмәгәннәр, яки белгән очракта да аны телгә алмаганнар. Моны ничек аңларга соң? Мәсьәләгә ачыклык кертү нияте белән без «Мөһиммәт әз-заман»ның кулъязма нөсхәләренә мөрәҗәгать итеп карарга булдык. Әсәрнең өч кулъязмасы табылды. Аларның икесе Казан университеты каршындагы Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең Көнчыгыш кулъязмалары бүлегендә, берсе СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивында саклана. Әсәрнең кулъязма вариантларын

---

[1] Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең Көнчыгыш кулъязмалары бүлегендә бу мәкаләнең К. Насыйриның үз кулы белән язган каралмасы да саклана. Анда «Казан календаре»ндагы мәкаләгә кермәгән кайбер өстәмә мәгълүматлар да бар. Ләкин «Мөһиммәт әз-заман» исемле әсәр телгә алынмый.

[2] Ш. Мәрҗани. Мөстафад әл-әхбар. II кисәк. Казан. 1900 ел. 239—241 битләр; Вәфият әл-әсләф, VI кисәк. 182 а — 184 б битләр; VII кисәк. 181—183 битләр.

[3] Р. Фәхретдинов. Асар. 6 кисәк. Оренбург. 1904 ел. 300—316 битләр.

[4] М. Рәмзи. Тәлфикъ әл-әхбар вә тәлкыйх әл-асар фи вакаигы Казан вә Болгар вә мөлүке әт-татар. II кисәк. Оренбург. 1908 ел. 434 бит.

[5] «Мөһиммәт әз-заман» беренче тапкыр 1870 елда чыккан дип исәпләгәндә дә, «Рисаләи Мөһиммә» аннан 30 ел элегрәк басылган булып чыга.

1889 елгы китап нөсхәсе[1] белән чагыштыра башлагач, төрле нөсхәләрдә кулъязмаларның төрлечә булуы һәм кайбер башка характердагы аерымлыклар булуы ачыкланды. Шуңа күрә кыскача гына шул аермаларга тукталып китик.

*Китап нөсхәсендә* әсәр кереш өлеше белән башлана, шуннан 24 бәян (шигъри бүлек — Ә. Ш.) килә. Беренчесе — «Хәлял кәсеп итмәк бәяны», соңгысы «Инсаф улмакның бәяны» исемле. Ахыргы бәяннан соң 28 шигырь юлыннан торган «Мөнаҗәт» килә. Китап барлыгы 934 шигырь юлыннан тора.

*1358 т. номерлы кулъязма* төрле шигырьләр һәм проза әсәрләре язылган җыентыктан гыйбарәт. «Мөһиммәт әз-заман» шуның 58 б—75 а битләренә күчерелгән. Әсәрнең тексты, бәяннар исеме һәм аларның урнашу тәртибе китап нөсхәсендәгечә. Ләкин текстның күләме китап нөсхәсеннән 222 юлга артыграк (барлыгы 1156 юл). Билгеле булганча, китап вариантында «Инсаф улмакның бәяны» иң соңгы бүлек иде. Кулъязмада аннан соң тагын өч бәян килә («Рия улмакның бәяны», «Хәзәр итмәкнең бәяны» һәм «Нәсыйхәт әйләмәк бәяны». Өчесе бергә 210 шигырь юлы). Ләкин биредә китап нөсхәсендәге «Мөнаҗәт» юк. Әсәр баштан ахырга кадәр бер кеше кулы белән күчерелгән. Күчерүчесе һәм датасы күрсәтелмәгән. Университет китапханәсенә ул И. Хөсәенов архивыннан кергән. Инвентарь китапта, нинди мәгълүматларга таяныптыр, бу җыентыкның Сәйфулла (Сәйфетдин?) бине Халид әл-Фирсәви тарафыннан күчереп язылганлыгы әйтелгән.

*654 т. номерлы кулъязма* (*элекке номеры* 3928) 18 кәгазьле кулъязма дәфтәрдән гыйбарәт. «Мөһиммәт әз-заман» 1 а — 18 б битләргә күчерелгән. Дәфтәр тулы түгел. Баштан ике кәгазе төшкән, шуңа күрә әсәр икенче бәяннан гына башланып китә. 4 һәм 5 битләр арасында тагын ике кәгазь (барлыгы 102 шигырь юлы) югалган[2]. Әмма әсәрнең ахыры тулы. Монда да китап нөсхәсендә булмаган өч бәян бар һәм аларның күләме дә нәкъ 1358 т. номерлы кулъязмадагыча. Китап нөсхәсендәге «Мөнаҗәт» монда да юк. Әсәр барлыгы 918 шигырь юлыннан тора.

Кулъязманың үзендә күчерүчесе һәм язылу вакыты күрсәтелмәгән. Әдәбият тарихы белгече Мөхәммәт Гали бу кулъязма турында түбәндәгечә яза: «Бу әсәр 1820 елда язылган һәм шул ук елда остазы мулла Кәмалетдин Габдессәлам улы кушуы буенча Гыйззәтулла дигән шәкерт тарафыннан күчерелеп язылган. Шул нөсхә Казан университеты кулъязмалар бүлегендә 3928 шифрында саклана. Кулъязманың башы, ахыры юк. 1898 елда Казанда басылган»[3].

М. Гали кулъязманы күчерүченең исемен каян алгандыр, ул кадәресе безгә билгесез. Ә менә «кулъязманың ахыры юк» дип, ул дөрес күрсәтми. Әсәрнең ахыры бар, ләкин аның язуы кырылган һәм авыр таныла.

*Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивындагы кулъязма* — кечкенә күләмдә, барлыгы 30 кәгазьдән торган җыентык. Текст тулы түгел. Баштан һәм ахырдан битләре төшкән. Кереш белән башлана һәм «Рия улмакның бәяны»нда өзелеп кала. Барлыгы 883 юл. Ләкин шунысы игътибарга лаек, биредә дә 24 нче бәяннан соң «Мөнаҗәт» түгел, ә алдагы кулъязма текстлардагы кебек, «Рия улмакның бәяны» килә. Текстның кайчан һәм кем тарафыннан күчерелүе билгесез.

Төрле нөсхәләрне үзара чагыштырып караганнан соң шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: «Мөһиммәт әз-заман»ның нигез тексты булып исәпләнеп йөртелгән китап нөсхәсе тулы түгел, әсәрнең тулы тексты 1358 т. һәм 654 т. номерлы кулъязмаларда саклавып калган икән. «Мөһиммәт әз-заман» 24 бәяннан түгел, ә 27 бәяннан торган булган. Тагын шунысы бар: китап нөсхәсендәге «Мөнаҗәт» кулъязма нөсхәләрнең берсендә дә очрамый. Димәк, аның китапка өстәлеп кенә куелган бу-

---

[1] 1889 һәм 1898 елгы басма нөсхәләр арасында бернинди дә аерма булмау сәбәпле, без аларны «китап нөсхәсе» дип кенә йөртәбез.

[2] Дәфтәр битләре соңыннан номерланган.

[3] Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы. 58 фонд. 1 опись. Саклау берәмлеге 232. 1 а бит.

луы бик мөмкин. Ниһаять, бары кулъязма нөсхәләрдә генә сакланып калган соңгы өч бәянда әсәрнең үзе һәм аның авторы турында яңа мәгълүматлар китерелгән. Мәсәлән, 1358 т. номерлы кулъязмада шагыйрь үзе турында болай ди:

Сабыр итдем, агадин вәгъдә көтдем,
Кәлүп кырык сикез яшимә җитдем;

Ә 654 т. номерлы кулъязмада исә:

Кәлеп кырык тукыз яшемгә йитүм,—

дигән юллар бар.

Кулъязмаларның һәр икесендә әсәрнең язылган елы да күрсәтелә:

Тарих мең дә сикез йездә егерме,
Язылды маһе мәүлүд вакыты көне.

Исәпләп карыйк: 1820 елда 48 яки 49 яшенә җиткән кеше 1771—1772 елларда туган булып чыга. Бу саннар Г. Утыз Имәнигә туры килми. Әдәбият тарихында Утыз Имәнинең 1754 елда туган булуы билгеле. Димәк, әсәрне икенче бер кеше язган дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Инде игътибар беләнрәк укый башласак, күрәбез: шагыйрь үзенең исемен дә китерә икән ләбаса. 1358 т. һәм 654 т. номерлы кулъязмаларның икесе дә түбәндәге юллар белән тәмамлана:

Гаделшаһның сүзендин әйләсәң ишт,
Тоелмасмы берәрсе күңлеңә хуш.

Эзләнүне дәвам иттерәбез. Университет китапханәсенең Көнчыгыш кулъязмалары бүлегендәге каталогтан авторы Гаделшаһ булган кулъязмалар эзлибез. Һәм, чыннан да, аның монда «Нәсыйхәтнамә» исемле бер әсәре бар икән [1]. Алып укып карыйбыз һәм ул шул ук «Мөһиммәт эз-заман» әсәре булып чыга.

Шигъри текст 24 кәгазьле кулъязма җыентыкның 3 б — 22 б битләренә язылган. Бәян исемнәре, аларның урнашу тәртибе һәм шигъри текстның үзе дә сүзгә-сүзгә «Мөһиммәт эз-заман»ның китап нөсхәсе белән туры килә. Биредә дә шигъри текст, башка кулъязмалардагы кебек үк, китап нөсхәсеннән өч бәянга артыграк — барлыгы 27 бәяннан тора. Әмма шулай да бу кулъязманың 1358 т. һәм 654 т. номерлы кулъязмаларыннан аермасы бар. Аерма шунда: биредә иң соңгы бәян («Нәсыйхәт әйләмәк бәяны») алдагы кулъязма текстлардан 118 шигырь юлына кимрәк (1358 т. һәм 654 т. номерлы кулъязмалардагы бу бәян 158 шигырь юлыннан тора). «Нәсыйхәтнамә»дә «миңа 48 яшь» һәм «1820 елда язылды» дигән урыннары юк. Ләкин шулай да текст «Гаделшаһның сүзендин әйләсәң ишт...» дигән сүзләр белән тәмамлана. Кулъязманың күчерүчесе һәм язылу датасы да күрсәтелгән. Шигъри текст ахырына гарәпчә (биредә тәрҗемәсен бирәбез): «Бу китапны күчерүче Базарлы Шәкшенең икенче имамы Хәбибрахман бине мулла Габделлатыйф, 1884 ел, 21 январь»,— дип язылган [2].

Димәк, «Мөһиммәт эз-заман» әсәре 1884 елда «Нәсыйхәтнамә» исеме белән дә йөртелгән икән. Алай гына да түгел: кулъязма нөсхәләрдә беренче урында бу исемгә ишарә дә бар икән бит. Менә аларның кайберләре:

Нәсыйхәтнамә калсун шимди бәндин,
Будыр килгәй телдин, шөйлә әлдин [3].
(*«Нәсыйхәт әйләмәк бәяны»*)

Аяуң гыйбрәт, күрүп әһле мәзарәт [4],
Идәм сәңа нәсыйхәт ба-гыйбарәт [5].
(*«Әһле мәзарәт бәяны»*)

---

[1] Кулъязма 536 т. номеры белән саклана.

[2] Саба районындагы Шәкшә авылы элегрәк Базарлы Шәкшә дип аталып йөртелгән. Ә күчерүче турында без әлегә башка материал таба алмадык.

[3] Әлдин — кулдан.

[4] Әһле мәзарәт — вафат булган кешеләр.

[5] Ба-гыйбарәт — аңлатмасы гына.

Нәсыйхәтдүр сүз имди белсәңез сез,
Гата калсун[1] нәсәбкә шимди бу сүз.

Күрәсез, «Мөһиммәт эз-заман» әсәренең кульязмалары аның Гаделшаһ исемле шагыйрь тарафыннан язылган булуы турында сөйлиләр. Ә 1889 һәм 1898 елгы китап нөсхәләрендә исә «Мөһиммәт эз-заман» Утыз Имәни әсәре дип күрсәтелә. Боларның кайсысы дөрес, кайсысы хакыйкатькә туры килә? Моның өчен безгә иң әлек Гаделшаһның кем булуын белергә кирәк. Чыннан да, кем ул Гаделшаһ? Әдәбият тарихында аның турында нинди дә булса мәгълүмат билгеленмәгән. Аның башка әсәрләре булганмы? Әлеге сорауларга җавап эзләп, әдәбият тарихы буенча язылган фәнни хезмәтләргә мөрәҗәгать итик. Р. Фәхретдиновның «Асар»ында[2] Гаделшаһ исемле берничә кеше телгә алына. Әмма күп мәгълүмат бирелми: я аларның исемнәре генә әйтеп кителә, яки үзе турында бераз сөйләнсә дә, бер сенең дә туган, үлгән еллары китерелми, шигырь язарга һәвәслеге турында әйтелми. Шуңа күрә без әлегә Гаделшаһлар арасында без эзли торган шагыйрьнең булу-булмавын һәм, булган очракта да, аларның кайсысы икәнен әйтә алмыйбыз. Шулай да Казан университетының фәнни китапханәсендәге кульязмалар арасында кызыклы гына ике җыентык табылды. Аларның берсе — Төхфәтулла бине Гаделшаһ исемле кешенең кульязма җыентыгы (№ 664 т.). Шунысы әһәмиятле, бу кеше дә шигырьләр язган икән. 664 т. номерлы кульязмада аның «Пәнд вә нәсыйхәт» (60 шигырь юлы) һәм «Тәхрир мулла әл-мәрхүм Төхфәтулла» (14 шигырь юлы) исемле ике шигъри әсәре күчерелгән. Язылу датасы — 1835 ел. Күчерүчесе күрсәтелмәгән, кульязма автограф булса кирәк. «Пәнд вә нәсыйхәт» әсәрен автор үзенең хатынына багышлап язган. Биредә шагыйрь аны шәригать кушканча яшәргә, ят кешегә күз салмаска, әдәпле булырга үгетли.

Шул кадәресе аеруча кызыклы, бу әсәрнең стиле «Мөһиммәт эз-заман» стиленә якын. Чагыштырып карыйк:

Гәр салурсән, ят кешигә күзеңни,
Санма адәм соңра сән үз-үзеңни.
*(«Пәнд вә нәсыйхәт»)*

Үзең кайда, җәмәгать шунда дорсын,
Күзүн бакуп караса, сәни күрсен.
*(«Мөһиммәт эз-заман»)*

Икенчесе — Утыз Имәнинең улы Әхмәтҗан Болгари кулы белән күчерелгән фарсыча әсәрләр җыентыгы (№ 422 т.). Әсәрләр арасында, буш калган 36 кәгазьдә, башка бер кеше кулы белән болай язылган: «1837 елда Казан губернасының Спас өязенең Төгәлбәй иленең ... ил имамы мелла Мир Галаэтдин Габдулла угылы бер «Кыйссаи Йосыф» — алтын берлә чите тарткан, вә кәнә[3] бер шәл, вә кәнә (?) ... ошбуларны мәҗмугысы[4] йөз сумга вирдем Оренбург губернасының Тимәш авылының Әхмәтҗан Габдерәхим угылына Гаделшаһлар хозурында[5] ... бән указной имам мелла Мир Галаэтдин разый улып, кулым куйдым».

Димәк, 1837 елда Утыз Имәнинең улы Әхмәтҗан ниндидер бер Гаделшаһ исемле кеше белән бер йортта утырдаш булган. Бу, безнең карашыбызча, очраклы хәл булмаска кирәк. Әлеге деталь Утыз Имәни белән Гаделшаһ арасында ниндидер мөнәсәбәт булганлыгына ишарә ясый кебек.

Инде хәзер мәсьәләнең икенче ягына игътибар итик: без «Мөһиммәт эз-заман» әсәренең язылу стилен Утыз Имәнинең башка әсәрләренең (инде ышанычлы рәвештә Утыз Имәнинеке дип әйтергә мөмкин булган әсәрләр, мәсәлән, «Гавариф

---

[1] Гата калсун — бүләк калсын.

[2] «Асар» — Р. Фәхретдиновның X—XIX гасырларда яшәгән төрки-татар әдипләре, укымышлыларының тәрҗемәи хәлләре турында язылган хезмәте. Барлыгы 15 кисәктән тора.

[3] Кәнә — янә, тагын.

[4] Мәҗмугысы — бөтенесе, барлыгы.

[5] Хозурында — алдында, янында.

эз-заман», «Тәнзиһ эл-әфкяр фи нәсаих эл-әхъяр», «Манзум» һәм башкаларның) язылу стиле белән чагыштырып карадык. Ләкин бу да безгә «Мөһиммәт эз-заман»ны нәкъ менә шушы шагыйрь язган дип кистереп әйтер өчен җитәрлек материал бирмәде. Чөнки стильләр арасында охшашлык та бар, аерымлык та җитәрлек [1]. «Мөһиммәт эз-заман» әсәрендәге кайбер тәгъбир, сүз тезмәләрен без Утыз Иманинең башка әсәрләрендә дә очратабыз. Мәсәлән, «Мөһиммәт эз-заман» әсәрендә «Егет улмакның бәяны» түбәндәгечә башлана:

Егет улсаң, егетлек күргәз илгә,
Мәхәббәтлек путасын багла билгә.

Утыз Иманинең дә «Манзум» исемле шигырендә:

Сәгаять футасыни багла билгә,
Безнең дик кыйл татбикъ нөсхәләргә [2],—

дигән сүзләр бар [3].

Шул ук вакытта «Мөһиммәт эз-заман»ның теле Утыз Имәни әсәрләренең теленнән аерыла да кебек. Мәсәлән, «Гавариф эз-заман» белән «Тәнзиһ эл-әфкяр» әсәрләре күбрәк гарәп, фарсы сүзләрен катнаштырып, борынгы катлаулы телдә язылган булсалар, «Мөһиммәт эз-заман» исә татар халкының сөйләшенә якын телдә, гади татар сүзләрен кулланып иҗат ителгән. «Тәнзиһ эл-әфкяр» һәм «Мөһиммәт эз-заман» әсәрләренең аерым юлларын чагыштырып карыйк:

Фәсахәтдин кемә кем тиксә бәһрә,
Нәсаих әйләгәй әһле диярә [4].
*(«Тәнзиһ эл-әфкяр».)*

Малым вар дип фәкыйрьне күрмәгел хур,
Сүзем кадерледүр дип улма мәгърур.
*(«Мөһиммәт эз-заман».)*

Әдәбият тарихында бу аермага элегрәк тә игътибар иткәннәр. Мәсәлән, югарыда искә алынган мәкаләсендә шул ук Г. Толымбайский болай яза: «Утыз Имәни турында кайбер тикшерүчеләр яки тикшерми сөйләүчеләр: «Аның теле бик әшәке — бик фарсыча», диләр. Бу әсәренә карагандa (сүз «Мөһиммәт эз-заман» турында бара — Ә. Ш.), һич булмаганда, аңа шундый карашларның дөрес булып җитмәвен әйтергә була».

Безнең бу күзәтүләребез әлегә «Мөһиммәт эз-заман» кем әсәре? дигән сорауга нигезле җавап бирә алмыйлар. Аның өчен яңадан-яңа тикшеренүләр, эзләнүләр кирәк. Киләчәктә «Мөһиммәт эз-заман»ның чын авторы, һичшиксез, ачыкланыр дип ышанасы килә. Без исә мәсьәләне көн тәртибенә кую һәм галимнәребезнең игътибарын әлеге кызыклы фактка юнәлтү белән чикләнә

---

[1] Бу әсәрләрнең стильләрен чагыштыру үзе аерым бер мәкалә язуны сорый.

[2] Тырышлык путасын билгә бәйлә, нөсхәләргә безнең кебекияр (буйсын).

[3] Казан университеты китапханәсенең кульъязмалар бүлеге. 1265 т. номерлы кульъязма. 43 а бит.

[4] Бирәүгә сүз сәнгатеннән өлеш тисә, ул ил халкына үгет-нәсыйхәт әйтсен.

**Рафаэль Мостафин**

# ТӘНКЫЙТЬКӘ — ТӘНКЫЙТЬ УТЫ

Советлар Союзы коммунистлар партиясенең XXIV съезды, илнең экономик, социаль һәм фәнни үсеше өчен яңа перспективалар ачу белән бергә, әдәбият, сәнгатьнең чәчәк атуы өчен дә киң мөмкинлекләр тудырды. Партия съездында каралган теоретик һәм практик мәсьәләләр һәммә кешегә, шул исәптән язучыларга да, турыдан-туры кагыла. Анда, иң мөһим бурычларның берсе тесендә, коммунистик аңга ия булган яңа кеше тәрбияләү мәсьәләсе дә куелды. Бу мәсьәләне уңышлы хәл итүдә әдәбият һәм сәнгать әһелләренә ифрат җаваплы эш йөкләнә.

Бүгенге заман һәм иҗтимагый үсешнең хәзерге торышы язучылар, аерым алганда, тәнкыйтьчеләр алдына зур, яңа бурычлар куя. Леонид Ильич Брежневның отчет докладында әдәби тәнкыйтькә карата каты, әммә гадел сүзләр әйтелде. «Шик юк ки,— диде ул, — әгәр әдәбият-сәнгать тәнкыйте партия линиясен тагын да активрак үткәрсә, таләпчәнлекне такт белән, художество кыйммәтләрен иҗат итүчеләргә игътибарлы мөнәсәбәт белән бергә бәйләп, зуррак принципиальлек белән чыгыш ясаса, совет әдәбиятының һәм сәнгатенең уңышлары тагын да зуррак булыр, ә кимчелекләре тизрәк бетәрләр иде».

Күрәсез, съезд безнең алга таләпчәнлекне такт белән, әдәби байлык иҗат итүчеләргә принципиаль карашны игътибарлы мөнәсәбәт белән бәйләү бурычын куя. Бүгенге татар тәнкыйте үзенең шул вазифаларын ничек үти соң?

Бүгенге татар әдәбиятында кызыклы үсеш процессы бара, әдипләребез яңа иҗат уңышлары яулыйлар. Ул уңышларда әдәби тәнкыйтьнең дә күпмедер өлеше бар, билгеле. Бездә әдәби процессның төрле тармакларында эшләүче сәләтле тәнкыйтьчеләр отряды өешты, бүгенге әдәби процесста сизелерлек роль уйнаган тәнкыйть хезмәтләре язылды. Мисал рәвешендә, Х. Госман, Г. Халит, И. Нуруллин, Й. Нигъмәтуллина, Н. Юзиев, Т. Галиуллиннарның монографияләрен һәм проблемалы мәкаләләрен телгә алып узарга мөмкин.

Ләкин тәнкыйтьчеләрнең эшен алар язып бастырган мәкаләләр, алар чыгарган китаплар саны белән генә үлчәргә ярамый. Әдәби тәнкыйть нигездә әдәбияттагы әхлакый климатны билгели. Бәләкәй генә рецензияләр, кечкенә күләмле полемик

мәкаләләр һәрвакыт мөстәкыйль әһәмияткә лаек та булмасыннар да ди, әмма алар әдәбият кырындагы чүп үләнне утарга, туфракны йомшартырга булышалар. Җитлеккән, камил үсешкә ирешкән тәнкыйтьтән башка камил әдәбият була алмый. Менә ни өчен партиябез әдәби тәнкыйтьнең ролен һәм иҗтимагый авторитетын күтәрүгә шундый зур игътибар бирә.

Дөресен әйтергә кирәк, әдәби тормышыбызның әхлакый атмосферасында да мәгълүм бер үсеш, үзгәреш сизелә. Хәзер безнең тәнкыйтьтә язучыга төрле ямьсез исемнәр тагу, аның язганнарын дәлилсез һәм тупас төстә юкка чыгару очраклары күренми диярлек, тәнкыйть вульгар социологизм авыруыннан да терелеп килә. Безнең тәнкыйть яшь талантларга, әдәбияттагы һәм тормыштагы уңай тенденцияләргә торган саен игътибарлырак була бара, перспективасы булмаган ялгыш агымнарга каршы кыюрак, рәхимсезрәк төстә көрәшә. Бу — барлык кимчелекләр бетерелгән, бөтен мәсьәләләр уңай хәл ителгән дигән сүз түгел, билгеле. Мин ахыргача чишелеп, хәл ителеп бетелмәгән шул мәсьәләләрнең кайберләренә укучыларның игътибарын юнәлтмәкче булам.

## ТӘНКЫЙТЬ НИГӘ ДӘШМИ!..

«Хәзер нәшрият ел саен бик күп китап чыгара. Шуларның бик азы гына тәнкыйть фикере ишетеп бара». Безнең адреска карата иң еш әйтелә торган гаепләү сүзләре әнә шулар.

Нихәтле гадел бу гаеп?

Татарстан китап нәшрияты ел саен 300—350 исемдә яңа китап чыгара, һәр өч китапның берсе — матур әдәбият китабы. 1970 елда, мәсәлән, яшьләр һәм балалар өчен чыгарылган әсәрләрне дә кертеп, 120 исемдәге китап басылган. Шуларның йөзләбе татар телендә. «Газета-журнал мәкаләләре елъязмасы» буенча санап карадым, шул ук елда яңа чыккан матур әдәбият әсәрләренә 61 рецензия басылган. (Кайбер китапларга 2—3 рецензия язылуын исәпкә алсак, нәшрият чыгарган яңа китапларның яртысы рецензиясез калып килә, дип санарга була.) 1971 елда да эшләр шул чамадарак.

Татарстан китап палатасы мәгълүматларына караганда, әле берничә ел элек кенә бездәге һәр дүрт яки биш китапның нибары берсе матбугат сүзе ишетеп барган булган. Күрәсез, хәзер күпмедер алга китеш бар. Әмма барлык әдәби продукциянең яртысы рецензия күрми кала икән, бу шулай ук әйбәт түгел.

Мин, нинди китаплар рецензияләнми кала икән, дип кызыксынып карадым. Иң начар рецензияләнеп барганы — балалар һәм яшьләр өчен чыгарылган китаплар икән. Бездә балалар әдәбиятына караган мәсьәләләр белән махсус шөгыльләнә, бу өлкәдәге яңалыкларны даими күзәтеп бара торган тәнкыйтьчеләр юк диярлек. Иң шәп дигәндә, балалар өчен язылган әсәрләрнең аеруча күренеклеләре әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышларда телгә алынып узыла. Ә күпчелек китаплар берниндн фикер ишетми кала. Тәнкыйтьче кадрлар мәсьәләсен хәл итми торып, бу эшне юлга салу кыен булыр, күрәсең.

Дәшми калу ягыннан икенче урынны тәрҗемәләр һәм кабат басылган әсәрләр тота. Билгеле, кабат басылган һәр әсәр махсус рецензиягә мохтаҗ булмаска мөмкин. Әмма еш кына яңа басма әлеге әсәргә башкарак, үзгәрәк караштан чыгып күз ташлау, кайбер элекке бәя һәм карашларны яңадан карау, әсәрнең яшәүчәнлек һәм тормышчанлык көчен ачыклау өчен менә дигән сылтау була ала. Аннан соң әсәрләрне кабат басып чыгару политикасы үзе үк тәнкыйтьнең игътибарына мохтаҗ. Кабат чыгару өчен һәрвакыт иң яхшы әсәрләр генә сайлап алынамы? Чыннан да кирәк әйберләр «кәгазь җитми» сылтавы белән чыкмый калмыйлармы?..

Менә бер генә мисал. Казанның һәм республиканың бөтен киоскалары Х. Сарьянның «Әткәем һөнәре» (русча исеме — «Память отца») исемле китабы белән тулган. Болай ул начар әсәр түгел. Ләкин аны 100 000 данә тираж белән кабат чыгару никадәр дөрес булды икән?!. Күзгаткан мәсьәләләре, сәнгатьчә эшләнеше дәрәҗәсе белән дә әсәр андый ук җаваплылыкны күтәрә алмый.

Тәрҗемәләр хакында да шул ук фикерне әйтергә мөмкин. Рус теленә тәрҗемә итү өчен иң лаеклы әсәрләр сайланамы? Шулай бер вакыт бер рус язучысы белән бүгенге татар әдәбияты турында сөйләшеп киттек. Безнең әдәбият турында шактый түбән фикердә тора бу. Ахырдан ачыкланды, бүгенге татар әдәбияты хакында ул М. Хәсәновның «Юллар, юллар...» романыннан чыгып хөкем йөртә икән. «Юллар, юллар...» исә шактый йомшак, җиңел кулдан, ияреп язылган әсәр. Заманында ул, җитди кимчелекләре өчен, тәнкыйть тә ителгән иде. Нинди ниятләрдән чыгып нәшрият аны рус телендә бастырды икән? Тагы шунысы да кызыклы. Тәрҗемә иткәндә егерме табаклы бу роман биш-алты табак күләмендәге повестька әйләнгән. Калганы, җилгә тоткан җим кебек, кибәккә очып беткән. Менә дигән шәп әсәрләр була торып, йомшак яки урта кул әсәрләрне тартып-сузып рус теленә тәрҗемә итү һич аңлашылмый.

Һәм, ниһаять, башкалар белән чагыштырганда, күбрәк яшь һәм башлап язучы авторларның китаплары рецензияләнми кала. Тәнкыйтьнең яшьләр иҗатына аерата игътибарлы булырга тиешлеге турында сөйләп тормыйм, ул кадәресе һәркемгә мәгълүм...

Безнең тәнкыйть әдәбият кырындагы шушы ак тапларны бетерергә сәләтлеме?

Татарстан язучылар союзы каршындагы тәнкыйть секциясендә утыздан артык кеше исәпләнә. Шуларның яртысы — Язучылар союзы членнары. Әгәр тәнкыйть секциясенең һәр члены елга 3—4 рецензия генә язса да, яңа китапларга бәя биреп бару эше тулысынча хәл ителә, дигән сүз. Өстәвенә, рецензияләрне язучылар үзләре, журналистлар, әдәбият укытучылары һәм гади укучылар да яза бит әле. Бер карaганда, бик гади кебек: яңа чыккан китапларны үзара бүлешергә дә һәр китапка рецензия биреп барырга. Безнең тәнкыйтьчеләргә мондый тәкъдимнәр бер генә мәртәбә ясалмады. Моны практик яктан тормышка ашырып карарга тырышучылар да булды. Хәлбуки, әлегә аларның берсе дә әллә ни уңышка китергәне юк.

Беренче карашка гади тоелса да, мәсьәлә алай җиңел хәл ителә алмый. Иң элек, яңа китапларны вакытында рецензияләп бару эше, тәнкыйтьчеләрдән дә бигрәк, матбугат органнарына бәйле. Кызганычка каршы, безнең газета-журналлар тәнкыйть фикеренең әһәмиятен һәм ролен бөтен тирәнлеге белән аңлап җиткермиләр кебек. Бу эш күпчелек очракта үз агымына куела. Китап басылып чыгып тәнкыйтьче кулына эләккәнче шактый вакыт уза. Ә бит нәшриятның планнары ким дигәндә бер ел алдан билгеле була. Шуннан чыгып, рецензияләрне дә алдан планлаштырырга, китаплар белән басылган вакытта ук танышa торырга булыр иде. Кыскасы, оештыру эшләрен юлга салганда, тәнкыйтьнең колач киңлеге дә, оперативлык дәрәҗәсе дә шактый арта төшәр иде. Объектив сәбәпләрдән тыш, субъектив характердагылары да бар. Әгәр без тәнкыйтьне әдәби иҗатның бер төре дип таныйбыз икән, шуны истән чыгармаска тиешбез: прозаик яки шагыйрьнең үзен аеруча дулкынландырган, уй-хисләрен ныграк кузгаткан нәрсәләр хакында язарга хакы булган кебек, тәнкыйтьче дә ни кушсалар шуны гына эшләп йөри алмый, аның да сайларга, кирәк икән дәшми калырга да хакы бар. Бер мисал китереп узыйм. Күптән түгел яшь прозаик Мәгъсүм Хәбибуллинның «Кискеч җыры» исемле китабын кулга алдым. Иң изге ниятләр белән, нинди дә булса фикер әйтү нияте белән укый башладым. Әмма кечкенә генә китапны көч-хәл белән, үз-үземне мәҗбүр итеп кенә укып чыктым. Нәрсә язасың аның турында?.. Автор актуаль темага тотынган, әсәр бүгенге эшчеләр тормышына багышланган (сүз уңаенда әйткәндә, шуның аркасында гына ул дөнья күргән дә, күрәсең). Әмма сәнгатьчә эшләнеш ягыннан ул зәгыйфь, йомшак, схематик һәм сүлпән әсәр. Шушы фикерне әйтү өчен генә тәнкыйть мәкаләсе язып тору кирәкме икән?..[1]

---

[1] Хәер, М. Хәбибуллинның китабына рецензия шулай да чыкты («Социалистик Татарстан» газетасы. 1971 ел. 1 декабрь саны). Рецензент Д. Зөбәерова газета хезмәткәренең әдәби әсәр язу эшенә алынуын уңай факт буларак билгеләп үтә, повестьның темасын, күтәргән мәсьәләләрен мактый. Рецензиянең күп өлеше әсәрдәге кимчелекләрне санауга (ышандыру көче җитмәү, схематизм, иллюстрациячелек һ. б.) багышланган.

Мин, чын күңелдән тырышып, әсәрнең уңышлы якларын, яшь авторның үзенчәлекле сыйфатларын эзләп карадым. Әмма тапмадым. Шул ук вакытта аның повесте кычкырып торган халтура, кемгәдер сукырларча ияру дә түгел. Автор иң өстә яткан сюжет алымнарын файдалана, аның иҗади хыялы тапталып беткән гадәти эздән бара. һәм шул аның повестен йөзләрчә башка әсәрләр белән бер төсле итә (ихтимал, автор ул китапларның байтагын бөтенләй укымагандыр да). Повесть тәнкыйть фикере үзәнлык материал бирми. Ул, безнең әдәби процесс факты булудан бигрәк, авторның шәхси биографиясендәге бер вакыйга булып калган.

Үз тәҗрибәм буенча беләм, әсәр нәрсәсе беләндер сине кузгатып җибәрсә генә, синдә соклану яки, киресенчә, ачу хисе уята алса гына, әгәр ул автор белән нәрсә хакында да булса бәхәсләшү, анда күтәрелгән мәсьәләләр буенча фикер алышу теләге уятса гына — яхшы рецензия языла. Башка жанрларда эшләүчеләрдән аермалы буларак, тәнкыйтьченең төп материалы чынбарлык үзе түгел, аның әдип хыялында эретелгән, язучы аңы аша узган образлы күренешләре генә. Шуңа күрә тәнкыйтьче язган рецензиянең тирәнлеге һәм яңгырашы күп кенә дәрәҗәдә тикшерү объекты итеп алынган китапның идея-сәнгатьчә көченә дә бәйле.

Шуңа күрә тәнкыйтьчедән дөньяга чыккан һәр китапка рецензия таләп итү талымсызлыкка гына китерергә мөмкин. Хәтта иң усал рецензияләр дә китапка укучының игътибарын көчәйтә (күп кенә очракларда шома, уңай рецензияләрдән дә ныграк), ә бит һәр китап та андый гомуми игътибарга лаек булмый.

Безнең матбугат битләрендә берничә ел буе Н. Фәттах, Ә. Баянов, А. Гыйләҗев кебек урта буын прозаикларның повесть-романнары турында бәхәс барды. Алар адресына күпме усал сүз, күпме тәнкыйть фикере әйтелде. Ул кадәр сүзне кайбер талантсыз язучы гомер буена да ишетмәскә мөмкин. Әмма, минем уемча, бу нәтиҗәле тәнкыйть булды, хәтта әлеге авторлар өчен, кайбер урта кул китапларга карата чыккан берни дә бирмәслек рецензияләргә караганда, мактаулы тәнкыйть булды. Чөнки бу прозаиклар иҗатында бәхәсләшерлек, сүз алып барырлык әйбер бар иде.

Үзеннән-үзе шундый нәтиҗә сорала: әгәр тәнкыйть теге яки бу әсәр хакында дәшми кала икән, моның өчен тәнкыйтьчеләрне генә гаепләргә ашыкмаска кирәк.

### ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРГӘ РЕКЛАМА КИРӘКМЕ!

Берьяктан, яңа чыккан китапларны мөмкин хәтле тулы иңләргә кирәк, икенче яктан, тәнкыйтьче үзе теләгән әсәрне сайларга, хәтта дәшми калырга да хаклы, дибез. Бер-берсе белән сыеша алмаслык бу принципларны ничек бергә бәйләргә соң? Миңа калса, моннан чыгу юлы бар һәм ул күптән билгеле: яңа китапларны аннотацияләү эшен яхшыртырга кирәк. Бер генә матбугат органының да барлык китапларга рецензия урнаштырып барырга хәленнән килми, күпчелек очракларда аннотация белән канәгатьләнергә мәҗбүр була. һәм ул практикада шулай эшләнеп килинә дә. Әйткәнемчә, 1970 елда барлыгы 61 рецензия басылган. Тикшерә башлагач, шуларның 23 е аннотация булудан артмаган. «Казан утлары» журналының 1971 елгы унике санында эреле-ваклы 49 рецензия басылган. Ныклап тикшерә башласаң, шуларның кимендә 35 е аннотация булудан узмый. «Казан утлары» журналының тәнкыйть бүлегенә: «Бәләкәй рецензияләрне нигә имзасыз чыгарасыз?» — дип күп тапкырлар әйтелде. Чыннан да, укучы өчен рецензиянең эчтәлеге генә җитми, аның кем тарафыннан язылуы да бик мөһим. Кешесенә карап, фикернең кыйммәте һәм бәясе төрлечә була. Әмма, библиографик тасвирламаның бер төре буларак, аннотация имза куерсәтүгә мохтаҗ түгел, аның төп бурычы — яңа чыккан китап турында хәбәр итү, әсәрнең эчтәлеге һәм иң мөһим үзенчәлекләре белән таныштыру. Бездә алар еш кына буталып йөртелә.

Аннотация белән рецензия никадәр генә якын күренмәсеннәр, алар арасында күләм ягыннан гына түгел (гадәттә, аннотация бик кыска була), сыйфат ягыннан да аерма зур. Рецензия (һәм әдәби тәнкыйть үзе) теге яки бу әдәби күренешне аңлау, аны бәяләү өстенлек алган төстә башлана. Сүз примитив формадагы бәя турында

түгел, ә киңрәк мәгънәдәге бәя, идея-эстетик бәя хакында бара, билгеле. Сәнгать әсәрен В. Г. Белинский аңлаткан мәгънәдә бәяләү ул аңа тиешле балл кую, әсәрнең аерым уңышларын һәм кимчелекле якларын билгеләү һәм мактауның теге яки бу дәрәҗәсен («талантлы», «күренекле», «гениаль» һ. б.) куллану гына түгел. Барыннан да бигрәк, бу сәнгать әсәрен аның идея һәм образлар бирлегендә тикшерү, аның әдәбиятка нинди яңалык алып килүен, социаль тормышның нинди якларын яктыртуын ачыклау һәм, шул рәвешчә, аның гомуми әдәби процесстагы урынын билгеләү дигән сүз. Нәкъ менә шушы нәрсә икесе ике жанрга гына түгел, әгәр шулай әйтергә ярый, икесе ике өлкәгә: берсе — библиографиягә, икенчесе әдәби тәнкыйтькә караган аннотация белән рецензия арасында чик булып тора да.

Мин һич кенә дә аннотациянең ролен һәм әһәмиятен киметергә теләмим. Ул — бик мөһим һәм кирәкле жанр. Әгәр танылган язучылар яки тәнкыйтьчеләр аннотация язарга алына икән, монда гарьләнерлек берни дә юк. Башка һәр жанрныкы кебек, аның да үз кыенлыклары һәм серле яклары бар. Алай гына да түгел, мин, дөньяга чыккан бер генә китап та аннотациясез калмаска тиеш, дигән карашта торам. Шунда, ниһаять, безнең тәнкыйтьчеләрне гаепләргә урын калмас, ә иң мөһиме укучы яңа чыккан һәр китап турында вакытында информация ала барыр, иксез-чиксез китап диңгезендә җиңелрәк «йөзә» һәм үзенә ошаган, үз зәвыгына туры килгән китапны җиңелрәк таба алыр иде.

Бәла газета-журнал битләрендә бөләкәй рецензия дигән баш астында гадәти (яки аз-маз лирика кушылган) аннотацияләр чыгып килүдә генә түгел, ә жанрларның буталуында. Ә бу еш кына шуңа китерә, болай да бәләкәй язмасының 2—3 абзацында аннотация язучы китапка (еш кына бөтен бер романга) соңгы хөкемне чыгарырга маташа. Әмма, конкрет анализ белән ныгытылмаганга күрә, ул хөкем һавада эленеп кала. Мактау сүзләре дежур комплимент булып, ә тәнкыйть сүзләре дәлилсез һәм тупас сүгенү булып яңгырый. Һәм, киресенчә, рецензия исеме астында басылган әйберләрнең күбесе, тикшерә башлагач, гадәти аннотация булып чыга.

Шулай бер вакыт, яңа китабына матбугатта рецензия чыккач, бер язучы белән сөйләшеп тордык. Рецензия төссез, кызыксыз, шаблон тел белән язылган иде. Башта эчтәлек сөйләп чыгыла, аннан әсәрдәге проблемалар турында берничә сүз әйтелә, бер-ике вак кимчелеге күрсәтелә дә, рецензия һәрвакыттагыча «шуңа да карамастан» дигән омтимистик сүзләр белән тәмамлана. Шулай да язучы канәгать иде: беренчедән, рецензия «уңай» характерда, ә матбугат сүзенең җәмәгатьчелек фикере тудыру һәм китапның киләчәк язмышы өчен нихәтле мөһим булуын язучы үз тәҗрибәсе буенча яхшы белә. Беркемгә дә сер түгел, кайбер нәшрият әһелләре, үз зәвыкларына караганда, матбугат сүзенә ныграк ышаналар. Икенчедән, рецензия, аныңча, ахыр чиктә укучыларда кызыксыну уятачак, җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итәчәк, үзенә күрә реклама ролен үтәячәк.

Миңа калса, биредә без күп кенә рецензияләрнең сүлпән, аз канлы булуын китереп чыгарган тагын бер сәбәпкә — рекламага йөз тотуга якынлашабыз. Матур әдәбият әсәрләренә реклама кирәкме? Әгәр алар шуңа лаек икән, кинофильмнарга, концертларга, спектакльләргә кирәк булган кебек үк, һичшиксез, кирәк. Әмма шул ук вакытта, минем уемча, реклама һич кенә дә әдәби тәнкыйтьнең бурычына керми. Рекламаның иң яхшы формасы — үз вакытында ясалган объектив информация. Нәкъ менә аннотация тиешле информация бирергә, укучының игътибарын җәлеп итәргә, аны кызыксындырырга тиеш. Сүз дә юк, акыллы һәм тирән язылган рецензия (ул хәтта тискәре характерда булса да) үзенә күрә реклама ролен үти, ләкин бу рецензентның төп максаты түгел.

## НӘРСӘ УЛ «КОМПЛИМЕНТАРЛЫК»?

Безнең рецензияләрнең аннотация характерында булуы һәм, теләпме-теләмичәме, рекламага йөз тоту әдәби тәнкыйтьтә тагын бер авыру китереп чыгарды. Исеме — комплиментарлык. Кайчандыр, кем тарафыннандыр әйтелгән шушы сүз бик тиз таралып китте һәм ул тәнкыйтьнең бүгенге хәленә карата ифрат туры килә. Сүз та-

ләр тәнкыйте хакында гына бармый. Бу бөтен тәнкыйтькә хас кимчелек. 1971 елгы 61 рецензия арасында мин бер генә тискәре рецензия дә очратмадым. «Казан утлары» журналының 1971 елгы саннарында басылганнар арасында да тискәреләре очрамый диярлек. Аларга карап, безнең әдәбиятта тулы иминлек һәм тәртип хөкем сөрә, бөтенесе җитеш, бер генә кимчелек тә юк икән, дип уйларга мөмкин. Ләкин чынлыкта мәсьәлә ул кадәр үк шәп түгел.

Фикеребезне бер-ике мисал белән беркетик. Кайчандыр Сафа Сабировның яраткан үз темасы бар иде, ул елгачылар, аларның тормышы һәм хезмәте турында язып килде. Бу теманы ул белә һәм ярата иде, чөнки үзе озак еллар елга пароходларында йөзгән кеше. Аның беренче хикәя һәм очерклары үзләренең яңалыклары, тормышчанлык көче һәм детальләр төгәллеге белән аерылып торалар иде. Әмма, тәнкыйтьнең йомшаклыгыннан файдаланып, автор бер-бер артлы китап чыгару кәсебенә кереште. Бу үз чиратында язучының иҗади яктан бер урында таптануына гына түгел, хәтта артка китүенә китерде. Шуңа да карамастан, С. Сабиров чын мәгънәсендә принципиаль, таләпчән тәнкыйть сүзе ишетмәде. Киресенчә, тәнкыйть күбесенчә аның башыннан гына сыйпап килде.

Кайвакытта башкача да була. Тәнкыйтьчеләр әсәрне тетеп ташлый. Съезд хәтле съезд трибунасыннан язучының талымсыз һәм сәләтсез булуы турында сөйләнә. Шуңа да карамастан, әлеге язучыбыз китап арты китап чыгарып тора. К. Фәсәхов белән, мәсәлән, шундыйрак хәл килеп чыкты. Шагыйрьләр поэзия секциясенең К. Фәсәхов иҗатын тикшерүгә багышланган утырышын яхшы хәтерлиләрдер. Ул чагында усал һәм туры, мин әйтер идем, чын мәгънәсендә принципиаль сөйләшү булды. Чыгыш ясаучылар турыдан-туры: «Фәсәхов әсәрләре чын поэзиядән ерак тора, аларда талантсызлык примитив мещанлык белән чикләнә», дип әйттеләр. Бу сөер хәл бик җиңел аңлашыла. Әлбәттә, автор зур урында утырмаса (ул чагында К. Фәсәхов нәшриятта баш редакторның урынбасары булып эшли иде), аның әсәрләренең байтагы дөнья күрә алмаган булыр иде.

Тәнкыйтьнең йомшаклыгыннан файдалану шул дәрәҗәгә җитте, кайбер тәҗрибәле язучылар сүз сыйрдай рецензентны үзләре эзләп табалар һәм китапларына фикер әйтүне үзләре теләгән рухта оештыралар. Ә соңыннан матбугат аша бер әйтелгән фикерне үзгәртү ярыйсы ук кыен була.

Шулай да гаделлек өчен әйтергә кирәк: бездә теге яки бу әсәр уңае белән язылган кискен, принципиаль тәнкыйть мәкаләләре бөтенләй булмады түгел. Ләкин андыйлар шул хәтле аз, ул мәкаләләрнең һәркайсы, гадәттән тыш вакыйга буларак, хәтердә калган. Мин И. Нуруллин, М. Мәһдиев, А. Яхин, Ф. Хөснилэрнең усал, үткен мәкаләләрен күздә тотам. Әгәр уңай рецензиянең теләсә ниндие, хәтта иң йомшагы иң гарип язылганы да күбесенчә шома узса, тискәре рецензия, кагыйдә буларак, авторның үзенә дә, аны чыгарган матбугат органына да күп мәшәкатьләр алып килә. Шуңа да редакцияләр тискәре рецензияләрне теләмичә басалар, баскан очракта да бик нык шомартып, матурлап, авторның үзе белән алдан килешеп чыгаралар. Андый рецензия дөньяга чыккач аптырап каласың: автор яхшы китапның аерым кимчелекләре турында язамы, әллә начар әсәрнең кайбер уңышлы якларын күрсәтәме? һич аңларлык булмый.

В. Г. Белинский «Әдәби хыяллар» исемле мәкаләсендә болай язган иде:

«Һәммәсе дә тыныч-имин генә булса, һәр җирдә игагатьлек һәм мактау сүзләре генә яңгыраса, ул чагында намуссызлыкка, шарлатанлыкка, кабахәтлеккә никадәр киң мәйдан ачыла, чөнки фаш итүче, кырыс хаклык сүзен әйтүче юк!»

Кызганычка каршы, без тәнкыйтьчеләр күбрәк тыныч яшәргә тырышабыз, әллә автор белән мөнәсәбәтләрне бозасы килми инде, әллә башка сәбәпләре бар. Әйе, авторны аңларга була. Үз әсәре өстендә эшләүгә ул ничә еллар гомерен биргән, күпме йокысыз төннәр уздырган. Зур көч куеп эшләгән хезмәтең турында тискәре фикер ишетү авыр, билгеле. Үз тәҗрибәм буенча беләм, тискәре рецензиягә карағанда, мактап язу күп тапкыр күңеллерәк. Әмма әдәбиятның үсүен чыннан да телибез икән, моны усал, принципиаль, таләпчән тәнкыйтьтән башка эшли алмаячакбыз. Билгеле, тәнкыйть итү белән кирәгеннән тыш мавыгу, артык тупаслык, юри күпертү дә ярамый. Партия безне сәнгать байлыкларын тудыручыларга карата игътибарлы булырга чакыра. Һич кимчелекләргә күз йоммыйча, объективлыкка хыянәт итмиләр

чә генә. М. Горький, әдәбият өлкәсенә таза нервлы кешеләр килергә тиеш, дигән. Ак куллы кешеләргә әдәбият тирәсендә эш юк.

Шундый хәлне күз алдына китерик. Характеры йомшак булгангамы, әллә автор белән мөнәсәбәтен бозарга теләмичәме, тәнкыйтьче күренеп торган йомшак әсәрне мактап чыкты, ди. Моның белән ул дус язучысының күңелен күреп кенә калмый, ә күп меңләрчә укучыларны да аптырашта калдыра. Телисеңме-юкмы, алар нәкъ шулай язарга кирәк икән дип, бу әсәрдән үрнәк алырга мөмкин икән дип уйлаячаклар. Бу шулай ук яшь һәм башлап язучы авторларны ялгыш юлга кертәчәк. Тәнкыйтьне хаклы рәвештә давыллы китап диңгезендәге лоцманга тиңләгән нәшрият, газета-журнал кешеләре дә әнә шундыйрак язмаларга юнәлеш тота башлыйлар, башкаларын, әлеге калыпка туры килмәстәйләрен, хәтта талантлы язылган булсалар да, уздырмыйлар. Хәтта әсәренең йомшак якларын әйбәт белүенә карамастан, автор үзе дә, болай язсаң да ярый икән, дигән фикер белән килешә башлый. Билгеле, мин буяуларны куертыбрак җибәрдем. Бер рецензия, бер тәнкыйтьченең ялгышы гына мондый ук куркыныч тудыра алмый алуын. Әмма бөтен тәнкыйть бергә тотынса, моны эшләргә мөмкин. Менә ни өчен без тәнкыйтьнең ролен күтәрү, аның әдәбият һәм җәмгыять каршында җаваплылыгын үстерү турында кайгырытабыз да.

Әгәр соңгы ике-өч ел эчендә матбугатта чыккан рецензияләрне рәттән укый башласаң, критерийларның анык булмавы, фикерләрнең бер төрлелеге күзгә аеруча нык ташлана. Һәр китапта, аның иң талантлы язылганында да, аерым кимчелекләр табарга мөмкин. һәм, киресенчә, начар, алама эшләнгән китапта да теләгәндә нинди дер уңышлы якларны табарга була. Әгәр рецензент этикет саклау, автор белән әйбәт мөнәсәбәтләрне саклау турында гына кайгырта икән, ул чагында начар китап белән яхшы китап арасындагы чикләр бөтенләй югалачак.

Билгеле, бөтенесен дә бер чыбыктан сөрергә ярамый. Бездә әдәбиятның үзенчәлеген аңларлык, һәр яңа әсәрнең әдәбиятка нинди яңалык алып килүен дөрес чамаларлык, шуны аңлатып бирерлек, укучыга авторның катлаулы образлар системасын аңларга ярдәм итәрлек сәләтле тәнкыйтьчеләр дә бар. Узган 1971 елда басылып чыккан рецензияләр арасыннан минем үземә М. Мәһдиевнең «Чишелеш нульгә бетми» («Казан утлары» журналы. 1971 ел. 7 сан.) исемле рецензиясе аеруча ошады. Акыллы, объектив, гадел һәм таләпчән язылган рецензия. Рецензент А. Ганиев иҗатының көчле якларын да, кимчелекләрен дә дөрес күрсәтә, аның иҗаты хакында дөрес булмаган караш әйтүче кешеләр белән дә урынлы бәхәсләшә. Ф. Миннуллинның яшь прозаиклардан М. Маликова, Р. Кәрамиев иҗатларына багышланган рецензияләре үзләренең пафослары, логикалы фикерләре һәм эстетик тыгызлыклары белән аерылып торалар. Ш. Әхмәдуллинның Р. Харисов һәм Э. Мөэминоваларның шигъри җыентыкларына карата язылган рецензияләрендә дә авторның үз йөзе, аның әдәбиятка керткән өлеше турында конкрет, төпле фикер әйтелә. Шундый рецензияләрдән башка әдәби организмның нормаль яшәвен һәм үсүен күз алдына китерүе дә кыен.

## ТӘНКЫЙТЬ ҺӘМ СӘНГАТЬЧӘ ЭЗЛӘНҮ

Узган ел мин Балтик буе тәнкыйтьчеләренең Ригада уздырылган региональ киңәшмәсендә катнаштым. Анда, башка күп мәсьәләләр белән бергә, тәнкыйтьнең сәнгатьчә эзләнү процессында катнашуы хакында да сүз булды. Соңгы елларда Балтик буе әдәбиятларында эчке монологка корылган роман формасы зур үсеш алган. Киңәшмәдә катнашучылар бу жанрның үсеш мөмкинлекләре һәм бу өлкәдәге аерым кимчелекләр турында сөйләделәр. Байтак тәнкыйтьчеләрнең чыгышы әдәбияттагы интеллектуализм мәсьәләләренә багышланган иде.

Шул чыгышларны тыңлаганда, мин үзебезнең татар әдәбияты турында уйланып утырдым. Без алардан шактый артта барабыз икән. Безнең роман, повестьларны эстон, бигрәк тә литва язучыларының әсәрләре белән чагыштыра башласаң, безнең романнарның күп сүзле, озын булуын тагын да ачыграк сизәсең, безнең язучыларның пөхтә һәм динамик композиция төзи белмәүләре, сәнгатьчә сурәтләү чараларының

ярлылыгы тагын да ныграк күзгә ташлана. А. Гыйләҗевның «Урамнар артында яшел болын» романын, мәсәлән, Миколас Слуцкисның «Ашкыну» («Жажда») исемле романы белән янәшә куеп карау кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирер иде. Һәр ике роман бүгенге заманга багышланган, икесенең дә төп геройлары — журналистлар. Тематик уртаклык та бар. Ләкин Слуцкис романы бөтенсоюз күләмендә яңгырый алды. А. Гыйләҗев әсәре исә шундый ук киң яңгыраш ала алмады. Моның сере нәрсәдә? Безгә, тәнкыйтьчеләргә, уйлап, чагыштырып карау өчен бик җитди һәм гыйбрәтле мәсьәлә бу.

Кызганычка каршы, безнең тәнкыйть язучыларның яңалык эзләү өлкәсендәге адымнарын тиешенчә хупламый, ирешелгәннәр белән килешү, канәгатьләнү ягындарак тора. Хәлбуки, даими һәм киеренке тестә иҗади эзләнүләрдән башка әдәбият үсә алмый. Әдәби иҗат эше агымга каршы йөзү белән бер, аз гына туктадыңмы, ул сине артка, түбәнгә алып китәчәк. Партиянең XXIV съездында Л. И. Брежнев, партия безнең художникларның социалистик реализм методына таянып алып барган эзләнүләрен хуплый, ул форма һәм стиль төрлелегенә зур әһәмият бирә, диде.

Бу яктан безнең поэзиянең эшләре әйбәтрәк хәлдә. Минем уемча, безнең шагыйрьләр, аеруча яшьләр, прозаикларга караганда, яңа алымнарны активрак эзлиләр, уйлау рәвешләре буенча заманчарак, үзенчәлеклерәк һәм интеллектуальрәк күренәләр. Берничә еллар элек поэзиядәге традиция һәм новаторлык мәсьәләләре турында кайнар бәхәсләр булып алды. Үкенечкә каршы, сүз күбрәк бер мәсьәлә тирәсендә барды: татар поэзиясендә ак яки ирекле шигырь яшәргә хаклымы, юкмы? Берәүләр яңача язарга омтылыш ясаган һәр шагыйрьне үтереп мактадылар. Икенчеләре исә, киресенчә, аларны бөтенләй кире кактылар. Хәзер бәхәс сүрелдә һәм бик гади хакыйкать ачыкланды: эш формада түгел, ә эчтәлектә икән. Үтә заманча стильдә дә баналь һәм тупас шигырьләр язарга, традицион калып белән дә үлемсез әсәрләр тудырырга мөмкин.

Шушы уңайдан минем тагын бер нәрсәгә — бездәге бәхәс алып бару культурасы турындагы мәсьәләгә тукталасым килә. Дөресен әйтик, без әле чын мәгънәсендә фәнни, матур итеп бәхәсләшә белмибез. Безнең бәхәс я чукраклар талашын хәтерләтә: һәркем үзенекен генә такрарлый, башкалар сүзен ишетми дә, колак та салмый. (Поэзиядә Тукай һәм Җәлил традицияләре турындагы бәхәс, мәсәлән, шулайрак барды.) Яки ничек булса да оппонентның шәхесен кимсетергә, аны мыскыллар-га тотына. Я булмаса, безнең бәхәсләр, утынсыз яндырылган учак кебек, кабынырга кабынмас сүнеп калалар. («Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә драматургиягә багышланган бәхәс шулай сүнде.) Күрәсең, әдәби бәхәсләр нәтиҗәле үтсен өчен, беренчедән, бәхәснең төп мәсьәләсен һәм темасын дөрес сайларга, икенчедән, оригиналь фикер йөртерлек катнашучылар тартырга, өченчедән, фикер алышуның барышын оста оештыра белергә кирәктер.

Яңа форма һәм алымнар эзләү тәнкыйтьчеләрнең үзләренә дә карый. Яшермик, безнең тәнкыйть (сүз бер татар тәнкыйте турында гына бармый, билгеле) жанр һәм стиль төрлелеге белән мактана алмый. Ниндидер шаблон, төссез-йөзсез рецензия калыбы формалашты: башта китапның уңай яклары саналып чыгыла, аннан кимчелекләре күрсәтелә, ахырдан омтимистик рухтагы гомуми нәтиҗә ясала. Бездәге күп рецензияләр, ахырларында төрле имзалар торуга карамастан, бер кул белән, шактый коры һәм артык сак, әллә ни кызыклы булмаган бер үк кеше тарафыннан язылган төслерәк тәэсир калдыралар. Еш кына тәнкыйтьчене нәрсә борчый һәм дулкынландыра икәнен, аның нәрсәгә йөрәге әрнүен чамалап булмый. Безнең күп кенә рецензия һәм тәнкыйть мәкаләләренә социаль яңгыраш, публицистик пафос, фикер ачыклыгы һәм форма тәгаллеге җитми. Ө бит салкын акыл, тупас тел белән язылган тәнкыйть мәкаләләренең ышандыру көче дә, тәэсир көче дә әллә ни зур булмый. Ирекле формада, укылган әсәр турында уйлану төсендә язылган рецензияләр, рецензия-фельетоннар (соңгысы 30 нчы елларда шактый актив булган), полемик рецензияләр, әдәби портрет рәвешендә язылган рецензияләр бөтенләй очрамый диярлек. Күрәсең, безгә үзебезнең тәнкыйть арсеналын төрләндерү һәм баету турында җитдирәк уйланырга кирәктәр.

Бүгенге татар тәнкыйтендәге иң кыен мәсьәләләрнең берсе — методология мәсьәләсе. Билгеле булганча, марксистик-ленинчыл тәнкыйтьнең иң көчле коралы — социаль-эстетик анализ. Без исә бу корал белән һаман тиешенчә эш итә белмибез. Әдәби әсәр еш кына эчтәлеге һәм анда күтәрелгән социаль мәсьәләләр ягыннан гына, я форма җәһәтеннән генә анализлана. Иң яхшы дигән очракта да безнең тәнкыйть әдәби күренешләргә бәя бирергә мөмкин, ләкин ул тормышка үтә кыюсыз керә, чынбарлыкны аның революцион үсешендә тикшерергә омтылыш ясамый. Әйтик, Һ. Мәхмүтовның «Казан утлары» журналының 1971 елгы 2 санында басылган «Сәет Шәкүров драмалары» исемле мәкаләсе беренче карашка шактый тирән һәм төпле язылган төсле. Ләкин автор драматургия материалы белән генә чикләнә, бу драмаларда чагылган чынбарлыкның үзенә мөрәҗәгать итми. Ә шундый янәшә куеп карауларның мәкалә авторына файдасы тими калмас иде, ул Шәкүров пьесаларындагы аерым ситуацияләрнең уйлап чыгарылган булуын, кайбер образ һәм положениеләрнең әсәрдән-әсәргә күчеп йөрүләрен күрер иде.

Безнең тәнкыйтьтә язучыларның иҗат портретлары бөтенләй югалды диярлек. Алар урынын төче телле юбилей мәкаләләре ала бара (шунысын әйтергә кирәк, чын тәнкыйть мәкаләләреннән аермалы буларак, юбилей материаллары «Казан утлары»ның һәр санында басыла, кайбер саннарда хәтта берьюлы 3—4 юбилей мәкаләсе чыга). Проблемалы мәкаләләр урынын артык тирән булмаган, еллык күзәтү характерында язылган докладлар ала бара. Н. Дәүлинең 1970 елгы поэзиягә багышланган «Бизәк өчен түгел, кирәк өчен» исемле мәкаләсе, мәсәлән, шуның бер үрнәге. Болай мәкалә пафос, сугышчан рух белән язылган, 1970 ел поэзиясен шактый киң иңли. Ләкин мәкаләгә тирәнлек һәм дәлил көче җитми.

Кызганычка каршы, бездә, анализлы тәнкыйтькә караганда, билге, бәя куя торган тәнкыйть өстенлек итә. Бу исә тәнкыйтьнең йогынты ясау колачын тарайта, аның хәрәкәт көче язучылар, әдәби даирәләр белән чикләнә.

## ЯЗУЧЫ ТӘНКЫЙТЬЧЕ РОЛЕНДӘ

Шушы мәкаләне язарга җыенганда мин байтак язучылардан: «Соңгы еллардагы нинди тәнкыйть мәкаләсе һәм рецензияләр исегездә калган? Кай ягы белән исегездә калган?» — дип сорадым. Җаваплар төрлечә булды. Шулай да мин сөйләшкән кешеләрнең күбесе танылган прозаик Фатих Хөсни исемен атады. Аның «Социалистик Татарстан» газетасында басылган «Талантлар һәм ияреп йөрүчеләр», «Шунда, тын елга буенда» исемле мәкаләләре, моннан берничә еллар элек «Казан утлары» журналында чыккан «Кайда сез, олы язмышлар?» дигән мәкаләсе күпләрнең хәтеренә уелып калган. Ф. Хөснинең мәкалә һәм рецензияләре кайнар рух, күтәргән идеяләре, гаҗәеп шәп, җырлап торган теле белән аерылып торалар. Аларны хәтта безне, тәнкыйтьчеләрне, гаепләү өчен үрнәк итеп тә китерәләр: янәсе, үзе тәнкыйтьче дә түгел, ә кайбер тәнкыйтьчеләргә караганда шәбрәк яза. Андый кешеләргә мин болайрак дип җавап бирер идем: әгәр тәнкыйтьче шигырь, пьеса яки роман яза икән, аның язганнары хакында тәнкыйтьче итеп карап түгел, ә шагыйрь, драматург яки прозаикка куела торган таләпләрдән чыгып хөкем йөртергә кирәк. Тәнкыйть мәкаләсе язарга алынган шагыйрь яки прозаик турында да шул ук сүзләрне кабатларга мөмкин. Әйтик, Сибгать Хәким, шигырьләре кебек үк, гаять эмоциональ, үткен һәм шигъри яңгырашлы мәкаләләр язып килә. Әмма алар, барыннан да бигрәк, тәнкыйть мәкаләләре, алар бездәге тәнкыйть фикерен үстерәләр. Күптән түгел китап кибетләренә М. Әмирнең «Үзебез турында» исемле әдәби-тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы чыкты. Аларны рәттән укыганда безнең күз алдыннан соңгы ун ел эчендәге әдәби хәрәкәт уза. Аерым мәсьәләләр буенча М. Әмир белән килешмәскә, нинди дер мәсьәләләр хакында бәхәсләшергә мөмкин, әмма бер нәрсә бәхәссез: күренекле прозаик Мирсәй Әмир соңгы елларда әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә актив һәм нәтиҗәле эшләгән, әдәбияттагы сәламәт һәм тормышчан башлангычларны үстерү, социалистик реализм принципларының сафлыгы һәм нык лыгы өчен көрәшкән.

Шагыйрь Равил Фәйзуллинның Гамил Афзал иҗаты турындагы мәкаләсе дә күпләрнең хәтерендә. Күп кенә юбилей мәкаләләреннән аермалы буларак, автор шагыйрьнең кабатланмас иҗат йөзен, Г. Афзал шигырьләренең аерылып торган сыйфатларын ачарга тырыша. Шәйхи Маннурның бүгенге поэзия мәсьәләләренә багышланган мәкаләсен шулай ук мактап телгә алалар. Әдәби тәнкыйть мәкаләсе чыгарган һәр язучы тәнкыйтьче буларак чыгыш ясый, шуңа күрә: «Ул бит профессиональ тәнкыйтьче түгел, аннан нәрсә көтәсең»,— дип сөйләнүләр урынсыз. Ә бездә андый хәлләр булгалап тора.

Берничә ел элек «Казан утлары» журналы «Шагыйрь турында — шагыйрь» исемле яңа рубрика керткән иде. Иң изге нияtләр белән, әлбәттә. Шагыйрь үз иптәшенең китабын, теләсә кемгә караганда да, нечкәрәк, яхшырак бәяли, аның иҗат лабораториясенә керә ала, яңа поэтик күренеш турында укучыларга әйбәтрәк аңлата ала. Узган ел, мәсәлән, бу рубрика астында М. Садриның ике чыгышы басылган. Беренчесе күлне вәгъдә итәрлек зур исем белән чыккан: «Нури Арсланов портретына берничә сызма» («Казан утлары» журналы. 1971 ел. 3 сан). Әмма, кызганычка каршы, автор Нури Арсланов иҗатына хас тәп үзенчәлекләрне түгел, хәтта аның әсәрләренең, һич югы, кайбер үзенчәлекләрен генә дә ача алмаган. Бу кызыклы шагыйрь әсәрләрен күзәтеп баручылар ышаныйрлар: соңгы елларда Н. Арсланов үз иҗатында көтелмәгән сикереш ясады. Ул электән үк югары культуралы, әдәби телгә сизгер, аның белән сак эш итә белүче шагыйрь иде. Әмма аның шигырьләренә чын кайнарлык, колач киңлеге һәм рух күтәренкелеге җитенкерәми иде. Соңгы елларда иҗат иткән шигырьләре Нури Арслановны татар поэзиясенең беренче сафына чыгарды. Аның бүгенге шигырьләре югары гражданлык пафосы, фикер һәм хис тирәнлеге, ниндидер эчке хөрлек һәм иркенлек белән аерылып торалар. Җыйнап кына әйткәндә, соңгы елларда Н. Арсланов шигърияtенә шарык акылы өстәлде. М. Садри мәкаләсендә әнә шул яңалыкны, сыйфат сикерешен, соңгы елларда шагыйрь иҗаты нинди үзенчәлекләр белән баюын ачарга хәтта омтылыш та юк. Шагыйрьнең иҗат йөзе турында ул, мәсәлән, мондыйрак җөмләләр белән сөйли:

«Берничә ел буена күп көч салып, шагыйрь «Егет яуда сыналыр» дигән эпик әсәр язды... Ул иҗатында искиткеч активлык күрсәтә... Шагыйрьнең тәрҗемә өлкәсендә дә күп эшләвен әйтергә кирәк... Утыз ел буена дәүләт эшендә эшләп, утыз ел буена иҗатыңны актив дәвам иттерү — бу үзе бер батырлык» һ. б. Ләкин бит чын шигърияtнең кыйммәте шагыйрьнең күпме әсәр язуы, теге яки бу әсәр өстендә күпме эшләве белән билгеләнми. Биредә, башка теләсә кайсы өлкәгә караганда да, сыйфат, практик нәтиҗә мөһим. Шулай да була, шагыйрь бөтенләй көч куймый яңа әсәр яза, аның шул әсәре милли поэзиянең алтын фондына керергә мөмкин. Һәм киресенчә дә була, берәр чакрымнан тир исе аңкып торган озын поэмалар әдәбиятны берни белән дә баетмыйлар, алай гына да түгел, аңа зыян китерәләр.

Мәсьәләгә бу рәвешчә якын килү бер М. Садрига гына түгел, безнең күбебезгә хас. Кайчакта талант дәрәҗәсе буенча бик уртача, әмма күп яза торган шагыйрь китап арты китап чыгара. Башта тәнкыйть аңа игътибар итми, чөнки тегенең тиргәр җире дә, мактар урыны да юк. Еллар узә тора, моның юбилее килеп җитә. Язучылар союзы идарәсе түгәрәк датаны билгеләп узарга була, редакцияләргә тиешле кәгазьләр җибәрелә. Менә шул чак шагыйрьне «әдәбиятта күп эшләгәне», фәлән мең юл шигырь язганы өчен мактый башлыйбыз... М. Садриның икенче мәкаләсе Әдип Маликов иҗатына багышланган. Ул «Көчле ихтыяр җырчысы» дип атала («Казан утлары» журналы. 1971 ел. 7 сан). Бөтенләй башка пландагы, бөтенләй бүтән характердагы бу шагыйрь хакында да ул шул ук сүзләрне кабатлый диярлек.

Икенче бер өлкән язучы белән булган әңгәмә хәтергә төшә. Мин аңардан: «Нигә соңгы вакытларда тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләр язмыйсыз?»,— дип сорадым. «Беләсезме,— диде ул,— яшьлектә без һәммәбез дә бер-беребезнең әсәрләренә мәкалә һәм рецензияләр яза идек. Ул чагында тәнкыйтьчеләр аз иде, аларның безнең хакта язганнарын көтеп тора алмадык. Ошаганын мактадык, ошамаганын кайнарланып сүктек. Хәзер исә хәлләр үзгәрде. Тәнкыйтьчеләр буа буарлык. Барысы да диярлек кандидатлар, я докторлар. Тәнкыйтьнең методологиясе үсте, аның эстетик арсеналы баеды. Мондый шартларда,— дип тәмамлады ул сүзен,— мин яшь чактагы кебек җиңеллек белән тәнкыйть жанрына тотынырга җөрьәт итмим».

Минемчә, тәнкыйть мәкаләләре белән әдәби хәрәкәткә катнашудан баш тартып, ул дөрес эшләми. Ләкин аның сүзләрендә дөреслек тә бар. Күрәсең, биредә таләп ике яклы булырга тиеш: тәнкыйть мәкаләләре язарга алынган шагыйрь яки прозаиктан без фәнни тирәнлек һәм тәфсилле анализ таләп итәргә хаклы, алар, үз чиратында, тәнкыйтьчеләрдән тел һәм стиль төзеклеге һәм мавыктыргыч итеп яза белү таләп итәргә тиешләр. Шул таләпләрнең бергә кушылуында, синтезында мин әдәби тәнкыйть фикеренең уңышлы үсә алу юлын күрәм.

## ТӘНКЫЙТЬ ҺӘМ НӘШРИЯТ

Укучылар белән очрашу вакытында миңа шундый сорау бирделәр:

— Нәшриятта яки журналда нинди дә булса яңа әсәр басыла. Ахырдан берәр тәнкыйтьче тота да шуны пыран-заран китерә. Ничек аңларга моны? Башкача эшләп булмыймыни? Әйтик, алдан ук әсәрне әлеге тәнкыйтьченең үзенә яки башка берәүгә биреп укытырга, кимчелекләрен бергәләп төзәтергә. Шул чагында укучыларга да яхшырак булыр, тәнкыйтьчеләргә дә мәшәкатьләнәсе калмас иде...

Күпмедер дәрәҗәдә укучы, һичшиксез, хаклы: бездә, чыннан да, төссез, йомшак әсәрләр шактый күп чыга әле. Өлкән язучылар: «Утызынчы елларда яңа әсәр тәмамлаган кеше иң элек аны каләмдәш дуслары янына күтәреп килә иде»,— дип сөйлиләр. Яңа әсәр секция утырышларында гына тикшерелеп калмаган, идарә утырышларына да куелган. Хәзер секция утырышларында, кагыйдә буларак, яшь һәм башлап язучыларның гына әсәрләре тикшерелә, анда да нәшриятның тематик планына кертү өчен кирәк булганда гына. Идарә утырышларына турыдан-туры иҗат эшенә карамаган мәсьәләләр шул тикле күп куела, анда яңа кульязма уку түгел, укылган әйбер турысында сөйләшергә дә вакыт калмый.

Нәшриятта кульязмаларга эчке рецензия язу эше әле һаман тиешле югарылыкка куелмаган. Бернichә ел элек А. Яхинның «Начар китап ничек дөнья күрә?» исемле мәкаләсе чыккан иде. Анда ул нәшриятта чыга торган китапларга язылган рецензияләрнең түбән сыйфатлы булуларын бик дәлилле итеп ачкан иде. Аннан бирле хәлләр әллә ни үзгәрмәде. Күптән түгел тәнкыйть секциясендә без яшь тәнкыйтьче Т. Галиуллинның кульязма җыентыгын тикшердек. Тикшерү барышында шул нәрсә ачыкланды: нәшрият аның җыентыгын эчке рецензия өчен тәнкыйтьченең кульязмадагы мәкаләләрендә исеме бөтенләй телгә алынмаган шагыйрьгә биргән, ә соңгы нәтиҗә ясау өчен, кульязманы тәнкыйтьченең мәкаләләрендә сүгелә торган редакторга биргән. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, эчке рецензент та, редактор да кульязмага беравыздан тискәре бәя бирәләр. Секция катнашканнан соң гына мәсьәлә уңай якка хәл ителде кебек.

Әлегә хәтле эчке рецензентның кемлеге кешегә белдерелми, сер булып кала иде. Билгеле, бу да мәгълүм бер роль уйнагандыр. Кызык кына килеп чыга: һәр яңа китапта аның редакторы, корректоры, хәтта художество редакторы күрсәтелә, ә эчке рецензентларының, китапка яшел урам ачкан кешеләрнең исемнәре билгесезлек томаны эчендә кала. Әгәр китапта аңа эчке рецензия язган кешенең дә исем-фамилиясе күрсәтелсә, бу эчке рецензия эшенә җаваплырак карарга өйрәтер иде. Бу катлаулы эш түгел. Киләчәктә нәшрият бу мәсьәләне юлга салачак икән диләр.

Кабатлап әйтәм, бездән үз хуҗалыгыбызны тәртипкә салуны таләп итүе белән укучы хаклы. Шуның белән бергә, әлеге укучының сүзләрендә әдәби тәнкыйтьнең бурычларын аңлап бетермәү дә сизелә. Тәнкыйтьче «ярый», «ярамый» дип печать сугып утыручы контролер түгел. Хәтта нәшрият соравы буенча тегеяки бу кульязмага бәя бирергә алынганда да ул инде тәнкыйтьче түгел, эчке рецензент кына. Эчке рецензия тар даирә кешеләр, ягъни автор һәм нәшриятның 2—3 кешесе өчен языла. Тәнкыйть мәкаләсе исә, язучыны күздән төшермәстән, барыннан да бигрәк киң катлау укучылар өчен языла. Шуңа күрә дә чын мәгънәсендәге тәнкыйть китап дөньяга чыкканнан соң, әлеге әсәрне башкалар белән янәшә куеп карау теләге тугач, китапның уңышлы һәм уңышсыз якларын бәяләү, анда күтәрелгән мәсьәләләр буенча уйлану, фикер алышу ихтыяҗы тугач языла.

Тәнкыйтьче судья түгел, ул әдәбиятның өстендә тормый, ә аның эчендә яши. Әдәби тәнкыйтьче башкалар язганны гына бәяләп калмый, үзе дә фәлсәфи, эстетик байлык тудыра. Белинский, Чернышевский, Добролюбов, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти шундый иҗатчылар булганнар.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, фәнни кыйммәте зур булган тәнкыйть хезмәтләре соңгы елларда байтак язылды. Ләкин безнең китап нәшриятында тәнкыйть китапгары чыгаруга караганда, дөяне энә күзе аша үткәрү җиңелрәк. 1972 елгы тематик планга күз салыйк. Анда йөздән артык әдәби китап бар. Шуларның нибары икесе әдәби тәнкыйтькә һәм әдәбият белеменә карый. Ике процент та туры килми бит. Тәнкыйть секциясе нәшрият белән тыгызрак элемтә урнаштырырга тырышып карады. 1970 елда секция утырышларының берсендә без нәшриятның җаваплы җитәкчеләре белән очраштык. Сүз эчке рецензияләр, аларның сыйфатын күтәрү, бу эшкә әзерлеклерәк кешеләрне тарту кирәклеге һәм башка мәсьәләләр тирәсендә барды. Секция утырышында халык өчен, культурабыз өчен кирәкле кульязмалар телгә алынды. Алар арасында Исмәгыйл ага Рәмиевнең энциклопедик характердагы әдәби сүзлеге дә бар иде. Кызганычка каршы, ул сүзләрнең күбесе нәтиҗәсез калды.

Партиябезнең тәнкыйтьне үстерүгә кайгыртучан карашы безне шатландыра. Ләкин тәнкыйтьне үстерү ул, барыннан да элек, булган байлыкның кадерен белү, аны дөньяга чыгару дигән сүз. Сүз аңа ташлама ясау, түбәнрәк таләпләр кую турында түгел, марксистик-ленинчыл тәнкыйтьнең, социалистик реализм әдәбиятының аерылмас бер кисәге булган тәнкыйтьнең тормыштагы законлы урынын яклау турында бара.

**Шәмси Хамматов,**
тарих фәннәре кандидаты

# БОЛЬШЕВИСТИК ТАТАР МАТБУГАТЫНА НИГЕЗ САЛУЧЫ

Халыклар дуслыгы һәм пролетар интернационализм идеяләрен ялкынланып пропагандалаган марксист-журналист Хөсәен Ямашевның тууына 1972 елның 19 январенда 90 ел тулды. Ул 1903 елдан Ленин партиясе члены булды. Хөсәен Ямашев Идел һәм Урал буе халыклары арасында марксизм-ленинизм идеяләрен таратуда зур роль уйнады. Аның хезмәт ияләре массаларын революцион рухта тәрбияләү юнәлешендәге фидакарь эшенә большевистик үзәк матбугат органнары югары бәя бирделәр. В. И. Ленин редакциясендә чыккан «Пролетарий» газетасы 1905 елда Х. Ямашевны принципиаль партия эшлеклесе, пролетар интернационалист дип сыйфатлады. «Ул,— дип язды газета,— һичбер милләтчелек әсәре булмаган «ортодоксаль» юнәлештәге тәпле социал-демократ» [1].

Хөсәен Ямашев үлгәннән соң «Звезда» исемле большевистик газета болай дип язды: «Вакытсыз дөнья куйган Хөсәен Ямашев йөзендә татар социал-демократлары үз мөхитен яхшы белгән, кушелләрне җәлеп итү сәләтенә ия булган, социализм идеяләрен илһамланып пропагандалаган кешене югалттылар. Үз эшенә нык ышанган, хезмәт сөючән, корыч ихтыярлы бу кеше көрәшче булып туган иде» [2].

Хөсәен Ямашев революционерларның В. И. Ленин партиянең горурлыгы дип атаган гвардиясеннән иде. «Бу кешеләр,— дип язды Владимир Ильич,— ...пролетар массалар арасында нык, тайпылышсыз эшләп, **аларның** аңын, **аларның** оешмасын, **аларның** революцион үзешчәнлеген үстерүгә ярдәм иттеләр» [3].

* * *

Татарстан китап нәшрияты 1971 елның ахырында тарих фәннәре докторы Х. Хәсәновның большевик Хөсәен Ямашевның тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган «Революционер-интернационалист» исемле монографиясен рус телендә бастырып чыгарды. Бу күренекле партия эшлеклесенең революцион эшчәнлегендәге башлангыч чорга кыскача характеристика биргәндә, китап авторы аның иҗтимагый-политик карашларының рус марксистлары йогынты-

---

[1] «Пролетарий» газетасы. 1905 ел. 11 октябрь. 22 сан.

[2] «Звезда» газетасы. 1912 ел. 14 апрель. 24 сан.

[3] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 16 том. 371 бит.

сында формалашуын күрсәтә. XX гасыр башында Казанда революцион эшкә җитәкчелек иткән Н. А. Семашко, В. В. Адоратский, Н. Н. Накоряков, Н. Е. Вилонов, И. С. Саммер, С. А. Лозовский, Я. М. Свердлов кебек партия эшлеклеләренең Х. Ямашевка тәэсире гаять зур булды. Алар аңа халыкара эшчеләр хәрәкәте тәҗрибәсе, К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әсәрләре белән танышырга ярдәм иттеләр, аны пролетар интернационализм рухында тәрбияләделәр. Марксизм идеяләрен яхшы үзләштергән Х. Ямашев партия оешмасы җитәкчелегендә татар халкы арасында оештыру һәм пропаганда эшен актив башлап җибәрүчеләрнең берсе булды.

Революцион идеяләрне җәелдерүдә аерым түгәрәкләрне генә түгел, бәлки киң катлам хезмәт ияләрен дә колачлардай пропаганда чаралары табарга кирәк иде. Большевиклар эшчеләр сыйныфына, хезмәт ияләренең башка катлауларына турыдан-туры йогынты ясаучы партия матбугатын пропаганданың шундый куәтле чарасы дип санадылар.

Россиядә эшчеләр матбугаты листовкалар һәм прокламацияләр рәвешендә барлыкка килде. В. И. Ленин әнә шундый листовкаларны эшчеләр матбугатының беренче карлыгачлары дип атады. Хөсәен Ямашев революцион әдәбиятны татар теленә тәрҗемә итүне оештыручыларның беренчеләреннән булды. Аның бу өлкәдәге эшенә РСДРПның Казан комитеты юнәлеш биреп торды.

1903 ел башларында Казанда татар телендә гектографта басылган цензурасыз беренче марксистик листовка чыгу — Татарстан матбугаты тарихында әһәмиятле вакыйга. Листовкаларны һәм прокламацияләрне бер үк вакытта ике телдә — рус һәм татар телләрендә — чыгару эшчеләрнең милли отрядларына һәм крестьяннарның киң катлау массаларына социал-демократик йогынтысын көчәйтүдә гаять зур роль уйнады.

«Татар эшчеләре ана телендәге беренче прокламацияләрне шатланып каршыладылар»[1],— дип язды ленинчыл «Искра» газетасы. Ул РСДРПның Казан комитетының бу башлангычын хуплады, листовкаларны ике телдә чыгару татар эшчеләре массаларына яктылык китереп кенә калмас, бәлки Казан капиталистларына гына файдалы булган һәм революцион хәрәкәткә шиксез зыян китергән милли дошманлыкны какшатыр, дип билгеләп үтте.

Прокламацияләрне ике телдә чыгару РСДРПның Казан комитетының пропаганданы җирле шартларны, край халкының милли составын исәпкә алып оештырганлыгын күрсәтә.

Х. Ямашевның турыдан-туры катнашы белән чыгарылган листовкаларда марксизмның төп положениеләре, пролетар интернационализм һәм халыклар дуслыгы идеяләре аңлатылды. Массаларны революциягә әзерләү өчен барлык милләт пролетарийларына сыйнфый мәнфәгатьләренең уртаклыгын, Россиядәге эшчеләр сыйныфының милли отрядлары арасындагы дуслыкның нинди зур көчкә ия икәнлеген төшендерергә кирәк иде.

Пролетар интернационализм принципларын аңлату ул чордагы листовка әдәбиятының төп эчтәлеген тәшкил итте. Бу яктан алганда, «Казан шәһәренең барлык эшчеләренә» дигән исемдә рус һәм татар телләрендә чыгарылган прокламация характерлы. Аның татарча текстын Х. Ямашев язган. Пролетар интернационализм рухы белән сугарылган бу прокламациядә азатлыкка ирешүнең бердәнбер юлы — патша строена каршы кискен көрәш икәнлеге әйтелә. Аны җиңү өчен барлык милләт хезмәт ияләрен социал-демократик эшчеләр партиясе байрагы астына берләштерергә кирәк. Татар эшчеләре дә, рус эшчеләре дә капиталистлар тарафыннан бер үк дәрәҗәдә эксплуатацияләнә. Прокламация эшчеләрне бертуганнар кебек бер семья булып яшәргә чакыра, рус һәм татар эшчеләре арасында дошманлыкның изүче сыйныфларга гына файдалы икәнлеген ассызыклап күрсәтә.

Партиянең III съезды карарларыннан һәм В. И. Ленинның төрле милләт эшчеләре арасында пропаганда эшен көчәйтү турындагы күрсәтмәләреннән чыгып, Хөсәен Ямашев беренче рус революциясе елларындагы чыгышларында, листовкаларында һәм басмаларында татар пролетариатын, хезмәт иясе крестьяннарны, укучы яшьләрне царизмга каршы көрәштә рус эшчеләре сыйныфы белән, башка милләт хезмәт ияләре белән берләшергә өнди.

Ленинчыл «Пролетарий» газетасы үзенең 1905 елда чыккан 22 санында, РСДРП

[1] «Искра» газетасы. 1903 ел. 1 март саны.

Казан комитетының хезмәт ияләре арасындагы эшенә уңай бәя биреп, болай дип яза: «Партия комитеты шулай ук татарлар арасында да эш алып бара. Татарлар аерым район итеп бүленмәгәннәр. Аларның алдынгы элементлары, башкалар белән берлектә, оештыручылар төркеменә керәләр. Кайберләре рус түгәрәгенә йөриләр. Бөтенесе дә гомуми массовкаларда катнашалар. Ләкин телдә аермалык аркасында татарлар өчен татар телендә аерым түгәрәкләр төзергә, кайсыбер чакта тик татарлар өчен аерым оештыру җыелышлары ясап, шуннан соң гомуми оешмаларга кертү методларын кулланырга туры килә. Прокламацияләрне татар теленә тәрҗемә итәргә кирәк була. Аларны тик татарлар гына баса алалар. Моның өчен комитетта татар оештыручысы бар (Хөсәен Ямашев күздә тотыла.— Ш. Х.). Комитет бу оештыручының фикерен бик хуплый. Әгәр Казан халкының 30 проценты татар булганлыгын искә алсак, бу, әлбәттә, шулай булырга тиешлеген аңлыйбыз...» [1].

Казан большевикларының шул исәптән Х. Ямашевның, пропаганда түгәрәкләрендәге эшләре һәм марксистик прокламацияләрне, революцион җырларны басып чыгарулары эшчеләрне, хезмәт иясе массаларын сыйнфый бердәмлек һәм пролетар интернационализм рухында тәрбияләделәр. Казан большевиклары самодержавиенең милләтләр арасында дошманлык кабызу юлы белән эшчеләр сыйныфы сафларын таркатырга һәм революцияне буарга омтылуын массаларга армый-талмый аңлаттылар. Мәсәлән, РСДРПның Казан комитетының «Бакудагы суеш турында барлык эшчеләргә» исемле листовкасы татар теленә тәрҗемә ителде. Бу прокламация царизмның реакцион политикасын ачып бирде, самодержавие изүенә каршы уртак революцион көрәштә барлык милләт хезмәт ияләренең дуслыгын ныгытырга чакырды. Листовка «Яшәсен барлык милләт эшчеләре арасында туганлык» дигән сүзләр белән тәмамланган иде.

Х. Ямашев ярдәмендә тәрҗемә ителгән «Татар иптәшләр!» дигән прокламациядә РСДРПның Казан комитеты патша властьларының, жандармнарның провокаторлар аркылы большевиклар исеменнән листовкалар чыгаруын һәм татар халкын русларны кыйнарга чакыруын фаш итте.— Аларга ышанмагыз, иптәшләр! — диелгән иде прокламациядә.— Һәрвакыт исегездә тотыгыз: без сезне үз изүчеләребезгә — рус хөкүмәтенә каршы гына көрәшергә, ләкин сезгә һәрвакыт: бөтен рус халкы белән союзда булганда гына дошманнарыгызны җиңәрсез, дип әйтәбез. Аннары листовкада болай диелгән: барлык милләт эшчеләре — татарлар, руслар, еврейлар, әрмәннәр һәм башкалар бер-берләренә туганнар кебек кул сузганда, барысы бердәм дус семьяга кушылганда гына эшчеләр җиңүгә ирешәчәкләр.

Казан партия оешмасының актив эшлеклесе Х. Ямашевның хезмәт иясе массаларын интернационализм рухында тәрбияләү юнәлешендәге зур эшләре нәтиҗәсендә патша хөкүмәте Казанда татарлар белән руслар арасында суеш оештыра алмады.

«Казан татарларына» дигән листовкада (ул 1905 елның ноябрендә басып чыгарыла) Хөсәен Ямашев халыклар дуслыгын тагын да ныгытырга, самодержавиене җиңү өчен коралы восстание оештырырга өнди. Прокламация менә шундый ялкынлы сүзләр белән тәмамлана: «Яшәсен бөтен халыкның бер-бере белән дуслыгы! Бетсен милләтләр арасына дошманлык салучылар! Бетсен самодержавие! Яшәсен бөтен халыкның коралланып күтәрелүе!» [1]

Шулай итеп, большевиклар партиясенең төп документларын ана телендә тәрҗемә итеп чыгару татар эшчеләрен интернациональ бердәмлек рухында тәрбияләүдә бик зур роль уйнады. Монография авторы Х. Хәсәнов РСДРПның II съездында кабул ителгән партия Программасын, В. И. Ленинның «Өч конституция һәм дәүләт төзелешенең өч тәртибе» исемле мәкаләсен һәм башка марксистик әдәбиятны тәрҗемә итүдә һәм пропагандалауда Х. Ямашев, прогрессив демократик интеллигенциянең башка вәкилләре башкарган зур эшкә тулы туктала. Мәгълүм ки, шуннан беркадәр элегрәк «Авыл ярлыларына» дигән листовка татар телендә чыгарылган иде. Аның

---

[1] Бу өзек Галимҗан Ибраһимов тәрҗемәсендә китерелә. Карагыз: «Урал» һәм «уралчылар». Казан. 1927. 22 бит. Шулай ук «Пролетарий» газетасы. 1905 ел. 11 октябрь саны.

[1] Татарстан АССР тарихы. I том. Казан. 1955 ел. 422 бит.

исеме үк В. И. Ленинның шул исемдәге брошюрасы нигезендә төзелгәнлеген әйтеп тора.

* * *

1905 елның ахырында, Мәскәү восстаниесе кызган бер чорда, патша охранкасы РСДРПның Казан комитетын тар-мар итә. Ләкин аның берничә актив хезмәткәре, шул исәптән Х. Ямашев, кулга алынудан котылып кала. Ямашев яшерен рәвештә Уфага күчә. Анда ул актив революцион эшкә кушыла. Казанда прокламацияләр чыгару тәҗрибәсеннән файдаланып, ул РСДРПның Уфа комитеты исеменнән ана телендә прокламацияләр һәм листовкалар чыгаруны оештыра. Алар татар һәм башкорт хезмәтчеләренә юллана, патша самодержавиесенә һәм буржуазиягә каршы көрәшкә өнди. Мәсәлән, II Дәүләт думасына сайлаулар уңае белән чыгарылган листовкада Х. Ямашев: шәһәр һәм авыл ярлыларының чын дусты — РСДРП гына, шушы партия членнары гына җир һәм азатлык өчен көрәшергә сәләтле, дип яза.

Хөсәен Ямашев революцион идеяләрне пропагандалауда матбугатның гаять зур роль уйный алуына үз тәҗрибәсендә ышана. Тагын да арырак барырга — татар телендә политик газета оештырырга кирәклеген ачык күрә. Реакциянең һөҗүме чорында В. И. Ленин беренче планга газета чыгаруны оештыру мәсьәләсен куя. В. И. Ленин болай дип язды: **«Хәзер партиягә... дөрес чыгып килә торган политик орган — партия органы, политик газета кирәк»** [1].

Х. Ямашевның татар телендә социал-демократлар органы чыгару турындагы инициативасын РСДРПның Урал өлкә һәм Уфа комитетлары яклый. Бу тәкъдимне партиянең күренекле эшлеклеләреннән берсе, РСДРП Үзәк Комитеты члены И. А. Саммер да хуплый. Ләкин полиграфия мөмкинлекләре булмау һәм полициянең эзәрлекләве көчәю аркасында, Уфа комитеты татар телендә большевистик газетаны Оренбургта чыгаруны кулайрак дип таба. Һәм 1907 елның 4 январенда Оренбургта Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә «Урал» газетасының беренче саны чыга.

Х. Хәсәновның «Революционер-интернационалист» дигән китабында «Урал» газетасында эшләү чорында Ямашевның талантлы оештыручы-публицист булуы яктыртыла.

Хөсәен Ямашев Идел һәм Урал буе большевиклары оешмасы тарихына, татар пролетар матбугатының үсеше тарихына матур сәхифә язган беренче большевистик газетаны оештыручы һәм аның идея җитәкчесе булды. «Урал» газетасын ике телдә — татар һәм рус телләрендә — чыгару нияте үзе генә дә инде бу органны оештыручыларның интернациональ курсын күрсәтә. Ләкин күп кенә сәбәпләр аркасында газета бер телдә — татар телендә генә дөнья күрә.

Большевистик «Урал» газетасы атнага 2—3 тапкыр дүртәр битле булып чыга. Аның тирәсендә алдынгы эшчеләрдән, социал-демократлардэн һәм прогрессив яшьләрдән хәбәрчеләр даирәсе туплана. Казанда, Уфада, Самарада, Сембердә, Чиләбедә, Бозаулыкта, Чистайда, Алабугада, Кузнецкида һәм башка байтак шәһәрләрдә газетаның даими хәбәрчеләре була. «Урал» газетасы партиянең Урал өлкә, Казан, Уфа комитетлары һ. б. белән даими элемтә тота, подписка үткәрүдә, эшчеләр тормышы турында материаллар җыюда аларның ярдәменә таяна.

Җирле тормышны гына түгел, бәлки бөтен Россиядәге эшчеләр һәм крестьяннар хәрәкәтен киң яктырту максаты белән газета үзенең битләрендә 15 тән артык бүлек булдыра. «Партия тормышы», «Эшчеләр тормышыннан», «Авыл тормышыннан», «Соңгы хәбәрләр», «Думага сайлаулар», «Чит ил хәбәрләре», «Укучы яшьләр тормышыннан», «Оренбург хәбәрләре», «Редакциягә хатлар» — менә төп бүлекләрнең кайберләре. Газета битләрендә Петербург, Мәскәү, Варшава, Киев, Рига, Баку һәм башка зур промышленность үзәкләрендә барган революцион вакыйгалар турында хәбәрләр игълан ителә.

«Урал» газетасы илнең төрле өлкәләренә тарала. Оренбург, Уфа, Казан, Самара һәм Сембер губерналарыннан тыш, аны Урал һәм Идел буендагы башка шәһәрләр эшчеләре дә алдыралар. Мәскәү, Касыйм, Астраханьда, Томск, Малмыжда аңа язылу пунктлары була. «Урал»ны Урта Азия, Казагыстан, Кавказ һәм Кырым халыклары да белә.

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. 34 нче том. 360 бит.

Хәзер билгеле булуынча, газетадагы күп кенә имзасыз мәкаләләрне публицист Хөсәен Ямашев язган. Ул актив партия эшен журналистика эше белән оста бәйләп алып барган. Партиянең милли кадрлары арасында Х. Ямашевның ул замандагы иң белемле марксист-ленинчыларның берсе булуы, ике телне — рус һәм татар телләрен — яхшы белүе, ил тормышын белеп торуы аңа бу эштә бик нык ярдәм итә. Ул матбугатта ленинчыл позицияне, большевиклар партиясе политикасын, пролетар интернационализм принципларын эзлекле үткәрә.

«Урал» газетасының беренче санында «Идарәдән» дигән мәкаләдә Х. Ямашев, большевиклар партиясе куйган бурычлардан чыгып, партия органының политик курсын билгели. «...Без үзебезнең гәзитәбездә, пролетариатны бергә кушылырга өндәп, аның сыйныфына билгеле аңын арттырырга булышу кеби крестьян халкын һәм шәһәр фәкыйрьләрен дә үзара кушылырга өндәячәкмез»[1].

Газета бу бурычларны намус белән үти. II Думага сайлауга әзерлек һәм сайлауларны үткәрү чорында ул большевистик тактиканы пропагандалый. «Урал» социал-демократлар фракциясе депутатларының, шул исәптән большевик депутатларының, чыгышларын тулысынча игълан иткән бердәнбер матбугат органы була.

Газета үзенең икенче санында В. И. Ленинның «Дәүләт думасына кемне сайларга?» дигән мәкаләсен урнаштыра һәм шуның белән татар хезмәт ияләренә өч төп политик партиянең максатларын аңларга ярдәм итә. Карагруһчыларны, кадетларны, аларның милләтчелеген һәм великодержавиечел шовинизмын фаш итеп, В. И. Ленин социал-демократлар партиясенең интернациональ характерын күрсәтә. Бу—Россиядә яшәүче барлык халыкларның: руслар, латышлар, поляклар, еврейлар, малорослар, әрмәннәр, грузиннар, татарлар һәм башка милләтләрнең аңлы эшчеләре партиясе.

Шунысы кызыклы: бу — В. И. Ленинның татар теленә тәрҗемә итеп большевистик «Урал» газетасында урнаштырылган беренче әсәре була. Мәгълүм ки, аңа кадәр В. И. Ленин мәкаләләре татар телендә гектограф ысулы белән басылган листовкаларда гына игълан ителгән була.

[1] «Урал» газетасы, 1907 ел, 4 гыйнварь, 1 сан.

Буржуаз милләтчелеккә каршы көрәш «Урал» газетасы эшендә аеруча зур урын алып тора. Х. Хәсәнов үзенең китабында әлеге мәсьәләгә шактый киң туктала. «Урал» милли татар буржуазиясенең һәм аның «Мөселман иттифакы» партиясенең халыкка каршы политикасын рәхимсез фаш итә һәм бу политикага каршы большевизмның милли мәсьәлә буенча төп лозунгысын куя.

Х. Ямашевның актив катнашы белән язылган «Мөселман иттифакы», «Милләтчеләр», «Тагын милләтчеләр» дигән мәкаләләрдә газета буржуаз милләтчелекнең социаль һәм идеологик асылын ачып сала, пролетар интернационализм принципларын, эшчеләр сыйныфының милли отрядлары арасында дуслык идеяләрен яклый. Газета: изелгән халыкларны бердәнбер яклаучы — социал демократия генә, дигән фикерне эзлекле үткәрә. «Урал» пролетариат партиясе Россия территориясендә яшәүче һәр милләткә үзбилгеләнү хокукы бирү өчен көрәшә, барлык милләт пролетарийлары бердәм һәм нык тупланган көч булып чыгарга тиешләр,— дип яза.

Хөсәен Ямашевның: «Милләтчеләр... байларның фикерен, байлар теләгән нәрсәләрне сөйләргә, язарга байларга ялланган»[1] кешеләр, милләтчеләр «хөкүмәт белән килешү юлы белән, манифестлар чыгару юлы белән баралар. Болар һаман да иске золымнарны йомшартып, яңаларына урын калдыра торган юл белән баралар. Болар ул золымнарны тудырып тора торган нәрсәнең тамырын өзеп ташлый торган юл белән бармыйлар»[2],— дигән сүзләре бүген дә бик актуаль.

Беренче май бәйрәме турында язылган мәкаләдә «Урал» капиталга каршы көрәштә барлык илләр эшчеләре бергә эш итәргә, бер-берләренә туганнарча ярдәм күрсәтергә тиешләр, дип күрсәтә. Бу чакыру безнең заманда да заманча яңгырый.

Шунысы әһәмиятле, редакция хезмәткәрләре Х. Ямашев җитәкчелегендә марксистик әдәбиятны татар теленә тәрҗемә итеп бастыруны дәвам иттерәләр. «Урал» газетасы биш брошюра чыгара. Аларда эшчеләр сыйныфының тарихи миссиясе

[1] «Урал» газетасы, 1907 ел, 21 гыйнварь саны.

[2] «Урал» газетасы, 1907 ел, 10 март саны.

ачып бирелә, РСДРПның максатлары, социализм һәм интернациональ бердәмлек идеяләре пропагандалана. Брошюралар барлык милләт хезмәт ияләрен тупланырга һәм рус пролетариаты җитәкчелегендә самодержавиегә һәм буржуазиягә каршы көрәшкә әзерләнергә чакыра.

Революцион социал-демократлар комитетының прокламация, брошюра һәм мәкаләләрен рус теленнән татарчага тәрҗемә итеп басып чыгару татар хезмәт ияләрен марксизм-ленинизм белән таныштыруда, халыклар арасында дуслыкны ныгытуда гаять зур роль уйнады.

Хөсәен Ямашев һәм «Урал» газетасы журналистлары татар әдәби телен үстерүгә дә сизелерлек өлеш керттеләр. «Милләтчеләр» дигән мәкаләдә болай диелә: «Татар телендә газеталар чыга башлады. Яңа сүзләр белән дөнья тулды. Забастовка, союз, учредительный собрание, митинг, оратор, социалист, революция... Бу сүзләрне ишетеп, диннән башка бернәрсә дә белмәгән милләтчеләр дә гаҗәпкә калдылар»[1].

«Урал»чылар татар телен эшче һәм крестьян массаларына аңлаешлы булмаган гарәп-фарсы сүзләреннән арындыру юнәлешендә күп эшлиләр. Шул ук вакытта газета битләрендә «пролетариат», «партия», «коммунист», «интернационал», «капитал», «программа», «листовка» һәм башка бик күп интернациональ иҗтимагый-политик терминнар еш күренә. Газетада бай рус теленең лексик составыннан алынган сүзләр кыю кулланыла. Һичшиксез, бу — татар телен баетты, аның лексикасын интернациональ терминнар белән тулыландырды. Милли телне үстерүдә моның зур әһәмияте булды, ул киң катлау халык массаларында, шулай ук Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури һәм башкалар кебек демократ язучыларда яклау тапты. Совет татар матбугаты «Урал» публицистларының традициясен яңа шартларда дәвам иттерә һәм тагын да үстерә, шуның белән ике халык арасындагы дуслыкны ныгытырга ярдәм итә.

Большевистик «Урал» газетасы, чыга башлавыннан соң өч ай үткәч, 1907 елның 27 апрелендә ябыла. Аның җитәкчесе Х. Ямашев патша властьларының эзәрлекләве аркасында Оренбургтан китә. Гомере шулай кыска гына булуга да карамастан, газета гаять зур политик роль уйнады. Ул большевистик татар матбугатына нигез салды, прогрессив журналистлар, әдәби кадрлар тәрбияләде, реакция шартларында марксизм-ленинизм идеяләрен хезмәт ияләренең аңына җиткерде. 1907 елның 7 июлендә Уралдагы большевистик оешмаларның Чиләбедә үткәрелгән киңәшмәсендә Х. Ямашев татар эшчеләрен революцион рухта тәрбияләүдә, төрле милләт хезмәт ияләре арасында дуслыкны ныгытуда «Урал» газетасының әһәмияте турында сөйләде.

Казанга кайткач, реакциянең котырынуына карамастан, Х. Ямашев «Казан мөхбире» газетасын революцион социал-демократиянең легаль органына әверелдерергә тырыша. Бу уңай белән «Волжский листок» газетасының 1908 елдагы 28 январь санында, «Яңа басмалар» дигән рубрика белән, түбәндәге кызыклы хәбәр урнаштырыла: «Шушы көннәрдә җирле мөселман газеталары саны «Казан мөхбире» исемле яңа матбугат органы исәбенә артты. Ул берничә генә сан чыккан һәм соңыннан администрация тарафыннан ябылган җирле мөселман газетасы «Урал»да эшләгән татар журналистлары төркеменең якыннан катнашы белән чыга».

«Казан мөхбире»ндә Х. Ямашевның берничә мәкаләсе басыла. Аларда автор халык интересларын яклый, милләтчеләрнең чын йөзен ача, патша хөкүмәтенең халыкка каршы политикасын фаш итә. Ләкин милли буржуазиянең таләбе буенча монда да Хөсәен Ямашевка журналистлык эшен алып баруны тыялар.

Рецензияләнә торган монография конкрет мисаллар нигезендә демократик матбугат органнарына «Урал» газетасының һәм Х. Ямашевның идея йогынтысы мәсьәләсен шактый киң яктырта. Аерым алганда, Оренбургта ук инде «Карчыга» сатирик журналының, большевистик органнан үрнәк алып, хөкүмәткә каршы материаллар игълан итүе күрсәтеп үтелә. Хөсәен Ямашев йогынтысында Казандагы «Яшен», «Ялт-йолт» исемле сатирик журналлар да хезмәтчел татар халкының мәнфәгатен яклый.

Хөсәен Ямашевның революцион эшчәнлеге күпьяклы. Х. Хәсәновның «Революционер-интернационалист» исемле китабы чыгу уңае белән, без бу мәкаләдә башлыча Х. Ямашевның журналистиканы үстерүдәге эшчәнлегенә, большевистик татар матбугатына нигез ташы салуына, аның пролетар интернационализм һәм халыклар дуслыгы идеяләрен пропагандалавын яктыр-

[1] «Урал» газетасы. 1907 ел. 21 январь саны.

туга туктадлык, шуңа бәйле рәвештә әлеге проблема буенча кайбер фикерләребезне уртаклаштык.

1927 елның гыйнварында «Урал» газетасының чыгуына егерме ел тулу уңае белән, матбугатта аның тарихы, тоткан роле турында күп языла. Мәсәлән, «Кызыл Татарстан» газетасы үзенең «Урал», егерме еллыгың котлы булсын!» дигән редакцион мәкаләсендә болай дип язды:

«Моннан егерме ел элек гыйнварның 17 сендә (искечәдә 4 ендә) Оренбург шәһәрендә татар телендә беренче большевик газите «Урал»ның беренче номеры чыкты.

Газитне төзүче, аңа юлбашчылык итеп, чыгарып алып баручы редактор-большевик Хөсәен Ямашев булып, газиткә матди яктан ярдәм итүче, аңар булышучы Россия социал-демократлар партиясе иде.

Шул ук елда татар большевигы Гафур Коләхметовның беренче драма әсәрләре «Яшь гомер», «Ике фикер»ләре язылды.

Шул ук «Урал» газите тарафыннан «Эшчеләрнең котылуы үзләренең эше булырга тиешле», «РСДРП авыл халкы өчен нәрсә булдырырга тырыша?», тагын башка шундый исемнәрдә социаль-сәяси китаплар сериясе чыкты.

Менә шуларның һәммәсен искә алып, без 1907 нче елны татар эшче әдәбиятының һәм вакытлы матбугатының башлангыч елы, туган елы дип әйтә алабыз... Тарихын «Урал»дан башлаган большевизм матбугаты Октябрь революциясеннән соң гына корыч нигезләргә басты, дөрес адымнар белән алга китте» [1].

Шулай итеп, Хөсәен Ямашев татар телендә большевистик матбугат чыгаручы, марксистик-ленинчыл әдәбиятны һәм партия документларын татар теленә тәрҗемә итүне оештыручы, ялкынлы публицист, пролетар интернационализм һәм халыклар дуслыгы идеяләрен дәртләнеп пропагандалаучы булды. Татар большевистик матбугатының ул башлап җибәргән гүзәл традицияләрен, бигрәк тә Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң, милли журналистларның шуннан соңгы буыннары тагын да үстерделәр һәм баеттылар. Бу традицияләр әле дә дәвам итә.

Х. Ямашев башлап җибәргән эш — марксистик-ленинчыл әдәбиятны, партиянең төп документларын тәрҗемә итү эше һаман киңрәк колач ала. Күп санда тәҗрибәле журналист-тәрҗемәчеләр тәрбияләнде. К. Марксның һәм Ф. Энгельсның төп әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителде, дүртенче басма буенча В. И. Ленин әсәрләрен чыгару эше тәмамланып килә. Татар хезмәт ияләре партия һәм хөкүмәт документлары белән үзләренең ана телләрендә танышалар.

Матбугатта интернационализм принцибы — ә Хөсәен Ямашев партия публицисты буларак шул принципны эзлекле үткәрде — партия-совет матбугатының какшамас принцибына әверелде. Бу принципның эчтәлеге һаман тирәнәя, формалары төрләнә бара. Халыклар дуслыгы идеясен пропагандалау — матбугатыбыз эшендә төп юнәлешләрнең берсенә әверелде. Татар партия-совет матбугаты үткән юлга борылып карaганда, без аның бишеге янында торган кешеләргә, өлкән журналистларга, беренче чиратта Хөсәен Ямашевка рәхмәт хисе белән мөрәҗәгать итәбез.

Ләкин шуны әйтми булмый: без әле журналистика фәне алдында зур бурычлы, чөнки Х. Ямашевның күпьяклы публицистик эшчәнлеге җитәрлек өйрәнелмәгән. Аның публицистик әсәрләрен басып чыгарырга, журналистлык эшчәнлеге турында махсус хезмәт язарга кирәк. Большевистик басмаларда, листовкаларда, мәкаләләрдә Х. Ямашевның интернационализмны пропагандалавы үзенчәлекләрен тирәнрәк тикшерәсе иде. Кыскасы, сүз партия журналистикасы тарихында Х. Ямашевның ролен һәм урынын тулырак ачу зарурлыгы турында бара.

Х. Ямашевның тормышы һәм эшчәнлеге — ялкынлы көрәшче, патриот-интернационалист тормышы үрнәге. Аның публицистикасы — большевистик милли матбугатның иң якты сәхифәләреннән. Х. Ямашев бүген дә матбугатның партиялелеге, сугышчанлыгы, интернациональлеге өчен безнең белән бергә көрәшә.

Җыеп әйткәндә, Х. Хәсәновның китабы — авторның Х. Ямашев тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган элекке тикшеренүләренең дәвамы, күпьеллык тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Бу хезмәтләре белән ул Татарстан партия оешмасы тарихын, Идел һәм Урал буенда революцион көрәш тарихын өйрәнүгә сизелерлек өлеш кертә. Партия работниклары, журналистлар, язучылар, укытучылар, пропагандист кадрлар аның китабында үзләренең көндәлек эшләре өчен кыйммәтле фикерләр һәм кызыклы фактлар табарлар.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасы, 1927 ел, 16 январь саны.

# ИНЕШЛӘР ИДЕЛГӘ КУШЫЛА

...Рәйханә менә тагын шул ук басуда караңгылык айкап йөри. Аның өчен хәзер монда бар да бүтән. Көннәр, төннәр башка, кешеләр башка. Берсе дә, берсе дә мәңгелек түгел. Әмма йөрәге генә моның белән килешергә теләми.

— Нәрсә дә булса мәңгелек булырга тиеш ләбаса!

Әйе, тәүге мәхәббәтен күп еллар элек сугышка озаткан һәм әле һаман аның кайтуына ышанган, көткән, шуның бөтен бәхетен-газабын кичергән изге күңел авыр чакларда таяныр нәрсә эзли, үзенең бар сафлыгы һәм тирәнлеге белән аның булуын тели. Кайчандыр ире Рәхим трактор белән җир сөргән басуга да ул шуның өчен килгән. Тик Рәйханә мәңгелек нәрсәне читтән эзләп кенә ялгыша. Мәңгелек — ул аның үзендә. Ул — тугрылык. Аның тугрылыгын вакыт та кимерә алмый, очраган кыенлыклар да какшатмый. Киресенчә, бу тугрылык җирдәге тормышны, кешеләрне, аларның өметен үзе ныгыта.

«Инешләр Иделгә кушыла» җыентыгындагы[1] иң зур хәзинә дә — әнә шул тугрылык. Анда тупланган хикәяләр, укучы хөкеменә куелган тормыш конфликтлары, җир астыннан бәреп чыккан саф сулы чишмәләр инешләргә, ә ул инешләр олы диңгезләргә кушылгандай, барысы бергә тугрылык дигән изге хиснең безгә бар тирәнлеген, сафлыгын, яктылыгын ачып бирәләр. Бу тугрылык Тәүфыйк Әйди хикәясендә яшьлек мәхәббәтенең, кешеләр белән бергә үсеп, ныгып, авыр еллар дәвамында олы, бернәрсә каршында да какшамаслык, үзенә тирән ихтирам белән баш идерә торган мәхәббәткә әверелүендә чагыла. Хикәянең исеме дә «Тугрылык» дип атала һәм ул фикере, образларының көче, аларның гомумиләштерү сәләте, күтәренкелеге белән җыентыкның үзәгендә тора.

Менә ындыр кырыенда хатыннар көшел очыралар. «Алтын бөртекләргә әверелгән кояш нурлары очынып күккә күтәрелә дә яңадан аска юнәлә. Җир тарта. Биеккә омтылган салмак бөртекләр, ялкау кибәкләрне узып, тып та тып кире коела. Төшкәндә дә тәнем, бәдәнем авыртыр дими, атылып төшә. Күрәсең, аның өчен изге урын ике генәдер: я җир, я кояш!»

Яшь автор тасвирлаган ул орлыклар гади орлык кына түгел. Алар — тормыш җилгәргеч тарафыннан һавага чөелгән хатыннар үзләре. Шунда инде берәүләр, игелексез кибәк булып, җил иркенә бирелә, ә икенче берәүләр: «я кояш, я җир!» дип, атылып җиргә төшәләр. Нәкъ инде менә үзенең тәүге мәхәббәт кояшының алтын нурларыннан ныгыган һәм таза бөртек кебек җиргә, изгелек булып кешеләр күңеленә төшүче Рәйханә. Ул да бит, авылларындагы яшь гаиләнең җимерелеп барган бәхетен коткарып калу өчен, яңгырлы төндә станциягә чаба. Чөнки Рәйханә кешеләрнең бәхетле булуларын, үзләренә килгән олы бәхетнең кадерен белүләрен тели, шуның өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли. Әнә шундый Рәйханә апалар инде тормыш юлын атлап китүчеләргә юл күрсәтүче ут булып балкыйлар, гомергә хәтергә сеңеп калалар. Рәйханә ире Хәбирне ташлап китеп баручы Сабираны калырга үгетләгәндә, сузып-сузып, станциядәге паровоз кычкырта. Шушы мизгелдә яшь язучының безнең игътибарны паровозга, бәхеткә баручы пассажир поездларына юл

[1] Коллектив. Инешләр Иделгә кушыла. Татарстан китап нәшрияты. 1971 ел.

арчып йөрүче искереп беткән эшчән паровозга юнәлтүе безгә Рәйханәнең бөтен асылын, олылыгын, фидакарьлеген ачып сала. Паровозлар да бит бүген, үзләренә артык дан дауламыйча, ләкин һаман да юлдан төшмичә, акрын гына үз эшләрен эшләп йөриләр; еракка китәсе яшел вагоннарны, кулларыннан тотып, олы юлга чыгарып җибәрәләр. Тик җитез электр поездларында җилдерүче кәефле пассажирлар гына аларга артык игътибар итмиләр...

Тормышыбыз егерменче гасыр казанында кайный. Кеше шәхесенең, аның рухи дөньясының нык үзгәрүе, яңа биеклекләргә күтәрелүе һәм көчле ихтыяҗларының, таләпләренең интенсивлашуы, янәруы кайбер яшь кешеләргә тоташ имансызлык, бер генә «аллага» ышануның бетүе, өметсезлек булып күренергә мөмкин. Кеше рухы өчен хәлиткеч булган мондый икеләнүле эзләнүләр чорында гыйбрәтле тормыш юлы узган, дөнья күргән берәр кеше белән очрашу бик кирәк. Һаҗәр (К. Тимбикова. Синең өчен. Повесть.) безнең өчен әнә шундый кеше. Аның тормышы — катлаулы, авыр, газаплы бәхет. Ләкин барыбер бәхет! Вакыты-вакыты белән ул үзе моңа шикләнеп тә кала, үзенең гел ялгышларын гына күрә:

«Бөтен тормышым гел ялгышудан гына торамыни соң минем? Эзләнәм, табам, кош тоткандай куанып йөрим. Бераздан гына ул табышымның аю кулындагы алма икәнен белеп өзгәләнә башлыйм. Ник яшим соң мин? Кемгә кирәгем бар?»

Әйе, бүгенге әдәбиятыбыз геройлары үз язмышларына куанып яки аны каргап кына яшәмиләр. Алар үз тормышларының мәгънәсен, әһәмиятен ачыкларга теләп уйланалар, зур дөньяда үзләренең кем икәнлекләрен, рольләрен аңларга телиләр. Ә үзүзеңне аңлау ул — тормышта урыныңны табуга таба зур адым бит. Яшьлегендә Һаҗәр алдында үз тормышын ничек кызыклырак, файдалырак итү мәсьәләсе тормаган. Бу мәсьәләне аның өчен сугыш заманы хәл иткән — ул фронтка киткән әтисе урынына тракторга утырган. Ләкин бу сорауны ул барыбер әйләнеп үтеп китә алмый. Еллар үткәч, бирелеп кенә колхоз басуында эшләп яткан Һаҗәрне тормыш яшь галим белән очраштыра. Һаҗәр сайларга тиеш: бер юл яраткан эшендә калдыра, тәрбиягә алып үстергән кызыннан аермый, ә икенче юл сөйгәненә, үз тормышында бердәнбер булган кешең белән кавыштыра.

Шундый кыен хәлдә калган Һаҗәрдә без үз замандашыбызны, бүгенге проблемалар, конфликтлар героинясын күрәбез. Аның уйлары безнең уйларга барып тоташа. Чыннан да, кайсы юл мине соңгы чиктә бөтен тормышым, бар кылган эшләрем өчен үкендермәячәк? Кайсыннан барсам, мин үземә кыен булса да, йөрәгемдә олы канәгатьләнү, үз-үземә ышану, бәхет тоеп барачакмын? Н. Г. Чернышевский сүзләре, тәңге яшен кебек, күңелне яктыртып уза: «Минем бөтен язмышым өчен әһәмиятле, бөтен тормышым шуңа бәйләнгән, минем өчен чиксез дәрт булган шундый бер эш кирәк».

Һаҗәрнең үз эшенә, яраткан кызына тугры булып калуы да ниндидер корбан түгел. Бу — аның чынбарлыгы, асылы, табигате. Алардан башка Һаҗәр юк, ул үзе булып кала алмый.

Яшь язучы Кояш Тимбикованың Һаҗәре һәм Тәүфыйк Әйди Рәйханәсе белән беренче танышу — безнең өчен зур шатлык. Аларда без үз күңелебез тансыклаган кешеләрнең чын, катлаулы һәм эчкерсез, тирән кичерешләре белән дулкынландыра торган тормышларын күрәбез. Алар — үзләренең олы тугрылыклары белән безнең бүгенге тормышыбызны күтәреп, аны матурлык һәм изгелек югарылыгыннан төшерми тотып торучылар сыман. Һәм чорыбыз әдәбияты үзенең төп игътибарын тормышның нигез төзелешенә, төп авырлыкны күтәреп торучыларга юнәлдергән. Шуның белән үзенең дә әһәмиятен, көчен, дәрәҗәсен күтәргән вакытта безнең яшь язучыларыбызның да шушы дөрес юлда булулары — әйбәт, күңелле. Алар да тормыш корылмасының төп терәкләрен, иң таза баганаларын күрсәтергә телиләр һәм оста сәнгать чаралары белән кайсы багананың үз җилкәсендә күпме авырлык күтәрә алуын, ни дәрәҗәдә ышанычлы икәнен исәпләп чыгаралар. Ә бит зур төзелеш өчен бу бик әһәмиятле!

«Инешләр Иделгә кушыла» җыентыгын укып чыгасың да яңадан тугрылык турында уйлана башлыйсың. Рәйханә, Һаҗәр кебек геройларның тугрылыклары яктылыгында авторларның бүгенге көнгә, бүгенге әдәбиятка тугрылыклары күз алдына килеп баса. Бирәдә, мөгаен, «Салават күпере» белән Фәрит Гыйльметдинов яктылык үзгендә торадыр. Гражданнар сугышы чорыннан алынган бер эпизод шундый матур, оста итеп сурәтләнгән, хикәя геройларының сулышын сүзләр музыкальлеге аша да, як-

ты буяулар белән ясалган гүзәл картиналардан да, әдәби детальләрнең мәгънәле торышлары һәм куелышлары аша да, аларны бәйләүче күзгә күренмәгән җепләрнең нәфис яңгыравында да тоябыз. Бер малай авызыннан сөйләнгән бу хикәя ихлас булуы, яшь укучы күңеленә шаккатырырлык вакыйга белән түгел, ә хис тирәнлеге, самимилек, саф гүзәллекне тою һәм кичерү аша тәэсир итәргә омтылуы һәм шуңа ирешүе белән балалар өчен язылган бүтән хикәяләрдән аерылып, күтәрелеп, нурланып, җылылык сибеп тора. Ахырда түзгән чәчле бер кызчыкның:

— Малайлар, салават күпере! Яшеле миңа! — дип, яшәү төсен сайлавы да бик тәэсирле. Кайчандыр дошманнар яндырып үтергән Айсылу да шулай кычкырган бит.

Фәрит Гыйльметдинов һәм Тәүфыйк Әйди хикәяләрендәге эре планлылыкка, тирәнлеккә, киңлеккә омтылу бүгенге прозабызның үсеш юнәлеше белән тәңгәл килсә, аны көчәйтсә, җыентыкның күп кенә әсәрләрендә бу юнәлештән читкә өстерәүче агым да чагыла. Хәтта Кояш Тимбикова әйбәт образ тудыра алса да, аның повестеның, әдәби әсәр буларак, көчәйтерлек күп урыннары калган. Шуларның берсе — ваклыклар. Һаҗәрнең төнлә эшләп барган тракторда йоклап китүе һәм чак кына упкынга очмый калуы. Ул, тормышта зур вакыйга булуга карамастан, әдәби әсәр өчен ваклык булып кала. Упкын караңгылыгы безнең Һаҗәрне бер яктан да яктыртмый. Фикер көче ягыннан әйбәт кенә килеп чыгарга тиешле эпизодларны сурәтләгәндә, авторның газеталарда да инде тапталып беткән салкын сүзләр куллануы бу эпизодларның тәэсирен, образлылыгын нык киметә.

Билгеле, җыентыктагы әсәрләр шушы ике-өч әсәр белән генә чикләнми. Болардан тыш, анда тагын унлап автор катнаша. Аларның да шактый төзек, шома язылган хикәяләре бар. Биредә мин үземне аеруча нык дулкынландырган әйберләргә генә тукталдым.

Бүгенге хикәябез үсешендәге ямьсез яклар җыентыкка кергән «Җир яшәргәндә» (Мөгъсүм Хәбибуллин), «Күл буенда пар тирәк» (Г. Шәрәфи) һәм Г. Сәйфетдинов әсәрләрендә дә күренә. Аларның ямьсезлеге шунда, бу әйберләрдә сәнгать, аның нигезе булган образлылык юк яки бик йомшак. Авторлар үз максатларын вакыйга сөйләүдә, фактлар бирүдә генә күрәләр. Ә аларның эчке көченә, мәгънә пружинасына, тәэсир байлыгына игътибар итмиләр. Шуның аркасында хикәяләр вакыйгаларны, өстән-өстән генә аерып, көчле хис-тәэсирсез, тавыш-тынсыз һәм битараф ачалар.

Авторларның үзләренеке кебек, аларның хикәяләрендәге персонажларның да үз сүзләре, үз йөзләре булмау, аларның бик схематик, җансыз фикерләве дә — әнә шул тирәнлекнең җитмәвеннән.

Бүгенге прозабыз бу кимчелекне нигездә җиңеп, төзәтеп килгәндә, аның яңадан яшьләр иҗатында күренүе уйланырга мәҗбүр итә. Урта буын, хәтта өлкән язучыларыбызның җиңел кулдан язылып атылган һәм матбугатта күренгәләп торган әсәрләре дә яшь авторларның үз иҗатларына булган таләпчәнлекләрен йомшарталар, ахры. Ничек кенә булса да, шунысы ачык: бу агым инешләрне бүгенге прозаның олы, көчле Иделенә алып чыкмый.

Бу китап турындагы гомуми тәэсирне тагын шунысы боза, аның билгеле бер адресаты юк. Җыентыкка кергән әсәрләр кече яшьтәге мәктәп балаларыннан алып, яшьләр дип аталырга лаеклы 9—10 класс укучыларына кадәр адресланган. Ә алар бит — ике зур дөнья! Китапның исемен «Инешләр Иделгә кушыла» дип куюы аның яшь әдәби көчләр җыентыгы икәнен әйтә. Ләкин монда игътибар үзәгендә китапның төп хуҗасы — укучы торырга тиеш иде.

Шулай да яшь прозаикларның җыентыгын туплап чыгару — әдәбият күгебездә сирәк балкып торган салават күпере. Ул безнең өчен зур сөенеч. Шуңа күрә Фәрит Гыйльметдинов хикәясендәге түзгән чәчле кызчык кебек:

— Малайлар, салават күпере! Яшеле миңа! — дип кычкырасы килә.

**Мансур ВӘЛИЕВ.**

# МЕСКЕНЛЕКТӘН КИЛГӘН АВАЗ...

«Казан утлары» журналы редакциясенә илебезнең төрле почмакларыннан көн саен дистәләрчә хатлар килә. Хат авторлары «Казан утлары»нда һәм Татарстан китап нәшриятында басылган яңа әсәрләр хакындагы тәэсирләре белән уртаклашалар, киңәш сорыйлар, журналга шигырьләрен, хикәяләрен тәкъдим итәләр. Укучылар җибәргән шигырь, хикәяләрнең яхшы дип табылганнары журнал битләрендә урын ала, сәнгатьчә эшләнеше түбән булган әсәрләрнең авторларына редакция хезмәткәрләре һәм танылган әдипләр, киңәшләрен биреп, җавап язалар.

Төрле телдә, төрле шрифтта һәм төрле яшьтәге кешеләр тарафыннан язылган бу хатларны укуы рәхәт. Шул хатлар аша син күпме дустың белән сөйләшкәндәй буласың, аларның йөрәк җылысын тоясың. Билгеле, хатларның географиясе Татарстан һәм туган илебез белән генә чикләнми, чит мәмләкәтләрдә яшәүче ватандашларыбыздан да ара-тирә хәбәрләр килеп тора. Күпчелек очракта үзләренең мөһаҗирлектәге язмышларыннан зарланучылар ватандашларыбыз арасында, сирәк кенә булса да, Совет Татарстанына, татар халкына кара ачу, нигезсез үч саклаучы бәндәләр барлыгы турында да сөйли ул хатлар. Шундыйларның әйтүенә караганда, имеш, илебездә татар әдәбиятының, сәнгатенең үсеше хакында борчылулар юк. Имеш, татар әдәбиятын һәм сәнгатен Америкада, Көнбатыш Германиядә һәм башка чит илләрдә яшәүче татарлар үстерә.

Карап карыйк: чит илләрдә бүгенге татар әдәбиятының үсеше хакында «борчылып» ятучылар аны ничегрәк үстерәләр икән.

Күптән түгел «Казан утлары» журналы редакциясенә чит илдән бер китапчык килеп керә. Редакция аны, танышып чыгу өчен, миңа биреп торды. Тышлыгына латин хәрефләре белән «Ш. Нигъмәти Шигырлары» дигән сүзләр язылган. Нәшер ителгән урыны — Көнбатыш Германия, Мюнхен шәһәре. Китапны Аяз Хәкимоглу дигән берәү төзегән һәм редакцияләгән. 48 битле бу китапчыкка кереш сүзне дә шул ук Аяз Хәкимоглу язган.

Китапчыкны кулга алу һәм исемен уку белән үк шул нәрсә күзгә ташлана: «шигырь» сүзе, немец телендәге кебек, җөмлә уртасында да баш хәрефтән язылган. Озак еллар немецлар арасында яшәү, күрәсең, Нигъмәтигә дә, Хәкимоглуга да йогынтысыз калмаган. Аннары Аяз Хәкимоглу үзенең фамилиясен «Хәким улы» яки «Хәкимугълы» дип язасы урынга «Hakimoglu» дип алган. «Мөһаҗирлектәге яшь буынны милли рухта (татар рухында — Р. Х.) тәрбияләргә» тырышучы бу бәндәгә үз фамилиясен төрекчәгә җайлаштырып язу, белмим, нигә кирәк булгандыр...

Әдәбият дөньясында җырлап торган матур тел белән язылган шигырь китаплары була. Аларны рәхәтләнеп укыйсың, алардан үзенә бер төрле кабатланмас ләззәт аласың. Икенче бер төр шигырьләрне, һәр юл саен тукталып, андагы фикерләрнең тирәнлегенә гаҗәпләнеп, образларның байлыгына соклана-соклана укыйсың. Ш. Нигъмәти язмаларын (аларны шигырь дип әйтергә тел бармый), ичмасам, шома гына укып та булмый. Аларда укучыны уйландырырлык фикер тирәнлеге дә, игътибарны җәлеп итәрлек образлар да юк. Акың каравы, ритмик чатаклыклар, өч-дүрт юл саен очрап, аптыратып бетерә торган орфографик хаталар, урынсыз прозаизмнар һәм шигырьнең иң гади кануннарын да белмәү хакында сөйли торган башка төрле кимчелекләр тулып ята. Элементар хаталар шул кадәр күп ки, аларны редактор Хәкимоглу юри төзәтмичә калдырмадымы икән, дип шикләнә башлыйсың. Кем белә бит, бәлки, Ш. Нигъмәтигә бу китапчык китерәчәк дан Хәкимоглуның эчен пошыргандыр, көнләштергәндер, һәм ул, форсаттан файдаланып, Ш. Нигъмәтинең наданлыгын фаш итәргә теләгәндер... Бәлки, Хәкимоглу белем дәрәҗәсе ягыннан үзе дә Нигъмәтидән әллә ни ерак китмәгәндер: һәрхәлдә, намуслы һәм үз эшенә җитди караучы редактор булса, А. Хәкимоглу китапчыкны бу хәлендә укучыга тәкъдим итмәс иде.

Ш. Нигъмәти дә, бәлки, түбәндәге язмасында Хәкимоглу һәм аның нше башка «дуслары» турында сөйлидер:

Киң урманнар бакчам булса,
Хайваннары булыр дусларым.
Хайваннар бит алар көнләшмиләр,
Дуслык антын алар бозмыйлар,
Кич утырып гайбәт язмыйлар.

Хәкимоглу язган сүзләргә карагандa, Ш. Нигъмәтинең большевизмга каршы көрәшкәндә язган шигырьләренең кыйммәтлеләре сугыш беткән вакытта югалганнар һәм бу китапка аның анда-монда сакланып калган һәм сугыштан соң язган әйберләре генә кергән икән ләбаса. Авторга, аның китабына моннан да «шәп» рекламаны Хәкимоглу кебек «тугрылыклы», чын «дус» кына ясый ала.

Ш. Нигъмәтинең «мөһаҗирлектәге яшь буынны милли рухта тәрбияләү һәм илебезне [безнең Татарстаныбызны — Р. Х.] большевизмнан азат итү өчен көрәштә файдасы» тиярлек язмалары булгандырмы, юктырмы, анысы билгесез. Әмма Хәкимоглуның рекламасында хаклык бар. Китапчыкка тупланган язмалар күңеле, рухы, акылы картайган бәхетсез бер бәндәнең уйларын, кичерешләрен чагылдыралар. Хәкимоглу үзенең кереш сүзендә бу хакта да басым ясап әйтә: бу шигырьләр авторның «әкренләп картаюын һәм картлык көннәренең караңгылыгын чагылдыралар», ди. Янәсе, картаеп, шәлберәеп калган кешедән ничек инде көрәштә корал булырлык шигырь өмет итәсең!.. Шул рәвешчә, Хәкимоглу үзенең «дустыннан» усал итеп көләргә дә, аны астыртын гына мәсхәрәләргә дә күп сорап тормый.

Сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан Ш. Нигъмәти китабына тупланган язмалар уникe-унөч яшьлек баланың беренче, өйрәнчек әсәрләрен хәтерләтә. Образсыз җөмләләрдән, мантыйксыз юллардан, беркатлы фикерләрдән һәм минем-синең, икән-микән, йөрәк-киләчәк, менәрмен-күрермен кебек рифмалардан гыйбарәт бу язмаларны Хәкимоглу, күрәсең, башкасы, шәбрәге булмаганга чыгарырга мәҗбүр булгандыр. Татар әдәбиятын «үстерүче» чит илдәге ватандашларыбыз арасында, күрәсең, Ш. Нигъмәти кебекләр дә «шагыйрь» хисабында йөриләр.

Дөрес, арада кызыклы гына язылганнары да очрап куя. Мәсәлән:

Беләм, дөнья, син ялган.
Синең ялганлыгыңны белеп алданмам.
Аулама мине алтын күрсәтеп,
Алдама мине язуыңны күрсәтеп...
Кышың киң түгел, кызың тиң түгел...

Тик Шәйхзадә Бабичның 1915 елда ук язылган мәгълүм шигырен хәтерләтә түгелме соң ул! Менә Ш. Бабич шигыре:

Әй, дөнья, шашма!
Юкны алдашма;
Синең хәлеңә
Мин бит бик ашна...
Беләм: син ялган,
Белеп алданам.

Алдама мине
Язың күрсәтеп,
Аулама мине
Кызың күрсәтеп...
Язың киң түгел,
Кызың тиң түгел!..

Әмма, Ш. Нигъмәти язмасыннан аермалы буларак, Бабич шигыре ялтырап, җырлап тора. Классик шагыйрьне шул рәвешчә бозу да әдәбиятны үстерүгә керә микәнни!

Тагын бер мисал:

Эзлим айлар, эзлим еллар,
Эзлим һич туктамыйча.
Көндез эзлим, төннәрендә
Уйкымын йокламыйча.

Мене Сәгыйт Рәмиевнең 1909 елда язылган «Сызла, күңелем!» дигән мәшһүр шигыре:

Сызла, сызла, сызла, күңелем!
Сызла бер туктамыйча.
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча!

Ш. Нигъмәтинең Дәрдмәндтән, Крыловтан «чәлдергән» язмаларын китереп тормыйм инде. Үзенең бер язмасын аз гына үзгәртеп, ике мөстәкыйль әсәр итеп бастырган, ягъни үзеннән-үзе урлаган кешегә чын шагыйрьләрдән күчереп язу, күрәсең, берни дә түгелдер. Прогрессив сәнгать дөньясында һәм безнең илдә Ш. Нигъмәтинең бу «шаярулары» плагиат дип атала, һәм плагиатта гаепләнүче кеше хөкем ителә, җәзага тартыла... Редактор буларак, Ш. Нигъмәтинең башкалардан урлаган шигырьләрен дә җыентыкка кертеп, А. Хәкимоглу «дустын» шактый күңелсез хәлдә калдырган. Бәлки, Хәкимоглу моны Нигъмәтине тагы бер мәртәбә төп башына утыртыйм әле дип тә эшләмәгәндер. Бәлки, болар Хәкимоглуның татар әдәбиятын һәм сәнгатен белмәве белән генә аңлатыладыр. Әмма ни генә булмасын, Ш. Нигъмәти кебек бәндәләр шагыйрьләр рәтендә йөргәч, А. Хәкимоглу кебек белемнәре чамалы адәмнәргә китап чаклы китап язмышы ышанып тапшырылгач, чит илләрдәге «әдипләрнең» хәле, чыннан да, мөшкилдер.

Мин Болгария, Польша, Германия Демократик Республикасы, Чехословакия, Япония, Франция һәм башка илләрдә яшәүче төрле милләттәге яшьтәшләремне беләм. Укымышлы, киң мәгълүматлы, югары зәвыклы XX гасыр кешесенә Ш. Нигъмәти язмалары дәрәҗәсендәге әсәрләрне тоттыру кешене, заманны, әдәбиятны ихтирам итмәү булыр иде. Хәер:

Кешеләргә мин сөйли алмыйм,
Алар бар да усаллар,
Кыяфәтләре белән пәйгамбәрдәй,
Йөрәкләре белән җыланнар,—

дигән бәндәдә заман кешесенә, яшьләргә карата нинди ихтирам булу мөмкин!.. Алай гына да түгел, Нигъмәти мөһаҗирлектәге яшь буынны күзләренә карап алдый. Үзе Советлар илендә, Иртеш елгасы буенда үткәргән «гөнаһсыз яшьлек чагык» сагына, «үткән хаталарны төзәтә алмый гомерең буе үкенеп янарсың», дип офтана, үзе мөһаҗирлектәге яшь буынны Совет илендәге яшьтәшләренә каршы котыртып, алдап ата, аларның болай да бәхетсез язмышын үзенеке кебек гөнаһлы, яшьлекләрен үкенечле итмәкче була. Татар илендә «ирек таңы» аттырыр өчен тырышып йөреп тә берни булдыра алмаячагына төшенгән, «инде юллар эзләмәм, маяк эзләп, инде күкне күзләмәм»,— дип, идеалларына кул селтәгән һәм мескен язмышына буйсынган бу бәндә, яшьләргә карап:

Кайда гына син торсаң да,
Истамбулга юнәлт йөзеңне.
Сөй син аны туган анаң кебек,
Сакла аны кызганмыйча үзеңне,—

ди. «Әйдә безнең белән зур эшкә, милләт ирке өчен көрәшкә», дип тәкерек чәчә. Беркайчан да тормышка ашмаячак бу чакыруга каршы татар халкының тугрылыклы улы Тукай 1907 елда ук үз сүзен, хак сүзен әйтте инде:

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр:
— Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! — диләр.
Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен...

Татар әдәбиятыннан, татар тарихыннан мәгълүматлары булмаган, эмиграциядә туып, татар халкыннан аерылып үскән кешеләрдән Тукайның бу җавап сүзләрен Нигъмәти һәм Хәкимоглу кебек бәндәләр яшерәләр, ахры, һәм яңа фикер дип, әллә кайчан серсеп беткән лозунглар күтәреп чыгалар. Капитализм илләрендә яшәүче ватандашларыбызның илебез тарихы һәм аның бүгенгесе турында дөреслекне белмәүләреннән явыз максатларда файдалану — төрле «советологларның», «татароведларның» һәм буржуаз милләтчеләрнең яраткан ысулы.

Ш. Нигъмәти язмаларының лирик герое кылган кыңгыр эшләремне сизмәсләрме, сизсәләр кичерерләрме-кичермәсләрме дип, баш ватучы җинаятьчене хәтерләтә. Бөек Ватан сугышы башлангач, илне «большевизмнан азат итү» кебек «бөек теләк белән юлга чыккан», шул теләген тормышка ашыру өчен илен, халкын саткан бу бәндәгә кайчакта «күмелгәч тә инде үзеңне кемнәр ни дип искә алырлар!» шикелле

тыигысыз уйлар кылә башлый. Бу инде — вөҗдан газабы. Ләкин этлекләр эшләнгән, пакьлеккә таба илтә торган күперләр яндырылган... Туган иленә кайту юлын халкына хыянәте белән кискән бу бәндәне үзенең Мюнхендагы дуслары, ватандашлары ничек искә алырлар икән соң! Ш. Нигъмәти аларны үзенең язмаларында бүреләр һәм гайбәтчеләр дип тә, канэчкечләр һәм хайваннар дип тә, әләкчеләр дип тә атый. «Кунак ашы — кара каршы» димәсләр микән! Нигъмәтинең хәзерге хуҗалары үз илен сата алган кешенең, җае чыкса, ят илне дә рәхәтләнеп сатачагын, үзен саткан хыянәтченең башкаларга да хыянәт итәчәген белмиләр түгелдер. Гомумән, тормышны пычрак дип атаучыны (Ш. Нигъмәтинең тормышы, бәлки, пычрактыр да), дөньяны ялган дип бәяләүчене, ми — тәрек дип, халкы исеменнән баш тартучыны ничек искә алачаклары көн кебек ачык. Шуны сизеп булса кирәк, Ш. Нигъмәти:

Авырмас иде башкаем,
Минем язмышым кара,—

ди үзенең бер язмасында.

Шунда ук ул язмышының ни өчен кара икәнлеген дә аңлатып китә: «читтә ялгыз булганга» һәм Совет Татарстанын милләтчеләр Татарстаны итәргә дигән нияте, «уйлары реаль булмаганга». Бу уйлары белән Ш. Нигъмәти Хәкимоглуның әлеге китапчык «илебезне большевизмнан азат итү өчен көрәштә файдалы булачак» дигән өметләрен чәлпәрәмә китерә түгелме соң! Алданган, алданган Хәкимоглу! Алдаган, алдаган Ш. Нигъмәти үзенең редакторын! Китапчыкның кереш сүзендә автордан зирәгрәк булып күренгән Хәкимоглуны Ш. Нигъмәти матур итеп төп башына утыртып куйган...

Ш. Нигъмәти «милләт азатлыгы» турында сөйләнергә ярата. «Милләт азатлыгын» ул татар халкының большевизмнан, ягъни социализмнан, азат булуында күрә. Социализмның илебездәге барлык милләтләргә чын хөрлек китерүе хакында, шул хөрлеккә нигезләнеп, татар халкының әдәбияты, рәсем, музыка, театр сәнгате, экономикасы нинди югарылыкка күтәрелүе турында «Казан утлары»н укучыларга сөйләп торасы юк. Ш. Нигъмәти һәм А. Хәкимоглу кебек бәндәләр бүген, күрәсең, татар халкын әнә шушы иректән «азат» итәргә хыялланалар. Безнең бу ирегебездә — ил уллары Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитовлар рухы, аларның йөрәк тибеше. Алар — татар совет халкының милли каһарманнары, ә каһарманнарны халыкка көчләп тагып та, халыктан көчләп алып та булмый. Кан белән яулап алган, кан түгеп Антантадан, җан биреп фашизмнан саклап калган ирекне — шулай ук!

А. Хәкимоглу үзенең кереш сүзендә Ш. Нигъмәтине «ирек сөюче татар улы» дип атый, аны халык улы дип бәяләмәкче була. Халык улларының халыкка каршы кара ният, хаинлек саклап йөрүләрен кешелек тарихы белми. Халыкның туры уллары дип тарих Муса Җәлил, Юлиус Фучик, генерал Карбышев кебек чын патриотларны исәпли. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре кебек чын патриотларның авазлары, Моабитларны җимереп, илгә кайта, халык йөрәгенә юл таба һәм мәңге үлмәс җыр булып яңгырый.

Ш. Нигъмәтинең очы очка ялганмый торган язмаларын укыганда явызлыгыннан үзе үк кибә башлаган бер бәндә белән очрашкан кебек буласың. Күңеленең салкынлыгы чиркандырып җибәрә, уйларының мескенлеге кызгандыра. Туган туфрагын саткан бәндәнең язмышы менә нинди була икән дип, баш чайкап куясың.

Рөнат ХАРИС

# *ЯҢА КИТАПЛАР*

**Р. МОСТАФИН. По следам поэта-героя. Рус телендә. Мәскәү. 1971 ел.**

Европа илләренең бик күп шәһәрләрендә сугышта үлгән билгесез солдат истәлегенә, фашизм һәм империализм корбаннары истәлегенә мәңгелек ут яна... Икенче бөтендөнья сугышы миллионнарча кеше гомерен кисте, миллионлаган кешеләрнең фаҗигале һәм героик язмышлары әле һаман да безгә билгесез булып кала бирә. Аларның көрәштәшләре сөйләгәннәрдән, шул чордан калган документ, хатлардан гына без күп нәрсә белә алмыйбыз...

Икенче бөтен дөнья сугышында, фашистлар лагеренда, үлем камерасында һәлак булган кешенең язмышын белү никадәр авыр эш икәнлеген мондый эшкә алынган кеше үзе генә белә торгандыр. Фашист җинаятьчеләре, җинаятьләре өчен җавап бирүдән куркып, эзләрен бик нык яшерергә тырышканнар. Сугыш беткәннән соң да геройларның язмышын ачыкларга керешкәнче байтак еллар үтте. Вакыт дигән нәрсә үз эшен эшләп өлгергән: шаһитләр үлгән, документлар югалган, хәтердәгеләр онытыла башлаган...

«Герой шагыйрь эзеннән» исемле китабында Рафаэль Мостафин безне фашизм тоткынлыгында һәлак булган татар шагыйре Муса Җәлилнең язмышын ачыклау эшенә алып керә китә, геройның язмышы белән кызыксынучы кешеләр ярдәмендә берничә ел буена җыеп, туплап килгән эзләнү нәтиҗәләрен бирә.

Мин үзем дә, герой шагыйрьнең язмышын ачыклау эшенә катнашучы кеше буларак, бу китапны эчке бер дулкынлану белән укып чыктым. Бигрәк тә китапта Муса Җәлилнең язмышын ачыклау күп кешеләрнең уртак эше итеп күрсәтелүен, бу эшкә катнашучы бик күп кешеләрнең (Советлар Союзында һәм башка илләрдә яшәүчеләрнең дә) хезмәтенә тиешле бәя бирелүен басым ясап әйтеп үтәсе килә. Шуның белән бергә, китаптагы төгәл ачыкланган фактлар (алар байтак!) айсбергның судан калкып торган өлеше кебек күренсә, су астындагы өлешен исә күп тырышлык куеп та ачылмый калган нәрсәләр тәшкил итәдер кебек.

Теге яки бу фактны ничек тапканлыгын, ачыклаганлыгын күрсәтү авторның төп бурычы түгел. Бу алым — ялкынлы патриот һәм интернационалист Муса Җәлилнең образын мөмкин кадәр документаль һәм ышандыргыч итеп тудыру чарасы гына. Р. Мостафин, чын күңелennән яратып, сокланып, укучыга Җәлилнең көрәштәш дусларын да күрсәтә.

Рафаэль Мостафин гади репортер гына түгел, бу эзләнүләргә ул актив катнашучы кеше. Шушы хәл авторның, беркадәр мавыгып китеп, кайбер нәрсәләргә артыграк урын бирүенә дә сәбәп булган, күрәсең. Мәсәлән, шагыйрьнең Моабит дәфтәрен коткарып калган Андре Тиммерманска, Рениеро Ланфредини белән чагыштырганда, китапта урын шактый аз бирелгән кебек. Минемчә, Ланфредини язмаларын тарихчылар яңадан бер карап чыгарга, кайбер нәрсәләрне ачыклый төшәргә тиеш шикелле. Болар, әлбәттә, кечкенә кимчелекләр. Авторның төп уңышы — фашизмга каршы көрәшкән герой шагыйрь Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында яшьләр өчен дулкынланып укырлык китап язуында. Яшьләргә мондый китаплар бик кирәк. Совет пионерларының һәм яшьләр клубларының, мине хәтта Берлиннан эзләп, дистәләгән хатлар җибәрүләре дә шул хакта сөйли. Алар туктаусыз эзләнәләр, кызыксыналар, Муса Җәлил турында яңа материаллар җибәрүемне сорыйлар. Әлеге китапның тиражы шактый зур, укучыларның ихтыяҗын канәгатьләндерер дип уйлыйм.

**Леон НЕБЕНЦАЛЬ,**
немец язучысы

Вакыйф Нуруллин

# ЛЮЗИЯ

ХИКӘЯ



Хатын-кыз иптәшләр!

Як-ягыгызга карагыз әле: ир-ат заты юкмы ул тирәдә?.. Нигә алай дип сорыйммы? Аныￂсын соңыннан аңларсыз. Ә хәзер тагын бер кат тирә-ягыгызны бик яхшылап тикшерегез: ир-ат токымыннан берәрсе, озын муенын сузып, тыңлап тора күрмәсен!.. Ярый, булмаса бик әйбәт. Ә хәзер мине тыңлагыз!

Иң элек сезгә минә мондый сорау: әйтегез әле миңа, ир-ат кавеменнән дә юләр, ир-ат кавеменнән дә көнче, ир-ат кавеменнән дә алдакчы һәм вәгъдәсез җан ияләре бармы бу дөньяда?.. Нигә дәшмисез?.. Әһә, уйлашыйк әле, дисез икән. Ярый, ярый, уйлаша торыгыз! Ә мин шул арада сезне азрак үзем белән таныштырып китим.

Исемем Люзия булыр минем. Нәрсә?.. Сәеррәк исем икән, дисезме? Килешәм. Минем үземә дә сәеррәк тоела бу исем. «Иллюзия»гә, ягъни гомер булдыра алмастай нәрсәләргә алданып, шуларга ирешәм дип, омсынып йөрүне аңлата торган сүзгә бик тартым ул, шулай бит?

Ләкин, ни хәл итмәк кирәк, мин кушкан исем түгел бит. Әти белән әни уйлап тапкан нәрсә. Хәзер үзләре дә үкенәләр үкенүен. Җисемеңә болай ук муафыйк булырын белгән булсак, муеныбызга пычак салсалар да, бу исемне кушмаган булыр идек, дип акырышып еламыйлар гына тик. Хәтта исемемне үзгәртеп, Люция дип тә дәшеп карыйлар. Ләкин эш узган шул инде. Исемне үзгәртсәләр дә, җисемне берни дә эшләтә алмыйлар.

Ә минем җисем бик нык муртайган инде. Ничә яшьтә соң син, дисезме? Бу турыда сораганны бер дә яратмыйм мин. Әйткәндә дә, кешесенә карап, я биш-ун яшькә, яки унбиш-егермегә кечерәйтеп әйтәм. Әмма сез үзебезнең кавем, кешегә-карага шауламассыз дип уйлыйм. Шушы айның уникенче числосында утыз сигезне тутырып, утыз тугызынчыга чыктым инде мин. Ә үзем әле һаман ялгыз яшим, һаман кияүдә түгел әле... Нигә барыгыз да берьюлы авыр сулап, көрсенешеп куйдыгыз? Шушы яшеңә җитеп, шушы чибәрлегең белән

сиңа да кияү табылмагач, без нишләргә тиеш икән соң инде дип аптырашка калдыгызмы әллә? Хафаланмагыз юкка. Сораучылар да, алучылар да бик күп булды мине! Ул яктан, шөкер, зарланырлык түгел... Ә шулай да күрсенешеп бик дөрес иттегез сез. Күрсенерлек эшләр булды минем. Ул турыда мин мөмкин кадәр зарак уйларга тырышам. Ләкин барыбер уйландыра шул...

Аннары, юк-юк дисәң дә, малай да хәтергә кереп, күңелне борчып куя. Нинди малаймы? Унҗиде яшен тутырып, унсигезенче белән бара торган малаем бар икәнлеген әйтмәдеммени соң әле мин сезгә? Гафу, алайса, гафу, хатын-кыз иптәшләр. Әйе-әйе, бик матур һәм бик таза булып үсеп җитеп килә торган, быел унынчыда укыячак малаем бар минем!

Дөрес, минем янда тормый ул торуын. Авылда, әти белән әни янында яши. Тууына тугыз ай тулган көнне әни кулына тоттырып, үзем шәһәргә бәхет эзләргә китеп барган идем, шуннан бирле гел аларда тора инде. Шәһәрдә яшәсәм дә, бөтенләй үк онытып бетермим мин аны. Ел аралаш, ике елга бер тапкыр булса да, авылга кайтып, хәлен белеп, күрешеп торырга тырышам. Ләкин малай мине рәтләп белми дә, белергә теләми дә. Акылга утырасы урында елдан-ел кирегә китә — миннән читләшә бара. Тездә чакта сөйдерә, тездән төшкәч — көйдерә, дип менә шушы минем малай шикелле балаларга карата әйтә торганнардыр, күрәсең. Элек, ул сабый чагында, кайтып төшсәм, әнием дә әнием дип, сырпаланып кына тора, бер минутка да янымнан китми торган иде. Ике-өч көн торып, ә кайчакларда хәтта берәр атна яшәп, китеп барган чакларымда артымнан күз яшьләре белән елап калыр иде. Ә менә соңгы дүрт-биш ел эчендә, әйтерсең, пәри алыштырып куйды инде! Әни дип тә әйтми башлады хәтта. Элек егерме алты тиенлек бер кисәк шоколад алып кайтсам да түбәсе күккә тия торган иде. Ә менә бу елгы соңгы кайтуымда, егет булып килә, Мишәдә иптәшләре белән су коенган чакларында трусик киеп, уңайсызланып йөрмәсен, кеше арасында кеше төсле булсын дип, бер сум да кырык тиенлек өр-яңа сатин плавки алып кайткан идем — шуңа да исе китмәде:

— Кирәк булса, минем үземнең дә ике нейлон плавкием бар. Тик әлегә хаҗәтләре генә юк. Безнең Мишә болыны сезнең Казан пляже кебек түгел ул, анда плавкисыз да рәхәтләнеп коенырга була: сарыклардан башка җан ияләре күрми мине анда. Ә сарыклар күрсәләр дә гаеп итмиләр! — диде дә, плавкиема борылып та карамыйча, урамга ук чыгып китте.

Җәйге каникулы вакытында көтүче ярдәмчесе булып, колхоз сарыкларын көтеп йөргән була икән. Ә сөйләшүенә караганда — бер дә харап. Бик эредән чирттергән була. Әле шушы соңгы кайтуымнан киткәндә, иңләп кенә, тәмле телем белән генә:

— Тагын берәр елсыз кайта алмам инде, улым. Исән-сау булып тор. Моңарчы йөземә кызыллык китермәдең, кара аны, моннан ары да шулай матур гына тот үзеңне! — дигән идем, шуңа ничек дип җавап бирде дисез?.. Күзенең агы белән каш астыннан гына усал итеп бер карады да:

— Үзеңә булмаган акылны кешегә сатып маташма, ичмаса! Ничек яшәргә кирәген без үзебез чамаларбыз анысын. Бар, юлыңда бул! Һәм, адәм көлдереп, бүтән монда кайтып йөрисе булма! — дип калды.

Ә мин инде аның тәмам үсеп, кеше булып килүенә куанып, картаймыш көнемдә бер таянычым булыр дип өметләнеп йөри идем тагын. Көт инде болай булса, таяндырыр!.. Хәер, безнең совет законнары бик гуманный бит алар — андый гаделсезлеккә юл куймаслар әле. Үз теләге белән газиз анасына ярдәм кылмый икән, ул чакта суд

аша ярдәм иттерергә туры килер... Ә шулай да үйландыра, хатын-кыз иптәшләр. Үйландыра малайның бу кыланышлары!..

Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың шул. Әти бик яман холыклы бәндә безнең. Әле менә шушы узган юлы кайтканымда гына да, малайның мине күрше авыл марҗасы урынына да күрмәвенә хәтерем калып:

— Нишләттегез сез, әти, бу малайны? Әлек әни дип үлеп торадырые, ә хәзер бөтенләй бизгән әнә. Син шулай котыртасындыр инде,— дигән идем, секунд эчендә күркә шикелле кабарынып чыкты да, урыныннан ук сикереп торып:

— Һәй, яхшыдан яман туган нәмәрсә! Нишләп мин котыртыйм ди аны? Үз акылы юкмыни аның? Синең ниткән сәрхәнтәй икәнлегеңне күрмимени ул? Кара ул иреннәреңне дә кара ул чәчләреңне! Дөнья гыйбрәте итеп буяп бетергәнсең бит! Күлмәк итәгеңә генә күз сал әзрәк: штан бөрмәңә менеп җитә язган лабаса! — дип, ярты сәгать буена котырынды. Анда да туктар исәбе юк иде әле, чыгып китеп кенә котылдым...

Я, хатын-кыз иптәшләр, минем теге сорауга җавап әзерләдегезме? Я, кайсыгыз сүз алып сөйләргә тели?.. Сузмагыз! Минем озаклап көтеп торырга вакытым юк. Сезнең ирләрегез кебек, кайтып керешемә колач җәеп, сагынып каршы алучы кешем юк минем. Әле менә бүген Мәскәүнең үзеннән килгән бер командированный абыегыз янына барасым бар... Я, я, кайсыгыз нәрсә әйтергә тели?.. Ничек? Үз соравыңа үзең генә җавап бир инде, дисезме! Кызык икән сез! Ә минем сезнең фикерләрне ишетәсем килгән иде... Ну, ярый, алай бик үтенеп сорагач, тыңлагыз, алайса, рәхим итеп. Башладык!

Курыкмыйча әйтә алам: минемчә, ир-ат нәселеннән дә юләр җан ияләре юк бу җир йөзендә! Ни өчен алай кистереп әйтәмме? Белмәсәм тик кенә торыр идем, белгәнгә күрә әйтәм. Мисал дисезме? Рәхим итегез!

Моннан егерме еллар элек, Люзия апагызның чәчрәп торган кыз чагында, Наил исемле бер егет кисәге, дөньясын онытып, гашыйк булган иде. Ә Люзия апагыз Наилне түгел, Назыймны ярата, шунысы белән йөри иде. Наил шушы нәрсәне бик яхшы белә. Ләкин, белә торып белә дигәндәй, һаман артымнан чаба бу минем.

— Теләсәң ни эшләт, Люзия, ләкин мин сине яратудан мәңге туктамаячакмын. Мәхәббәтеңә үк дип әйтмим, һич югында, синең белән бер кич кенә сөйләшеп утырырга лаек булыр өчен, әйт, зинһар, нинди эшләргә тиеш мин? — дип аптырата.

Шуның өстенә, атна саен дип әйтерлек, ислемаендыр, пудрасындыр, иннек-кершәнендер бүләк итеп тора бу миңа. Ә Назыйм уйлап та карамый андый нәрсәләр хакында. Шулай булса да, мин аны якынрак күрәм. Үземне гел аңа озаттырам. Ләкин Наил миңа үпкәләми. Аның күзе-башы тонган, мәхәббәттән исергән ул. Һаман миңа бүләк ташый, һаман бер генә тапкыр булса да озата кайтырга рөхсәт итүемне үтенә. Шул тиклегә барып җитә — күзеннән яшьләр бәреп чыга кай чакларда.

Бу хәлләрне тамаша кылу бер үк вакытта кызык та, кызганыч та миңа.

Шулай да тора-бара кызыгы кимеде, кызганычы арта башлады. Һәм мин, кешене гел болай тинтерәтеп йөрү килешеп бетмәс, бүләкләрен дә алмаска, аннары аның көче җитмәстәй бер авыррак эш кушарга да бөтенләй котылырга кирәк бу тиле гашыйктан, дигән карарга килдем.

— Наил җаным,— дидем мин аңа.— Наил акыллым, әгәр мине яратуың хак икән, әйдә көндезге нәкъ сәгать уникедә мәчет манарасына мен дә: «Тыңлагыз! Тыңлагыз! Авылыгыз егете Нәбиев Наил

сөйли! Ул шушы авылның Люзия исемле бик чибәр бер кызын ярата һәм гомере буена аны шулай сөеп кенә торырга сезнең каршыгызда ант итә!» — дип кычкыр әле. Кычкыра алсаң — Назыймны ташлыйм да синең белән генә йөри башлыйм.

Безнең авылның мәчете инде хан заманыннан бирле эшләми, шунлыктан манарасына менеп берәүнең дә азан әйткәне юк. Ә минем манарадан кычкырганны бик ишетәсем килә иде. Теге тинтәк, Наилне әйтүем, тәки риза булды бит шул сүзгә.

— Синең өчен манарага гына түгел, айга менеп кычкырырга да әзер мин, Люзиякәем! — генә диде дә нәкъ мин кушкан көнне, нәкъ мин кушкан сәгатьтә манарага менеп, нәкъ мин әйткән сүзләрне кычкырды. Куркып-оялып кына да түгел, өч тапкыр рәттән кычкырды!..

Я, менә шушыннан соң кайсыгыз әйтә ала инде ир-ат кавемен акыллы дип?.. Нәрсә, син вәгъдәңдә тордыңмы соң, дисезме? Сез нәрсә, ахмак дип белдегезме әллә мине Назыймымны шул юләр Наилгә алмаштырырга? Мин бит аңа чынлап түгел, уйнап кына әйткән идем манарадан кычкырырга. Аны биздерер өчен генә әйтелгән сүз иде ләбаса ул!..

Тик шунысы гына бик үкенечле булды: әлеге юләр дигән Наилем укыды-укыды да, укый торгач, мин гомеремдә күз алдыма да китермәгән зур дәрәҗәгә иреште: Казан институтларының берсендә кафедра мөдире, профессор ул хәзер. Ишетүемә караганда, химия өлкәсендә башкарган фәнни хезмәтләрен безнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы беләләр, ди.

Үзгәрсә дә үзгәрә икән, җәмәгать, кеше дигәнең! Әлеге дә баягы, шул Наилне әйтүем әле. Элек минем белән бер генә сәгать сөйләшер өчен дә җәһәннәм тишегенә барып керергә әзер торган шул йомыкый, хәзер үзем телефоннан шалтыратып, үзем очрашырга чакырганда да «Рәхмәт, булмас ахрысы, вакытым бик тыгыз бу көннәрдә», дигән булып, якын да килми. Бер вакыт хәтта институты ишеге төбендә көтеп торып, күзгә-күз очрашып:

— Наил иптәш Нәбиев, сез бит заманында манарага менеп, Люзия исемле бер кызны гомерегез буена яратырга ант иткән идегез. Шәт, ул антыгыздан ваз кичмәгәнсез бит әле? — дип тә әйтеп караган идем. Шунда да алай бик капланып төшмәде. Авызының бер чите белән генә елмайды да:

— Күрәм, сез һаман шаян икәнсез әле. Ә мин ул заманнан соң чак кына үзгәрдем шул инде. Кыскасы,— борчак пешерә алмабыз сезнең белән! — диде дә, нәкъ үзенең күзләре төсле куе зәңгәр «Волга»сына утырып, китеп тә барды.

Я, әйтегез инде сез шул мәхлукны юләр түгел дип! Башта, миңа аның хаҗәте бер тиен булганда, үзе минем арттан өтәләнеп йөрде. Ә хәзер, мин аның өчен үлеп торганда, әйләнеп тә карамыйча китеп барды...

Назыйм белән эшләрең ничек булып бетте дисезме? Иң элек шунысын әйтим: пычагым да чыкмады анысыннан! Тарта-суза җидәнчене бетергән килеш тәки калды ул. Белеме шулай чамалы гына булса да, мине акылга өйрәтә белде үзе. Бер-ике ел табан астыма олтырак булырга әзер булып артымнан йөрде-йөрде дә, мине алдап, көмәнле итеп, армия хезмәтенә китеп барды. Ә аннан кайткач, минем тырнагыма да тормый торган бер мокыт кына кызга өйләнде дә әле һаман да шуның белән яшәп ята. Җиде балалары бар хәзер. Үзе дә, хатыны да тракторда эшләп йөргән булалар. Карап торырга әллә ни шаккатмалы нәрсәләр булмасалар да, ару гына эшлиләр, ахрысы: әле узган айда гына икесенең дә рәсемнәрен газетада бастырып, мактап язып чыгардылар... Минем теге малай әнә шул хәерсез Назыйм-

ныкы инде ул. Әле ярый, шул мәртәткә башымны бәйләмәгәнмен. Баш бәйләнгән булса, тәки рәхәт күрсәтәчәк бәндә түгел икән. Үзе шикелле тракторчы ук итә алмаса да, бала-чага фермасы мөдире итми калмас иде. Шулай бит, хатын-кыз иптәшләр?..

Нәрсә? Ә болай нинди рәхәт күрдең соң син, дисезме?.. Шактый четерекле сорау бу минем өчен. Ник дигәндә, рәхәт күрү мәсьәләсендә алай зурлап мактанырлык нәрсәм бар дип әйтә алмыйм. Ләкин шул ук вакытта артык зарланырлык та булмады шикелле.

Теге мәртәт Назыймнан туган малайны әниләрдә калдырып, шәһәргә баргач та кайбер минем хәлдә калган кешеләр шикелле борын салындырып, кайгырып-аһ орып йөрергә туры килмәде миңа. Кая гына барсам да, егетләрнең күзләре миндә, минем белән бер сөйләшер өчен утка керергә әзер булып торалар иде. Җаным теләгәнен сайлап алырга мөмкин иде. Мин нәкъ шулай иттем дә: Әсәдулла исемле бер бик атчаенные, бик чибәре, бик тазасы белән ныклап торып йөри башладым. Бер ай йөрибез без моның белән, ике-өч ай сөешәбез. Бары да әйбәт, бары да яхшы. Ләкин бит гел болай икең ике җирдә торып булмый. Кавышырга да кирәктер бит инде, ниһаять! Ә кавышу турында тешен дә агартмый теге Әсәдулла абзагыз. Я мине үзләренең өенә (Яңа бистәдә тора иде ул, үз өйләре, әти-әнисе бар иде) алып кайтып, яисә үзе безнең тулай торакка килеп, сөешә дә — шуның белән эше бетә моның. Көтеп-көтеп тә дәшәр чамасы сизелмәгәч, кавышу хакында мин үзем сүз каттым моңа. Шуннан ары да ашыгырга исәбе юк бит бу пәри сукканның. Күзен дә йоммыйча:

— Болай да ир белән хатын булып яшибез бит инде без, шулай булгач нигә безгә андый искелектән калган вак-төяк формальностьлар артыннан йөреп, баш катырып торырга? — ди бу миңа.— Без синең белән язылышып тора башлаганга карап кына кояш барыбер кире яктан чыкмас бит инде! — ди.

Шулай итеп, көлкегә алган булып, турыны кыекка саплап йөри дә йөри бу. Эшләр болайга әйләнә башлагач, мин дә шулай аның кебек бераз шаяртып карарга — тегене профкомга дәштереп, бераз «эшкәрттереп» чыгарырга ниятләгән идем. Ләкин ул миннән өлгеррәк булып чыкты: тотты да, миңа да әйтеп тормастан, безнең фабрикадан эштән китеп тә барды!.. Менә шундый алдакчы әшәке җан булып чыкты анысы.

Шуннан мин нишләде дип уйлыйсыз инде сез?.. Китсәң кит, бар, олак шунда, синнән юньлерәкләре дә бетәсе түгел минем өчен, дидем дә мин фабрикага килеп эшли башлаган көннән бирле минем белән бер сөйләшергә җанын фида кылырга әзер булып, ләкин мәхәббәтен теле белән әйтеп-аңлатып бирергә йөрәге җитмәгән бер слесарьга кияүгә чыгып та куйдым. Бу юлы бөтен шартларын китереп чыктым. Сәмигуллам фабрикада иң яхшы эшләүче слесарь иде. Аның аркасында комсомол туйларына тикле ясадылар. Хәтта, бер генә бүлмәле булса да, квартирына тикле бирделәр.

Шулай итеп, законның бөтен кагыйдәләренә туры китереп, чынчынлап ир белән хатын булып яши башладык без. Сәмигуллам минем өчен үлеп тора. Шул тикле ярата — телим икән һавадагы йолдызларны чүпләп алып бирергә әзер бу. Аның шулай минем өчен җан атып торуын күреп, үзем дә яхшы ук якын итә башладым мин аны. Тик, кызганычка каршы, бу рәхәтем дә озакка бармады. Әлеге дә баягы, шул ир-ат кавеменең көнчелеге һәм алдакчылыгы аркасында инде!

Сәмигуллам белән матур гына, тату гына яшәп яткан көннәрдә, теге чакта, мин койрыгына басарга җыена башлагач, фабрикадан качып киткән һәм берничә айлар күзгә-башка бөтенләй күренмичә

качып йөргән әлеге куян йөрәк — Әсәдулла, тагын кайдандыр калкып чыгып, эштән кайтышыма каршы килеп тора башлады бит, җәмәгать! Сәмигуллам икенче сменада эшли торган көннәрдә фабрика чатына килеп каршы ала да озатып кайта башлады бит шул мәртәт. Озаткан саен әйтә бу миңа:

— Бигрәк тә түземсез инде үзең дә, Люзия,— ди.— Тоттың да бер мокытка башыңны бәйләдең дә куйдың. Мин бит фабрикадан заводка синә өйләнергә теләмәүдән түгел, киресенчә, сине өзелеп яратканга гына киткән идем. Кибеткә товар бушатучы булып эшләп, тизрәк квартира алырга да шуннан ары сиңа өйләнеп, бәхетле итеп яши башларга дигән уй белән киткән идем мин аннан. Инде менә синнән дә коры калдым, квартира бирергә чамалары да күренми әле. Бигрәк тә бәхетсез җан булганмын инде! — ди.

Тора-бара, әйдә, элекке дуслык хөрмәтенә генә булса да, аз гына серләшеп утырыйк әле, дигән булып, тагын өйләренә чакыра башлады бу мине. Ир хатыны икәнлегемне, ир хатынына алай ут итеп иркенәеп йөрергә ярамаганын да бик яхшы беләм. Мин эшне профкомга җиткерергә җыена башлагач теге вакытта качып котылуы да бик хәтеремдә. Ләкин, шулай булса да, нигәдер кызгандым бит шуны. Ул да адәм баласы, җитмәсә, заманында мине яратып та йөргән кеше иде бит, дип уйладым да тасма теленә тәки эредем бит тегенең. Аңа ияреп йөргән вакытларда кеше-кара күрер дип шикләнеп, Сәмигулла икенче сменада вакытларда үзен генә өйгә керткәли башладым бит моның...

Сез ничек уйлыйсыз, хатын-кыз иптәшләр, дөрес эшләгәнменме мин?.. Нәрсә, безнең алай итеп караган юк, белмибез, дисезме?.. Неужели? Я, я, мәтәштермәгез! Булгандыр, сезне дә, гомерегездә бер генә тапкыр гына булса да, озатканнардыр әле. Сез просто әйтергә генә шикләнәсез. Ишетелсә — ирләрегездән рәхим-шәфкать булмаячагын бик яхшы беләсез сез. Шуңа гына дөресен әйтергә шөллисез. Шулай бит?.. Тукта, нигә алай бик каты шаулаша башладыгыз әле сез? Ни җитми сезгә, нәрсә ошамады?.. Әһә, безгә үзеңнең бер тиенгә дә тормый торган фәлсәфәңне көчләп такма, без, синең кебек, хатын-кызларның да абруена тап төшереп, ир-атның да башын әйләндереп йөрүчеләр түгел, дисез инде, алайса. Мактанмасаң да була, алай күкрәк кагарлык эшләрең күренми әле, дисез. Каралә, дөрес сукалыйсыз бит сез, чукынмышлар. Әйе, алай зурдан кубып ук лаф орырлык эш кырганым булмады минем. Ләкин мин сезнең каршыда мактанырга да җыенмыйм бит әле. Киресенчә, зарланып утырам. Кызык өчен түгел, гыйбрәт булсын өчен сөйлим мин боларны сезгә. Ир-ат токымы тирәсендә чамалабрак кыланырга кирәк икәнлеген, югыйсә, ул юньсез затларның сезне дә минем кебек төп башына утыртып калдырулары бик ихтимал икәнлеген аңлату өчен генә сөйлим. Туктагыз әле, кайда туктап калган идем әле мин?.. Әһә, булды, искә төште: Әсәдулла белән, тфү, түгел, Сәмигулла белән нилектән аерылышуыбызны әйтмәкче идем бит.

Анысы менә болайрак килеп чыкты. Әз-әзләп кенә, атнага берике яки атна аралаш кына Әсәдулла белән күрешкәләгәнне дә сизенгән бит минем теге мокыт дип йөргән Сәмигуллам. Сизенгән дә бу, көнчелегенә көч килеп, бер көнне эшеннән сорап кайтып, саклап торган. Саклап торган да Әсәдулла белән утырган чагыбызда гына өстебезгә килеп тә керде. Килеп керде дә күршедәге пенсионерларны шаһитлеккә чакырып, минуты белән эшне судка җиткерде. Андый очракларда судта да алай озын-озак сөйләшеп тормыйлар икән, хатын-кыз иптәшләр. Безне бер сүзсез аердылар да куйдылар.

Шулай итеп, ул Сәмигулладан да уңмадым мин. Аның көнчелеге аркасында харап булдым. Нәрсә?.. Әсәдулласы нишләде, дисезме?

Нишләсен инде ул мөртәт. Анык билгеле инде: тагын шулай җир йоткандай юкка чыкты ул алдакчысы! Ә бит, дөресен генә әйткәндә, шул кабахәтнең юхалыгына алданып шушындый хәлгә калган кеше мин. Ул өтәләнеп йөрмәгән булса, әле хәзер дә Сәмигуллам-җан кисәгем белән чөкердәшеп яшәп яткан булыр идек без...

Шул хәлләрне башымнан кичергәннән ары да кияүгә чыккан идем әле мин. Хатыны алдагы елда гына үлеп киткән тол ир иде анысы. Өч малай, ике кыз атасы иде. Тик балалары берсе дә үзе белән тормый, төрлесе төрле якка таралышып беткәннәр, этиләре белән хат аша гына хәбәрләшеп торалар да ара-тирә кунакка кайткалап киткәлиләр иде. Үземнән унтугыз яшькә олырак булса да, бик ипле, бик сабыр, минем өчен бер нәрсәсен дә кызганмый торган кеше иде ул. Исеме дә колакка ятышлы — Нургазиз атлы иде. Олы кешенеке шулайрак була торгандыр, күрәсең, холкы ягыннан гына түгел, башка якларыннан да бик тыйнак: кирәкле-кирәксез чакта бер дә алай вакланып, борчып маташмый торган иде, мәрхүм. Черегән бай ук булмаса да, мин теләгән әйберләрнең байтагын алып бирергә тырыша торган иде. Эше дә хәйран әйбәт — зур заводларның берсендә транспорт начальнигы булып эшли иде. Мине дә, йөрмә шул фабрикаңда чиләнеп, кил үземнең янга, дип үз заводларына экспедитор итеп урнаштырган иде. Эштән ике-өч сәгатькә соңарып кайткан чакларымда да ашарга үзе пешереп көтеп торыр һәм бер дә зурлап ачуланмас иде.

— Бик сагынып көткәнгә күрә миңа гына шулай тоелды микән, матурым, әллә нигә озаграк йөргән сыман булдың бүген,— дип кенә әйтә иде дә, мин аңа:

— Сиңа гына шулай тоелгандыр, баһадирым! — диюгә каймак урынына эри дә китә торган иде.

Болай карап торырга әйтерлек таза һәм зур гәүдәле кеше булмаса да, баһадир дигәнне бик ярата иде шул, мәрхүм.

— Боерган булса, пенсиягә чыгарга да санаулы айлар гына калып бара. Менә күрерсең, пенсиягә чыккач болай гына булмам әле мин. Шундый гайрәтләнеп китәрмен — таный да алмассың Нургазизеңне! — дип, аеруча куанып-дәртләнеп йөри башлаган иде.

Ләкин андый көннәрен күрә алмыйча калды шул. Бер кичне йокы алдыннан минем белән әзрәк шаярып алырга итенә башлаган иде, шул чакта кинәт кенә йөрәген тотып сыгылып төште дә мин ашыгыч ярдәм машинасын чакыртып йөргән арада, ансат кына итеп, бу фани дөньядан китеп тә барды. Әйбәт кеше иде, бичара, авыр туфрагы җиңел булсын...

Беребез дә мәңгегә килмәгән бу дөньяга. Япь-яшь кенә көенчә үлеп китүчеләр дә була. Ә Нургазиз абзагыз, инде әйткәнемчә, ашын ашаган, яшен яшәгән дигәндәй, зур сугышны башыннан кичергән, аннары килеп, шактый гына җаваплы урыннарда эшләгән, кыскасы — хәйран гына таушалган кеше иде. Шуңа күрә аның вафат булып китүе артык гаҗәп тә тоелмады миңа. Минем исне китәргәне бөтенләй башка кеше иде, хатын-кыз иптәшләр!..

Нургазиз абыегыз исән чагында эштән соңга калып кайткалаштыргалаганымны һәм андый чакларда я уен-көлкегә алган булып, яки юлда машинабызның көе китте дә шуның белән булашып соңгарылды, дип алдашканымны әйткән идем бугай инде мин сезгә, шулаймы?.. Ярый, әйткән булсам — бик шәп. Хәзер сезгә бер сорау, алайса: нигә алай соңга калгалаштыргалаган дип уйлыйсыз инде сез мине?.. Я, нигә?.. Әһә, һәрхәлдә, дәүләт эше артыннан гына йөрмәгәнсең инде, андыйга охшамагансың, дисезме? Дөрес чамалыйсыз бит сез — җеннең җырак әбиләре! Әйе, дәүләт эше белән йөрмәдем мин андый вакытларда. Монысы — бик дөрес! Ләкин, шул ук

вакытта, үзем теләп, үз теләгем белән генә йөрү дә түгел иде ул. Хикмәте бар иде аның.

Ә ул хикмәт әлеге шул ир-атның — җир йөзендәге иң яман затның алдакчы һәм куркаклыгына, мәкерле һәм хәйләле булуына барып тоташа. Конкрет кына әйткәндә, ул нәрсә менә болай булды: Нургазиз абыегыз заводына урнашып, экспедитор булып, безнеңчә әйтсәк, машинага төяп, заводка алып кайтыла һәм заводтан озатыла торган товарларга җаваплы кеше булып эшли башлагач, шул завод шоферларының, бөтенесенеке үк булмаса да, байтагының күзе кыза башлады бит миңа. Товар илтергә яки товар алып кайтырга дип, янәрына утырып юлга чыктыммы, хәзер, авыз суларын корытып, минем алда сандугач булып сайрарга тотына бит болар. Билгеле, мин аларның ул сүзләренә ереп китмим. Башта шаярып-көлеп барган булам да, тегеләр тирәнгәрәк керә башлау белән:

— Кара аны, егеткәем, Нургазиз абыеңа бу кыланышларыңны җиткерсәм, эшең бик хөрти булачак лабаса синең! — дип, хәзер айнытып җибәрә торган идем мин аларны. Нургазиз абыегыздан бик шүрли торганнар иде — начальниклары иде бит!..

Әнә шул йөзләгән шоферлар арасыннан бер теленә тилчә чыккырысы тәки үзенекен итте бит, имансыз! Телгә генә түгел, төскә-биткә дә бик хәтәр чибәр нәрсә иде шул анысы, каһәр. Минем өше әле кырыкка җитеп кенә барган, ә үзе алтмышка җитеп килгән ир белән торучы җанлы хатын-кыз гына түгел, җансыз агач та каршы килмәс иде аңа. Аның белән бер машинага утырып, берәр җиргә барырга мөмкинлек булмыйча атна-ун көн үтсә, хәзер йомылып кына яныма килер иде дә, күзләрен майландырып:

> — Люзиякәй, Люзия апай!
> Тилмерәм бит күрергә!
> Нургазизеңне почта ит
> Арабызда йөрергә! —

дип, күңелемне алгысытып китәр иде. Шулай итеп тәки мине Нургазиз абыегыздан үземне алдагы көндә аның белән бергә җибәрүен үтенергә мәҗбүр итәр иде.

Ә инде очрашканнан соң озатып калган чакларында исә, елардай булып:

— Әй, бәгырь кисәгем! Шушы тикле чибәрлегең белән, яшь гомерләреңне әрәм итеп, шул карт алаша белән торасың бит! — дип кызганып калган була торган иде.

— Ичмаса, тизрәк үлеп тә китми шул карт алашаң. Ул ычкынса, ике дә уйлап тормыйча, семьямны ташлар идем дә, типтереп, синең белән бергә яши башлар идек! — дигән чаклары да күп булды аның...

Инде менә Нургазиз абыегыз үлеп киткәнгә дә ике ел тулып килә. Ләкин әлеге хөрәсәннең (исемен дә атыйсым килми шуның!) семьясын ташларга җыенганы юк кына түгел, хәтта узган елдан бирле бөтенләй якын ук килми башлады. Әле өченче көн генә аның белән бергә товарга барырга туры килеп, шунда:

— Нишләдең син, абзыкаем, нигә бер дә эзең-юлың күренми минем тирәләрдә? — дип сораган идем, башта күзен кысып, хәйләкәр итеп елмаеп куйды. Аннары:

— Ярамый, җан кисәгем, Люзия! Тол хатыннарны кимсетергә китап кушмый! — дип кенә җавап бирде дә, берни дә булмагандай итеп, үзалдына сызгырынып бара башлады...

Менә шулай, хатын-кыз иптәшләр: ир-ат кавеменнән дә юләр, ир-ат кавеменнән дә көнче, ир-ат кавеменнән дә алдакчы һәм вәгъдәсез җан ияләре юк, минемчә, бу җир йөзендә. Юк!

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИҖАТ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ҖЫЕЛЫШЫ

Январь азакларында Казан шәһәренең Актерлар йортында иҗат оешмаларының берләштерелгән партия җыелышы булды.

Җыелышны Татарстан язучылар союзы партия оешмасы секретаре язучы Габдрахман Минский ачты.

КПСС Үзәк Комитетының 1971 елгы ноябрь Пленумы йомгаклары һәм иҗат оешмалары алдында торган бурычлар турында доклад белән КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф Вәлиев чыкты.

Докладтан соң фикер алышуларда М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры директоры М. Ф. Боголюбов, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры баш режиссеры М. Х. Сәлимҗанов, композитор Җәүдәт Фәйзи, язучы Габдрахман Минский, В. Качалов исемендәге рус драма театры режиссеры Н. Ю. Орлов, художник Е. И. Киселева, Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе директоры урынбасары М. А. Тажетдиновлар чыгыш ясадылар.

Иҗат работникларының берләштерелгән партия җыелышы тикшерелгән мәсьәлә буенча резолюция кабул итте.

## ХӨСӘЕН ЯМАШЕВ ИСТӘЛЕГЕ

Республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле революционер, большевик Хөсәен Ямашевның тууына 90 ел тулган көнне зур күтәренкелек белән билгеләп үтте.

Мәктәпләрдә, эшчеләр арасында, музейларда ялкынлы революционерның туган көнендә кичәләр үткәрелде.

Казан шәһәренең комсомол-яшьләре, революция ветераннары аның кабере янына митингка җыелдылар. Яшьләр Хөсәен Ямашев каберенә тере чәчәк бәйләмнәре куйдылар.

19 январь көнне Казан шәһәренең күп санлы хезмәт ияләре Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрына тантаналы җыелышка килделәр.

Тантаналы җыелышны КПССның Казан шәһәр комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин ачты.

Күренекле революционер, большевик, интернационалист, публицист Хөсәен Ямашев турында доклад белән КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыкты.

Тантаналы җыелышта КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. А. Табеев, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов һәм башка җитәкче работниклар катнашты.

Җыелыштан соң сәнгать осталары концерт бирде.

* * *

Күренекле революционер Х. Ямашевның тууына 90 ел тулган көннәрдә РСФСР Министрлар Советы карары белән Татарстан мех производствосы берләшмәсенә Хөсәен Ямашев исеме бирелде.

* * *

Казан шәһәр Советы башкарма комитеты Казан шәһәренең Ленин һәм Совет районнарын тоташтырачак яңа проспектка Хөсәен Ямашев исемен бирү турында карар кабул итте.

* * *

Татарстан журналистлары союзы правлениесе журналистика буенча Хөсәен Ямашев исемендәге еллык премияләр билгеләде. Бу премияләр газеталардагы, журналлардагы, радио һәм телевидение тапшыруларында бирелгән, идея һәм әдәби яктан иң яхшы эшләнгән, замандашыбызның героик образын, аның Ватаныбыз файдасына фидакарь хезмәтен ачык һәм аңлаешлы чагылдырган, производство, фән, культура, әхлак темалары буенча актуаль проблемаларны тирәнтен һәм дәлилләп яктырткан әсәрләргә, брошюраларга, китапларга, очерк җыентыкларына республиканың Журналистлар союзы правлениесе тарафыннан бирелә.

Һәркайсы 250 шәр сумлык ике премия билгеләнде, алар лауреатларга Почетлы диплом белән бергә тапшырыла.

Хөсәен Ямашев исемендәге премияләр бирелү турындагы карар һәр елның Матбугат көнендә игълан ителә.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында Татарстан язучылар союзы правлениесе председателе, СССР язучылар союзы правлениесе секретаре шагыйрь Зәки Нурига 50 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсе булды.

Кичәне кереш сүз белән шагыйрь Әхмәт Исхак ачты. Юбилярның тормыш юлы һәм иҗаты турында докладны филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт ясады.

Кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова, РСФСР язучылар союзы правлениесе секретаре, М. Горький исемендәге РСФСР дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрә Людмила Татьяничева, башкорт шагыйре Муса Гали, белорус шагыйре Я. Колесник һ. б. юбилярны кайнар котладылар, истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе, Казан театрлары артистлары зур концерт бирделәр.

* * *

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре, актив җәмәгать эшчәнлеге өчен һәм 50 яшь тулу уңае белән, Татарстан язучылар союзы председателе, шагыйрь Зәки Нури КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

26 январьда «СССР халыклары әдәбияты һәм тәнкыйтьнең торышы» дигән мәсьәлә буенча СССР язучылар союзының пленумы булды. Анда Татарстан язучылар союзы председателе Зәки Нури, язучы Мирсәй Әмир һәм тәнкыйтьчеләрдән Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин бардылар. Рафаэль Мостафин фикер алышуларда катнашты.

## ЯҢА КИТАПЛАР

1972 елның беренче яртысында Мәскәүнең «Наука» нәшриятында Рәмзия Мөхәммәдованың «Татары-мишари» исемле китабы басылып чыкты. Бу — татар халкының мишәр этник группасын өйрәнүгә багышланган беренче хезмәт. Анда Мордовия, Чувашстан, Татарстанның Буа, Чүпрәле районнарында һәм Рязань, Пенза, Саратов, Ульяновск, Горький өлкәләрендә яшәүче мишәрләрнең этнографиясе (көнкүреше, кием-салымнары, гореф-гадәтләре һ. б.) яктыртыла. Бу тарихи хезмәттә татар мишәрләренең бай тарихы, Казан татарлары белән булган культура уртаклыгы һәм этногенезы мәсьәләләренә зур урын бирелә.

Рус телендә басылган бу китап, анлаешлы, гади тел белән язылып, киң катлау укучылар өчен дә кызыклы булачак. Китапта беренче тапкыр басылган бик күп яңа этнографик иллюстрацияләр бирелгән. Күләме 15 табак.

* * *

Мәскәүнең «Советская Россия» нәшрияты СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән «Россия халыклары, туган халыклар семьясында» дигән сериядә китаплар чыгара башлады. Бу сериянең беренче карлыгачы — «Без Казаннан, Иделдән» дигән китап. Китапның авторлары Гариф Ахунов белән Марсель Зарипов Татарстанның үткәне һәм бүгенге көне, гүзәл табигате һәм яңа туган яшь калалары, фән, халык хуҗалыгы һәм культура өлкәсендәге зур казанышлары турында җылы лирик тонда сөйлиләр. А. Шакиржановның профессиональ осталык белән төшерелгән бик күп фотолары һәм Татарстанның күренекле художниклары И. Әхмәдиев белән Л. Насыйровлар эшләгән рәсемнәр китапны бизәп, баетып торалар. Күләме 15 табак.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында драматург Хәй Вахитның «Кияүләр» исемле музыкаль комедиясе куелды. Комедиягә музыканы Сара Садыйкова һәм Рәшит Гобәйдуллин яздылар.

Комедияне сәхнәгә РСФСРның атказанган, Башкортстанның халык артисты, күренекле башкорт режиссеры Вәли Гәлимов куйды. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Хәсби Фазлуллин дирижерлык итте. Рольләрне РСФСРның халык артистлары Фәхри Насретдинов, Мөнирә Булатова, Азат Аббасов, Венера Шәрипова, ТАССРның халык артисткасы Гөлшат Сәйфуллина, ТАССРның атказанган артистлары Йосыф Гыйззәтуллин, Фагыйлә Тимирова һ. б. башкардылар.

* * *

Минзәлә дәүләт театры шушы елның гыйнварында драматург Риза Ишморатның «Хикмәтле Сәйфи» исемле комедиясен сәхнәгә куйды. Театрның баш режиссеры Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мулланур Мостафин сәхнәләштергән бу спектакльдә Сәйфи ролен Әхмәдиша Җиһаншин, Хәерниса ролен Фәез Бәдриев, Мәрмәрия ролен Әлфия Мусина, Искәндәр ролен Рамил Газизов, Тәнзилә ролен Рәүҗидә Юзикаева, Эмша ролен Нуретдин Нәҗмиев, Җен ролен Расил Әхмеровлар башкардылар. Спектакльнең музыкасын Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Әнвәр Бакиров язды. Сәхнә оформлениесен художник Әлфир Яһудин эшләде.

Кайбер кешеләрдә әлегә кадәр яшәп килә торган искелек калдыкларын һәм шуңа каршы көрәшне кызыклы алым белән чагылдырган, шуның белән бергә заманыбыз таләпләрен яхшы тоеп иҗат ителгән бу спектакльне тамашачылар яратып кабул итте.

* * *

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасын тагын сәхнәгә чыгарды.

Халкыбызның яраткан бу әсәрен сәхнәгә танылган артист һәм режиссер Хәким Сәлимҗанов куйды. Галиябану ролен Мәсгудә Хәйруллина, Хәлил ролен Р. Әбделмәмәтев һәм Исмәгыйль ролен И. Йомагулов башкардылар.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ҺӘМ ЧИТ ИЛ МАТБУГАТЫ

АПН (матбугат яңалыклары агентлыгы) дөньяның унике телендә «Страна Советов» дигән журнал чыгара.

Журналның 1971 ел ноябрь аенда һинди, бенгаль, инглиз телләрендә басылган 21 саны тулысы белән Татарстан тормышына багышланган. 500 мең экземпляр белән басылган бу сан Сибгат Хәкимнең «Барсы да кешеләрнең йөзендә» дигән мәкаләсе белән ачыла. Шагыйрь бу мәкаләсендә, үз тормышыннан чыгып, республикабызның культурасы, халкыбызның традицияләре турында уйлануларын яза.

Журналда Татарстан хөкүмәте җитәкчеләренең чыгышлары, республикабызның тарихына караган материаллар, аның авыл хуҗалыгы, промышленносте, фән үсеше турында тирән эчтәлекле мәкаләләре басылган. Муса Җәлил шигырьләре, татар фольклоры материаллары бирелгән. Казан елга портыннан, Түбән Кама төзелешләреннән фотолар да журналлар эчтәлеген бик баета.

* * *

Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, 1971 елның көзендә Германия Демократик Республикасында булып, андагы язучылар һәм журналистлар белән очрашып кайткан иде. Бу очрашулар тәэсирендә немец язучысы Ганна-Гейде-Краце Берлинда басылган «Новое время» (Neue Zeit) газетасында «Кешене бәхетле итү» дигән мәкалә язып бастырды. Ганна-Гейде-Краце Рафаэль Мостафин белән Берлин һәм Казан турында, Татарстан республикасы һәм татар халкы турында сөйләшеп утыруларын яза. Аның мәкаләсендә мондый юллар бар:

«...Менә ул бүлмәгә килеп керде һәм без үзебезне күптәнге танышлар кебек хис итә башладык. «Дөньяны танып белүебез бер үк булганга, әр ике ил турында күп белгәнгә һәм бер максат белән кешене бәхетле итү өчен яшәгәнгә шулай ул», — диде Рафаэль Мостафин».

«...Безнең Габдулла Тукай дигән бөек шагыйребез бар. Ул бик иртә, 27 яшьтә үк үлә. Ул авыру була, фәкыйрьлектә үлә. Мин аның шигырьләрен яратып укыйм, кайберләрен яттан беләм. Мин белгәннәре — шагыйрьнең искиткеч күп шигырьләреннән, татар халкының революциягә хәтле булган тормышы турындагы шигырьләренең бер өлеше генә».

Рафаэль Мостафин Ганне-Гейде-Крацега Габдулла Тукайның шигырьләр томын бүләк итеп калдыра.

## ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯ

1971 елда СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының этнографлары татар халкының этнографик атласын төзү өчен материал туплауга керештеләр. Зур фәнни хезмәт булган бу атласка төрле этник группаларда барланган фактларның территориаль таралышы, гомумән, халыкның материаль һәм рухи культурасы тулысы белән чагылдырылачак. Бу хезмәт фактларның җитмәве аркасында хәзергә кадәр тоткарланып торган кайбер мөһим тарихи проблемаларга, шул җөмләдән, татар халкының этногенезы мәсьәләсенә дә, ачыклык кертәчәк. Этнографик атлас практик яктан да файдалы кулланма булырга тиеш.

Атласка материал җыю буенча оештырылган беренче экспедиция узган елның июнь аенда үткәрелде. Этнографлар Мамадыш районының Уразбахты, Колочча, Кече Кирмән, Иске Комазан, Ишки, Шәдче, Дүсмәт, Кукмара районының Әсәнбаш, Оштарма-йомья, Ядгәр, Мәмәшир, Сәрдекбаш, Уразай, Төркәш һәм Киров өлкәсе Вятские Поляны районының Урта һәм Түбән Шөн авылларында булдылар. Бер группа этнографлар Пенза өлкәсенең Каменка районындагы Кикин дигән татар авылына бардылар.

Нәтиҗәдә институтның этнография фонды фәнни яктан кыйммәтле күп төрле материаллар (язмалар, рәсем-фотолар, төрле экспонатлар һ. б.) белән тулыландырылды. Район, колхоз җитәкчеләре, мәктәп директорлары, укытучылар һәм колхозчылар этнографларның максатын дөрес аңлап, эшләрендә ярдәм иттеләр. Экспедициянең җитәкчесе тарих фәннәре кандидаты Рәмзия Мөхәммәдова иде, анда тарих фәннәре кандидаты Рәүфә Уразманова, кече фәнни сотрудник Полдыз Мөхәммәтшин, лаборант Тирсинә Сафина, КДУ студентлары Равил Вергазов, Дамир Исхаков, фотограф Рифгать Якупов, сәнгать училищесы студенты Шамил Биктюшев һ. б. катнашты.

Пенза өлкәсендә үткәрелгән экспедициядә Р. Уразманова, П. Мөхәммәтшин, Т. Сафина, художник А. Мазанов эшләде.

1972 елда экспедиция Саба, Балык бистәсе, Лаеш, Балтач районнарына чыгачак.

## ДУСЛЫК КИЧӘСЕ

СССР төзелүнең 50 еллыгына багышлап, башкалабыз Мәскәүгә илебезнең күп өлкәләреннән сәнгать осталары иҗади отчет белән килләр.

Татарстан республикасының сәнгать осталары үзләренең концертларын 11 гыйнварда СССР Культура Министрлыгының дәүләт концерт залында башлап җибәрделәр. Халыклар дуслыгына багышланган бу концертта М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры солистлары, Татарстан АССРның дәүләт җыр һәм бию ансамбле һәм башка иҗат коллективлары катнашты.

Татар халкының яраткан җырчылары В. Шәрипова, Ф. Насретдинов, И. Шакиров, Э. Җәләлетдинов, Г. Ильясов, Ә. Заһидуллиналарның чыгышларын башкала тамашачылары алкышлап каршыладылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Татар совет драматургиясендә унышлы эшләп килгән драматург Юныс Әминевка, 50 яшь тулу уңае белән, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, 50 яшь тулу уңае белән, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының баш художнигы Әнвәр Нагаев Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

## УРТА ДИҢГЕЗ БУЕНДА

Советлар иленең бер төркем художниклары, СССР Художество Академиясе командировкасы белән, Италиядә булып кайттылар. Баручылар арасында Татарстан художниклар союзы председателе Харис Якупов, Ленинград художнигы Ю. М. Непринцев, Молдавиядән И. Богдеско, Мәскәүдән З. М. Велинский һ. б. бар иде. Алар 32 көн буена Рим, Неаполь, Флоренция, Венеция һәм башка шәһәрләрдә булып, Италиянең сәнгать музейлары, архитектура истәлекләре, халкының тормышы белән танышып йөрделәр. Иҗади эш алып бардылар.

## СТУДЕНТЛАР — КамАЗга

Ленинград Культура институтының Казан филиалы студентлары кышкы каникулларда КамАЗ төзүчеләр белән очраштылар. Укытучылар һәм студентлардан торган 50 кешелек зур төркем Чаллыга килеп, төзүчеләргә концертлар бирде, культура-агарту эшендә эшләүчеләргә практик ярдәм күрсәтте һәм үзләре тулы бер смена эшләп, КамАЗ салучыларга булышты.

## ЧАЛЛЫДА ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

ТАССРның атказанган артисты Әзәл Яһудин, Кама автомобиль заводын төзүчеләр янында булып, кызыл почмакларда, төзелеш мәйданнарында, мәктәпләрдә татар шагыйрьләренең яңа шигырьләрен укып йөрде. Бу кичәләр туып килгән яшь каланың 19 урынында булды, зур күтәренкелек белән үтте.

## КЫСКА ХИКӘЯЛӘР КИЧӘСЕ

Казан шәһәренең промышленность предприятиеләрендә, Суворов училищесында тәрбияләнүчеләр янында, «Казан» санаторийында ял итүчеләр, медицина эшчеләре коллективларында «Кыска хикәяләр кичәсе» үткәрелде. Бу кичәләрдә Тукай премиясе лауреаты Айрат Арсланов Габдрахман Минский, Вахит Монасыйпов һ. б. хикәячеләрнең әсәрләрен укыды.

## ДЕКАДА ЙОМГАКЛАРЫ

СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышлап, Казанда республикабыздагы халык театры коллективларының смотры үткәрелгән иде. Шушы көннәрдә жюри декада нәтиҗәләрен игълан итте.

Әтнә, Азнакай, Биектау халык театрлары беренче дәрәҗә, Чаллы халык театры икенче дәрәҗә, Чистай һәм Алабуга халык театрлары өченче дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнделәр.

РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисткасы Рәшидә Җиһаншина җитәкчелегендә эшләгән жюри бу коллективларның уйнау осталыклары узган елларга караганда шактый үскән булуларын билгеләп үтте.

Шуның белән бергә кайбер коллективларның репертуар сайлауда талымсызлыклары, әсәрнең жанрын дөрес билгеләмәүләре, образларны тирән ача белмәүләре дә тәнкыйтьләнде.

## ТАТАР ҖЫРЛАРЫ УКРАИНАДА

Татарстанның җыр һәм бию ансамбле Украина шәһәрләрендә гастрольдә булып кайтты. Артистлар үзләренең чыгышларын Мәскәүдә башлап, Украинаның Житомир, Ровно, Луцк, Львов, Ужгород, Ивано-Франковск, Тернополь, Хмельницк шәһәрләрендә уздырдылар. Соңыннан Горькийга кайтып, гастрольне тәмамладылар. Татар халкының моңлы һәм шаян җырларын, дәртле биюләрен украин тамашачылары яратып, зур канәгатьләнү белән карадылар.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР КЛУБЫ

Кышның иң салкын көннәре булуга да карамастан, «Казан утлары» редакциясенә бик күп язучылар, артистлар, журналистлар җыелган иде.

Ул көнне редакция каршында эшләп килгән «Кызыклы очрашулар клубы»ның тагын бер утырышы булып, тарих фәннәре кандидаты Равил Фәхретдинов белән очрашу үткәрелде. Бу кичәдә яшь галим Татарстанның археологик картасын төзү буенча эшләнгән эшләр турында сөйләде, татар халкының үткәне турында бирелгән бик күп сорауларга җаваплар кайтарды.

# ГАЗИЗ МӨХӘММӘТШИН



Шәфкатьсез үлем каләмдәш дустыбызны арабыздан тартып алды — кинәт авырып язучы Газиз Мөхәммәтшин 39 яшендә вафат булды.

Хезмәт сөючән, тырыш һәм тыйнак иптәшебезнең башкарган иҗади хезмәтләре безнең күз алдында булды. Казан педагогия институтын тәмамлагач, ул Төмән өлкәсендә балалар укытты, кайткач «Чаян» журналы, «Татарстан яшьләре» газетасында эшләде, «Ялкын», «Казан утлары» журналында җаваплы редактор булды.

Газиз Мөхәммәтшин соңгы елларда «Казан утлары» журналының редколлегия члены иде. Үзе дә күп кенә хикәяләр, повестьлар, «Йөрәктәге эзләр» романын язып бастырды. «Тынгысыз төн» комедиясе сәхнәдә уйналды. Балалар өчен байтак әсәрләр иҗат итте. Газиз Мөхәммәтшин каләмдәш дусларының иҗатына да гадел һәм таләпчән булды һәм журнал эшенә күп ярдәм итте.

Гомере вакытсыз өзелгән дустыбыз һәм каләмдәшебезнең якты истәлеге язучыларыбыз, журнал сотрудниклары һәм күп санлы журнал укучылары күңелендә мәңгегә саклаunion.

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ,
«КАЗАН УТЛАРЫ» РЕДАКЦИЯСЕ.

## Юксынырбыз, сагынырбыз сине...

Сиңа хат бар, Газиз дустым, Язучылар союзы идарәсенең зур көзгесе янында. Үзең дә беләидең бит, әдәбият сөючеләр укылган әсәрләре хакында авторлар белән сөйләшә-киңәшәләр, бәхәсләшәләр. Тагын шундый хатларның берсе килгән. Аны бары тик син генә ачарга тиеш идең...

Шул хат килгән хәбәрне әйтергә теләп, якын-тирәдә син юкмы дип, эзли китсәм... бетенләй әллә нинди хәбәр... Фикерне чуалтты да ташлады. Юк, теләсә нәрсә белән килешергә мөмкин, ләкин моның белән... Әле кырык яше дә тулып җитмәгән кешене үлде дип ничек тел барып әйтмәк кирәк! Гомумән, без бу үлем белән беркайчан да килешә алмабыз.

Син бик уенчак, шаян кеше идең. Дөньяда гел уйнап-көлеп кенә яшәгән кебек. Кайчакларда хәтта: «Ул кайчан уйлый һәм эшли икән!» кебегрәк сәер сорау да туа торган иде. Ләкин сыйфат ягыннан бүтәннәрнекеннән һич ким булмаган, берсеннән-берсе матур хикәяләреңне күргәч, шатлана идек. Шулай шаярып кына дигәндәй, синең зурлар һәм балалар өчен байтак повестьларың, республикабыз сәхнәләрендә озак һәм зур уңыш белән барган комедия әсәрең, хәтта романың барлыкка килде. Соңгы көннәрдә балалар өчен яңа повесть тәгәлли идең. Бөтенесен бергә җыйгач, әйбәт кенә ике-өч том. Әйе, халыкның саф һәм күтәренке рухи дөньясын зурлый торган күп әсәрләр иҗат иттең син. Әмма, хезмәтләрең ничек кенә икърар итсәк тә, талантының алгы көннәрдә әле чагыштыргысыз күп уңышлар китерәчәгенә ышанып яши идек. Шуңа күрә үлемеңә һич тә ышанасы килми. Нишләрләр икән дип, безне юри сынап каравың, шаяруың гынадыр сымак.

Ах, шулай булса икән дә, арабызга яңадан кайтып килә алсаң икән: без, дусларың, ничек шатланыр идек. Кайтсаң икән дә язылып бетмәгән әсәрләрең янына килсәң икән. Яңаларын язсаң икән. Эштән бушаган араларыңда Идел буена килеп, көймәдә йөрергә чакырсаң икән. «Синең белән болай йөреп кайту үзе бер гомер бит ул» дигән сүзләреңне һич оныта алмыйм. Әдәбиятыбыз кебек, безнең шәхси тормышыбыз да синсез бик күпкә фәкыйрьләнде.

Көзге янындагы хат ачылмыйча, мәңгелек сер булып, сине көтеп калды. Ә син инде әйләнеп килмәссең бу йортка.

Әсәрләрең халыкта, исемең безнең күңелләрдә яшәр.

Бер дә туктамый сагынырбыз, юксынырбыз сине.

ӘХСӘН БАЯНОВ.

## ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 6 нчы САНЫНДА

Үзбәк язучысы Нәзир Сәфәревнең *«Каргышлы һәм өметле көн»* повесте бирелә. Әсәрдә үзбәк халкының революциягә кадәрге тормышы, азатлык өчен көрәше, төрле милләтләр арасындагы дуслык сурәтләнә. Бу санда Шамил Бикчуринның *«Каты токым»* романының дәвамы, Фатих Хөснинең *«Циклон»* һәм Гамил Афзалның *«Карабаш күлендә»* исемле хикәяләре басыла.

Шигырь сөючеләр Нури Арсланов, Зиннур Насыйбуллин, Фаил Шәфигуллин һәм Разил Вәлиевләрнең шигырьләрен укырлар.

Зәки Әхмәтҗановның *«Герой каберендә чәчәкләр»*, Малик Хәмитовның *«Бәхетле язмыш»*, Ләбибә Ихсанованың *«Замандашым турында»*, Мәгъсүм Насыйбуллинның *«Прокурор»* дигән очерклары Ватанны саклап һәлак булган батыр солдат, профессор Габделхак Галиуллин, артистка Гәүһәр Камалова һәм Әлмәт прокуроры Тәлгат Шәмсетдинов турында сөйли.

Равил Фәйзуллинның бер еллык шигъри хәзинәбезгә ясаган күзәтүе, Игорь Алексеевның Татарстанда кино сәнгатенә багышланган мәкаләсе дә укучыларыбызның игътибарын җәлеп итәчәк.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210